# Казан утлары

12
ДЕКАБРЬ
1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ЖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

12
ДЕКАБРЬ
1968

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

А. В. ЛУНАЧАРСКИЙ. Ленин һәм сәнгать . . . . 3
Н. И. АЛЬТМАН. Ленинның беренче скульптурасы. 5
АЛЬБЕРТ РИС ВИЛЬЯМС. Ленинның шәхси тормышында тимердәй дисциплина. Ленин кешеләр белән ничек аралашты . . . . . . . . . 7

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Н. АРСЛАНОВ. Тел тибрәтеп бер сүз әйтмим; Гамьсезлектән җырлый, диләр мине; Дүрт киңәш; Рус балалайкасы; Синең тавышың; Парчалар; Ике тәрҗемә. Шигырьләр . . . . . 10
Ә. ЕНИКИ. Вөҗдан. Повесть. . . . . . . . . 15

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Т. СӘГЫЙТОВ. Өлкән дуслар ярдәме. Очерк. . . 85
С. РАДЗИЕВСКАЯ. СУ хуҗасы. Очерк. . . . . 95

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

А. ЯХИН. Революция солдаты. . . . . . . . 104
И. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Шамил Усманов — комиссар. 106

ШӘҺИТ ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

С. САБИРОВ. Кайнар йөрәкле көрәшче. . . . . 113

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Г. ТАҺИРҖАНОВ. Фирдәүси һәм Колгали. . . . 120

БАТЫРЛАР КИТАБЫНА

З. ӘХМӘТҖАНОВ. Мәңге сүнмәс чәчәкләр. Очерк. . . . . . . . . . . . . . . 128

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ХАРИСОВ. Шинельсез солдатлар. . . . . . 140
Л. ИХСАНОВА. Кыскалыкта осталык. . . . . . 142

## ХӘЙ ВАХИТКА 50 ЯШЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Сәхнәгә гашыйк. . . . . . 143

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

М. КРЫЙМОВ. . . . . . . . . . . . . . . 145

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

И. РУШАН. Үлмәүнең зарары, өйләнмәүнең файдасы турында; Хәлли Мәймүновичның колоритлар һәм калорияләр турындагы «фәлсәфә»ләре; Элекке «Ялт-Йолт» журналындагы «Шүрәле» традициясе җырлары; Түбән Кама; Инде дә. Шигырьләр. . . . . . . . . . 147
Н. ДӘҮЛИ. Мыштым; Таш кыз янында; Тост. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 150
«Казан утлары» журналы битләрендә 1968 елда басылган әсәрләр исемлеге. . . . . . . . 153

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редакторы **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 15/X-1968 ел. Басарга кул куелды 20/XI-1968 ел. ПФ 09073. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 64546 экз. Заказ Д-1673. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.




## *ЛЕНИН—БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

**А. В. Луначарский**

# ЛЕНИН ҺӘМ СӘНГАТЬ

Бөтен гомере буена вакыты бик аз булу сәбәпле, Ленин сәнгать белән чынлап торып шөгыльләнә алмады; ә инде өстән-өстән генә сүз йөртү аның өчен чит нәрсә булганга, ул сәнгать хакында фикерләр әйтергә яратмады. Хәлбуки аның зәвыгы әйбәт иде. Ул рус классикларын, әдәбиятта һәм рәсем сәнгатендә реализмны ярата иде.

1905 елда, беренче революция вакытында ук, аңа ничектер Д. И. Лещенко квартирасында кунарга туры килә. Анда дөньядагы иң зур художникларның тулы бер коллекциясе була. Икенче көнне иртә белән Владимир Ильич миңа: «Сәнгать тарихы — бик мавыктыргыч өлкә ул. Анда марксист өчен эш бик күп. Кичә, китаплар карап, иртәнгә чаклы йоклый алмадым. Сәнгать белән шөгыльләнергә элек тә вакытым булмавы һәм киләчәктә дә булмаячагы бик эчемне пошырды». Ильичның бу сүзләре хәтеремә нык кереп калды.

Революциядән соң төрле сәнгать-әдәбият жюрилары мәсьәләсе буенча миңа аның белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Мәсәлән, бервакыт, ул мине чакырып алды да, без аның белән һәм Каменев белән бергәләп, Христос-спаситель чиркәве янындагы зиннәтле постаменттан аударылган Александр III сыны урынына куелырга тиешле һәйкәлләр проекты күргәзмәсенә киттек. Ленин бу һәйкәлләрнең һәммәсен тәнкыйть күзе белән карады. Аларның берсе дә ошамады аңа. Футуристик планда эшләнгән һәйкәл каршында аеруча гаҗәпсенеп карап торды ул, ләкин аның фикерен сорагач: «Мин монда берни дә аңламыйм, Луначарскийдан сорагыз», диде. Мин дә монда бер лаеклы һәйкәл дә күрмим, дигәч ул куанып: «Мин сезне берәр футуристик карачкыны постаментка куярсыз дип уйлаган идем»,— диде.

Икенче юлы сүз Карл Маркс һәйкәле хакында барды. Мәгълүм скульптор М. үз дигәнен булдырырга аеруча тырышты. Ул һәйкәлнең зур проектын эшләде: «Карл Маркс дүрт фил өстенә басып тора». Мондый һич тә көтелмәгән мотив безнең бөтенебезгә дә, шулай ук Владимир Ильичка да, бик сәер күренде. Художник үз һәйкәлен төзәтергә керешеп ике-өч мәртәбә үзгәртте, ничек тә конкурста җиңеп чыгасы килде аның. Мин жюриның председателе идем. Аның проектын кире кагып, Алешин җитәкчелегендәге бер төркем художникның күмәк проектын кабул иткәч, скульптор М. жалоба белән Владимир Ильичка барган. Владимир Ильич аның жалобасын игътибар белән тыңлаган.

Мина махсус шалтыратып, яна җюри җыярга кирәклеген әйтте, Алешин проектын һәм скульптор М. проектын карарга киләм, диде. Алешин проектыннан канәгать булды, скульптор М. проектын кире какты.

Шул ук елны[1], 1 Май бәйрәменә, Алешин группасы Маркска һәйкәл куелырга билгеләнгән урынга һәйкәлнең кечерәк моделен ясап куйды. Владимир Ильич махсус рәвештә барып карады. Һәйкәлне берничә кат әйләнеп чыкты да нинди зурлыкта булачагын сорады һәм, ниһаять, аны яхшы дип тапты. Шулай да ул: «Анатолий Васильевич, художникка әйбәтләп әйтегез, чөнки охшатыбрак эшләсен, Карл Маркс һәйкәленә караган чакта аның әйбәт портретларын күргәндәге кебек тәэсир калырга тиеш, хәзергә охшашлык азрак төсле»,— диде.

1918 елда ук әле Владимир Ильич мине чакырып китереп, сәнгатьне агитация чарасы буларак үстерергә кирәк, диде. Шул чакта ул ике проект тәкъдим итте: беренчедән, йорт стеналарын, коймаларны һәм афиша ябыштырыла торган урыннарны зур революцион язмалар белән бизәргә кирәк, диде; шундук кайбер лозунглар да әйтте.

Икенче проект бөек революционерларга бик күп һәйкәлләр — Петербургта да, Мәскәүдә дә гипстан эшләнгән вакытлы һәйкәлләр кую турында иде. Владимир Ильичның бу идеясен ике шәһәр дә бик хуплап каршы алды. Һәр һәйкәлне шул революционер хакындагы речь белән тантаналы төстә ачарга һәм һәйкәл астына аңлатма язарга уйланды. Владимир Ильич моны «монументаль пропаганда» дип атады.

Петроградта бу «монументаль пропаганда» шактый уңышлы барды. Скульптор Шервудның Радищев һәйкәле шундый һәйкәлләрнең беренчесе булды. Мәскәүдә шуның күчермәсен куйдылар. Үкенечкә каршы, Петроградтагы һәйкәл җимерелде, кабат торгызылмады. Гомумән Петроградтагы яхшы һәйкәлләрнең күбесе материалының уалучан булуы аркасында җимерелеп бетте; мин әйбәт кенә һәйкәлләрне, мәсәлән, Гарибальди, Шевченко, Добролюбов, Герцен һәм бүтән бюстларны хәтерлим. Сул бөгелешләр йогынтысында эшләнгән һәйкәлләр начаррак иде; мәсәлән, Перовскаяның кубик стиль белән ясалган һәйкәле ачылгач, кайберәүләрнең бөтенләй котлары очты, ә З. Лилина катгый төстә һәйкәлне шундук алуны таләп итте. Шулай ук хәтеремдә, Чернышевский һәйкәле дә күпләргә артык купшы булып күренде. Иң әйбәте Лассаль һәйкәле булды[2]. Элекке шәһәр думасы янына куелган бу һәйкәл әле дә саклана[3]. Аны бронзадан койган булсалар кирәк. Карл Марс һәйкәле дә бик уңышлы ясалган иде. Марксны бөтен гәүдәсе белән сурәтләгән бу һәйкәлне скульптор Матвеев эшләгән иде. Үкенечкә каршы, ул җимерелгән, хәзер шул ук урында, ягъни Смольный тирәсендә, Матвеевның оригиналь пластик уй-фикерен саклаеча, Маркcның гадәти типта бронзадан ясалган баш сыны тора.

Мәскәүдә В. И. Ленин күргән һәйкәлләр әйбәт эшләнмәгәннәр иде.

Мәскәүдә канәгатьләнерлек итеп ясалган һәйкәлләр гомумән аз иде. Шагыйрь Никитин һәйкәле генә, ихтимал, бүтәннәренә караганда юньлерәк булгандыр. Владимир Ильич барлык һәйкәлләрне дә яхшылап карагандырмы-юкмы, әйтә алмыйм, һәрхәлдә, ул миңа: «монументаль пропагандадан» берни дә барып чыкмады, диде. Мин Петроград тәҗрибәсен һәм Зиновьев әйткәннәрне исенә төшердем. Владимир Ильич ышаныр-ышанмас башын селкеде дә: «Димәк, бөтен талантлар Петроградта, ә Мәскәүдә бөтен булдыксызлар җыелган булып чыгамыни?» — дип куйды. Мондый сәер күренешнең сәбәбен мин аңа аңлатып бирә алмадым.

Коненковның монументаль тактасына да Владимир Ильич беркадәр шикләнебрәк карады. Ул тактаның ышандыру көче җитәрлек түгел

[1] 1920 елны.
[2] Лассаль һәйкәлен художник Зелит эшләде.— А. Л.
[3] Истәлекләр 1924 елда язылган.

шикелле күренде аңа, сүз җае килгәндә шунысын да әйтик. Коненков үзе дә бу әсәрен тапкыр гына исем белән «мнимореаль такта», ягъни «реаль түгел такта» дип йөртә иде. Художник Альтман Владимир Ильичка Халтуринны сурәтләгән барельеф бүләк иткән иде. Владимир Ильичка барельеф бик ошады, шулай да миннән: бу барельеф футуристик әсәр түгелме? — дип сорады. Футуризмны ул гомумән яратмады. Аның Надежда Константиновна белән Вхутемас тулай торагында үткәргән әңгәмәсендә мин була алмадым. Вхутемасчылар барысы да «суллар» иде, соңыннан миңа бу сөйләшү хакында әйттеләр. Владимир Ильич алардан күбрәк уен-көлке әйтеп котылган, бераз мыскыллап та алган, әмма шундук: мондый нәрсәләр хакында җитди сөйләшүләрне өстемә алмыйм, чөнки үземне җитәрлек дәрәҗәдә хәзерлекле түгел дип исәплим, дигән. Яшьләр аңа бик ошаган, ул аларның коммунистик рухта булуларына шатланган.

Владимир Ильич гомеренең соңгы дәверендә сәнгать әсәрләренә күп вакыт бирә алмады. Ул берничә мәртәбә театрга барды, гел Художество театрында гына булды шикелле; бу театрга ул югары бәя бирә, куелган спектакльләр аңарда яхшы тәэсир калдыралар иде.

Владимир Ильич музыканы бик ярата иде. Бервакыт минем квартирада яхшы концертлар оештырыла иде. Кайчакта Шаляпин җырлый, Страдивариус квартеты, Мейчик, Романовский, Кусевицкий һәм башкалар уйный. Мин Владимир Ильичны күп мәртәбәләр чакырдым, ләкин ул һәрвакыт эш белән мәшгуль, бушый алмый иде. Бер мәртәбә ул миңа туп-туры: «Музыка тыңлавы бик күңелле, әлбәттә, әмма, ни өчендер, ул мине чыгырдан чыгара. Мин аны ничектер авыр кичерәм»,— диде. А. Д. Цюрупа Владимир Ильичны бер-ике мәртәбә өенә шул ук пианист Романовский концертына чакырып китерә алган. Владимир Ильич бик яратып тыңлады, әмма шактый дулкынланды булса кирәк, дип сөйләгәне хәтеремдә.

...Владимир Ильич үзенең эстетик унай һәм тискәре карашларыннан беркайчан да җитәкче идеяләр китереп чыгармады...

**Н. И. Альтман**

## ЛЕНИННЫҢ БЕРЕНЧЕ СКУЛЬПТУРАСЫ

Мин, 1920 елның язында Анатолий Васильевич Луначарский бюстын ясаганга күрә, Кремльдә аның янында еш була идем. Шул чакта миңа Владимир Ильич Ленинга илле яшь тулу көненә аның рәсемен ясарга тәкъдим иттеләр. Бу тәкъдимне мин бик теләп кабул иттем. Владимир Ильичның художниклар каршында утырудан баш тартканлыгын белә идем мин, шулай да аның рәсемен фотографиясеннән карап ясыйсым килмәде.

Мин Луначарскийның бу хакта Владимир Ильич белән сөйләшүен үтендем. Әмма үзем сөйләшүнең уңышлы чыгачагына бик үк ышанып бетмый идем. Ике-өч көннән Анатолий Васильевич миңа Ленинның риза икәнлеген хәбәр иткәч, шатлыгым эчемә сыймады. Луначарский Ленинның кыймылдамыйча бер урында утырырга вакыты юклыгын әйтте. Шуннан мин Ленинның рәсемен буяулар белән түгел, бәлки скульптура сурәте итеп ясарга булдым.

Мин Ленин кабинетына беренче мәртәбә кергән чакта анда берәү дә юк иде. Кабинетка мин станок, кирәкле инструментлар һәм балчык

кертеп куйдым. Владимир Ильичны көткән арада аның кабинеты белән танышырга керештем. Аның рәвеше хуҗасының нинди икәнлеге турында бик ачык сөйли иде. Кабинет гади генә итеп җиһазландырылган. Китап шкафлары, стенада география карталары. Диван шүрлегендә Петроград эшче һәм крестьян депутатлары Советы бүләк иткән Маркс рәсеме тора. Соңрак мин эшләгән С. Халтурин барельефын да шунда куйдылар, аны Ленинга Луначарский җибәргән булган. Бүлмә уртасында язу өстәле, өстәл өстенә телефон куелган. Кремль ишек алдына карый торган ике тәрәзә арасына көзге эленгән. Ленинның шушы көзгедә чагылуы рәсемен төшергәндә миңа аны төрле кыяфәтләрдә күрергә ярдәм итте.

Владимир Ильичны беренче мәртәбә күргәндә, башкалар шикелле үк, мин дә аның гадилегенә, тыйнаклыгына таң калдым. Бер эшченең Ленин турында: «Хакыйкать кебек үк гади ул» дип әйтүе тикмәгә генә түгел иде.

Ул чакта Владимир Ильич «Коммунизмда балаларча «суллык» авыруы» китабын иҗат итә иде. Ул аны бик тырышып, бөтен уй-фикерләрен туплап, баштанаяк бирелеп язды. Кайчакта ул теге яки бу фикерне урындыгының артына сөялеп уйлый торган иде.

Бүлмәдә тып-тын. Владимир Ильичка артык сораулар биреп мәшәкатьләмәскә тырыштым. Чөнки мин хәзерге вакытта Ленин башкарган эшнең гадәттән тыш әһәмиятле икәнен белә идем. Речьләрендәге шикелле үк, кулъязмасында да ул, Горький әйтмешли, һәр сүзне уч төбенә салгандай итеп, аның тәгәл мәгънәсен, эчтәлеген ачып бирә иде.

Икенче көнне ул, күзләрен кыса төшеп, минем тарафка карады да борын бик үк дөрес чыкмаган дип куйды. Бюст әле эшләнә генә башлаган, йөз сызыклары беленеп кенә килә иде. Бу хакта мин Владимир Ильичка аңлатып биргәч, ул бик гаҗәпсенеп:

— Ә Луначарский, һәр көнне яртышар сәгать эшләгәндә, бу эш нибары ике-өч көнгә барачак дип әйткән иде ич,— диде.

Берничә көннән соң ул Анатолий Васильевичның сүзләрен тагын хәтергә төшерде. Шуннан соң мин: рәсемне ике-өч сеанста ясармын дип Луначарскийга вәгъдә биргәнем юк, дидем. Ленин көлемсерәде дә:

— Алай булгач, Анатолий Васильевичның «сунарчылар» экияте булып чыга инде бу,— дип эчкерсез генә шаяртып куйды.

Ленинның скульптурасын ясау җиңел булмады. Владимир Ильич тик кенә утырмый, үз эше белән мәшгуль иде. Гадәттә ул өстәлгә иелеп үк утыра, мин аның баш түбәсен генә күрә идем. Ленинны төрле яктан күрү өчен, һәр очрактан файдаланырга мәҗбүр булдым. Ул кешеләр белән сөйләшкән чакта каралама рәсемнәр ясадым. Шул рәвешчә, натурадан төшереп алынган рәсемнәр сериясе хасил булды һәм ул минем эшемә бик ярдәм итте.

Тәрәзәдән кояш төшеп балчыкны киптерә, шуңа күрә аны һаман чылатып торырга туры килә иде. Еш кына мин эшләп утырган Ильич тирәсендә әйләнәм, аның я уң ягында, я сул ягында, я каршында, я артында туктап тора идем. Кабинетның идәне тапталып, балчык белән пычранып бетте. Мин моңа бик уңайсызландым. Тыныч кына эшләп утырган юлбашчыны да борчыйсым килми иде, һәм бер мәртәбә шулай әйтә куйдым:

— Владимир Ильич, сезне тәмам туйдырып бетергәнмендер,— дидем.

Ленин миңа ачык чырай белән карады да:

— Күпме кирәк, шулхәтле эшләгез, мин сезгә комачауламам,— дип җавап кайтарды.

Сирәк очрый торган энергияле һәм эшкә үтә сәләтле Владимир Ильич башкалар хезмәтенең дә кадерен белә һәм хөрмәт итә иде.

Бу искиткеч яхшы кешенең күңел көрлеге һәм мөлаемлыгы һәрнәрсәдә чагыла иде.

Ленин өстәл янында утырган чакта еш кына сызгыргалап куя иде. Ничектер шулай ана ачык хат кертеп бирделәр. Ул хатны укып чыкты да балаларча шаркылдап, рәхәтләнеп көлде. Аннары хатны ян кесәсенә салып куйды да язуын дәвам итте. Бераздан тагын алып карады да кабат көлә башлады. Ул шулай әледән-әле, ял итеп алган чакларында, хатны кесәсеннән берничә мәртәбә алып карап көлде.

Ленин китап белән мәшгуль булганлыктан, бу көннәрдә килгән кешеләрне кабул итү чикләнгән иде. Шулай да мин Кремльдә булган алты атна вакыт эчендә анарда инглиз профсоюзлары һәм немец эшчеләре делегацияләре булып китте.

Делегацияләрдән тыш, Ленин янына А. М. Горький, Ф. Э. Дзержинский, М. Ф. Андреева, Н. К. Крупская, М. И. Ульянова килеп йөри иде. Миңа таныш булмаган берничә кеше бар иде. Аларның берәүләре кабул итүгә үзләре сорап киләләр, ә икенчеләрен Ленин үзе чакырып китерә. Байтак кына кешеләрне алып килү өчен ул үз автомобилен җибәрә торган иде. Ул бөтен кешегә карата да ягымлы, һәркем белән уртак тел таба, еш кына шаярып сөйләргә, кайчакта ирония кулланырга ярата. Йомшак тел белән генә күрсәтмәләр һәм киңәшләр бирә. Ничектер сине бөтенләй үзеңеке итә иде. Ул чакта Владимир Маяковский үзенең «Иң кешелекле кеше» дигән атаклы сүзләрен әйтмәгән иде әле, әмма дөньяда беренче пролетариат дәүләте җитәкчесенең кешеләр белән аралашканын күргәч, миндә нәкъ шундый тойгы туды.

Беренче май көнне гадәтем буенча Кремльгә килдем. Урамнар гөрләп җырлап тезек сафлар белән демонстрацияче колонналар уза иде. Ленинның кабинетында булмавына мин бик гаҗәпсендем. Миңа: Владимир Ильич Беренче май өмәсендә, диделәр. Ленин, башкалар белән бергәләп, бүрәнә ташый булып чыкты.

— Бәйрәм белән тәбрик итәм сезне,— диде Владимир Ильич, кабинетына килеп керү белән.

Йөзе көләч, пиджак кайтармасында ал тасма ялтырый иде. Үзе бәйрәмчә пөхтә киенгән, илле яшьтә булуына карамастан, яшь-яшь күренә иде. Минем килүемә гаҗәпләнде ул.

— Бүген бәйрәм ич — Беренче май! — диде.

Минем эшем тәмамланып килә иде. Ленин янына соңгы көннәремне килдем. Минем скульптура әзер. Без аны кабинеттан алып чыктык та шундук бер бүлмәдә гипстан коеп та куйдык. Бу — Владимир Ильичның натурадан ясалган беренче скульптурасы иде.

## Альберт Рис Вильямс

# ЛЕНИННЫҢ ШӘХСИ ТОРМЫШЫНДА ТИМЕРДӘЙ ДИСЦИПЛИНА

Ленин шәхси тормышында үзе иҗтимагый тормышка кертә торган тимердәй дисциплина үрнәген күрсәтә иде. Ул чакта Смольныйда аның белән бергә булганнарның бөтен ашаганы щи белән борщ, арыш икмәге, чәй һәм ботка иде. Ленин үзе дә, хатыны һәм сеңелесе дә шулай тукланды. Революционерлар тәүлегенә уникешәр-унбишәр сәгать эшлиләр. Ленинның эш көне, кагыйдә буларак, кимендә унсигез-егерме сәгатькә җитә. Ул үз кулы белән йөзләрчә хатлар яза. Эшкә чумып китеп, кайчак ашавын да онытып җибәрә. Ул берәр кеше

белән сөйләшкән арада, хатыны аның янына бер стакан чәй күтәреп килеп: «Менә, иптәш, чәй китердем, эчәргә онытмагыз», дигән чаклары була иде. Еш кына чәй шикәрсез була, чөнки Ленин паекны бүтәннәр хәтле генә ала иде. Солдатлар һәм йомышка йөрүчеләр казармага охшаган шәп-шәрә стеналы зур бүлмәләрдә тимер койкаларда йоклыйлар иде. Ленин белән аның хатыны да шундый ук койкаларда йокладылар. Алар, эшләп тәмам арыгач, шул каты койкага ял итәргә яталар; теләсә кайсы минутта сикереп торырга мөмкин булсын өчен, еш кына чишенеп тә тормыйлар иде. Ленин бу мәхрүмлекләрне аскетларча яшәргә теләгәннән кичермәде, әлбәттә. Тигезлек принцибын тормышка ашырды ул.

Шундый принципларның берсе мондый иде: ул чакта теләсә кайсы совет хезмәткәренең эш хакы, уртача эшченең эш хакына тигез — айга 600 сум итеп билгеләнгән иде.

Ленин «Националь» гостиницасының икенче катындагы бүлмәгә күчкәндә, мин шул гостиницада тора идем. Яңа, совет законы бирелә иң әүвәл нәзакәтле һәм кыйммәтле ашларны бетерде. Көндезге ашка әзерләнә торган күп санлы блюдолар урынына ике блюдо калдырылды. Я аш белән ит, яисә аш белән ботка алырга мөмкин иде. Теләсә нинди кеше, халык комиссары да, кара эшче дә шулай гына ашый ала, икенче төрле әйткәндә: «Бөтен кешенең тамагы икмәккә туймый торып, берәү дә пирожный ашарга тиеш түгел», дигән таләпкә туры китереп яши иде. Кешеләргә икмәк тә житмәгән көннәр булгалый. Андый вакытларда Ленин да нәкъ бүтән кешеләр чаклы ала. Кайбер көннәрне икмәк бөтенләй булмый торган иде. Ул көннәрне Ленин да икмәк алмый.

Һөжүм ясалганнан соң Ленин авыр хәлдә яткан чакта врачлар аңа карточка белән алып булмый торган продуктлар белән туклапырга куштылар, аларны тик базарда спекулянтлардан гына юнәтергә мөмкин иде. Дусларының ялынып-ялварып үгетләүләренә дә карамастан, ул законлы паекка кермәгән ашамлыкларны авыз итүдән дә баш тартты.

Соңга таба, Ленин инде сәламәтләнә башлагач, хатыны белән сеңелесе аның ашау-эчүен яхшырту ысулын таптылар. Аның үз икмәген өстәл тартмасында тотуын белеп, алар аның бүлмәсенә үзе югында керәләр дә икмәк өстәп чыгалар иде. Ленин, бик мавыгып эшләп утырган чакта, өстәл тартмасына кулын тыгып икмәк ала да аның гадәттәге паекка өстәмә икәнлеген белми-нитми ашый торган була.

Ленин Европа һәм Америка эшчеләренә җибәргән хатында Антантаның сугыш белән тыкшынуы аркасында эшчеләр массасы өстенә килгән мәхрүмлекләр, ачлык газаплары хакында язды. Бу газап һәм мәхрүмлекләрнең бөтенесен Ленин халык белән бергә кичерде.

## ЛЕНИН КЕШЕЛӘР БЕЛӘН НИЧЕК АРАЛАШТЫ

Мин Ленинны арыган, талчыккан хәлендә бер генә мәртәбә күрдем. Совнаркомның төнге утырышыннан соң ул, хатыны һәм сеңелесе белән бергәләп, «Националь» гостиницасының лифтына килеп керде.

— Хәерле кич,— диде ул, хәлсез генә тавыш белән.— Хәер, алай түгел лә, хәерле иртә,— дип төзәтеп куйды аннары.— Көне буе, төне буе сөйләп арыганмын. Хәтта икенче катка да лифт белән күтәреләм.

Мин аның бик ашыгуын да бер генә мәртәбә күрдем. Бу хәл февраль аенда, Таврида сарае яңадан да каты бәхәс мәйданына әйләнгәч булды — Германия белән сугышны дәвам иттерү яки солых төзү турындагы мәсьәлә тикшерелә иде. Ленин кинәт кенә килеп керде дә, житез, гайрәтле адымнар белән вестибюль аркылы жилләнеп узып, трибунага

керә торган ишеккә юнәлде. Профессор Кунц белән без аны көтеп тора идек, шундук без аннан:

— Бер генә минутка мөмкинме, иптәш Ленин,— дип мөрәҗәгать иттек.

Ул җәһәт-җәһәт атлап барган жиреннән туктады да, «смирно» торгандай басып, нәзакәтле генә итеп баш иеп:

— Иптәшләр, зинһар дип әйтәм, бу юлга мине җибәрегез. Бер генә секунд та вакытым юк. Мине залда көтәләр. Үтенәм сездән, кичерегез, бүтән вакытта очрашырбыз,— диде һәм, тагын баш иеп, кулларыбызны кысты да китеп барды.

Большевикларның дошманы Уилкокс Ленинның кешеләр белән мөлаем мөгамәләсе турында мондый бер хәл сөйләде: бер инглиз коммерсанты, үзенең гаиләсен һәлакәттән коткарып калырга ярдәм сорап, Ленинга мөрәҗәгать иткән. Бу инглиз «канечкеч тиран» урынына, кулыннан килгән бөтен нәрсә белән булышырга әзер торучы, кешелекле, ягымлы, мөлаем кеше белән очрашкач, бөтенләй хәйран калган.

Ленин чынлап та шундый иде. Кайчак ул хәтта кирәгеннән артык ягымлы, нәзакәтле булып китә сыман иде. Инглизчә сөйләгән чакта Ленин башлыча китаплардан алган үтә нәзакәтле сүзләрне кулланганга бәлки шулай тоелгандыр. Әмма, бик ихтимал, бу аның кешеләр белән мөгамәләдәге гадәте булгандыр, чөнки Ленин, бүтән бик күп нәрсәләрдәге кебек үк, кешеләр белән мөгамәләдә дә бик әдәпле иде.

Ленин янына керү бик үк гади эш түгел иде. Әмма сез аңа барып кергәнсез икән инде, ул бөтенләе белән сезнең карамакта була. Ул бөтен игътибарын сезгә бирә, моңардан хәтта уңайсыз да була торган иде. Әдәпле генә исәнләшкәннән соң ул якын ук килеп утыра. Сөйләшкән вакытта еш кына гәүдәсен алга суза, иң тирән серләреңне белергә һәм күңелеңдә ни ятканны аңларга теләгәндәй, туп-туры күзеңә карап тора иде.

Безгә 1905 елны Мәскәү восстаниесендә катнашкан һәм баррикада сугышларында хәтта батырлык та күрсәткән бер социалистны бик еш очратырга туры килә иде. Хәзер ул ниндидер инглиз газета синдикаты һәм Плехановның «Единство» газетасы хәбәрчесе булып эшли һәм шактый булдыклы әфәнде шикелле йөри иде.

Буржуаз язучы сыңарлары белән очрашуны Ленин вакытны бушка әрәм итү дип карый иде; әмма бу кеше, үзенең үткәндәге революцион эшләреннән файдаланып, Ленин белән күрешүгә ирешә. Ленин белән очрашуга барганда аның күңеле ифрат күтәренке иде. Берничә сәгать узганнан соң мин аны тәмам аптырашта калган кыяфәттә күрдем. Ул миңа менә нәрсәләр сөйләп бирде: «Ленин кабинетына кергәч, мин аңа 1905 елгы революциядә катнашканлыгымны әйттем. Ленин, яныма килде дә: «Анысы шулай, иптәш, әмма сез бу революция хакына нилэр эшлисез?» — дип сорады ул, күзләремә туп-туры карап. Безнең ике ара күп дигәндә 15 сантиметр булгандыр. Мин кайчандыр баррикадаларда сугышканлыгым турында сөйли башладым һәм бер адым артка чиктем. Әмма Ленин бер адым алга атлады һәм, минем күзләремнән бер дә күзен алмыйча: «Анысы шулай, иптәш, әмма сез бу революция хакына нилэр эшлисез?» — дип кабатлады. Әйтерсең, мине рентген нурлары белән яктыртып соңгы ун ел эчендәге бөтен тормышымны үтәли карадылармыни. Мин түзә алмый, гаепле бала шикелле, башымны түбән идем. Сүз кушарга маташып карадым. Ләкин нәтиҗәсез. Шул килеш чыгып китәргә туры килде».

Берничә көннән соң бу кеше, үзенең бөтен тормышын 1917 елгы революция белән бәйләп, совет работнигына әйләнде.

**Г. КАМАЛИЕВ** тәрҗемәләре.

## Нури Арсланов

•

Тел тибрәтеп бер сүз әйтмим, баксаң
Беркем аңа йозак элмәгән,
Күп уйларым тоткын булып ята
Чыгалмыйча бу тән — төрмәдән...

Юк-бар белән мин сүз көрәштермим,
Эчтән тынам, эчтән сызланам:
Гади сүзләр белән хисләремне
Әрәм итәрмен дип кызганам.

Әмма уйлар җырга әйләнсәләр,
Анда бетә минем ихтыяр:
Ул чагында илһам кесәсенә
Уйламагыз хисләр, дип, сыяр!

Дулкынланып шуңа сөйләп киләм
Серләремне мин тик җырларда.—
Чөнки җырга йозак асып булмый,
Бикләп булмый җырны зинданга.

•

Гамьсезлектән җырлый, диләр мине;
Үзем генә беләм хәлемне...—
Өзелеп-өзелеп сулкылдый да бәгырем,
Җырлыйм: «...Бөркән зәңгәр шәлеңне»...

Бер мин түгел, әлмисактан бирле
Халкым минем моңны ярата.
Бик күбәеп китсә хәсрәтләрем,—
Җырлыйм: «...Җыру кайгы тарата».

Гамьсезлектән җырлый, диләр мине;
Гамьсезгә соң җыр-моң ни аңа?!
Эчендәге сагышлары кушкач,
Җырлый башлый миндәй дивана.

# Дүрт киңәш

*Һинд хикмәтләреннән*

1

Әгәр берәү берни белмәсә,
Һәм белмәсә үзенең белмәвен,—
Бәхәсләшмә андый бәндә белән,
Әрәм булыр вакытың, сөйләвең...

2

Әгәр берәү берни белмәсә,
Ләкин белсә үзенең белмәвен,—
Агу итеп сибәр җаһиллеген,
Белгәнеңне синнән көнләвен.

3

Әгәр берәү белсә бик күпне,
Тик белмәсә белүе турында,—
Ул йокыда булыр, уят аны,
Юнәлт аны дөрес юлына.

4

Әгәр берәү белсә бик күпне,
Һәм белүен белсә үзенең,—
Ияр аңа — ул чын хаким кеше,
От мәгънәсен һәрбер сүзенең.

# Рус балалайкасы

Балалайкада чирттереп
Урамда йөргәнем юк.
Балалайкада рус небен
Уйнаучы күргәнем юк.

Балалайка кыллары өчәү генә,
Уйнаулары йөрәккә төшә генә.
Балалайка кыллары нечкә генә,
Күз нярә кулларга көчкә генә.
Балалайка моңнары ла, моңнары,
Өздереп ала уззкне кыллары:
Бер карасаң Волгада саллар ага,
Стенька Разиннар корабларда бара,
Бер карасаң юлларда тузан туза —
Кыңгыраулар чыңлый, ямщиклар уза,
Я матрешкалар биеп китә кебек...
Ә кыллар бер сыкранып та, бер көлеп,
Рус көйләрен өздерә дә өздерә.
Шул чагында түз түзәлсаң, түз генә!
Бер сере бар балалайканың аның —

Ул ачып сала көйләрдә рус җанын!
Өч кенә кыл анда тик,— өч йөз аваз!
Ә халык җанын ачарга ул да аз!
Һәр халыкның думбрасы, кубызы бар;
Балалайка — рус моңына тугры яр.
Балалайка еракта чыңлый-чыңлый:
«Выплывают... Стеньки Разина челны...»

## Синең тавышың

Син озаттың мине: бу соңгы кат
Синең белән күрешү булган икән...
Шуңаргамы моңсу иде Идел,
Еракта ярлар, ялгыз җилкән...

Акчарлаклар канатында очып,
Озатып барды мине тавышың ерак.
Шундый үкенеч, шундый сагыш җанда! —
Әрнүләргә хәтта булмый чыдап...

Ватаныңдай чиксез иркен иде
Һәм зур иде, Әнвәр, хыялларың.
Сыялмадың тормыш кыршавына,
Азат җаның белән сыялмадың...

Без ярата идек синең белән
Шигъриятле кичәләрдә кат-кат
Тостлар күтәрергә, ялкынланып,
Мәхәббәтне һәм яшәүне мактап!

Дулкынланып шигырь сөйләгәндә,
Шигырең кебек көчле иде тавышың.
Юксынырлар Казан урамнары,
Алар инде сине кайдан алсын...

Күкрәгеңнән ташып чыкты җырлар...
Син үзеңне хискә иттең корбан;
Тәнең тынды, йөрәгең тынды синең,
Ә җырларың әйтте: тынмам, тынмам!

Тынамы соң җырлар! — көр тавышың
Элеккедәй, Әнвәр, шаулап тора;
Чын шигърият яңгырый тормыш белән,
Тик талантсыз җырлар гына тына.

## Парчалар

●

Акыллыга «башлы» дисәләр дә,
Диванага «башсыз» димиләр;
Мин «башлы»да һәм «башсыз» да түгел,
Ник башыма тынгы бирмиләр?..

●

Үз фикереңне үткәрергә тырыш,
Бәхәскә кер, якла;
Ләкин аны көчләп башкаларга
Бөти итеп такма!

●

Эчемлек тә әйбәт — тәмен белеп
Эчә белсәң генә:
Бүген таңнан торып үкенмәслек
Булсаң кичәгеңә.

## Ике тәрҗемә

## А. С. Пушкин

●

*А. П. Кернга.*

Мин хәтерлим гаҗәп бер мизгелне:
Гүя кинәт күктән индең син —
Пәйда булдың алда, күрдем сине,
Саф матурлык күрке идең син.

Өметсезгә борчыганда сагышым,
Шомлы, фани шау-шу эчендә,
Чыңлап торды озак нәфис тавышың,
Якты сының керде төшемә.

Еллар үтте, җил-давыллар узды
Тузгытып бар хыял-моңымны,
Мин оныттым нәфис авазыңны,
Фәрештәдәй гүзәл сыныңны.

Еракларда, сөргеннәрдә ялгыз
Үтте көннәр, тыныч-күңелсез,
Алиһәсез һәм хәятсыз-җансыз,
Илһамчысыз, яшьсез, сөюсез.

Уяныр чак житте ләкин җанга:
Насыйп булды тагын юлыгу —
Пәри заттай пәйда булдың алда,
Саф матурлык күрке — чын сылу.

Йөрәк ярсып типте шатлык белән,
Һәм уянды кабат күңелдә
Илһамчы да, хәят, алиһә дә,
Күз яше дә, көчле сөю дә.

## И. В. Гете

# Урман патшасы

*Баллада*

Дым тарткан караңгы урманнан кем чаба?
Кичеккән җайдак ул, алдында бер бала.
Әткәсе куенына сыена ул каушап,
Карт аны юата, җылыта кочаклап.

— Улым, ник тетрисең, ник алай каушадың?
— Әткәем, мин күрдем дәү урман патшасын,
Мәһабәт сакаллы, кара таҗ башында.
— Юк, улым, томан ул җәелә каршыда.

«Әй углан, я, миңа каерылып бер кара;
Илемдәй гаҗәп ил юк бөтен дөньяда:
Сине гөл-чәчәкләр, энҗедәй саф сулар,
Алтынга бизәлгән сараем каршылар».

— Әткәем, падиша үзенә чакыра:
Ул бирәм ди миңа шатлык та, алтын да.
— Юк, улым, тик сиңа ул шулай тоела:
Яфраклар шаулашып җилләрдә коена.

«Кил миңа, әй углан, шәп минем урманым,
Күрерсең син анда шук урман кызларын;
Алар ай калкуга уйныйлар, очалар,
Тирбәтеп, иркәләп йоклатыр-кочарлар».

— Кызларын чакыра дәү урман патшасы,
Әткәем, кызлары кул изи барчасы.
— Берни юк, төн тыныч, куаклар тынганнар:
Ул энә җилләрдән бөгелә ак таллар.

«Әй углан, мин гашыйк синең ак йөзеңә,
Теләпме, көчләпме — булырсың үземә».
— Әтием, тотынды ул арттан куарга,
Минә ул җитте дә, бик авыр суларга...

Ә атлы чаптыра — әй оча аргымак,
Баласы борчыла, сыкрана зар елап.
Килеп тә җиттеләр — юл бетте барасы.
Тик юлчы кулында җан биргән баласы...

Әмирхан Еники

# ВӨҖДАН

*(Ышанып сөйләү)*



Бәкер дус, ялгышмасам, менә утыз биш ел инде безнең очрашканыбыз юк. Уйласаң, шактый гаҗәп бит бу!.. Син Казанда, мин Ташкентта — бу ике араны безнең халык гел йөреп тора, аннары йөрү үзе дә хәзер бик ансатлашты — самолетка утырсаң, биш-алты сәгатьтән, әйтик, Казанда буласың. Ә шулай да без күрешә алмыйбыз. Ни өчен, сәбәп нәрсәдә? Күрәсең, кеше әле бары үзе теләгәнчә генә йөри алмый. Я сылтавы табылмый, я жае чыкмый, я вакыты булмый. Мин үзем, мәсәлән, Себердән алып, Кавказга чаклы күп кенә шәһәрләрдә булдым, ә менә Ташкенттан кул сузымында гына торган күрше Фрунзеда була алганым юк. Барып күрәсем бик килүгә дә карамастан...

Казан исә минем өчен башка исәптәге шәһәр, кайта алмавымның сәбәбе дә башкада. Казанда мин укыдым, эшләдем, иртә яшьлегемне шунда үткәрдем, хәтта беренче мәхәббәтемне дә шунда кичердем. Туып-үскән җирем дә Казаннан ерак түгел... Кыскасы, минем үз шәһәрем ул, туган-туфрагым кебек үк якын, кадерле ул миңа... Әмма шулай булуына карамастан, минем юлым Казанга күптән өзелде. Сугышка чаклы бөтенләй кайтасым да килмәде, ә сугыштан соң бер генә тапкыр кайткан идем, анда да дүрт—биш көннән артык тора алмадым (отпускамның ахыры иде). Ләкин син, Казанга минем ниндидер үпкәм бар икән дип, уйлый күрмә. Казан үзе, әйткәнемчә, миңа якын, кадерле, сагынам да, онытмыйм да мин аны... Ә ташлап китүемнең, аннары кайтмыйча йөрүемнең сәбәбе исә башкада.

Менә шул сәбәпне мин сиңа сөйләргә җыенам, Бәкер дус!.. Үзең беләсең, безнең арада кайчандыр кыска вакытлы, әмма шактый якын, керсез дуслык булып алды. Сиңа ничектер, ләкин миңа калса, яшь чактагы дуслыктан да ныграк, сафрак дуслык юк шикелле... Олая башлагач туган дуслыклар нигәдер ул хәтле бик тирәнәеп, ныгып китә алмый. Күрәсең, яшь чакта без ихласрак, эчкерсезрәк, саф күңеллерәк була ала торганбыздыр. Шуңа күрә безнең дуслыгыбыз да һәртөрле исәп-хисаплардан өстен торгандыр инде.

Ләкин озак еллар күрешмәгәч, мондый дуслык әкренләп суына, сүнә бара, әмма бөтенләй үк онытылмый, ничектер үзеңнең ерак яшьлегең төсле һаман күңелдә саклана. Без дә, Бәкер, синең белән бик еракләштык, ике төрле кешегә әйләндек, уртак нәрсәләребез дә калмады диярлек. Ә шулай да менә хәзер мин сиңа үземнең, русча әйтсәк, исповедымны (бу сүзнең татарчасы юк та шикелле) язарга керешәм.

Чөнки мин яшьлегемә кайтам, ә яшьлегемдә иң якын дусларымның берсе булып син торасың. Ерак булсаң да, үзгә булсаң да синә сөйләү минем өчен җиңелрәк.

Аннары соңгы вакытларда безнең хат языша башлавыбыз да ничектер минем теләмне чишге. Ул хатлардан син инде минем кайда, кем булып эшләвемне беләсең. Шулай ук минем өйләнмичә ялгызак бер кеше булып калуым да сиңа билгеле. Бу соңгы хәл синдә зур кызыксыну уятты булса кирәк, менә икенче тапкыр инде миннән: «Хәбиб, ничек ул алай килеп чыкты, нишләп өйләнмичә калдың, сәбәп нәрсәдә?» дип сорап язасың... Әйе, бик четрекле сорау, үтә шәхси, нечкә, авыр мәсьәлә бу минем өчен... Моның сәбәбен мин бервакытта да, беркемгә дә сөйләмәдем. Теләгем дә булмады, кирәк дип тә тапмадым. Дөресен генә әйткәндә, баштарак сиңа да язасым килмәгән иде. Ләкин син, Бәкер, үзеңнең хатларың белән ничектер минем еллар күмеп киткән, бик иске дәфтәр шикелле каядыр тик кенә яткан хатирәләремне кузгаттың. Һәм менә котылгысыз рәвештә шуларны, ниһаять, сиңа сөйлисем килү теләге туды... Бел, бары сиңа гына...

Әлбәттә, мин бөтен үткән гомеремне сөйләргә җыенмыйм — бу хәзергә мөмкин эш түгел. Мин бары башымнан кичкән бер вакыйганы гына сөйләп чыкмакчы булам. Ләкин бу вакыйга үзе дә сиңа минем ни өчен Казаннан китүемне, озак еллар кайтмыйча йөрүемне, ниһаять, ни өчен өйләнмичә калуымны да аңлатып бирер дип ышанам...

Ә хәзер вакыйганың үзенә дә күчәргә була.

* * *

Утызынчы елның җәй башында мин, ниһаять, рабфакны бетереп чыктым. Яхшы укыдым, яхшы тәмамладым... Билгеле, мин шат идем. Шактый биек тауга менеп житкәндәй ничектер җиңеләеп бер сулыш алдым, әмма шул ук вакытта миңа бераз ямансу да иде. Дүрт ел гомер үтте дә китте... Дүрт ел буена иялләшкән, күнегеп беткән нәрсәләрдән — рабфак бинасыннан, класс-аудиторияләрдән, тулай торактан, шул торак белән рабфак арасын бергә таптаган иптәшләрдән аерылыр көн дә килеп җитте. Аерылышыр вакыт җиткәч, кешегә вак кына, юк кына әйберләр дә бик якын булып тоела башлый икән. Ничектер, аларны тиз генә онытып булмас кебек... Мәсәлән, шул ук торакны (элеккеге «Франция» номерларын), аның иләмсез биек түшәмле, ун—унике кеше сыярлык зур бүлмәсен, бүлмә уртасындагы кара белән буялып, пычак белән тамгаланып беткән озын, шәрә өстәлен, бакыр чәйнеген, калай кружкаларын, ниһаять, тар, шыгырдавык тимер караватын... Бигрәк тә шушы капчык матрацлы, соры одеаллы, уртасы батып төшкән алама карават бер дә онытылмас кебек иде... Чынлап та ул замандагы, әллә лазаретлардан, әллә казармалардан җыеп китерелгән төрле иштәге, әмма барысы да иске, студент караваты берәр музейда сакланмыймы икән? — рәхәтләнеп үзенә тагын бер карар идем. Күпме хыяллар, күпме татлы уйлар, сагыш-уфтанулар, матур һәм ямьсез төшләр күреп уздырмадык без шул туйдырып бетергән, үзе шыгырдавык, үзе чыдам караватыбыз кочагында!..

Әйе, боларның барысы да искә төшереп сөйләргә генә калды. Син беләсең инде, рабфак — укуның ярты юлы гына, аны бетергәч тә ВУЗга китәргә кирәк. Теләсәң кайсына — рабфак бетерүчеләр өчен бөтен җирдә ишекләр ачык. Ләкин мин, уйлап тордым да, бу мөмкинлектән файдалануны бер елга кичектерергә булдым. Ник дисәң, дүрт ел буена баш күтәрмичә уку шактый ялыктырды, аннары иң начары — матди яктан бик бетеренгән идем. Стипендия такы-токы ашаудан артмады, беркайдан, бернинди ярдәм юк, очы-кырые күренмәгән өз-

лексез кытлык. Бигрәк тә кием-салым бик хөртиләнде: аякта ямаулы ботинкалар белән ертык галош, өстә иләнә-иләнә аркау җепләре чыга башлаган пинжәк-чалбар, ә кышкы пальто инде ул, бичара, студентның үзе кебек чыдам — икенче шәхсенә әйләнеп дигәндәй өстендә йөри дә йөри. Алыштырып-яңартып җибәрергә һич рәт юк. Син дә хәтерлисендер әле, мин җәйге каникул вакытларында авылга әнине күрер өчен бер-ике атнага гына кайтып килә идем дә, аннары көзгә чаклы диярлек пристаньдә яки станциядә йөк бушатып, өс-башлык акча эшләргә тырыша идем. Тик рәхәтләнеп эшләрлек эше генә гел булып тормый иде. Кыскасы, чынлабрак акча табасы, ВУЗга кергәнче ничек тә бер бөтенәеп, яңарып аласы килде. Болар өстенә тагын шундый уй да бар иде: гел уку да уку, ә тормышны юньләп күргән юк, ул әнә ашыгаашыга ничектер читләтеп үтеп бара. Бер елны югалтканнан ни булыр?.. Ичмасам, чын хезмәт дигән нәрсәне татып, үзем теләгәнчә бер торып та алырмын. Бәлки, бу миңа киләчәк профессияне сайлау мәсьәләсендә дә ярдәм итеп куяр... Әнә шулай уйлап, мин, әйткәнемчә, ВУЗга китүне бер елга кичектереп, эшкә керергә булдым.

* * *

Ул елларда безнең Казанда мехлар эшкәртү производствосы бик кызу гына үсә башлаган иде. Кыска гына арада Яңа Бистәдә берничә мех фабрикасы ачылды. Гел татарлар гына тыгызланып утырган бистәдә чын фабрикалар ачылу — бу, һичшиксез, зур вакыйга иде. Бистә тормышына, политэкономия теле белән әйтсәк, яңа производство мөнәсәбәтләре керде. Анда яшәгән җыен кустарь, ломовой, вак сәүдәгәр халкын шул фабрикалар үз эчләренә тарта башладылар... «Кайда эшлисең?» дигәч, «меховойда!» дип кенә җибәрүчеләрне еш очратырга була иде... Газеталар да меховойлар турында мактап һәм мактанып язарга тотындылар...

Менә шуның тәэсиренә бирелеп булса кирәк, мин дә Яңа Бистәгә таба юнәлдем. Яңа җир, яңа эш, мин әйтәм, хезмәт юлымны шуннан башласам, начар булмас дим. Ләкин мехның нәрсә икәнен әзрәк кенә белсәм дә (әти мәрхүмнең читенә кама тоткан туны бар иде), аның ничек эшләнүе турында һичбер хәбәрем юк иде. Яки болай дип кенә белә идем: матур-мамык тиреле җәнлек урманда чабып йөри, аны атып яки капкынга эләктереп алалар да, шуннан соң тиресен сыдырып, иләп-йомшартып якага куялар... Менә шул. Ә фабрика чаклы фабрикада аны нишләтәләр, бу кадәресен күз алдыма китерә дә алмый идем.

Ул вакытта инде фабрикалар белән идарә итәр өчен «мехкомбинат» дигән нәрсә дә оештырылган иде — мин менә шунда барып кердем. Август башларында булды бу — аңарчы авылга, әни янына кайтып килгән идем... Мехкомбинатта миңе яхшы каршы алдылар. Сораштылар, документларымны карадылар, ләкин яңа гына рабфак бетергән, моңарчы әле бер җирдә дә эшләмәгән «яшел» егет булуымны белгәч, бераз уйга калдылар. Кая, нинди эшкә алырга?.. Белеме бар, әмма берниндй тәҗрибәсе юк кешегә лаек эш табу, күрәсең, җиңел түгелдер... Мин үзем исә теләсә нинди эшкә керергә, хәтта өйрәнчек булып эшли башларга да риза идем. Шулай да бераз уйлашканнан соң миңа әйттеләр: сезне фабриканың берәр цехына кара эшче яки өйрәнчек итеп алудан мәгънә юк, чөнки рабфак бетергән кешене кара эшче итеп алу просто килешми, ярамый, ә өйрәнчекнең хезмәт хакы бик кечкенә.. Шуңа күрә без сезне, әгәр риза булсагыз, мехбазага җибәрәбез, анда укыганрак егетләр кирәк, эше дә чистарак, диделәр.

Ә нәрсә ул «мехбаза» һәм кем булып мин анда эшләргә тиешмен?.. Мехбаза ул бөтен фабрикаларның эшләп чыгарган әзер продукцияләре кирә торган җир икән. Анда әзер мехларны сортларга бүләләр, клейма

сугалар, сорты-сорты белән бәйләп, ящикларга салып, алдан килгән наряд буенча төрле шәһәрләргә озаталар. Мехларны дөрес итеп сортларга аеру шактый нечкә, җаваплы эш икән. Чөнки аларның күп өлеше экспортка китә, имеш. Бу эштә зур квалификацияле белгечләр эшлиләр икән.

Мин менә шул мехбазаның каракүлләр цехына өйрәнчек булып барырга тиешмен. Андагы өйрәнчекләрнең хезмәт хакы да, фабрика өйрәнчекләренә караганда, шактый өстен икән. Шул ук вакытта мине цех начальнигының ярдәмчесе итеп тә билгеләделәр,— әлбәттә, аерым хезмәт хакы белән. (Өйрәнчекне бер үк вакытта начальник ярдәмчесе итеп кую хәзер бик сәер тоелыр, ләкин ул заманда һәм яңа оешкан производствода андый хәлләр була иде, моның үз логикасы, үз политикасы бар иде.)

Озын сүзнең кыскасы, әнә шулай эшкә урнашып, мехчы булып киттем мин... Мехчы абзагызның матди ягы да бер ай эчендә диярлек шәбәйде: кырык сум да алтмыш сум — барлыгы йөз сум, ә бу ул заманда шактый зур акча иде. Сентябрь башында ук инде мин хәзерге Куйбышев урамындагы бер марҗадан кечкенә бүлмә табып, рабфак торагыннан шунда күчтем. Бүлмә ишек алды түрендәге иске генә агач йортта иде, тыныч, аулак, урам шау-шуы бөтенләй ишетелми диярлек. Кровате, өстәле, урындыгы, хәтта трюмо көзгесе дә бар,— прәме җәннәт! Минем бит әле үз гомеремдә беренче тапкыр аерым бүлмәдә торуым — рәхәт нәрсә икән ул. Дөрес, башта минем белән шул ук мехбазадан Вафа исемле егет тә торды. Ләкин озак түгел — бер ай, ай ярымнан үзенә бүлмә табып, чыгып китте.

...Толчоктан мин бер тотылган будильник сатып алдым. (Каплап куйсаң гына йөри торган иде.) Һәр кичне үзен сәгать алтыга борып куям, һәр иртән шуның калтырана-калтырана чәрелдәвенә уянып китәм, «житәр, көчек!» дип тиз генә сикереп торам, әйбәтләп салкын су белән юынам, аннары кухняда гына Серафима түтәйнең бирәр стакан куе чәен эчәм дә, салкынча тын иртәдә гаҗәеп бер тән һәм җан җиңеллеге тоеп, батыр басып, эшкә юнәләм. Һәрхәлдә, бүгенге язмышымнан мин бик канәгать әле...

* * *

Мехбаза Бауман урамындагы элекке ломбард йортына урнашкан иде. Бу — шәһәрдәге иң зур, биек йортларның берсе. Анда кайчандыр ломбард булуын без инде белмибез,— белгәнлеккә төшкән чакта актык кимеммне илтеп салып, бурычка акча алып тору күптән бетерелде, ләкин йортның һәр катындагы ялан кадәр заллары үзләре үк аларның кеше малын, кеше күз яшен җыяр өчен махсус ясалган булуын әйтеп торалар иде. Менә шул йортка хәзер һәркөнне Казан мех фабрикаларыннан эшләнеп чыккан «йомшак алтын» йөге-йөге белән килеп керә һәм безнең куллардан үтеп, чит илләргә, төрле шәһәрләргә китә тора.

Мехбаза, әйткәнемчә, күптән түгел оештырылган үзенә бер мөстәкыйль хуҗалык иде ул. Аның үз житәкчесе (управляющие), үз конторасы, үз штаты, үзенең партия һәм профсоюз оешмалары бар. Банк белән дә турыдан-туры үзе эш итә. Кешеләрне эшкә алу яки эштән чыгару да аның үз кулында — мехкомбинат бу очракта тәкъдим итүче, җибәрүче генә... Тагын шуны да әйтергә кирәк, мехбаза фабрикаларның әзер продукцияләрен алып торучы гына түгел, аларны чимал белән тәэмин итеп торучы да иде... Моны снабсбыт диләрме?.. Кыскасы, бирел эшләтүче һәм эшләткәнен сатып ятучы бик бай бер фирма сыман оешма иде ул. Ике йөз илледән кеше эшли иде үзендә...

Мехбаза яна оешкан бер хуҗалык булгач, аның бөтен коллективы да, билгеле, яңа иде, ягъни бер вакыттарак җыеп алган кешеләрдән тора иде. Боларның бер өлеше мехкомбинаттан килгән, сайлап куелган, билгеләнгән җитәкче кадрлар, икенче зур өлеше төрле җирләрдән чакырылган квалификацияле белгечләр һәм шуларга өйрәнчек итеп алынган яшь егетләр, яшь кызлар... Белгечләр дигәнебез мехны танучылар, мехны сортларга бүлүчеләр, аларга бәя куючылар... Мехбазаның тоткасы алар. Нинди мех кайсы сортка керә, кайсысын экспортка җибәрергә ярый — бары алар хәл итә... Тагын иң кызыгы шунда, бу белгечләрнең күпчелеге, бигрәк тә бөтен каракулчеләр Мәскәү, Ленинград тирәсеннән табып, чакыртып китерелгән мишәрләр иде... Маматов, Ишмаметов, Байтирәков, Ширинский кебек ничектер ихтыярсыздан хөрмәт кузгата торган фамилияләр... Болар, һичшиксез, зур осталар, кайчандыр Мәскәү фабрикаларында (мәсәлән, Ирзиннарда) һәм Ленинград аукционында эшләгәннәр, ә кайберләре әлегрәк үзләре дә мех белән сәүдә иткәннәр. Хәтта аларның берсен, Ишмаметовны, Бохара әмиренең каракулләрен чит ил купецларына сатып торучы булган диеп тә сөйлиләр иде. Болар инде, иптәшкәй, каракүл нәкышләрен нәфис гарәп язуын укыгандай укый-таный беләләр. Шуңа күрә дә мехбаза аларның күбесен, һәркайсы белән аерым договор төзеп, зур хезмәт хакы бәрабәренә чакырып китергән иде.

Шунысы гаҗәп, Казан үзе борын-борыннан тире-яры, мех эшләре белән танылган шәһәр булса да, җирле татарлардан чын мехчылар юк дәрәҗәсендә аз иде. Чимал складында сарык тиреләрен сортлаучы ике татарны исәпләмәгәндә, әзер мехта эшләүче бер генә белгеч тә юк иде. Бигрәк тә каракүл танучылар. Ни өчен бу болай, булып та таралып, югалып беткәннәрме — әйтүе дә читен. Кыскасы, ул чакта чын мехчылар — мишәрләр, бу эш тулысынча алар кулында иде[1].

Инде менә без, моңарчы мәче тиресе белән куян тиресен дә аера белмәгән яшь егетләр, яшь кызлар, шул мишәр дәдәйләрдән мех сортлауның нечкә серен өйрәнергә һәм тора-бара аларны акрынлап алыштырырга тиеш идек.

* * *

Ләкин мин бит әле өйрәнчек кенә түгел, цех начальнигының (ул вакыттагыча әйтсәк, мөдиренең) ярдәмчесе, әлеге шул зур белгечләргә беркадәр баш кеше дә... Баштарак мондый хәл миңа шактый сәер, читен, уңайсыз да булып тоелган иде. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән цех эшеннән беренче мәртәбә атлап кер, бернибелмә, үзең нибары өйрәнчек кенә бул, ә шулай да ниндидер начальник кисәге булып йөр!.. Әллә ничек бер уен төсле бу... Ләкин озак та үтмичә, мин үз хәлемнең алай ук искитмәле түгел икәнлеген күрдем: минем вазифам бик гади һәм бик кечкенә иде.

Ин әлек цех начальнигының үзе турында берничә сүз. Бу кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге Васильев дигән бер кеше иде. Тутырып әйткәндә, Василий Иванович Васильев. Үзе бик ябык, күкрәге тар, калак сөякләре беленеп тора, ә куллары озын, авыр... Аз сүзле, сүлпән хәрәкәтле, елмаюны белми яки бик сирәк кенә, ничектер көчәнеп кенә елмая, ә эчкә баткан күзләре җирән күе кашлары астыннан әгъйифь бизгәк уты белән янып, шул ук вакытта уйчан-хәлсез карыйлар... Беренче күргәч тә мин бу караңгы чырайлы сөмсер кеше белән эшләве бик авыр булыр дип борчылган идем. Характеры начарга ох-

---

[1] Сүз бирелә мехны эшкәртүчеләр түгел, ә әзер мехны танучылар, сортлаучылар турында бара. Югыйсә мехны эшкәрткән фабрикаларда татарлардан зур гына белгечләр бар иде.

шый, эшемнән бер дә канәгать булмас, гел гаебемне табып, тиргәп кенә торыр дип курыккан идем. Ләкин бик тиз мин бу борчылу-куркуның нигезсез икәнен аңлап алдым. Тышкы кыяфәтләре белән әнә шулай шомландырса да, Василий Иванович асылда шактый йомшак, иплә һәм эчкерсез бер кеше булып чыкты. Ул, бичара, бик авыру икән (чахотка кимерә үзен), һәм аның сөмсерлеге дә, сүлпәнлеге дә, күзләрендәге бизәк уты да әнә шуңардан килә икән.

Кыска гына арада мин аның хакында мехбазага элегрәк кергән кешеләрдән дә, шулай ук Василий Ивановичның үзеннән дә күп кенә нәрсә ишетеп белдем. Ул бик түбәннән чыккан, укуны юньләп күрмәгән дә, әмма тормышның авыр, каты мәктәбен үткән. Дүрт ел буена Герман сугышының пычрак һәм салкын окопларында аунаган, шуның бөтен фаҗигасен, газабын кичергән, 1917 елда ук большевиклар партиясенә кергән, октябрь көннәрендә кызыл гвардеец булып, Петроградны яклаган, аннары гражданнар сугышын башыннан ахырынача узган... Ләкин хикмәт анда гына түгел. Мине барысыннан элек җәлеп иткәне шул булды,— Василий Иванович бу мактаулы эшләре белән һич тә мактана белми иде. Иң гади, иң тыйнак кеше булып йөри бирә, әмма эчке иманы нык, таза булырга тиеш... Шулай сизә идем мин аны.

...Аның мехбазага килеп эләгүе дә ул вакыт өчен шактый кызыклы. Әйтүенә караганда, Василий Иванович кайчандыр яшүсмер чагында тире иләүчедә өйрәнчек малай булып эшләгән икән. Һәм менә шушы «һөнәрен» белгәч, аны тотканнар да мехбазага цех начальнигы итеп җибәргәннәр.

— Нишлисең, башыңа төшкәч, башмакчы буласың,— ди ул үзе, ялкау гына елмаеп.

Хәер, мәсьәлә бик ачык: тире иләүчедә өйрәнчек малай булып эшләве түгел, ә ышанычлы коммунист булуы аны бирегә китергән. Яңа производство, иске белгечләр — монда инде, һичшиксез, коммунист күзе, коммунист кулы кирәк була.

Ләкин Василий Иванович, авыру сәбәпле, үзенә бик ныгытып ярдәмче сорый башлый. Татар булсын ди (чөнки безнең цехта күпчелек татарлар), укыганрак, аңлырак кеше табарга куша. Шулай итеп мине, моңарчы мех дигән нәрсәне иснәп тә карамаган яшь егетне, бугаять тыйнак, ипле-сабыр агайга ярдәмче итеп куялар.

Мех эшен әкренләп өйрәнер, анысы качмас, ә хәзер җитәкчелекне ныгытырга кирәк дип уйлаганнардыр инде. Чынлап та мактанып әйтүем булмасын, Васильев өчен мин бик кулай ярдәмче булып чыктым. Иң элек аның бер дә яратмаган, кая әләксә шунда тыгып йөрткән яки кечкенә өстәлендә чәчелеп яткан язу эшләре — төрле рапортлары, докладнойлары, нарядлары — барысы да миңа күчте. Шулай итеп мин аңа бик әйбәт писарь булдым. Аннары фабрикадан кайткан мехларны вакытында цехка китерү, сортланып эшләре беткәнне тизрәк цехтан озату да минем өскә төшә башлады. Гомумән һәртөрле йөгерү-чабу белән бәйләнгән эшләргә Васильев агай гел мине җигә торган булды. Шуның өстенә тагын тәнәфес вакытларында беседалар үткәрү, газеталар уку кебек агарту эшләрен дә ул тизрәк миңа йөкләде. Мин, билгеле, боларның барысын да рәхәтләнеп үтим, чөнки мин яшь, мин яңа кеше, аннары Васильев агай да гадәтенчә боерык биреп түгел, ә арган, йончыган кеше сыман үз итеп кенә: «Давай, брат, син генә эшлә инде» дип куша торган иде.

Тагын шуны да әйтергә кирәк, аның үзен көн дә диярлек һәр төрле утырышларга — я управляющийга, я бюрога, я фабкомга чакырып кына торалар. Кайчагында көннең яртысын ул шуларда утырып уздыра. Ул югында инде мин цехта баш кеше булып калам, бөтен эшкә һәм бөтен кешегә күз-колак булып торам... Менә минем ярдәмчелек вазифам

асылда шулардан гыйбарәт иде. Күргәнеңчә, әллә ни катлаулы, кыен эш түгел, һәм мин аларның барысына да бик тиз өйрәнеп, күнегеп киттем.

* * *

Начальник ярдәмчесе булгач, мин тиз арада мехбазаның югары җитәкчеләрен дә күреп, белеп өлгердем. Цехтан үткәндә алар туктап сорашып киткәләр, я булмаса чакырып алып, берәр боерык бирәләр, кайчак исә управляющий кабинетына утырышка-фәләнгә дә чакыралар. Әйтергә кирәк, аның кабинетына кереп, утырып чыгу бу минем өчен үземә күрә бер дәрәҗә иде. Калын, гөмбәз аяклы, яшел постаулы зур өстәл торган биек, якты кабинеттан мин ничектер үсеп киткәндәй булып, хәтта бераз горурлана да төшеп чыга идем.

Кабинетның хуҗасы, ягъни мехбаза управляющие, Решевский дигән кеше иде. Юлий Давидович Решевский... Башта мин аны поляк түгелме икән дип уйлаган идем, ләкин поляк булып чыкмады ул... Хәер, хикмәт анда түгел. Нинди генә милләттән булмасын, әмма ул үзенә бер гаҗәеп оригиналь кеше иде. Аны Казан мехбазасына управляющий итеп Мәскәү җибәргән. Бирегә килгәнче ул «Главпушнина»да зур урында эшләгән һәм чит илләргә дә чыгып йөргән диләр... Һәм моңа бер дә икеләнмичә ышанырга була: бөтен кыяфәте, килеш-килбәте, өс-башы аның чит илләр белән эш итүче югары белгечләр арасында кайнаган, шуларның купшылыгын һәм бәйсезлеген отып алган, коеп куйган интеллигент бер кеше булуын әйтеп тора иде... Кечкенә җыйнак гәүдәле, нәфис ак чырайлы, салкын соры күзле, бармаклары да кызларныкыдай нечкә-озын, җитмәсә, шул бармакларның берсендә бриллиант кашлы алтын йөзек тә уйнаклап тора. Ә бит ул заманда алтын йөзек кияр өчен чыннан да бик бәйсез кеше булырга кирәк иде... Кием-салымын инде әйткән дә юк: безнең Казан кышына үч иткәндәй ул бик затлы тегелгән кыска драп пальтодан, калын кепкадан, сары штиблетлардан, тик муенына эре шакмаклы мамык шарф кына урап йөри торган иде.

Мин аңа бик кызыксынып, хәтта беркадәр сокланып та карый идем. Мех эшендә аны зур белгеч диләр, чит ил фирмалары белән эш итүче оста коммерсант диләр. Ә бит ул шактый яшь әле, утыз бишләр тирәсендә генә булыр. Кай арада үскән, кай арада бу дәрәҗәгә ирешкән диген! Күрәсең, бик башлы кеше, сәләтле кеше... Аннары Мәскәүдә аның зур элемтәсе, зур таянычы да булырга тиеш. Һәм моны барысы да беләләр дә иде шикелле... (Җәяләр эчендә генә тагын шуны да әйтим: ул Шетинкин гостиницасында ике бүлмәле номер алып, шунда ялгызы гына тора иде. Семьясы Мәскәүдә — бер айны үзе кайтса, икенче айда хатыны килеп, торып китә икән. Күргән кешеләр, аның хатынын да гаҗәп сылу, матур һәм искиткеч шәп киенгән бер асыл сөяк дама дип сөйлиләр.)

Решевскийның иң беренче кайгысы — мехларны мөмкин кадәр экспортка күбрәк чыгару иде. Еш кына ул безгә: «Онытмагыз, илгә валюта кирәк, барысыннан элек валюта өчен эшләргә тиешсез!» дип әйтә торган иде. Аның бу хакта үзенә чакырып сөйләшкән, киңәшкән кешеләре дә күбрәк әлеге белгеч мишәрләр була торган иде. Шуларга таяна, шулардан таләп итә... Мехбазаның башка төр эшчеләре белән аның алыш-биреше аз иде. Инде коллектив тормышына килгәндә, ул бу турыда кайгыртуны тулысынча партия, профсоюз җитәкчеләренә тапшырган иде.

Һәм бу урында мехбазаның тагын бер җитәкче кешесе — партоешма секретаре (бер үк вакытта кадрлар бүлегенең мөдире) турында да әйтеп китәргә тиешмен. Бу — Перов Федор Николаевич — урта яшь-

ләрдәге кеше. Йөзе чиста-матур, ләкин чәчләренә чал керә башлаган инде, күз төпләре дә йончыган кешенекедәй шешенке, ә күзләре менә бик тере, ничектер өстән генә капшап узгандай җитез карыйлар. Гомумән аның кыяфәте гел шулай ике төрлерәк тәэсир калдыра торган иде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр, белмим, тик күрә башлагач, мин бер нәрсәгә игътибар иттем: ул һәрвакытта Решевский янында була — пәкъ менә командир янындагы комиссар сыман. Управляющий кабинетында үткәрелгән утырышларның берсеннән дә калмый, сүзгә аз катнаша, күбрәк тыңлап кына утыра. Аның каравы, гомуми җыелышларда ул күп сөйли һәм, әйтергә кирәк, бик кайнар сөйли... Һәркөнне газеталарда язылып барган политик мәсьәләләр белән аның яхшы таныш булуы күренеп тора, һәм шуны ул тыңлаучыларга бик оста җиткерә дә белә.

Цехка кергәндә дә ул култык астына бер кочак газета кыстырып йөри, шулардан берәрсен цех начальнигына яки аның ярдәмчесенә тәнәфес вакытында кычкырып укыр өчен биреп калдыра. Мине дә ул бу эшкә бик тиз җикте. Беренче танышкач та:

— Менә бик яхшы, безгә сезнең кебек грамотный егетләр кирәк тә,— диде үзенең әз генә нечкәрәк тавышы белән.— Монда халык яңа, бик чуар, пропаганда эше беренче чиратта торырга тиеш. Ә Василий Иванович үзе — авыру кеше, аннары грамотасы да чамалырак, так что бу эш сезнең өстә, кем, иптәш Юлдашевмы әле?..

— Әйе, Юлдашев.

— Менә шулай, иптәш Юлдашев... Ә нәрсә укырга кирәклеген мин үзем сезгә күрсәтеп бирермен.

Һәм шулай итә дә торган иде. Мин дә аның күрсәтеп биргәннәрен цехта укып чыгарга тырыша идем (болар күбрәк бишьеллыкны үтәүгә, колхоз төзүгә, корткычларны, сыйнфый дошманнарны фаш итүгә багышланган материаллар була торган иде), шуның өстенә, әгәр вакыт җитсә, чит ил материалларын да укымыйча калдырмыйм, чөнки бу тема тыңлаучыларны һәрвакытта кызыксындыра торган иде.

Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен тиз генә белү бик читен. Минем үземә парторг Перов гомумән ошый иде, ләкин менә безнең Василий Иванович аны ни өчендер бик үк өнәп бетерми... Бер-ике мәртәбә мин аңардан: «Ялтырарга ярата бу кеше!» дигән сүзне дә ишеткәләдем. Башта моңа гаҗәпләндем, аннары аңлаган кебек тә булдым: Василий агай үзе аз сүзле, тыйнак кеше булгач, тегенең, кешеләрдән читтәрәк һәм өстәрәк торып дигәндәй, күп сөйләргә яратуын ошатмый иде, күрәсең.

Кыскасы, безнең мехбазаның ике җитәкчесе — управляющие белән парторгы — әнә шундый, берсе үз-үзенә бик нык ышанган, бик тәкәллефле — горур, икенчесе — шактый шома телле, тынгысыз, өлгер кешеләр иде.

* * *

Смена башланып, цехтагы эшләр бетә төшкәч, мин үзем дә өйрәнчеккә әйләнеп, каракул сортлау өчен киң, озын өстәл янына баса идем. Минем өйрәтүчем Әмин әкә Маматов. Нишләптер мин аңа «әкә» дип дәшәргә өйрәнеп киттем. Ул үзбәк түгел, үзбәккә охшаган җире дә юк, чыкылдап торган мишәр. Ләкин мин үзем Үзбәкстанда бераз яшәгән кеше, ә анда үзеңнән олы кешегә аеруча хөрмәт йөзеннән «әкә», «әкә җан» дип дәшәләр. Менә мин дә, шул гадәт буенча, үземнең остама «абзый» диясе урында «әкә» дип дәшә башладым. Бу ничектер бик табигый килеп чыкты, хәтта миңа ияреп бүтәннәр дә аңа шулай дәшә торган булып киттеләр. Ул үзе дә моны бик тыныч, бик табигый кабул итте.

Әмин әкә бик таза гәүдәле, кызыл чырайлы, аю сыман алпан-тилпән атлап, ашыкмыйча гына йөри торган бер кеше иде. Ләкин гаҗәп шат күңелле, уен-көлке ярата торган кеше, кызыл чыраеннан бервакытта да елмаю төшми, һәм юк кына кызыктан да балаларча рәхәтләнеп, корсагын селкетә-селкетә көлеп җибәрә иде. Аннары җыр дигәндә үлә дә китә торган иде; ул үзе бер көй, бер авыз җыр белми, әмма инде кеше җырлаганны эреп, чөчеп дигәндәй көне буе тыңларга да әзер. Күршесендә өйрәнчек булып эшләүче Бибинур исемле кызны да ул һаман: «Канатым, яле бер сәк кенә, ваты минем өчен генә «Алиябану»ны күләп ал!» дип кыстап кына тора. Кыскасы, беренче караштa Әмин әкәне чынлап кайгыра да, борчыла да, хәтта кәефсезләнә дә белмәгән гаҗәп ваемсыз, пошамансыз бер кеше диярсең!.. Һәм шушы кеше, әйткәнемчә, безнең мехбазаның иң зур белгече иде. Баш белгеч. Мәсәлән, үзе кебек оста белгечләр тарафыннан экспортка әзерләнгән каракүлләрне ул, управляющий белән «Главпушнина» вәкиле алдында, яңадан бер карап уздыра, һәм аның кулыннан узган мехларның берсе дә инде кире әйләнеп кайтмый иде.

Аның янында эшли башлагач, мин башта бик аптырый идем: өстәлдә өелеп яткан каракүлләр минем өчен барысы да бер төсле, ничек итеп аларны бер-берсеннән аерырга — һич акылым җитми иде. Ә ул шул каракүлләрне, бизәкләренә карап, уналты, унсигез төрләгә аерып сала да һәркайсының ишен табып, өсти генә бара. Бик нечкә эш бу... Каракүлдәге бизәк шәкелләрен, бердән, аера, икенчедән, ишен таба белү өчен, ничек дим, рәссам күзе кирәк. Әмин әкәдә нәкъ менә шундый күзләр булган инде, күрәсең!..

Мишәр абзыйларның бөтәннәрен баштарак мин аерып бетә алмыйча йөрдем. Аларның кайсысы Ариф абзый да кайсысы Алим абзый — аптырабрак калгалый идем... Ничектер яшьләре белән дә, буй-сыннары, хәтта характерлары белән дә алар барысы да бер төслерәк иде. Барысы да диярлек кырык-кырык биш ләр тирәсендә, эре-тазалар, басынкы-салмаклар... Биредә шуны да әйтеп китәргә кирәк, минем элегрәк мишәргә карашым ни сәбәптәндер бик үк шәптән түгел иде. Ләкин бергә эшли башлагач, бу карашның никадәр хата булуын бик тиз аңладым. Яман белән яхшы һәр миллаттә, һәр кабиләдә була ул, бер яклы гына хөкем итү һич тә ярамый икән... Минем янымдагы мишәрләр исә барысы да диярлек бик әйбәт кешеләр иде. Ничектер менә бөтенесенә дә бер үк дәрәҗәдә хас булган тыйнаклык һәм әдәплелек бар иде аларда. Үзләренең шул каты телләре белән йомшак кына сөйләшәләр, берәүгә дә тупас кагылмыйлар, бервакытта да кычкырышмыйлар, киресенчә, бер-берсенә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торалар. Гомумән бик бердәм халык. Ихтимал, бу кадәресе аларның гел читтә, читләр арасында эшләп йөрергә мәҗбүр булуларыннан килә торгандыр инде.

Мишәрләр гадәттә бик әче, бик әшәке итеп сүгенергә яраталар дип ишеткәнем бар иде, ләкин минем бу дәдәйләремдә андый нәрсәнең эзе дә юк иде. Тик кәефләре бик кырылган чакта гына «явыл», «сатана», «брамат» дип кенә җибәргәлиләр иде. Олы кешеләр, алама сүзгә өйрәнмәгәннәр.

Эшкә килгәндә алар бик дисциплиналы халык, бик гаделләр, бик күндәмнәр, сменага һәрвакыт яшьләрдән алда киләләр һәм звонок булганын да көтмичә, аерылып торган китапларына тотынган шикелле, тизрәк каракүлләренә ябышалар иде. Эшләрен бик яраталар, һәм безне дә чын ихластан өйрәтергә тырышалар иде.

...Мишәрләрдән бер коммунист та бар иде. Вафа Янбулатов. Утнысуны кичкән, бик үткен, бик башлы егет... Алдарак күргәнсеңдер, ул минем бүлмәдә бер ай ярым чамасы торып та киткән иде. Ләкин Вафа үзенең үткәне белән дә һәм хәзерге вакыттагы эше белән дә бездәге мишәрләрдән шактый аерылып тора иде. Ул барысыннан да яшь, Кызыл

Армиядә хезмәт иткән, Урта Азиядә басмачыларга каршы сугышып йөргән һәм шунда партиягә дә кергән булса кирәк. Аннары бездәге мишәрләрнең күпчелеге әзер мехта (мехбазаның үзендә) эшләсәләр, Вафа Плотәндәге чи тиреләр складының мөдире булып эшли иде. Шуна күрә аңа үз токымнары белән артык аралашып йөрергә туры да килми иде...

Мишәрләр турында тагын нәрсә әйтәсем калды?.. Алар ике-өчесе бергә, Суконныйдагы берәр апаның бүлмәсенә кереп, шунда үзләре чиратлашып пешергән уртак казаннан ашап, эшкә йөрүдән башканы белмичә тыйнак кына торып яталар. (Җәяләр эчендә генә әйтим, алар мишәрчә, итне бик мул салып, ашны бик тәмле пешерә торганнар иде...) Барысының да диярлек семьялары Рәзән-Касыйм тирәсендәге авылларда,— болар алган хезмәт хакларының күп өлешен шул семьяларына җибәреп торалар. Элек-электән үк ул шулай килгән инде: үзләре каядыр читтә, еракта эшләп яки алыш-биреш итеп йөргәннәр, ә хатыннары, бала-чагалары белән, болардан килгән акчага үз авылларында тук, тыныч кына яши биргәннәр. Йорт-җирләре, сизүемчә, таза-бай булырга тиеш.

Ләкин соңгы бер ел эчендә авылда зур вакыйгалар башланып китте: анда колхозлашу бара, җирләрне, малларны кушалар, кулакларны бетерәләр, көрәш гаять кискенләшкән, төрле шомлы хәбәрләр йөри. Бу хәбәрләр безнең мишәр абзыйларны да куркуга салган иде. Үзләре производствода эшләүче булсалар да, алар, табигый, авылдагы семьялары, йорт-җирләре өчен борчылалар, уйланалар, эчләреннән генә кайгыралар иде. Күрәсең, авылда купкан өермә кайберләренең семьяларына да кагыла башлагандыр,— күбесе мехбазада эшләүләре турында белешмә алып, үзләренең авыл советларына җибәрделәр. Ләкин борчыларын тыштан сиздермиләр, күп сөйләнмиләр, хәтта авыл хәлләре турында бик төпченеп сорашудан да тыелалар.

Бездә эштән соң еш кына төрле җыелышлар була торган иде. Мишәрләргә бер әйтү житә, барысы да түбәндәге зур контора бүлмәсенә бөтенесеннән алда диярлек төшеп, озын эскәмияләргә күгәрченнәр шикелле тезелешеп утыралар. Тыгызлыктан тирләп-пешеп бетсәләр дә, кузгалмыйлар, чыгып йөрмиләр, кыскасы, өйләренә ут капса да, җыелыш ташлап китү юк. Ә җыелыш озакка сузыла, ялкынлы сүзләр күп була,— сүзләр дә күбрәк зур мәсьәләләр, ягъни чорыбызның бөеклеге, илдә бөтен фронт буйлап капитализм калдыкларына һөҗүм башлануы, сыйнфый көрәшнең кискенләшүе, һәр җирдә уяу булырга кирәклеге турында бара. Һәм моны башлыча ни өчендер әлеге шул иске белгечләргә — сакаллы мишәрләргә карап сөйлиләр иде кебек... Белмим, бу сүзләр мишәр абзыйларда ниләр уяткандыр — әйтүе читен, чөнки алар бер вакытта да сорау-фәлән бирмиләр, чыгып сөйләмиләр, бары тик бик игътибар белән тыңлап кына утыра торганнар иде.

Әйе, мишәрләргә ышанып бетмиләр иде. Һәм алар үзләре дә моны сизәләр иде шикелле. Шунадыр инде бик тыйнак булырга, гадел эшләргә, сак сөйләшергә тырышалар иде. Ләкин бу гына җитми иде, ахрысы. Эчләрендә ни, заманга ничек карыйлар, хәзерге үзгәрешләрне кабул итәрләрме, юкмы — менә нәрсә шикләндерә, менә нәрсәне белəселәре килә. Кайберәүләр фикеренчә, алар — иске белгечләр, капиталга хезмәт иткәннәр, хосуси милекчелек белән агуланганнар, бай яшәгәннәр, кыскасы, безнең заманга күпмедер дәрәҗәдә ят кешеләр. Бәс, шулай булгач, аларга карата һәрвакытта уяу булырга кирәк.

Билгеле, мин дә уяулык кирәктер шул дип уйлый идем, ләкин яхшымы-начармы бер гадәтем бар — кешегә һич сәбәпсездән ышанмыйча шикләнеп карый алмыйм, яратмыйм алай карауны. Кеше яхшы эшли, гадел эшли, бернинди кыек эше сизелми, берәүгә дә зарары тими, ә син тот та аның турында бу алама кеше булырга тиеш дип, анар-

дан шикләнеп, аны сагалап йөр, имеш. Юк, әллә ничек минә табигатем кабул итә алмый моны...

Уяулык күрсәтү җәһәтеннән бездә бик тырышып йөрүче Басыйр Рәҗәпов дигән бер шадра егет бар иде. Бездән бер катка түбән, пушнина цехында эшли... Моңарчы мин белгән шадралар барысы да ничектер бик сөйкемле, тыйнак була торганнар иде, ә бу, ничек кенә дип әйтергә, әллә нинди усал, зәһәр шадра иде. Үзе бик астыртын, һавалы, шуның белән бергә шәктый эрсез дә. Җитмәсә, өйрәнчек кенә булуына карамастан, ни сәбәптәндер, билгеле бер хөрлек белән дә файдалана, ягъни эш вакытында цехлар буйлап йөрергә ярата иде. Сынаганын бардыр инде, шадра кешеләр гадәттә бик төз-спай гәүдәле булалар. Бу да нәкъ шундый — нечкә гәүдәсен бик төз, ә башын ата каз шикелле текә тотып, еш кына безнең цехтан узгалый торган иде. Башта мишәрләр янында тукталып, аларның эшләрен карап тора, аны-моны сораштыра, аннары мине бер читкә экрен генә дәшеп ала.

— Я, эшләр ничек? — ди бу, серле генә итеп.

— Эшләр яхшы бара,— мин әйтәм.

— Яхшы микән соң?

— Ник яхшы булмасын. Мехларны, күпме керсә дә, сортлап кына торабыз, цехта озак яткырмыйбыз, вообщем, абзыйлар шәп эшлиләр.

— Эшләмичә хәлләре юк,— ди Басыйр, авыз кырые белән генә елмаеп.

— Ә алардан тагын ни кирәк? — дим мин, ачуым кила башлап.— Җырлап-биеп тә торсыннармы әллә?

Басыйр, кылыйрак күзләрен кыса төшеп, миңа бераз карап тора да әйтә:

— Алар өчен синең үзеңә биергә туры килмәсен, парин!

Мин дә аңа батырып карыйм:

— Сүзеңне ачык әйт, нәрсә болгатып маташасың.

Басыйр нишләптер кинәт кенә йомшарып китә:

— Я, я, мин уйнап кына... Син бит монда начальник кеше, үзебезнең кеше, вәт мин сиңа дусларча әйтәм: син ул мишәрләргә бик ышанып бетмә, күзеңне ачыбрак кара, беләсең хәзерге вакытны.

— Минем аларга ышанмаска хакым юк.

— Белмисең әле син бер нәрсә дә, белмисең,— ди бу сузып кына.

— Барысын да бик яхшы беләм, ләкин син, Рәҗәпов, кычытмаган җирне кашып йөрисең, менә шул.

— Шулаймы?!. Ярый, без моны син әйткәнчә теркәп куйыйк. Соңыннан кемнеке кычыта башлар, күрербез.

Минем аңа отыры саруым кайный, кырт кисеп кенә үзенә: «Бар, кит моннан...» дип әйтәсем килә, ләкин ул шуны үзе үк сизгәндәй китәргә ашыга һәм, ике арадагы күперне сакларга теләгәндәй, иптәшләрчә генә әйтеп китә:

— Вообщем, бүдәнә сугыштырмыйк әле без, парин, син миңа, мин сиңа кирәк булырбыз. Ә пока!

Баштарак аның миңа шулай каты гына бәрелүе берничә тапкыр кабатланды. Ләкин минем бер дә курыкмыйча нык торуымны күргәч, егет шактый йомшарды. Хәтта дуслык та күрсәтә башлады. Яхшы атланып, үз итеп, минем бүлмәгә дә килгәләп йөрде. Ашап-эчеп утырган чаклар да булды. Билгеле, мин дә аңа кырын тормадым. Бергә эшләгән иптәш үзе теләп якыная икән, нигә аннардан качарга яки нигә аны читкә тибәрергә?.. Яшьлек, үзең беләсең, читләшүдән бигрәк якынаерга, дуслашырга ярата. Аннары аның белән бергә утыру да күңелле булып кала торган иде. Ул чыкылдап торган Казан егете, сүзгә бик җор, өзеп-чатнатып әйтә белә, һәм ингыравык тавыш белән матур гына җырлый да. Шушы яклары өчен булса кирәк, мин ача шактый

иялэшеп тэ киткэн идем. Эмма шулай да чын ихлас дуслык безнең арада урнаша алмады. Нигэдер минэ күнел дигэнең ышанып бетми иде бу кешегэ, һэм тикмэгэ генэ булмаган икэн ул.

* * *

Югарыда эйткэнемчэ, безнең цехта элеге каракүлче мишэрлэрдэн башка, шуларга өйрэнчек итеп куелган күп кенэ яшьлэр эшли иде. Э аларның яртысы диярлек кызлар иде. Минэ шул кызларның берсе белэн... Хэер, бу хакта сүз башлаганчы, мин үз хэлем турында эйтеп бетерим эле.

Цехтагы яшьлэр арасында мин яшькэ дэ олырак, уку-белем ягыннан да өстенрэк идем. Шуның белэн бергэ цех начальнигының ярдэмчесе дэ. Э бу нэрсэ инде мине башкалардан аерыбрак куя, миңа инде начальник итебрэк карыйлар. Минем кечкенэ генэ булса да властем бар, бүтэннэргэ куша, боера алам, зур гына хөрлек белэн дэ файдаланам — йөрим, карыйм, тикшерэм. Кешелэр миңа йомышлары, зарлары, үтенечлэре белэн килэлэр... Цех начальнигына эйтэсе сүзлэрен дэ күбрэк минем аша җиткерэлэр, чөнки Васильев агайның миңа ышанганын күреп торалар.

Карт белгечлэр белэн дэ, яшьлэр белэн дэ минем арам гомумэн яхшы иде. Яшьлэр өчен мин — үз тиңнэре кебек үк диярлек була, э мишэрлэр миңа «үзебезнең татар малае» дип карыйлар иде. Элбэттэ, мин моның белэн барына да бертигез ошый идем, барысы да миннэн бик канэгать иде дип эйтергэ җыенмыйм. Бервакытта да алай булмый ул. Эчлэреннэн көнлэшүчелэр дэ, яратып бетермэүчелэр дэ булгандыр, һичшиксез, булгандыр... Моңа бер дэ искитэргэ ярамый — коллективта бит кырык төрле кеше. Мин үзем дэ һэркемгэ бер үк дэрэҗэдэ ошарга, ярарга тырышмый идем,— тырышсаң да ничектер булдырып булмый аны... Тик шуны гына эйтэсем килэ, цехта эшлэгэндэ миңа берэү белэн дэ дошманлашырга, ачыктан-ачык бэрелешергэ туры килмэде.

Инде хэзер яңадан тегє кызларга кайтыйк. Эйе, безнең цехта кызлар күп иде. Һэм озак та үтми, шул кызлар арасыннан берсенең миңа шактый игътибар итүен сизэ башладым. Минем буем-сыныммы, укыган егет булуыммы, эллэ начальник кеше булып йөрүемме кызның күңелен җэлеп иткэндер инде, белмим, эмма ул миңа очраганда күзлэрен тутырып, озаграк итеп карый иде, янына килеп сөйлэшкэндэ дэ күзлэремэ туры карарга тырышып, сөйкемле елмаеп һэм бик телэп сөйлэшэ торган иде. Хэтта яныннан китеп баргач та мин аның артымнан карап калуын сизэ идем. Бу бит башка берэүгэ дэ түгел, э миңа гына! Һэм мин моны тоймыйча, моңардан беркадэр исереп китмичэ кала алмый идем. Һэм, билгеле, минем дэ аңа игътибарым көннэн-көн экренлэп көчэя бара иде. Ул кыз Ариф абзый Байтирэковта өйрэнчек булып эшли. Исеме аның Хафаза иде.

Моңарчы кызлар белэн танышып, яратышып йөрүдэ минем тэҗрибэм бик аз иде эле. Укыганда, үзең белэсең, кыен эш ул. Дөрес, эле берэү, эле икенче белэн дигэндэй мавыгып киткэн вакытларым булгалады. Озата барулар да, капка төбендэ суыктан таптанып торулар да, көчлэп кочарга, үбэргэ азапланулар да булмады түгел, булды. Лэкин эш тиз сүтелэ торган иде. Элеге шул студент хэерчелеге,— өс-баш хөрти, кесэдэ акча юк, акча булмагач, кызыңны телэгэн җиргэ илтеп тэ, күпмеазмы сыйлап та булмый, шуннан тотасың да кулыңны селтисең! Боерган булса, укып бетергэч боларның барысының да үчен алырмын эле дип үз-үзеңне юаткан буласың. Шулай ул ярлы студент хэле — мэхэббэтен дэ, бэхетен дэ кичектереп торырга мэҗбүр.

Әмма хәзер минем хәл башка инде. Акча бар, аерым бүлмәм дә бар, һәм, иң мөһиме, еллар буенча буылып, тынгылык бирмичә килгән мәхәббәткә көчле сусау да бар. Кемнедер ярата башларга вакыт иде, кирәк иде. Ләкин... ләкин шулай да мин бу Хафаза туташка егылып китүдән баштарак тыелып маташкан булдым. Ул өйрәнчек кенә, ә мин, ни әйтсәң дә, начальнигрәк кеше, үзенә күпмедер буйсынган кыз белән роман башлау килешмәс, ярамас дигән уй мине тотыбрак торды. Андый нәрсәне бик тиз сизеп алалар, сүз китәчәк, берәр күңелсез эш килеп чыгуы да мөмкин. Аннары тагын кызның миңа туфырып караулары, елмаеп сөйләшүләре минем башымны әйләндерсә дә, мин аңа карата үземнең чын хисләремне ачык кына белми идем әле. Нәрсә бу, кыз үзе миңа шулай йөзен борганга күрә генә туган хисләнүме, әллә чын яратуның туа башлавымы? Һәрхәлдә, беренче караштан ук түгел.

* * *

Кызны сиңа ничек кенә сурәтләп күрсәтергә?.. Дөресен генә әйткәндә, аның ул хәтле һуштан егарлык матурлыгы да юк кебек иде. Буйга кечкенә, аяклары да бик үк туры-спай түгел, йөргәндә — әз генә чайкалыбрак йөри, кыскасы, буе-сыны белән ике бистә арасында үскән кызларга бик охшаган иде. Ә син беләсең инде, Казанның бу начар, сасы һавалы жирендә үскән кызлар арасыннан чын сылулар сирәк очрый... Әмма мине сихерләгән гүзәллеге аның йөзендә, йөзеннән дә бигрәк күзләрендә иде.

...Ничек кенә итеп язсам да, сурәтләп бирә алмам кебек... Болай: йөзе аның түгәрәк, бит урталары әз генә чокыраеп тора, елмайганда энжедәй вак кына тигез тешләре ачыла һәм бит чокырлары тирәнәеп китә; маңгае чиста — ак, ә кашлары нечкә — кара; борыны кыска, җәенкерәк, ә иреннәре яңа гына ачылган иртәнге чәчәктәй кечкенә, йомшак, тәмле-сусыл кебек... Һәм, ниһаять, күзләре... озынчарак зур күзләре — ничек кенә дип әйтим — антрацит күмердәй чем-кара иде. Ләкин хикмәт анда гына да түгел. Хафазаның ул күзләре һәрвакыт диярлек юка гына дым пәрдәсе белән өретелгән була иде, һәм бу дым пәрдәсе аларны, бер карасаң, ерак-томанлы итеп күрсәтә, ә икенче карасаң, ничектер юып алгандай, ачыкландырып-яктыртып җибәрә иде. Әйе, хикмәтле күзләр!

Һәм менә шул кечкенә буйлы, йомры гына кызый үзенең ходай биргән сихри күзләре белән цехтагы барлык кызлар арасында диярлек иң чибәрләрдән санала иде. Бигрәк тә безнең мишәр абзыйлар аңа мөкиббән китеп гашыйк булганнар иде. Сөеп карыйлар, сөеп кенә дәшәләр, ике сүзнең берендә: «Хафаза, якты күзем!», «Хафаза, ак канатым!» дип кенә торалар. Билгеле, алар бервакытта да әдәп киртәсеннән чыкмыйлар, андый-мондый нәрсә сиздермиләр, бары гаҗәеп бер гөлгә карагандай, аңа сокланууларын яшерә алмыйлар. Әйтергә кирәк, Хафаза да үз бәясен яхшы белә иде. Шаркылдап көлми, чытлыкланмый, сырпаланмый, тик кызларга кирәк кадәр генә үзен азрак һавалы, азрак кына иркә-назлы итеп тота... Шуңадыр инде мишәрләр Хафазаны акыллы кызга саныйлар иде.

...Баштарак мин, әйткәнемчә, сагаеп һәм сакланыбрак маташтым. Ләкин сизәм, керә... керә кызый әкренләп йөрәккә... Берни эшләр хәл юк, һәркөнне сигез сәгать без бер цехта, һәркөнне мин аның яшерен генә дәшеп караган дымлы-якты күзләрен очратам, һәркөнне энҗедәй тешләрен күрсәтеп, елмаеп кына әйткән сүзләрен ишетәм. Мин аның кечкенә буен, кыска аякларын күрми башлыйм, ә йөзе-күзе, сөйкемле елмаюы бөтен бер кыяфәтенә әверелеп, минем хыялымнан чыкмый башлый. Мин инде аны көтеп алам, цехка килеп кергәнен күрмәсәм дә,

сизәм һәм ялгышмыйм. Әгәр дә авырып-интеп эшкә килми калса, мин аны бик юксынам, борчылам, тынычлыгымны югалтам. Алай гына да түгел, мин Хафазаның үзенең дә шундыйрак хәл кичерүен — мине күрергә теләвен, мине эзләвен, мин булсам аңа да яхшы, булмасам — аңа да күңелсез булуын тоеп торам. Шулай итеп, безнең йөрәкләр арасында ниндидер бер бик нечкә, әмма бик нык җеп сузылды. Без инде әкренләп, бер-беребезнең серен укый алган кешеләргә әйләндек... Бу хәл вакыт-вакыт мине һаман әле борчып куйгалый иде, әмма моңа, бу хәлгә, каршы тору мөмкин түгел иде инде.

Менә шулай, дус кеше!.. Килде мәхәббәт, миңа да килде. Ни әйтим? Бәлки, өстәп, тагын шуны әйтәсе калгандыр: мәхәббәтнең килүе төрлечә булырга мөмкин — беренче караштан, әкренләп йөри торгач, ләкин дә аның тагын бер этәргече бар икән, бу — кеше сүзе, кеше димләве... Ышанасыңмы шуңа? Әлбәттә, кеше димләве белән генә чын мәхәббәт бервакытта да туа алмый, әмма шулай да йөрәккә төшкән чаткыны көйрәтеп, көчәйтеп җибәрергә кеше сүзе җитә кала. Әлеге мишәр абзыйлар, индер сизенеп булса кирәк, Хафазаны миңа үтереп мактый башладылар: мировой кыз — акыллы, әдәпле, инсафлы, сөйкемле, чибәр, матур, роза, ласточка, шикәр, бал — тагын әллә ниләр. Кыскасы, бер сандык хәзинә! Мин ни... кызарам, җилкәне кашыган булам, ә үзем әйе дим инде, телдән әйтмәсәм дә күңелемнән гел әйе дип кенә торам, Хафаза бит ул!.. Һәрбер тиле гашыйк төсле мин дә Хафазамны бары яхшы итеп кенә, пакь итеп кенә, гүзәл итеп кенә күрәм. Җитмәсә әле, кешеләр дә аны әнә шундый итеп күрәләр икән. Я, иңгә кунган асыл кош түгелмени ул!!

Алга йөгеребрәк булса да тагын шуны әйтим: Хафаза белән без күз карашып, сынашып йөрүдән узып, инде артык яшеренмичә шактый якынаеп йөри башлагач, шул ук мишәр абзыйлар моны бик тиз күреп алдылар һәм кызны миңа чынлап торып димләргә дә тотындылар. Бу җәһәттән бигрәк тә Әмин әкә мине яман кысрыклый башлады. Бер генә түгел, әллә ничә тапкыр бу миннән тота да сорый:

— Син, кәбәм, үләнмәгән егетме?

— Үләнмәгән егет,— мин әйтәм.

— Соң шулай булгач, ник авызыңны ачып йөрисең?

— Аңламыйм, Әмин әкә!

— Аңламыйсың?.. Мин сиңа, Хафазаны ычкындырма, дип атәм. Үлән шуңа, үлән!

— Ә ник мин аңа үләнергә тиеш әле? — дигән булам инде мин.

— Их, брамат,— ди Әмин әкә, ботын чабып.— Шундый кызга да үләнмәгәч, сине кем дип кенә әтергә?! Үзе красавица, үзе умница, андыйны вет син, парин, көндез чыра яндырып та таба алмыйсың. Үлән, ычкындырма, акылың булса!

— Ычкындырма, ычкындырма!.. Әйтерсең, эш миннән генә тора... Хафаза үзе ни уйлыйдыр бит әле.

— Ә син анысы өчен хафаланма. Үзебез аның белән сүләшербез. Күр дә тор, ике куллап риза булыр... Без вет сизәбез.

— Белмим шул,— дим мин, бу юлы җилкәне чынлабрак кашып.

— Беләсе юк, рисковать кирәк. Туеңны да үзебез кутәрешербез. Мин инде монда үзебезнең братлар белән сүләшкәләдем...

— Рәхмәт, Әмин әкә, рәхмәт!..

Хәер, чын күңелдән рәхмәт әйтсәм дә мин мондый сөйләшүләрне баштарак уенга гына алган идем. Ләкин күрәм, мишәрләрем минем белән уйнап кына сөйләшмиләр. Хәтта бервакыт Әмин әкә миңа мондыйрак нәрсә дә әйтеп ташлады: әгәр синдә Хафазага өйләнү теләге булмаса, кызның башын юкка әйләндереп йөрмә, үзебез бүтән яхшы кеше табабыз — әнә Арифның Касыймда житкән улы бар, чакырып китерәбез дә шуңа сватать итәбез, янәсе.

Бу инде ультиматумга охшый иде. Гаҗәп, безне болар көчләп диярлек өйләндерергә тырышалар! Ни өчен?.. Чынлап та ни өчен?.. Озак та үтми моның сере ачылды: алар фикеренчә, әгәр мин өйләнмәсәм, Хафаза кебек шундый әйбәт кызның әллә нинди юньсез кешегә эләгеп куюы бар,— менә нәрсә аларны бик борчый икән! Кызык... Яхшы ат белән яхшы кызны яман кулга җибәрмәү — бу татарның борыннан килгән гадәте булса кирәк.

Ә мин уйланам, көн-төн борчылып һәм сөенеп уйланам: шулай ук Хафаза минем өчен генә яратылган кыз микәнни, шулай ук язмыш безне мәхәббәт җепләре белән гомерлеккә бәйләп куяр микәнни?!

* * *

Әйе, Хафаза белән безнең дуслык көннән-көн көчәя, тирәнәя бара. Мин үзем кызлар белән йөреп шомарган егет түгел, ләкин аның кирәклеге дә сизелми, ничектер үзеннән-үзе бик табигый рәвештә без берберебезгә һаман якынаеп киләбез... Көн дә мин цехка иртәрәк килеп тегесен-монысын эшләп йөргән арада ишектән күземне алмыйча аны көтәм. Ул гадәттә башына эре кара чәчкәле кызыл яулык бәйләп, кулына бик кечкенә чемодан тотып эшкә килә иде. Күз кырыем белән генә күреп калсам да, мин аны шул яулыгыннан танып алам һәм аз гына тыелып торганнан соң янына барып, кечкенә йомшак кулын кысам: «Нихәл, кадерлем, килдеңме?» дим әкрен генә... Аның дымсу күзләре шунда ук яктырып китә, ал алмалары да алсуланып китә, ә үзе сөенеченнән бары тик башын гына кагып куя. Аннары якын тирәдәге кешеләрдән уңайсызлангандай: «Кара, минем каракүлләрем күп калмаган икән,— дигән була,— син, Хәбиб, миңа тизрәк яңаларын китерерсең, яме!..» Ә бераздан смена башлана... Мин аңардан өч өстәл аша гына эшлим, ләкин аның ягына еш карый алмыйм — каракүл игътибарны үзенә бик нык бәйли, әмма барыбер уем аңарда, аны тоеп эшлим... Нәкъ шушындый ук хәлне ул да кичерәдер кебек, күзләре каракүл бизәкләрендә булса да күңеле гел миндәдер кебек — мин моны да сизеп торам шикелле... Һәр сәгать саен биш минутлык тәнәфес булып ала. Егетләр, кайбер мишәр абзыйлар ишек төбендәге махсус урынга тәмәке тартырга китәләр, ә кызлар аякларын ял иттерер өчен өстәлләренә менеп утыралар. Мин ул вакытта тәмәке тартмый идем әле, шуңа күрә, әгәр Хафаза ялгыз гына калса, тизрәк аның янына барам, әгәр кызлар җыелып өлгерсә, шул тирәдәрәк утырган Әмин әкә яки Ариф абзый янына барып, сөйләшеп торган булам. Һаман бер нәрсә инде — ничек тә Хафазага якынрак буласым, аны күреп һәм аңа күренеп торасым килә.

Ләкин болай яшеренеп, тыелып маташуның мәгънәсе юк иде, әллә ничек уңайсыз да иде — барыбер күрәләр, беләләр. Без инде, смена беткәч, еш кына бергә кайтабыз, җыелышлар вакытында да гел генә бер тирәдәрәк утырырга тырышабыз... Аннары безнең һич ничек тә яшерергә мөмкин булмаган үзара мөнәсәбәтебез, күз карашларыбыз, сөйләшүләребез барысын да әйтеп, кычкырып тормыймыни?!. Юк, яшерену мөмкин түгел иде инде, һәм без, ниһаять, берәүдән дә качмый-яшеренми башладык.

Безнең мехбазадагы яшьләрнең күпчелеге татар кызлары, татар егетләре иде. Күбесе Казанның үзеннән... Алар арасында Хафазаны электән үк белүчеләр бар икән. Шуларның берсе — әлеге Басыйр булып чыкты. Ул еш кына Хафаза янына бара, бик үз кешедәй аның белән көлеп, сөйләшеп тора. Баштарак бу хәл минем эчемне пошыра иде. Көнләшү дип әйтмәс идем мин моны, чөнки хатынлы Басыйрның Хафазаны үзенә карата алуына күңелем һич ышанмый, ләкин шулай да аның кыз тирәсендә артык сырпалануы миңа ничектер шикле күренә

иде. Кыскасы, яратмый идем мин ул кешенең Хафаза тирәсендә чебен шикелле әйләнүен... Ахырда моның сәбәбен белер өчен туп-туры Хафазаның үзеннән сорарга булдым.

— Әйт әле, Хафаза,— дидем,— нишләп бу Басыйр бик еш синең яныңа килеп йөри? Берәр серегез бармы?

Соравым дорфарак чыкты, күрәсең, Хафаза миңа гаҗәпләнгәндәй бер карап куйды.

— Нигә алай дисең, Хәбиб? — диде ул, сузып кына.

— Просто беләсем килгән өчен генә,— дидем мин, уңайсызланыбрак.

— Без бит бер мәктәптә укыдык. Аннары кайчандыр бер үк урамда торган да идек. Күптәнге таныш, бары шул гына...

— Алай икән, мин моны белмәгән идем... Нәрсә, бер үк класста укыдыгызмы?

— Нишләп инде бер класста булсын, ул бит миннән күп олы... Мин беренче класска килгәндә, Басыйр әллә өченчедә, әллә дүртенчедә укый иде шунда. Бөтен шәрикләре арасында иң зур малай иде. Мин аны куып та җитә яздым — дүртенчегә күчкәндә, ул һаман бишенчедә утыра иде. Ләкин шуннан ары укымады, китте... Ул бүрек тегүче малае. Бер урамда торган чакта мин аның да бүрекләр күтәреп, базарга киткәнен күреп кала идем. Аннары без Акком астыннан Болак буена күчтек...

— Шуннан соң очрашмадыгызмы?

— Юк, очраштык... Бик кызык булды ул. Ике елмы, артыгракмы вакыт узгач, безнең мәктәпкә өр-яңа юнг-шторм кигән бер бик төз буйлы егет килде. Бу кем дип карасак, аптырап киттек: безнең Басыйр!.. Чәчләрен уртадан ерып, ике якка тарап җибәргән, биленә таянып кына сөйләшә — шадрасы булмаса, Басыйр дип тә белмәссең!.. Мин хәзер комсомолда эшлим, менә сезгә җыелыш үткәрергә килдем әле ди бу... Кызык!.. Бөтен кызлар, малайлар аны тыңлар өчен бер зур класска дөбердәшеп тулдык... Шәп сөйләгән иде шул чакта Басыйр. Ул бит начар укыса да, сүзгә бик оста малай иде. Комсомолның агымдагы бурычларын ярып кына салды безгә... Менә бит кеше ничек үзгәрә!..

Әйе, бу минем өчен дә кызык кына иде. Басыйрның кем икәнен, нинди юллар узганын тагы да ачыграк белә төштем. Хәер, аның начар укып та шәп сөйләүче булуына артык исем китмәде. Төрле кешедә төрле сәләт. Фәнгә теше үтмәгән, житди, тирән белемне сендерә алмаган, ләкин кеше сүзен, китап сүзен өстән генә эләктереп ала белгән шома телле егетләрне минем күргәнем бар иде инде. Андыйлар гадәттә көндәлек политика белән бик мавыгып китәләр һәм җәмагать эшендә яки комсомол эшендә кайчак бер ялтырап та алалар. Әмма аларның ялтырап узулары, минемчә, озакка бармый, чатыр-чотыр ут-төтен чәчрәткән фейерверк шикелле бик тиз сүнәләр.

Ләкин бу очракта мине бер нәрсә шактый гаҗәпләндерде: комсомолда эшләгән, хәтта мәктәпләргә барып, җыелышлар үткәреп йөргән егет ни өчен, ничек итеп хәзер безнең мехбазага гади өйрәнчек булып килеп эләгә?.. Сәбәбе нәрсәдә?.. Моны минем беләсем килде, һәм туры гына шуны Хафазадан сорадым.

— Нигә,— диде Хафаза, бик гади генә итеп.— Кеше гел бер урында гына эшләми бит инде.

— Анысы шулай, ләкин кеше үз теләге белән зур эштән кечкенә эшкә күчәме соң?.. Әллә комсомол аны безгә җибәргәнме?

— Мин ул кадәресен белмим. Юктыр, чөнки аның комсомол эшеннән китүенә шактый булды инде.

— Ә ни өчен китте соң ул? — дип сорадым мин.

Хафаза җавап бирергә аз гына икеләнеп торды — гүя аңа бу ту-

рыда сүз алып баруы кыен иде. Әмма мин сорагач, әйтмичә дә мөмкин түгел... Тотлыга биреп:

— Ни... Басыйр, дөресен генә әйткәндә, үзе китмәде, аны... чыгардылар,— диде ул, ниһаять.

— Ни өчен?

— Синең бик беләсең киләмени? — диде Хафаза, нигәдер борчылып.

Бу хәл миңа бик сәер тоелды. Хафазаның миннән яшерерлек нәрсәсе булырга мөмкинме?! Аптырадым, ни әйтергә дә белмәдем, ахырда коры гына: «Ихтыярың!» дип куйдым. Шушы сүз аңа җитә калды булса кирәк, ашыгып, хәтта ялваргандай:

— Син ачулана күрмә, бәгырем! — диде ул.— Басыйр бу хакта сиңа әйтмәскә кушкан иде, ләкин мин әйтәм, әйтәм... тик икe арада гына калсын, яме!

— Аңламыйм мин сине, Хафаза! — дидем мин, отыры гаҗәпләнеп.— Ни өчен мондый кисәтү?.. Әгәр сиңа кеше серен ачу кыен икән, зинһар, әйтмә! Моның өчен мин сиңа һич ачуланмаячакмын. Тик... миңа ышанмавың гына...

— Юк, ышанам, әйтмә! — диде ул, тизрәк минем сүземне бүлеп.— И җаным, сер диярлеге дә юк аның, күпләр беләләр дә инде аны... Тик син яңа кеше, шуның өчен генә Басыйрның белгертәсе килмәгәндер. Бик ямьсез нәрсә бит... Эш болай: Басыйр авылдан килгән яшь кенә бер кызны үзенә ала.. Өч ай да тормыйча бичараны куып җибәрә — янәсе, кызның атасымы, агасымы шунда...раскулачивать ителгән, имеш... Шуннан соң озак та үтми, тагын бер чибәр генә шәһәр кызына өйләнә... Күпмедер торгач, бусын да аерып җибәрмәкче була, ләкин бусы инде теге авыл кызы кебек җебегән булып чыкмый... Бара да әйтә. Шуннан тикшерү башлана. Комсомолда эшләгән кеше өчен бик начар, оят эш ич бу, көн дә хатын алыштыру... Дөрес, моның өчен Басыйрны комсомолдан ук чыгармыйлар чыгаруын, ләкин райкомнан куалар... Менә аның бөтен тарихы шул.

— Алай икән,— дидем мин, уйга калып, һәм янымда гаепле кеше сыман ничектер уңайсызланыбрак басып торган Хафазага беравык сүзсез генә карап тордым. Уйларым яктыдан түгел иде. Әнә нинди козгын әйләнә икән минем кечкенә Хафазам өстендә! Әмма ул үзе шуны сизәме?.. Куркамы ул шул козгыннан?.. Һәм гомумән шушы хәлдән соң Басыйр белән аның арасында нинди генә мөнәсәбәт булырга мөмкин?

— Әйт әле, сөеклем, Басыйрның ул эшләренә син үзең ничек карыйсың? — дип сорадым мин, ниһаять.

Хафаза чын ихластан үпкәләгән тавыш белән:

— Сорыйсың тагын! — диде.— Билгеле, бик начар карыйм. Япь-яшь кенә кызны алдау — бик зур кабахәтлек ич!

«Ә сине дә алдамасмы соң ул?» дип әйтәсем килде минем, ләкин тыелып калдым. Аның урынына:

— Син үзең Басыйрдан курыкмыйсыңмы? — дип сорадым.

Хафаза балаларча беркатлылык белән күзләрен зур ачып, сузып кына:

— Менә әкәмәт, нишләп мин анардан куркыйм,— диде.— Нишләтә ала ул мине?.. Син дә инде...

— Юк, шулай да?

— Нәрсә шулай да?

— Гел синең тирәңдә әйләнә бит әле ул.

Хафаза кычкырып көлеп җибәрде:

— Тиле, тиле!.. Әллә көнләшәсең дәме?.. Куй, кеше көлдермә, җаным!.. Бел, өч тиенгә дә кирәкми ул миңа, өч тиенгә дә!.. Электән таныш булгач, килеп йөри инде шунда, кешене куып җибәреп булмый бит.

Мин дәшмәдем, мин бары аның күзләренә — элеге шул сабый баланыкыдай зур, дымсу, саф күзләренә генә төбәлеп карадым: бу күзләрдә ялган булмаска тиеш иде, әйе, булмаска тиеш!.. Һәм Хафаза да минем бу минутта ниләр кичергәнемне сизде булса кирәк:

— Борчылма юкка! — диде, кулыма әкрен генә орынып.— Сине борчырлык бер нәрсә дә юк, бәгырем, ышан!.. Басыйрны мин, бәлки, яныма якын да китермәс идем, тик ул да бит сине мактый.

— Мактый? — дип ычкындырдым мин, үзем дә сизмәстән.

Хафаза миңа тагы да якыная төшеп, бәхетле көлемсерәгән йөзен күтәреп, аз гына шукланып әйтте:

— Ышанмыйсың?!. Билләһи менә мактый шул, әйбәт егет, укыган егет, ди, аның белән дус булырга ярый, ди... Әллә ышанмыйсың?

Юк, нигә ышанмаска. Басыйр белән без бер-беребезне иснәп, танып алырга өлгердек инде. Соңгы вакытта, әйткәнемчә, ул үзе үк миңа елыша башлады. Әзрәк мактаса да, гаҗәп түгел... Тик нинди максат белән мактый икән ул? — менә хикмәт нәрсәдә. Бу минем өчен шактый серле табышмак. Ишеттегез инде, Басыйр бер күтәрелеп, түбән тәгәрәгән һәм бик ямьсез рәвештә тәгәрәгән кеше булып чыкты. Бу нәрсә аның хәзерге гамәлен бераз аңлата да кебек: шөһрәтнең, карьераның түмен бер татыган кеше «тәгәрәп төшүе» белән, әлбәттә, килешмәячәк. Димәк, ул яңа җирдә яңадан күтәрелергә тырышачак — теләсә ничек, теләсә нинди юллар белән... Әмма ләкин аның бу максаты өчен без нигә кирәк, нәрсә көтә, нәрсә өмет итә ул бездән?.. Һич аңлый алмыйм... Тик сизәм, мактавы да аның тикмәгә түгел, юк, түгел. Әмма, ни кызганыч, шул чакта мин нидер сизенсәм дә, ул кешенең кара эчен күрә белмәдем, Бәкер дус!

* * *

Хәер, бер Басыйрдан нигә ул хәтле шикләнеп-шүрләп торырга?.. Хафаза әйтмешли, кем ул, нишли ала ул безгә? (Шулай тынычландырдым мин үземне.) Безнең тирәдә яшьләр күп, иптәшләр күп, барысы белән дә арабыз яхшы... Яратышып йөрүебезгә дә ничектер җылы теләктәшлек белән карыйлар төсле... Һәрхәлдә, берәүнең дә көнләшүен, яман күзен сизмибез — чын яратуны кеше аңлый, хөрмәт итә белсә кирәк.

Безнең үзебезнең дә иптәшләр арасыннан чикканыбыз юк, гел бергә... бергә эшлибез, бергә күңел дә ачабыз. Төрле компанияләр үтеп тора, җыелышлар бик еш булып тора — берсен дә калдырмыйбыз. Ул елларда илдә барган зур вакыйгаларны без күңелебезгә бик якын ала идек, шулар белән рухлана идек, шуларга сөенә идек. Бигрәк тә төрле җирдә башланган зур-зур төзелешләр безне куандыра, безне хәйран калдыра иде. Әлбәттә, бу әле тормышта барысы да ал да гөл, безне борчыган мәсьәләләр, аңлавы читен хәлләр юк иде дигән сүз түгел. Һәр замандагы шикелле, ул чакта да бар иде алар, хәтта артыгы белән, ләкин без ул авыр мәсьәләләрдән, ул аңлавы читен хәлләрдән «вакытлы гына бу, тиздән барысы да әйбәт булачак» дип ансат кына үзебезне юата торган идек.

Аннары без яшь идек бит әле, бик яшь идек, шайтан алгыры!.. Ә яшьлекнең хыял күге, үзең беләсең, һәрвакытта аяз була, яшьлек, өзлексез искән җил төсле, кара болытларга баш өстенә җыелырга ирек бирми — гел куалап кына тора. Безнең мәхәббәткә сусаган чагыбыз, безгә уен-көлке кирәк, шау-шу кирәк, дәрткә дәрман кирәк... Безнең арада матур гына җырлаучылар, биючеләр, оста гына гармунда уйнаучылар, мандолина чиртүчеләр дә бар иде. Һәм озак та үтми, без бер драмтүгәрәк сыман нәрсә дә оештырып җибәрдек. Һәр эшнең үз остасы табыла дигәндәй, бу эшкә дә дәртләнеп тотынучы үзенең һә-

вәскәре табылды. Ул — мехбазаның конторасында нииндидер бер бик кечкенә эштә утыручы Мостафа исемле егет иде. Үткән-сүткәндә мин аның гел энә-җеп тотып, кәгазьләр тегеп утырганын күреп уза идем. Аннары ул көн дә цехларга менеп, газеталар таратып төшә иде. Басыйрның әйтүенә карaганда, ул Казанның бик зур бер мәшһүр баеның малае, имеш, ләкин этисен ташлап чыккан да ярлы гына кешенең кызына өйләнеп, хәзер шулар семьясында яши, имеш. Моңа бер дә икеләнмичә ышанырга мөмкин, чөнки аның кыяфәте үк шуны раслап тора иде: нечкә озын буйлы, ап-ак чырайлы, аксыл чәчле, төскә чибәр, шуның өстенә кызлардай тыйнак, оялчан гына егет иде ул. Гүя аңа кемнәрдер дөньяда яшәргә рөхсәт иткәннәр дә, бу шуңа гаять сөенеп, рөхсәт итүчеләрнең ачуын китермим, югыйсә яшәүдән тагын мәхрүм итеп куярлар дигән төсле мыштым гына, куркып кына йөри иде кебек... Һәм шушы егет театрдан шактый хәбәрдар, үзе дә чибәр генә уйный белүче булып чыкты. (Кайчандыр аларның өйләренә зур артистлар җыела торган булган, ул шуларны күреп үскән икән.) Сәхнәдә Мостафа үзен, киресенчә, хөр, иркен, кыю тота иде, чөнки бу чын тормыш түгел, бары тик уен гына... Без аны түгәрәкнең режиссеры итеп куйдык. Мин дә, билгеле, читтә торып калмадым. Цех начальнигының ярдәмчесе булгангадыр инде, мине сайлап тормыйча гына бу түгәрәкнең җитәкчесе итеп таный башладылар. Репетиция көннәрен билгелим, халыкны җыярга кушам, аннары Мостафа белән икәү генә рольләр бүләбез — шуның белән минем эш тә бетә. Калганы инде Мостафа өстендә. Хәер, минем өстә тагын суфлерлык кала, мин бик әйбәт суфлер, әмма үзем, әллә килештермәгәнгә, әллә кулымнан килмәгәнгә күрә, бервакытта да роль алмый идем. Хафаза да, билгеле, шунда, ул да уенга катнаша, һәм аңа еш кына рольнең әйбәтен бирәләр. Ни өчен икәнен әйтеп тормасам да аңлашыладыр...

Менә шулай башланып китте безнең эш... Башта көчне сынар өчен бер-ике пәрдәлек кенә әйберләр куйгаладык. Ярыйсы гына чыкты кебек, халык та гомумән канәгать булып калды, ә мишәрләрне инде әйткән дә юк,— ни генә һәм ничек кенә уйнасаң да алар бик кәефләнеп карыйлар... Аннары, бер ныгып алгач, без «Галиябану»га тотынырга булдык. Моның да сәбәбе аңлашылса кирәк. Беренчедән, «Галиябану»— бик танылган әсәр, халык аны гаять яратып карый, икенчедән, һәрбер драмтүгәрәк «Галиябану»ны уйнап тамашачы алдында үзенчә имтихан тота, шуны ерып чыга алса, ул инде тагы да зуррак әйберләрдән курыкмый башлый, өченчедән, «Галиябану» — уйнар өчен бик күңелле, бик мавыктыргыч нәрсә. Кыскасы, бөтен клублар, бөтен түгәрәкләр уйнап күрсәткән әйберне нигә безгә дә куеп карамаска дидек без... Һәм, азаплана торгач, куйдык та. Әйтергә кирәк, бик кызыклы, бик әкәмәт килеп чыкты безнең «Галиябану»ыбыз!.. Әлбәттә, зур газаплар белән ирештек без бу «уңышка». Иң элек, һәрбер түгәрәктәге шикелле үк, бездә дә һәртөрле ризасызлыклар, үпкә-рәнҗүләр рольләрне бүлүдән башланып китте. Төп героиня — Галиябану роленә ике кызыбыз бар иде: Хафаза һәм әлеге Бибинур. Хафаза Галиябану булырга җан атып тора, ләкин Бибинур буе-сыны, матуррак җырлавы белән Галиябануга күбрәк килә төшә. Мостафа белән без шактый кыен хәлдә калдык. Икебез дә Галиябануны Бибинур уйнарга тиешлеген белеп торабыз, ләкин шуны туры гына әйтергә Мостафа, бичара, миннән курка, ә мин Хафазадан шүрлим. Аның теләгенә каршы килеп, үпкәләтәсем килми иде. (Шунда белдем, һәвәскәрләр һәм гомумән артистлар арасында роль өчен талаш бишектән үк башлана ахрысы.) Инде бу мәсьәләне тиз генә чишә алмагач, без Хәлил роленә күчтек. Хәлилгә исә безнең яраклы кешебез юк иде. Кемнән уйнатырга? Мостафа үзе буе-сыны белән бик туры килә, һәм әйбәт уйнаячак та ул, әмма җыр юк, җырдан бөтенләй мәхрүм... Нишләргә инде дип аптыраган чакта,

кемдер Миннулла исемле егетне безнең исебезгә төшерде: Миңнулла бар бит, коеп куйган Хәлил, менәтерә! — диде. Чынлап та безнең түгәрәк тирәсендә йөргән, ләкин монарчы бер спектакльдә дә катнашмаган андый егет барын белә идек. Дәшеп алдык үзен. Җырлатып карадык. Көчле, матур тавыш — шәп җырлый, каһәрең!.. Менә дигән Хәлил, артыгын эзлисе дә юк. Ну... кыяфәт суя!.. Тәбәнәк, юантык, аяклар да кылтый-былтый, бите дә шанхайчарак. Ничек ярата алыр икән Галиябану мондый Хәлилне — ай-һай?! Ләкин Миңнуллага конкурент юк, үзе дә «һи, уйныйм мин аны!» дип кенә тора. (Хәлилне кем генә уйнамас!) Җилкәләрне кашыдык тә егеткә рольне бирергә булдык. Грим, кием, биек үкчәле итекләр егетне тартып-сузып Хәлил ясамасмы, дидек.

Сөйгән егете Миңнулла буласын белгәч, Хафаза да бик тиз сүрелде. Мин дә аның колагына әкрен генә: «Көнләшәм, иркәм, мин сине Миңнулладан» дигәч, ул бөтенләй Галиябану роленнән баш тартты. Ә Бибинур — күндәм кыз, берсүзсез риза булды, һәм, әйтергә кирәк, Миңнулланы бөтен йөрәге белән яратырга тырышып, бик матур җырлап, елатырлык итеп уйнап та чыкты.

Исмәгыйльне Мостафа уйнады. Дөрес, башта ул, күнеле нидер сизенгәндәй, бу рольгә бик каршы торды, ләкин без инде аны көчлекөчли дигәндәй ризалаттык. Безнеңчә, ул үзе дә бай малае, аңа бай малае булып кыланасы юк, чыгасы да уйныйсы гына... Һәм без, билгеле, ялгышмадык: сәхнәдә тере Исмәгыйль үзе иде! Буй-сын шәп, кием шәп, ә уен? — судагы балыкмыни — йөзә генә егетең!.. Әмма моның нәтиҗәсе нәрсә булып чыкты диегез?.. Су буе күренешендә Мостафа-Исмәгыйль белән Миңнулла-Хәлил беренче тапкыр очрашкач, тамашачы аптырый да кала. Тора-бара бу аптырау чын-чынлап гаҗәпләнүгә әйләнә: күпләр, бигрәк тә хатын-кызлар, ачыктан-ачык: «Чистый юләр икән бу Галиябану, шундый сөлек кебек егетне яратмыйча, бер бүкәнгә гашыйк булган, тиле!» дия башлыйлар... Бичара Миңнулланың бик киерелеп, бик матур итеп җырлавы да тамашачыны үз ягына аудара алмый (хикмәт җырлый белүдәмени), хәтта бай малаеның аны атып үтерүе дә гомуми тәэсирне үзгәртми диярлек.

Шулай итеп, спектакль Исмәгыйль файдасына бетте. Минемчә, бер генә театр, бер генә түгәрәк тә мәшһүр «Галиябану»ны болай уйнап күрсәтмәгәндер әле... Әлбәттә, бу мактану түгел, киресенчә, без барыбыз да шактый хафага төштек, бигрәк тә Мостафа үзе ниндидер ярамаган эш эшләгән кешедәй бик борчылып йөрде. Мин аның хәлен аңлый идем: менә үзе бай малае булгач, Исмәгыйльне нинди шәп итеп уйнады дип әйтүләреннән курка иде ул, мескен! Асылда исә монда беркемнең дә гаебе юк. Исмәгыйль табылды, ә Хәлил — юк, бары шул гына. Хәер, алай дисәң, Миңнуллабыз Хәлилне уйнавыннан башын чөеп, бик һаваланып йөрде. Драмтүгәрәкләрдә шулайрак инде ул — уйнау важно, ә ничек итеп уйнау түгел... Озын сүзнең кыскасы, «Галиябану»ны куеп, без, кемдер әйтмешли, бик әйбәт кенә фәс кидек. Аның каравы, шактый тәҗрибә туплап калдык, хәзер инде тагы да зуррагына тотынырга була.

Ярый, бу хакта күбрәк сөйләп ташладым, ахрысы. Сине, билгеле, Хафаза туташ белән минем ара кызыксындыра, шуның ни белән бет-кәнен тизрәк беләсең килә торгандыр. Ышан, минем үземнең дә шуңа тизрәк барып җитәсем килә, әмма капкадан кермичә өйгә узып булмый дигәндәй, монда да азрак кереш ясамыйча һич тә мөмкин түгел.

* * *

Яратышып йөрүнең һәр көне безне отыры ныграк бәйли — якынайта бара. Без хәзер гел бергә — эштә дә, урамда да, өйдә дә... Яшеренеп торулар бетте. Күпләр инде безнең исемнәрне «Хәбиб-Хафаза» дип

бергә кушып кына йөртәләр. Мишәр абзыйлар туй көтәләр. Әледән-әле миңа күз кысып: «Тизме инде, кайчанрак?» дип сорап кына торалар. Кайчак нидер сизенгәндәй: «Син, брат, бик сузма, кызуында сук!» дип тә куялар. Без үзебез дә, гәрчә өйләнешү турында өзеп сөйләшмәсәк тә, шуның буласына ышанып йөри башладык.

Хафаза көн дә диярлек минем бүлмәгә килмичә калмый. Чакырганда яки иртәгә кайтканда гына түгел, ә теләсә кайчан гап-гади генә килә дә керә. Минем, Бәкер дус, синең алдыңда суфиланып (дәресрәге, ханжаланып) торасым килми... Егерме ике яшьлек егетнең хәлен беләсең, ул сөйгән яры янында чи агач булып кала алмый, ул аны сөяргә, назларга тиеш. Мәхәббәт үзе шуны сорый, кыз үзе шуны көтә, ниһаять, егетлек абруе шуны таләп итә. Без барыбыз да табигать балалары, тик «кеше» дигән зур һәм җаваплы исемебез бар... Һәм бер дә рияланмыйча гади генә итеп әйткәндә, мин дә, дөньядагы барлык гашыйклар төсле үк, сөйгән ярымны коча да, иркәли дә, үбә дә торган идем. Шунсыз инде чын ярату гүя булырга мөмкин дә түгел. Хафаза өчен дә бу шулай — аңа да яратуны гел тоеп һәм яратуын гел сиздереп торырга кирәк... Без бик якынайдык, бер-беребезгә тәмам ияләштек... Мәхәббәтнең бу гаять нечкә, яшерен ноктасына житкәч, кеше табигате кайчан һич көтелмәгән яктан ачылып куя.

Ничек кенә итеп әйтергә сиңа, минем Хафазам иркәләр-сөяр өчен шактый... йомшак кыз булып чыкты. Песи кебек дисәм, кимсетү булыр, һәрхәлдә, син аңлыйсыңдыр инде... Миңа гына ул шулаймы, чын, тирән ярату дәнмы бу?.. Вакыт-вакыт ямьсез шик күңелне тырнап куйгалый иде.

Шулай да аның миңа сыенып назланган чагында үзеннән бер сорадым:

— Хафаза, әйт әле, миңа кадәр синең берәр яраткан кешең булдымы?

— Булды,— диде ул, һич икеләнмичә.

— Кемне?

— Башта Рәүф исемле бер класста укыган малайны.

— Башта!.. Ә соңыннан?

— Соңыннан Гали исемле егетне... Җизнинең энесен...

— Хуш, тагын кемне?

— Бүтән юк.

...Тиледән сорама үзе әйтер... Кәефем әзрәк кырылса да, ләкин ни гаҗәп, аңа ачуым килмәде. Һаман әле тыныч кына сорашкан булдым:

— Я шуннан, синең ул ике егеткә гашыйк булуың ни белән бетте инде?

— Берни белән дә бетмәде.

— Ничек ул алай?..

— Менә шулай... Алар бит бер нәрсә дә белмәделәр. Үзеннән-үзе үтте дә китте.

Валлаһи, аның бу кадәр ваемсыз, хәйләсез сөйләвенә аптырап, мин ни диярга да белмәдем. Шактый дәшә алмый торгач, ул үзе башын минем күкрәгемә терәп, пышылдап кына сорады:

— Син ачуланмыйсыңмы?

— Юк,— дидем мин, аз гына көттереп.— Хәер... Синең гашыйкларың арасында өченче кеше булу минем өчен бик үк күңелледән түгел.

— Ни сөйлисең?! — диде Хафаза, курыккандай.— Син беренче, син минем беренче мәхәббәтем, мин хәзер генә яратуның нәрсә икәнен белдем.

— Ә тегеләр?

— Әйттем ич, үтте дә китте дип... Бер җүләрләнү генә иде ул.

— Алдамыйсыңмы?

— Ышанмасаң, минә йөрәгемне ачып кара. Анда син генә, Хәбиб, син генә!..

Һәм аның үзелеп әйткән бөтен сүзе, йөрәген ачарга теләгәндәй киерелеп миңа сыенуы берниндн шиккә урын калдырмый иде кебек... Әмма шулай да нинди йөрәк, нинди җан соң бу кечкенә, иркә, йомшак кызда?.. Ләкин үзе кушканча, аның йөрәген ачып карап булмый лабаса!

— Ә син, дустым, миңа ышанасыңмы? — дидем мин, ниһаять.

Ул дымлы күзләрен тутырып, сәерсенеп миңа карады:

— Аңламыйм... Нигә алай дип сорыйсың?

— Минем әйтәсем килә: әгәр мин сине алдасам, ташласам...

— Юк, юк,— диде ул, ишетәсе дә килмәгәндәй кабаланып.— Син мине алдамыйсың, син мине рәнҗетмисең... Мин сиңа ышанам, бәгырем, ышанам!

Менә хикмәт нәрсәдә икән!.. Ул миңа ышана, тәмам буйсынган хәлдә, актык чиккә кадәр ышана... Әйе, ул, минем Хафазам, бик нечкә күңелле, бик тиз хискә бирелүчән, сагаюны белми, әмма ләкин бу аның йомшаклыгымы соң?.. Кайбер җан иясе дә үзен шулайрак тота түгелме?.. Әйтик, яшь колын кешене үзенә якын җибәрә, муеныннан, сыртыннан сөйдерә, һәм, билгеле инде, ул кеше миңа кинәт искәртмәстән китереп сугар дип һич тә көтми... Минем Хафазам да әнә шундыйрак — ул да алдауны, явызлыкны көтми, аның булуына ышана алмый иде.

Сүз дә юк, Хафазаның миңа сабыйларча ышануы минем өчен бик кадерле иде. Учтагы кошчык шикелле сакларга кирәк иде аны... Безнең кавышыр көннәребез алда әле, ә хәзергә... менә шулай саф килеш, пакь килеш яратышырга — моның үз ләззәте, үз матурлыгы да гаҗәеп бит!.. Ул сиңа буйсына, ә син аны саклыйсың — бу чын мәхәббәт өчен зур горурлык түгелмени, Бәкер дус?!

Билгеле инде, мин үзем дә Хафазага ышандым, беткәнче җанымтәнем белән ышандым, алай гына да түгел, бөтен уй-фикерләремне бары аңа гына сөйлисем килеп тору минем күңел ихтыяҗына, ниндидер бер зарурияткә әйләнде. Хафаза минем мәхәббәтем, мин аның алдында көн кебек ап-акты булырга тиешмен дип уйлый идем... Шуңа күрә күңелемә ни генә килмәсен, шунда ук мин аны Хафазама җиткерә торган идем. Барысын — зурысын да, вак-төяген дә... Хәзер инде авыздан нинләр чыкканын хәтерләп бетерү мөмкин дә түгел, ләкин шулай да сүзнең күбрәк мәхәббәт тирәсендә әйләнүен яхшы хәтерлим. Үземнең яратуым хакында бәлки күп тә әйтмәгәнмендер («яратам»ны еш кабатларга яратмый идем), ә менә мәхәббәт турында гомумән акыл сату күп булгандыр — бу бит гашыйкларның бер бәласе... Аннары мин аңа еш кына шигырь укый торган идем.— Гомәр Хәйямнан алып үзебезнең Такташка хәтле... Син беләсең инде, поэзия ул минем «чирем» иде.

Рабфакта укыган чакта ук соңгы тиеннәргә булса да зур шагыйрьләрнең шигырь китапларын алгалый идем; аннан минем бер калын дәфтәрем бар иде — менә шуңа күңелгә ошаган шигъри парчаларны, акыл ияләренең үткен, тапкыр сүзләрен, шулай ук үземнең кайбер күзәтүләремне, фикерләремне язып бара торган идем. (Җәяләр эчендә генә әйтеп китим, Хафаза миңа килгән саен бу дәфтәрне бик кызыксынып актарып утырырга ярата иде...) Кыскасы, мин сөйгән ярым белән урамда йөргәндә дә, кара-каршы утырганда да, хәтта аны кочагыма алып сөйгәндә дә, настроениегә карап дигәндәй, шигъри юлларның төрлесеннән әз-әзләп кенә аның нәни колакларына әйткәли тора идем. Хафазаның шуңа бик кәефе килә иде, гүя тәмле шәраптән авыз иткәндәй, әзрәк исереп киткән төсле дә була иде... «Яхшы!» дип куя иде ул еш кына, башын чайкап...

Әнә шулай шигырь белән, ихлас сөйләшү һәм гөнаһсыз үбешүләр белән күңелле-матур гына, рәхәт-тату гына бара иде безнең бу дуслык-мәхәббәтебез... Һәм менә көннәрдән бер көнне кинәт барысы... җимерелде, бетте, юкка чыкты. Әйтерсең, минем аяк астымда җир упты — мин каядыр түбәнгә мәтәлеп төшеп киттем... Син инде шаккатып калгансыңдыр, колакларыңа ышанмыйча: «Бу ни хәл, ни булды?» дип куркынып, тизрәк сорыйсың киләдер... Аз гына сабыр ит, Бәкер дус! Синең кебек исләре китеп аптыраучылар аз булмады, хәтта менә мин үзем дә күпме еллардан соң һаман да әле ни булганын ачык кына төшенеп бетә алганым юк... Дөрес, теге чакта кайберәүләр миңа әйттеләр, син Хафазага артык ышангансың, менә шунда синең хатаң диделәр. Ләкин мин бу фикерне кире кактым, катгый рәвештә! Яраткан кешеңә ышанмыйча мөмкин түгел, абсурд бу!.. Әгәр без яратуны ышанудан аерсак, дөньяда мәхәббәт дигән нәрсә бетәр, юкка чыгар иде... Юк, мин ышануыма үкенмим, Бәкер дус, һич тә үкенмим. Әмма ышануны кем нечек аңлый — бу инде бөтенләй икенче мәсьәлә.

Сүз дә менә хәзер нәкъ шул турыда барачак. Тик моңарчы сөйләгәннәрдән шуны исеңдә тот: мин Хафаза белән утызынчы елның җәй ахырында танышып йөри башладым; көзге, кышкы айларда инде безнең дуслык бик тирәнгә керде, өйләнешү теләге дә туды, гәрчә бу хакта өзеп кенә сөйләшмәсәк тә, эшнең шуңа таба баруын икебез дә бик яхшы белеп тора идек. Ләкин утыз беренче елның февраль башларында миңа кинәт кенә авылга кайтып китәргә туры килде. Әни карчык каты авырып киткән икән, өйдән чакырып язган хат килеп төште. Мин үз исәбемә бер атналык отпуска алдым да тиз генә Япанчыга китеп бардым.

*
* *

Япанчы минем туган авылым — шунда тудым, шунда үстем. Туган авыл! Мактарга кирәктер инде аны, ләкин нәрсә дип мактыйм?.. Зур да түгел, кечкенә дә түгел, ике мәчетле гадәти генә татар авылы. Җиресуы да тирә-як авылларныкыннан бер нәрсәсе белән дә аерылмый. Үрләр, үзәнлекләргә җәелгән шәрә кырлар, чокыр-чакырлар, вак куаклыклар, үз урманы юк. Казна урманы авылдан биш чакрымда — без, малайлар, җыйнаулашып шул урманга җиләк-җимешкә, барлык урманга җиләккә, кычытканга... бик ерак булса да, бара идек — без, малайлар, җыйнаулашып шул урманга җиен каты, балтырган, җиләк җыярга, көзен чикләвеккә, баланга йөри идек. Авылның кечкенә инеше бар, түбән очтарак юкә бәйләмнәре, арба көпчәкләре, кисмәкләр батырырлык сай гына буасы да бар — без шуның пычрак суында, борын төбенә кара мыеклар чыкканчы, шапыр-шопыр коена торган идек. Хәзер болар барысы да калын кар астында инде.

Картайды җиһан!
Гөлләр дә бетте.
Кичмәктә заман —
Кышлар да җитте.
Исләр бетәкләр,
Карлар асылды;
Таулар, болаклар —
Бар да басылды...

Әйе, әнә шулай балалык хатирәләре дә акрынлап еллар астында күмелеп кала баралар. Туган авылым белән мине бәйләгән җепләр соңгы елларда бик нечкәрде. Сирәк кенә кайткалый торган кунак кына хәзер мин монда... Хуҗалык бетте диярлек, чөнки хуҗа кеше юк, абый Ташкентта утырып калды, апайлар кияүгә чыгып киттеләр, мин дә укырга китеп бардым, шулай итеп, таралышып беттек. Кайчандыр түгәрәк, таза гына тормышның болай бетүгә йөз тотуы әткәй үлгәннән

сон башланды. Унсигезенче елны бөтен илгә таралган рәхимсез тиф алып китте аны... Шул чагында әнкәй дә авырды, апайлар да авырды (тик мин генә нишләптер авырмадым), барысы да әкренләп аякка бастылар, ә менә иллегә дә житмәгән тап-таза ир күтәрә алмады — сынды да куйды. Миңа ул яшь иде, «ятим» дигән сүз иң кызганыч сүз булып тоела иде — инде менә мин дә ятим калдым. Боегып, мескенләнеп йөрдем, кызгану көттем, ләкин кызганып, баштан сыйпап узучы булмады шикелле, чөнки вакыты ул түгел иде, бик буталчык, киеренке вакыт иде — кеше кайгысы киштәдә!.. Без үзебез дә югалту хәсрәтен тиз оныттык...

Әткәй үлмәс борын әле абыйны да Кызыл Армия сафына алганнар иде. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә безнең йорт ике кулсыз торды да калды. Моның нәтиҗәсен ничек кенә аңлатырга?.. Ике тәртә берьюлы сынгандай, безнең тормыш арбасы бик тиз түбәнгә таба тәгәри дә башлады... Башта әкрен-әкрен, аннары отыры кызурак... Кучәрдән тәгәрмәчләр берәм-берәм ычкынган шикелле, атайдан калган күпмеазмы мал-мөлкәт тә һаман югала-бетә барды... Бер ел эчендә ике аттан бер алашага, ике сыердан бер сыерга калдык, сөрү, чәчүнең чиреген дә эшли алмадык, азык кытлыгы, курмы кытлыгы чынлап торып өебезгә керде... Ул арада егерме беренче елның ачлыгы да килеп житте.. Һай, бу ачлык!.. Тәмам бетереп, очлап куя язды ул безне... Кыш кергәнче ук әле ак келәтне дә сатып ашадык, жирән алашаны да ашадык, тимерле тарантас та тамакка кереп китте, инде яшькелт-кара алабутадан башка ашар нәрсә дә калмады. Әни шешенде, апа шешенде, минем яңакларга тырпаеп соры төкләр чыкты; ахрысы, берәм-берәм сәкегә сузылып үләргә генә калды дигәндә, ярый әле, абый Ташкенттан кайтып, безне ачлык тырнагыннан йолып алды. Бай яктан шактый акча белән кайткан иде ул, бәясе-ние белән хисаплашып тормыйча, чувашлардан бер еллык печкән үгез дә алып суйды, күрше базардан берике капчык алабута оны белән ярты капчык арыш оны, тагын күпмедер тары да алып кайтып бирде. Шул рәвешчә атна-ун көн эчендә әниләргә кыш чыгарлык азык җыеп калдырды да, мине үзе белән иртәгә, яңадан Ташкентка китеп тә барды.

Бик озак бардык без Ташкентка — җүләр әйтмешли, әллә ике атна, әллә өч атна. «Икмәкле шәһәрнең» юлы ай-һай озын, ай-һай авыр икән лә. Самара станциясеннән ычкына алмыйча ничә көн җәфаландык. Галәмәт зур, биек вокзал эче ачлыктан качып баручы, бетләп беткән сәләмә агайлар, хатын-кызлар, бала-чагалар белән тулы. Аяк басар урын да юк. Шунда мин беренче тапкыр кешенең җан биргәнен күрдем. Абыйның чемоданы өстендә бөрешеп кенә утырып тора идем, миннән нибары ике-өч адымда гына таш идәндә чалкан сузылып яткан бер урыс карты, биек түшәмгә каерылып карагандай, әллә ничек тагы да сузыла төшеп, сакаллы ияген кинәт-кинәт кенә бер какты, ике какты да тынып та калды. Шунда ук күзләре аларып, артка таба киткәндәй булды... Нишли икән бу дип, аптырап, куркынып тора идем, ул да булмый, янында утырган марҗасы: «Үлде!» дип чырылдап та җибәрде... Ләкин аның бу ачы тавышы, коега төшкән таш кисәгедәй, гөж-ж итеп улап торган вокзал эчендә юньләп ишетелмичә дә калды. Борылып карауч да булмады. Мәхшәр! Җылаш-талаш, акыру-бакыру, бәрелүсугылу — кая монда кеше үлде дип аяк астына карап тору?!. Тик минем генә миемдә уелып калды урыс агайның соңгы тапкыр ияк кагуы... Озак газаплады ул мине...

Әмма Ташкент үзе безне чалт аяз көнгә, җылы кояшы белән каршылады. Кыш бит, ә нинди җылыкай! Икмәге авызыма әләккәнче шушы сары майдай җылысы минем ачтан кибеп күшеккән тәнемне рәхәтләндереп эретеп җибәрде. Гүя кояш эчемә үк кереп оялады, атна буенча мин шуны гына тоеп, шуна гына сөенеп йөрдем.

Аннары бераздан абый мине приютка. Рәсәйдән килгән ач балалар йортына урнаштырды... Монда алабутаны түгел, арыш ипиен дә белмиләр, ашаганыбыз — ап-ак калач та дөге боткасы. Өрек, йөзем, шәпталы. Өстә ак бүздән күлмәк-ыштан, башта — дупы (үзбәк түбәтәе)... Торган җиребез тәбәнәк дувал белән әйләндереп алган зур җимеш бакчасы — чылтырап арыклар ага, түгәрәк һәүзләр елтырап ята... Бөтенләй икенче дөнья!.. Бер кызык искә төште әле: кайчандыр Бохара әмиренә: «Гали җәнап, фәлән илдә халык ачлыктан кырыла» дип әйткәч, әмир бик гаҗәпләнеп: «Нигә соң ул халык плау ашамый икән?».. дип сораган, имеш. Белмим, аның үз халкы плау гына ашап тордымы икән?.. Һәрхәлдә, әмирне куганнар. Менә мин дә хәзер шуның гөл багында яшим төсле... Кемгә рәхмәт әйтергә — абыйгамы, үзбәк халкынамы, совет властенамы?.. Әмма аңлый төшкәч, мин бу рәхмәтнең иң олысын әүвәл үзебезнең властька, совет властена, аннары кин күңелле үзбәк халкына йөрәгемдә саклап йөрттем... Хәер, бер мин генәме соң бу рәхмәтне йөрәгендә саклап йөртүчеләр?!

Мин инде приютта торганда күргән һәр төрле авырлыкларны, ямьсез якларны искә төшереп, сөйләп тормыйм. Җылы якта да бит гел аяз, кояшлы көннәр генә булып тормый — сөякләргә үтәрлек салкын томанлы, җепшек көннәр дә булгалый. Шуның төсле, кырык ата баласы җыелган җирдә дә төрле хәлләр — талаш-ызгышлар да, сызланып рәнҗүләр дә, хаксызга түгелгән күз яшьләре дә — һәммәсе булып торды. Ләкин адәм баласы гадәттә начарын онытырга, яхшысын гына хәтерендә сакларга ярата... Иң мөһиме шул — безне сакларга, укытырга, кеше итәргә тырыштылар.

Ике ел чамасы вакыт үткәч, буй җиткән үсмерләрне приюттан чыгарып, төрле җиргә эшкә яки уку йортларына урнаштыра башладылар. Шул чакта мин илгә кайтып китәргә булдым. Абый да каршы килмәде — ул үзе дә әле өйләнмәгән, күбрәк командировкаларга йөрүче ялгызак бер кеше иде. (Соңыннан минем абый ниндидер ике еллык курслар бетереп, юрист булып китте.) Кыскасы, Ташкент бик әйбәт, плау да бик тәмле, әмма авылны, өйне, әнине шулкадәр сагындым, күзәмә берни күренми башлады.

Өс-башны яхшы гына бөтәйтеп, шактый гына тансык күчтәнәчләр төяп, җәй башында кайтып төштем мин үзебезнең Япанчыга... Авыл, авыл... нинди тын һәм нинди буш!.. Әллә ничек сәер генә. Искерә дә төшкән, чүгә дә төшкән, боега да төшкән кебек... Ишек-тәрәзәләре кагылган өйләр яки бөтенләй бушап калган ихаталар да очрый — ачлык елның галәмәтедер инде бу... Ә шулай да никадәр таныш, никадәр якын ул миңа!.. Ник бер генә капкасы, бер генә агачы, бер генә сукмагы онытылсын!

Бу ике елда мин буйга бик үсеп киткәнмен, ахрысы — әнкәй дә кечерәйгән, апай да кечерәйгән, хәтта өйалды ишегеннән дә бөкрәебрәк керергә туры килә. Ә авылдашлар танымыйлар да: «Бәй, синмени бу, Хәбиб? Нәмә егет булгансың, малай!» диләр. Егет инде, егет, тик тавыш кына ныгып җиткәне юк әле, еш кына сынып киткәли, бигрәк тә көлгәндә «күкле-зәңгәрле» тавышлар чыгып куйгалый.

Минем кайтуыма өйдәгеләр бик сөенделәр... Сөенмичә, «йорт башы» кайтты бит... Ул җәйне миңа, хуҗа булып, җиң сызганып бик нык эшләргә туры килде. Агай-эне ярдәме белән азрак бодаен да, тарысын да чәчтек, печәнне дә чабып җыйдык, тиресен дә суктык. Ара-тирә кешеләргә дә эшләштергәләдем. Җәйнең үткәне сизелми дә калды, явымлы көз, аннары салкын кыш та килеп җитте. Менә шул чакта мин бер нәрсәне бик ачык аңладым: күңел минем авылдан аерылган икән инде... Авылда каласы килми, хәтта калу куркыта мине... Хыялымда бер генә уй, бер генә теләк: укырга кирәк, укырга, укырга!.. Авыл тормышы, крестьян эше минем өчен түгел, минем юлым башка булырга

тиеш. Заман үзе укырга өндәп, укырга чакырып тора.Ә минем сәләтем бар, мин моны беләм инде... Озын сүзнең кыскасы, әнә шулай урынынан купкан, һич тынычлана алмаган күңел белән тагын бер җәйне эшләп үткәрдем дә, әнкәй бичараны бик кыенлык белән күндереп, бөрмәле капчыкны яңадан иңемә астым. Юлым Казанга, үзебезнең башкалага инде... Калган ягын син беләсең инде.

Туган авылга кайткан саен үткәннәр ни өчендер гел генә искә төшә. Гүя иске сукмаклардан тагын бер үтәргә туры килә. Менә бу кайтуымда да барысын искә төшереп, үйламаган җирдән сиңа да сөйләп чыктым.

* * *

Кайтсам, авыл, арба басып киткән кырмыска түмгәгедәй, мыжгып тора. Бу ни хәл?.. Әле утызынчы елның кышында ук безнең авылны тоташ колхозлаштырып куйганнар иде. Шул чакта халык бер кузгалып, чайкалып, дулкынланып алган иде инде. Сөреләсе кешеләр сөрелеп, колхоз, ниһаять, оешып беткәч, беренче өермә-давыл үтеп киткән дә шикелле булган иде, ләкин бөтенләй үк басылып бетмәгән икән әле. Эш нәрсәдә?.. Моның серен миңа кайтып төшкән көнне үк белергә туры килде. Башта, теләпме-теләмичәме, колхозга кереп тулган агайлар Сталин хатыннан соң кире агылып чыга башлаганнар. Тоташ колхоз яртыга, чиреккә калган. Бу хәл оештырып йөрүчеләрне нык кына борчуга салган булса кирәк, алар ашыгыч чаралар күрергә тотынганнар. Иң элек колхоздан башлап чыккан яки чыгарга өндәгән берничә кешене авылдан сөргәннәр. Аннары күп кенә агайларның кергән чакта биргән атын, эш коралын, орлыгын кире чыкканда үзләренә кайтарып бирми башлаганнар (баштарак биргән булганнар)... Шуның өстенә, билгеле, һәркайсын көн дә идарәгә чакырып аңлаталар, үгетлиләр, куркытып та карыйлар — кыскасы, үз файдасын белмәгән үҗәт мужикны ничек тә хак юлга кертергә тырышалар. Ә мужик ни өчендер аңларга теләми, ни өчендер һаман дурт аягын терәп, карышып маташа... Менә шундый талаш-тартыш вакытына туры килдем мин. Әйтергә кирәк, бу тартыш агай белән идарә арасында гына түгел, һәр өй эчендә диярлек бара икән — хуҗа үзе икеләнебрәк булса да колхозга борыла башласа, хатыны дулап каршы тора, яки малае керик дисә, атасы тешен кысып, йодрыгын күрсәтә.

Минем үземә бу колхозлашу хәрәкәте, билгеле, турыдан-туры кагылмый иде. Мин шәһәр кешесе. Атайдан калган өйне исәпләмәгәндә, авылда минем атым да юк, туным да юк. Шулай ук әнкәй карчык та, бездән килгән ярдәм белән, ялгыз башы гына яшәүче — колхозга кирәк кеше түгел. Моңарчы әле аңа «кер» дип әйтүче дә булмаган.

Кыскасы, менә шундый хәл. Минем, билгеле, Япанчыдагы хәлләргә тыгылырга вакытым да, теләгем дә юк иде. Ләкин икенче көнне үк күрше-тирәдәге агайлар, туган-тумачалар миңа килә дә башладылар. Янәсе, шәһәрдән кайткан егет, үзебезнең егет, укыган егет, берәр файдалы сүз ишетеп булмасмы?.. Киләләр, ачык йөз белән: «Һи, Хәбиб туган, исән-сау гына кайттыңмы?» дип ике куллап күрешәләр, аннары ниндидер бер мескен кыяфәт белән ишек төбенә, миң буена чүгәлиләр. Ләкин зарларын әйтергә ашыкмыйлар, башта анысын-монысын, Казан хәлләрен сораштырган булалар. Һәркайсы диярлек: «Мәскәүдән ни ишетелә, Мәскәү ни яза?» дип сорап куя. Мин инде Казан турында, Мәскәү турында белгәннәремне бер дә иренмичә сөйлим, әлбәттә, мактап, зурлап сөйлим. Шуннан соң берәрсе авыр гына сулап: «Каланың эше рәхәт!» дип куя. Бусы инде миннән: «Нигә, авылда начармыни?» дип әйттерер өчен... Һәм сизә торып, шундыйрак сорауны бирәм дә:

— Нигә, авылда да бит хәзер зур үзгәрешләр бара, начармыни ул?

— Кем белсен аны! — ди элеге хәйләкәре, уйлап тормыйча гына.
— Барын бара да бит, Хәбиб туган, ләкин хәерлегәме соң ул? — ди икенчесе, уйланыбрак.
Минем ачыграк әйтәсем килә:
— Әгәр сүз колхозлашу турында бара икән, ул, һичшиксез, хәерлегә булачак.
Агайлар озак кына дәшми торалар. Болай алдан ук өзеп әйтүне яратмыйлар, ахрысы... Кайсы бүреген салып башын кашый, кайсы түн кесәсеннән ашыкмыйча гына тәмәке янчыгын чыгара. Ләкин мин тәмәке тарттырмыйм (түрдә, чаршау эчендә әнкәй авырып ята.) Хәер, алар үзләре дә моны беләләр — тәмәкеләрен төрәләр дә учларына гына йомып утыралар. Түземе беткәне генә өйалдына чыгып, бер-ике суырып керә.
Тагын мина сүзне башларга туры килә:
— Сез бит инде колхозга кергәнсез, шулай булгач нигә болай уфтанасыз?
— Кергән идек тә чыктык.
— Ни өчен?
— Керү ирекле дип әйтәләр бит...
Бу сүзләре мине шактый аптырашта калдыра.
— Кызык икән! — дим мин, ни әйтергә белмичә.
— Бик тә инде! — ди шунда берсе, ачулы киная белән.— Үкереп елыйсы гына, парин!
— Хәтта!.. Юк, сез ачык кына әйтегез әле, эш нидә соң?
Агайлар бер-берсенә карашалар. Кем, ниһаять, аңлатып бирә мәсьәләне?.. Гадәттә, элек мондый чакта арадан берәр олырак, тәҗрибәлерәк кеше барысы өчен әйтеп бирә торган иде. Бу очракта исә берсе дә, әллә саклык йөзеннән, әллә авызы пешкәнгә күрә, андый вазифаны һич өстенә алырга теләми. Әйтсә, бары үз исеннән, үзенә кагылган кадәресен генә әйтә. Мәсәлән, безнең күрше Гандәлиф абзый:
— Мин колхозга каршы түгел,— ди, алдына карап кына,— мужет, ул бик файдалы нәрсәдер. Тик мин белмим бит әле аны, колхозны әйтәм, сыналмаган эш... Менә кергәннәр эшләп күрсәтсеннәр, карыйк, әгәр дә мәгәр, әйткәнегезчә файдалы нәрсә булып чыкса, керермен, ник кермәскә?!. Мин мондагы кеше, качып китәргә җыенмыйм, алла сакласын!
— Мөселманнар да Мөхәммәт пигамбәргә барысы берьюлы иярмәгәннәр,— ди ана өстәп безгә туганрак тиешле Хисам абзый. Ул шулай китапчарак сөйли торган кеше инде.
Ә менә күпер төбе Бәдри абзыйның башка нәрсә борчый икән. Бу инде кайнар, этәчрәк кеше.
— Менә кара,— ди ул, кинәт минем борын төбендә кәкре, керле бармакларын тырпайтып.— Тигезме?.. Юк, тигезме?.. Шул шул, менәтерә, аппагым!.. Ә кешеләрне тигезләмәкче булалар. Тигезләрсең син аларны! Әйтик, менә мин үзем эшләргә кирәк булса, эшлим инде, җенен чыгарам, эшең генә чыдасын... Ә әнә теге, кем, кылый Зариф, Сәхәпләр күршесе, ул бит, парин, аркылы ятканны буйга алып сала торган кеше түгел, нелеп чабатасын бәйләргә дә иренә, астына күн теккән оектан йөри... Я, шундый кеше белән мин бер колхоз булдым, ди. Мин баш күтәрми эшләрмен, ә ул минем аркада бет симертеп ятсынмы? Булмый бит ул алай, туган, булмый!
— Шулай шул,— диештеләр абзыйлар, салмак кына.
— Туктагыз әле,— мин әйтәм.— Колхозда бит эшеңә карап бирә торганнардыр, эшләсәң тия, эшләмәсәң — юк.
— Анысы шулаен шулай да, әмма Зариф кебекләр дә эшләгән булып, селкенеп йөриләр, андыйларга да язарлар, ә бәрәкәте ни?..

— Аннары,— дип ялгап китә Гандәлиф абзый,— мәсьәләнең бу ягы да бар. Кергәндә, әйтик, берәү ике аты белән, берәү бер аты белән, ә берәү кысыр кәҗәсен җитәкләп керә. Бу да бит тигезлек түгел. Мал газиз, берәүгә дә буш килмәгән.

Озын сүзнең кыскасы, Бәкер дус, агайларның мондый зарлары, шикләре күп булды, әгәр барысын да язып китсәм, бик күңелсезгә әйләнер иде. Үзең күрәсең, монда колхоз дигән яңа, сыналмаган нәрсәдән курку да бар, ата-бабадан килгән, күнегеп беткән тормыштан аерыласы килмәү дә бар, «үземнеке» дип чат ябышып яткан мал-мөлкәтен кызгану да бар,— җыеп кына әйткәндә, авыл кешесенең чуар, каршылыклы характерына нәрсә хас булса, шулар барысы да бар... Ни әйтергә, ни диеп җавап бирергә тиеш идем мин аларга?.. Колхозны әле мин үзем дә якыннан күреп белмим, ә болай акылым белән генә аның нәрсә икәнен күз алдыма китерәм. Шуңа күрә бөтен әйткәнем: «Абзыйлар, юкка борчылмагыз, төрле шикләнүләрегезне ташлагыз, колхоз ул сезнең өчен, сезнең файдага, шуңа бик нык ышаныгыз!» — бары шул иде. Ләкин, билгеле инде, моның ише гомуми сүзләр аларның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга — чөнки минем кебек сакалсыз димләүчеләрдән алар аны бик күп ишеткәннәр. (Арадан берсе: «Колхозны башлап йөрүчеләр дә бит җыен яшь-җилкенчәк, нәрсә белә алар?» — дип әйтеп тә куйган иде.) Чөнки һәркайсының үз уе, үз исәбе бар, шуңа җавап кетә ул... Кызык бер момент: мин сөйләп беткәч, Гандәлиф абзый бүрегенең эченә карап, сакланып кына әйтә:

— Һәркемнең җилкәсендә үз башы бар, нәрсә аңа файдалы, нәрсә зарарлы, үзе хәл итәр, тик менә...— ләкин әйтеп бетерми.

— Тик... нәрсә соң, Гандәлиф абзый?

Гандәлиф абзый, авыр сүзне ничек чыгарырга белмәгәндәй, иреннәрен сәер генә кыймылдаткалап тора:

— Тик... көчләмәсеннәр иде, туган! — ди ул, ниһаять.

— Көчләү?.. Нинди көчләү?

— Һи... һи-һи,— дип көлештеләр агайлар.— Син юләр сатма инде, Хәбиб туган, бала түгелсең ләбаса!

— Юк, мин чынлап сорыйм,— дим, нигәдер уңайсызлана төшеп.

Шунда ук берсе тун кесәсеннән әллә ничәгә бөкләп тыккан иске газета тартып чыгара.

— Менә моны укыгансыздыр инде... Сталин хатын? — ди ул, тузып, тетелеп бетә язган газетаны сак кына ача башлап.

— Укыдым, билгеле.

— Соң шулай булгач?!. Монда бит крестьянны колхозга көчләп кертергә ярамый дип акка кара белән язылган... Көчләү булмаса, язар идемени?

— Ә сез хатның исеменә игътибар итегез: «Уңышлардан баш әйләнү» диелгән бит. Ягъни бөтен җирдә дә крестьяннар колхозга үзләре теләп, оешкан рәвештә керделәр, тик кайбер урыннарда гына тизрәк колхозлаштырып бетерү өчен көчләү юлына аяк басулар булды дип яза ич иптәш Сталин...

— Бездә дә ул шулайрак булды...

— Ничек булды?

— Башта өеребез белән кердек... Берәүләр теләп, берәүләр ияреп, берәүләр куркып дигәндәй... Аннары... менә кире чыктык.

— Ни өчен?

— Иптәш Сталин хаты күзебезне ачты. Теләмәсәң, кермәскә дә була икән...

— Димәк, сез колхозга бер дә керергә теләмисез инде?

Агайлар дәшмиләр. Аларның йөзләре ничектер шунда ук йомыла, иреннәре кысыла, күзләре каядыр читкә төбәлә — яратмыйлар алар бу сорауны, яратмыйлар!.. Тик болай дәшми тору уңайсыз була баш-

лагач кына Бәдри абзый, теш арасыннан чыгаргандай, мыгырданып әйтеп куя:

— Хикмәт анда түгел!

— Ә нәрсәдә соң?

Һәм ул кинәт кенә кычкырып сала:

— Көчләү булмасын!.. Әйе, менә шул, көчләү булмасын!

Аңа тизрәк ярдәмгә килгән кебек башкалар да берьюлы шаулап үзләренекен әйтергә ашыгалар:

— Закон бозмасыннар!

— Без мужет иртәгә үк барып керербез, түлке үз аягыбыз белән... Ирекле дек ирекле!..

— Соң! Кәҗәне генә мөгезеннән сөйриләр.

Агайларның бу сүзләрен ишеткәч, кылт итеп исемә төште: Горький үзенең бер әсәрендә бер герой авызыннан мондый сүзләрне әйттерә: «Я не позволю тащить меня на веревке даже и в рай...» Күрдегезме, кеше нинди ул?!

Ләкин миңа агайларны ничек тә тынычландырырга кирәк иде:

— Туктагыз әле,— дим,— башта кергәнсез, аннары үз иркегез белән чыккансыз, бу көчләү буламыни?

Агайлар тагы да яманрак шаулап, ачулы-зәһәр итеп көләргә тотыналар:

— Их-хи-хи! Тә-тә-тә! Ну Хәбиб!.. Сөннәткә утыртылмаган баламыни!.. Белмисең икән, туганкай, безнең мондагы хәлләрне, гүпчем дә белмисең икән... Әй, егетләр!

Менә шуннан соң алар минем аптыраган башыма безнең Япанчыда булган көчләү-кысуларның төрле мисалларын яудыра башлыйлар: кемнендер чыккан чакта атын бирмәгәннәр, ат урынына җигәргә ярамаган тай биргәннәр; кемнендер, ниндидер сылтау белән, сыерын тартып алганнар; бик күбесенә орлыкларын һаман да бирмичә йөртәләр икән; барысына диярлек әллә нинди адәм күтәрә алмаслык заданиеләр салып бетергәннәр... Ә җиргә килгәндә, берсен дә яңадан элекке үз басуларына чыгармаганнар, төрле ташландык түбә җирләрдән кисеп биргәннәр... Җалу белән йөрергә ярамый, йөрсәң — артыңнан: «Бу кеше колхозга каршы коткы тарата» дип язалар да бирәләр — шуның белән эшең бетте, кодагый! Әнә түбән оч Шәрифулланы авылдан ук сөргәннәр. Ни өчен диген! Янәсе, өй борынча кереп, әйдәгез, уптым чыгабыз дип котыртып йөргән, имеш. Үзе дә юләр инде. Башы нужадан, аягы чабатадан чыкмаган бер йолкыш югыйсә, ә теле аркасында подкулачник булып китте дә барды.

Белмим, бу зарларның күпмесе ни дәрәҗәдә дөрестер. (Авыл кешесе гомумән үзен кызгандырырга бик ярата.) Ләкин ничек кенә булмасын, алар юкны сөйләп утырмыйлар, алар башларына төшкән, үзәкләренә үткән нәрсәләрне — һичшиксез, күпмедер дәрәҗәдә булган нәрсәләрне — ачынып-әрнеп сөйлиләр. Моңа ышанмыйча мөмкин түгел, һәм, билгеле инде, минем дә бу көчләүләргә, бу хаксыз рәнҗетүләргә ачуым килә. Бигрәк тә үзебезнең халыкны, үзебезнең чын крестьянны көчләү-кыерсыту белән килешү һич мөмкин түгел, бу бик хәтәр-куркыныч нәрсә!.. Мин моны беләм, хаклы булуымны беләм, әмма менә хәзерге очракта мин нәрсә эшләргә тиеш, нәрсә эшли алам — монысына һич акылым житми... Каядыр, кемгәдер барып, турыдан-туры гына Япанчыда агайларны көчлиләр, кыерсыталар дип әйтеп булмый — моны фактлар белән исбат итәргә кирәк, ә фактларны башта әйбәтләп тикшерергә, белергә кирәк булачак. Моның өчен кайда вакыты, кайда шарты?.. Шуның белән бергә мин бер хакыйкатьне бик яхшы белеп торам: колхоз яшәргә, колхоз ныгырга тиеш, һичбер нинди кирталәргә, һичбер нинди корбаннарга карамастан!.. Бу эшкә хәзер бөтен партия һәм совет органнары, милиция, суд, комсомол — барысы да җигелгән,

барысы да, тауга авыр йөк сөйрәп мендергәндәй, колхозны тарталар. Мондый гаять киеренке, буталчык бер вакытта гаделлек эзлим дип ак-караны аермыйча, белер-белмәс барып тыгылу — каш ясыйм дип күз чыгару гына булыр иде.

Хәер, агайлар үзләре дә миннән ходатай булып йөрүемне сорамадылар. Минем авыру әнкәй янына кыска гына вакытка кайткан кеше булуымны алар күреп торалар. Бөтен сөйләгәннәре эчләрен бушатыр өчен дә берәр акыллы киңәш ишетер өчен генә булды, ахрысы. Шулай да мин аларга бик ныгытып, сезне колхозга көчләп керту булмаска тиеш, партия алай кушмый, партия аңлату, үгетләү юлы белән генә крестьянны колхозга тартырга куша, әле Ленин да урта хәлле крестьяннарны җәберләү-көчләүдән бик сак булырга кушып калдырган дидем; әгәр инде шуңа да карамастан сезне монда төрлечә кысалар икән, хаксызга кыерсыталар икән, сезнең бу турыда районга, Казанга хәтта Мәскәүгә чаклы язарга хакыгыз бар,— куркып тормагыз, дидем. Шуның белән бергә мин, билгеле, кабатлап алар өчен колхозның бик файдалы нәрсә буласын, иртәме-соңгы шуңа барыбер ышанырга туры киләчәген, хәзерге шикләнү-куркуларның нигезсез икәнлеген дә әйттем... Абзыйлар яңадан бәхәскә кереп тормадылар, йомылып сүзсез генә тыңладылар да авыр гына кузгалып, болай хәтер өчен генә: «Рәхмәт, туган!» дип чыгып киттеләр.

Әлбәттә, мин аларны нәрсәгә булса да ышандырдым, үзгәрттем дип һич уйлый алмыйм, чөнки Тукай әйткәнчә, шигырь (бу очракта — сүз) башка да дөньяны әйләндергән чыгыр башка!.. Һәркайсы үзенең ниндидер ихтыяҗы, ниндидер зары белән килгән булса, шуларны үзе белән, бүреге эчендә дигәндәй, кире алып та китте... Шуңадыр инде минем күңелдә авыр бер төер утырып калды, һәм бу төер миңа тынычлык бирми башлады.

Мин колхоз председателе Хәйрүш абзый белән сөйләшеп карарга булдым,— барыбер аның янына кереп, күрешеп чыкмыйча ярамас. Алдан шуны әйтим, минем әнкәй салкын тидерүдән үпкәсе шешеп авырган булган. Ул чакта бу күпләрне теге дөньяга алып китә торган хәтәр авыру иде. Ләкин, бәхеттән, мин кайтканда әнкәйнең кризисы узган, эш әкрен генә юнәюгә таба борылган иде. Әмма шулай да мин беренче көннәрдә бер яры да чыкмыйча гел аның янында булырга тырыштым. Аны өзлегеп-нитеп китүдән бик сакларга кирәк иде. Бер җирдән дә салкын-мазар үтәрлек булмасын дип, урынын да түр сәкенең тәрәзәдән ераграк почмагына күчердек, чаршау да кордык, әйләнәсенә өстәп ястык-мендәрләр дә салдык. Ярый әле, күрше авылдан кече апай да кайткан иде, ул авыруның төрле ихтыяҗларын үтәсә, мин аның аяк очыннан китмичә, әледән-әле пульсен капшап, кул сырты белән температурасын чамалап, бигрәк тә гел кибеп барган иреннәренә шикәрле җылы чәй эчереп тордым. Ул елларда хәзерге антибиотикларның берсе дә юк — кеше авыруны күбрәк үзе генә җиңә ала иде. Чыдам, сабыр, арык кына гәүдәле әнкәйнең моңа көче җитте — берничә көннән күзләре ачылды, сөйләшә башлады, әз-әз генә тамагына да каба башлады. Без дә апай белән бер иркен суладык — иншалла, куркыныч үтте шикелле... Ул арада минем китәр көнем дә килеп җитте.

Иртәгә китәм дигән көнне мин колхоз идарәсенә барырга чыктым. Авылны кар баскан, койма-читәннәрнең өстеннән үк калын көрт, тик капка аллары гына кереп-чыгып йөрерлек итеп көрәлгән, сукмаклар беткән — урам уртасындагы чана юлыннан гына барып була. Көн кояшлы, карга баткан авыл өсте гаҗәеп киң, иркен, якты, юл буйлап күксел табан эзе тонык кына елтырый, кыек читләрендә беренче тамчылардан сузылган бармак буйлык кына «сөңгеләр» җемелди, кайбер морҗалардан төтен тузгый, ишек алларында кояшка чыккан арык сыерлар күзләрен йомып, күшәп торалар, бер абзар түбәсеннән иkenче

абзар төбәсенә чыпчыклар фырлап очалар... Әле бу капкадан, әле теге капкадан чыгып киткән яки кайтып кергән берәр кара бишмәтле апай яки сары тунлы агай күренеп кала, ләкин каршыма туры гына берәү дә очрамый... Мин шушы карга күмелеп, әкрен генә кымшынып, сулап яткан тын, якты авыл өстенә карап, булачак очрашу турында уйланып барам.

...Хәйрүш абзый. Безнең Япанчыда колхоз оештыруны башлап йөрүчеләрнең иң беренчесе һәм колхозның беренче председателе — ничек каршы алыр икән ул мине? Ул да мине, мин дә аны беләм. Шахтер, коммунист кеше. Аның атасы Челәм Хөснулла авылның бер ярлысы иде. Җиргә артык ябышып ятмыйча, күбрәк Идел буена китеп, крушник булып йөрде. Аты булмады, йорт-җирен рәтләп карамады, ләкин акча төшереп кайткан чакларында синкедән генә пешергән ак күмәч ашады. Ни өчендер минем әткәй мәрхүмне ярата иде, кайтты исә, муллага бармыйча, әсмүхә чәен, бер кадак шикәрен күтәреп, безгә килә иде.

Хәйрүш абзый да этисе эзеннән китте. Егет дип әйтерлек яшькә житкәч тә, шахталарга китеп йөри башлады. Әле дә күз алдымда аның шахтадан кайткач, ялт иткән кара итек, кара чалбар, сары сатин күлмәк киеп, билен өч каптырмалы киң брезент каеш белән буып, урам уртасыннан бик фырт кына үтеп китүләре... Корыч чыбыктай нык сеңәрле, какча, җыйнак кына егет иде, усал-кыю да булган дип әйтәләр, чынлап та бер кайтуында ул югары оч Шәмсетдин картның Рәхимә исемле кече кызын качырып кына үзе белән алып та киткән иде.

Егерме бишенче-егерме алтынчы елларда Хәйрүш абзый этисенең иске куышы урынына менә дигән алты почмаклы, такта түбәле йорт салдырып керде. Авылда бер йорт! Моңа исләре китүчеләр дә күп булды. Хәер, ул елларда шахтага йөрүчеләр акчаны бик мул төшерәләр икән дип сөйлиләр иде. Бигрәк тә өйләнәсе егетләр, бер-ике кыш барып, эшләп кайтсалар, я ат алалар, я бура торгызалар иде. Шуның өстенә әле үзләре белән сандык-сандык чүпрәк-чапрак та төяп кайталар. Минем әнкәйнең дә сукранып мина: «Шул хәерче Казанга киттең дә баттың, әнә шахтага йөрүчеләр, ичмасам, баеп кайталар» дип әйткән чаклары булгалады...

Шулай да Хәйрүш абзый Япанчы җиренә тиз генә тамыр җибәрә алмады — яңа зур өенә хатыны белән балаларын кертеп утыртты да үзе һаман шахтага йөреп торды. Ялангай буш ихата эчендә шул ялгыз өеннән һәм читән абзарыннан башка аның бүтән каралты-курасы да, аты-туны да булмады. Тик авылда зур үзгәрешләр башланыр алдыннан гына ул шахтадан бөтенләйгә кайтып, җиң сызганып дигәндәй, колхоз оештыру эшенә тотынды. Ихтимал, авылның бердәнбер коммунисты булганга күрә аңа бу авыр, зур хәрәкәтне башлап җибәрергә кушканнардыр да.

Мин колхоз идарәсенә — авылдан сөрелгән кибетче Сәгъдиләр өенең урам башына барып кердем. Моннан бер ел элек кенә хуҗаларыннан бушаган бу таза, нарат өйгә казенный төс кермәгән дә кебек әле, ничектер гаилә тормышының исе, җылысы сизелә кебек — шул ук гади аш өстәле, шул ук пыяла шкаф, кара кәнәфи, шомарып беткән урындыклар, хәтта ишек төбендәге ләгән, чиләкләр дә хуҗалардан калган килеш тора шикелле... Тик өйнең бер почмагын җиңел кулдан ак такта белән бүлеп куйганнар. Председатель бүлмәсе икән ул,— мин шунда кердем. Хәйрүш абзый кызыл чүпрәк япкан кечкенә өстәл артында утыра иде. Башта ул мине танымады, аннары танып алгач, урыныннан авыр гына торып, миңа кулын бирде, утырырга кушты.

Мин беренче тапкыр күргәндәй аңа карап торам — үзгәргән, бик үзгәргән Хәйрүш абзый. Элек тә карасу йөзе хәзер көйгән касмак кебек кара-сары булып киткән, күзләренә дә сары йөгергән, кайчандыр

бик купшы йөрткән күперенке мыегы да нечкәреп, авызының ике ягыннан сәлперәеп төшкән. Күз төпләре шешенке, каш арасында тирән сызык. Зур, сөякчел куллары ничектер, иясенең ихтыярыннан тыш дигәндәй, өстәлдә хәрәкәтсез ята. Күренә, абзый арган, йончыган, таушалган. Мина килгән агайлар аның хакында сүз әйтүдән тыелсалар да, мин ишеткән идем инде: Хәйрүш бик усалланган, имеш, бер дә рәхим-шәфкать дигән нәрсәне белми, тоткан жиреннән шартлатып сындыра, имеш. Мөнә үзен күргәч, шуңа ничектер ышанасы килеп китте.

Шулай да сүз агай-энечә тату гына башланды.

— Кайттыңмы? — диде ул миңа.

— Әйе, кайттым... Мөнә әнкәй карчык авырып киткән...

— Ишеткән идем... Озаккамы?

— Юк, тиздән китәм.

— Әнкәңнең хәле ничек соң?

— Рәхмәт, әкренләп терелә инде.

— Ярый алайса,— диде Хәйрүш абзый, аннары йокымсыраган сыман алдына карап, тынып торды. Инде мин сүзне ничек дәвам иттерәсе икән дип уйлана башладым, ләкин шул арада ул үзе янадан телгә килде:

— Калада нишлисең, укыйсыңмы?

— Юк, хәзергә эшлим әле. Рабфактан соң бер генә ел булса да эшләп алырга булдым. Бераз материаль якны рәтлисе килде.

— Кайда эшлисең?

— Меховойда, дөресрәге — мехбазада.

— Нәстә эшлисең анда?

— Мехлар сортлыйбыз.

Хәйрүш абзыйның мыек астында: «Тапкансың эш!» дигән төсләрәк бер елмаю чагылып киткәндәй булды, ләкин ул бары:

— Ярый, бу да ярый,— дип кенә куйды.

Мин үзебезнең производствоны мактарга ашыктым:

— Ишеткәнсездер инде, Казанда мехлар эшләп чыгару бик нык үсеп бара бит. Яна фабрикалар салына... Эшләгән мехларның күбесе заграницага китә, без мөнә шуларны...

Ләкин Хәйрүш абзый, тыңлыйсы килмичә, минем сүзне бүлде:

— Син, парин, кайткансың икән инде, рабочий класс исеменнән безнең колхозчыларга бирәр докладмы-ниме шунда сөйләп китәр идең. Мөнә бу бер дильни эш булыр иде.

Билгеле, аның болай дорфа гына сүзне бүлүе минем кәефемне дә кырды һәм шактый гына аптырашта да калдырды.

— Нәрсә турында? — дидем мин, аңлап бетмичә.

— Мало што нәрсә турында. Пример, каланың авылга ярдәме турында яки международный палажения... Крестьянның хәзер күпне беләсе килә.

Әлбәттә, Хәйрүш абзый белән сак сөйләшергә кирәк иде.

— Иртәгә китәм шул,— дидем мин, әз генә үкенгәндәй.— Алдан хәбәрләшеп тә булмады. Аннары...

— Аннары... нәрсә?

— Япанчыдагы хәлләр белән дә танышлыгым аз. Сездән кайбер нәрсәләрне сорашып беләсе килгән иде, Хәйрүш абзый...

— Пример, нәрсәне?

— Ну, мәсәлән, авылның күпме хужалыгы колхозда инде хәзер?

— Житмеш проценты, ә язга йөз проценты белән колхозда булачак, вәт шул.

— Алай, яхшы икән,— дидем мин һәм маңгаемны сыпырган булып, аз гына уйланып калдым: житмеш процент булуы, әлбәттә, яхшы, ләкин Хәйрүш абзыйның язга йөз процент булачак дип кистереп әйтүе миңа

шактый сәер тоелды. Минем шунда ук аңа иң төп һәм иң четрекле соравымны бирәсем килде, әмма, сизеп торам, ул аны яратмаячак. Шулай да, үземчә йомшартырга тырышып, ярым сорау рәвешендә генә әйтеп куйдым: «Билгеле, агайлар барысы да үзләре теләп керә торганнардыр инде?..»

Хәйрүш абзый кызара төшкән күзләрен шунда ук миңа төбәде:

— Нигә алай дип әйтәсең? Без берәүне дә арканлап сөйрәмибез.

Юк, сөйләшү бу тонда киткәч, миңа да артык сагайган булып, сүзне икеле-микеле алып барырга ярамый иде. Әйткәч-әйткәч, ачык һәм туры әйтергә кирәк — шунсыз булмый. Әлбәттә, кызмыйча гына.

— Сүз арканлап сөйрәү турында бармый, Хәйрүш абзый, ә колхозга ирекле рәвештә керү принцибын саклау турында бара... Иптәш Сталин хатында нәкъ шул хакта әйтелә бит. Ләкин, кызганычка каршы, ирекле керү принцибын бозулар һаман да бар икән әле.

— Кайда?

— Менә үзебезнең шушы Япанчыда ук.

— Кемнәр әйтә?

— Кемнәр әйтә дип, сүз иясе белән йөрми инде.

— Юк, бу бик важны,— диде Хәйрүш абзый, кашларын усал җыерып.— Давай, ачык әйтеп сөйлә!

— Мин ачык сөйләшәм, Хәйрүш абзый... Менә агайларның әйтүенә караганда...

— Кайсы агайларның?

— Ну шушы авыл агайларының.

— Аларның төрлесе бар, кайсын тыңлыйсың бит.

Күреп торам, председатель миннән ничек тә аерым кешеләрнең исемнәрен әйттерергә тырыша, ләкин минем һич тә әйтәсем килми иде.

— Мин дә шушы Япанчы егете, Хәйрүш абзый (Хәйрүш абзыйны еш кабатлыйм шикелле), кемнең кем булуын азрак беләм... Ләкин хикмәт анда түгел. Минем сездән әнә шул бозулар дөресме дип сорыйсым килә.

— Пример, нинди бозулар?

— Иптәш Сталин хатын укыганнан соң колхоздан кире чыккан кешеләрне төрлечә кысасыз икән... Нигә бу, чыкмасыннар, яңадан керсеннәр дипме?

— Тукта, ничек итеп кысабыз?.. Давай, примерын китер.

— Примерлары күп аның, нигә миннән сорарга.

— Юк, шулай да?

— Ну, әйтик, колхоздан чыккан чакта агайларның кайсына атын, кайсына орлыгын бирмисез икән.

— Кемгә, пример?

— Соң бит инде аларны үзегез дә беләсез.

— Хәлүшләрне әйтәсеңме?

— Кайсы Хәлүш?

— Теге Божыр Хәлүш... Хәлиулла... Да, без аңа атын бирмәдек, ат урынына ике яшьлек тай бирдек. Ник дисәң, атын сатып сатачак та яңадан колхозга буш кул белән киләчәк. Беләбез без ул агайларны!.. Орлык белән дә эш шулайрак. Язга чаклы бирми торабыз, ату ашап бетерәчәкләр. Алар бит берәм-берәм колхозга барыбер кире кайтачак...

— Ә кайтмаса, кайтырга теләмәсә?

— Кайтмаса — күз күрер. Ә пока ярамый, орлык бик кадерле нәрсә, һәр бөртеге исәптә.

Хәйрүш абзыйның ачыктан-ачык әйткән бөтен сүзе һәм үзен шулкадәр бәйсез, хуҗа итеп тотуы мине бик гаҗәпләндерә иде. Ул бит һич акланмый, акланырга уйламый да, гүя бөтен хакыйкать аның ягында!

— Ләкин бу законсызлык була түгелме соң? — дидем мин, аңа каршы торасым килеп.

— Закон! — диде Хәйрүш абзый, мыскыллы елмаеп.— Ә колхозны таратып бетерсәк, ул законлы булачакмы?.. Син, брат, абзаң кебек адвокат булып кайткансың икән. Түлке кемне, нәрсәне яклыйсың?!

Аның бу сүзләре, ниһаять, минем бәгыремә килеп кадалгандай булды. Ачуым килеп китте, нигә әле мин бу кешедән куркып торам дигән уй белән, кыза төшеп, туп-туры үзенә әйттем:

— Мин партия боерыгын яклыйм, беләсегез килсә. Партия крестьянны, сездәге шикелле, төрле юллар белән кысып, көчләп колхозга кертергә кушмый, кушмый гына түгел, катгый рәвештә тыя.

Хәйрүш абзый кинәт кара янып китте, күзләрендә әллә нинди чәнечкеле утлар кабынды.

— Һа! — дип куйды ул, тәмам ярсып.— Син әле, малокосос, безне өйрәтергә кайттыңмыни? Алайса, белеп тор: без партия кушкан иң зур эшне эшлибез, без колхоз төзибез. Безгә колхоз кирәк, Япанчы агайларына колхоз кирәк!.. Башка юл юк!.. Инде кайбер тискәре беткәннәр, кулак коткысынаияреп, или анда сознаниеләре җитмәгәннән, кирелә-неп маташалар икән, без үзебез белербез аларга карата нинди политика үткәрергә!.. Указ кирәкми. Монда дураклар утырмыйлар... Белеп торабыз кемнәр синә барып сайраганын... Лучше син, егет, тыгылып йөрмә, кайткансың икән, кунак бул да әнә юлыңны кара!.. Ату...— Ул кинәт сүзен бүлде.

Әйе, бу инде үтереп хурлау гына түгел, ачыктан-ачык куркыту да иде. Минем бөтен эчемне диярлек ут алды, бер тезем үзеннән-үзе сикерергә тотынды, бугазымны ике яктан нәрсәдер буа башлагандай булды. Ләкин мин курку дигән нәрсәне һич тә тоймадым, киресенчә, аның үзе кебек үк минем дә үчләнеп-ярсып җавап кайтарасым килде, тик менә әллә ничек бер мәлгә сөйләү куәтемне югалтып җибәрдем... Ә Хәйрүш абзый шул арада түн кесәсеннән кер-ле кульяулык чыгарып, сәлперәйгән мыегын сөрткәләде дә, алдында яткан кәгазьләрне актаргалап, шуннан бер дәфтәр битен миңа таба этәрде.

— Менә синә барып җылаганнарның берсе, күпер төбе Бәдри, кичә гариза калдырып китте. Яңадан колхозга алуны сорый...

Мин аптырадым да калдым, күзләремә ышанмый торам... Бу бит чынлап та әлеге шул миңа килеп: «Көчләү булмасын!» дип иң нык шаулаган Бәдри абзый лабаса! Ни әйтергә, ничек аңларга бу халыкны?!

— Бик яхшы булган,— дидем мин, инде шактый сүрелеп.— Ләкин нидән күрәсез сез аның яңадан колхозга кайтуын?

— Кая барсын ул йолкыш,— диде Хәйрүш абзый, ваемсыз гына,— колхозга кайтмыйча...

— Ә сез миңа килгән ул кешеләрне әллә нинди дошманнар итеп күрсәтмәкче буласыз.

— Үзләренә дошманнар.

— Соң ул чагында яхшылап аңлатырга, төшендерергә кирәк аларга...

— Их, энем, энем! — диде Хәйрүш абзый, ачынып-сабырсызланып.— Белмисең әле син мужикны, белмисең!.. Коры сүз белән генә аны бер нәрсәгә дә күндереп булмый, көлә генә ул синнән, көлә генә! Менә син бер генә атна минем урында утырып кара, валлаһи дип әйтәм, ыштаныңны муеныңа урап, авылдан качачаксың! Кул кирәк монда, брат, кул! — Һәм аның өстәлдә яткан зур, сөякчел кулы гүя үзлегеннән таштай йодрыкка әйләнде, аннары әкрен генә кире ачылды... Хәйрүш абзый йөзен читкә борып, басынкы гына өстәде:

— Ярый, җитәр, яхшы чакта аерылышыйк, туган!

Мин урынымнан тордым. Күңелдә әйтәсе күп сүзләр бар кебек, ләкин, юк, чыкмый инде, бетте, дөрестән дә, яхшы чакта китү хәерлерәк. Без кул бирешеп аерылыштык.

Юл буенча үземне тиргәп кайттым... Ни пычагыма кирәк булгандыр миңа тыгылып йөрергә!.. Үз мәнфәгатьләрен аңламаган, үз мәнфәгатьләренә каршы торган агайлар, шуларны хак юлга буып сөйри-сөйри кырысланып, усалланып беткән Хәйруш абзый,— я, кем хаклы да кем хаксыз монда — аерып, хөкем итеп кара!.. Әнә, төерле белен генә килеп чыкты бу сөйләшүдән... Күңелдә авыр юшкын гына утырып калды, хәерсез!.. Әшулай да мин әйткән сүзләрем өчен үкенмим, мин беләм — алар дөрес сүзләр, хак сүзләр, ләкин шул ук вакытта Хәйруш абзыйның да бөтен кырыс кыяфәтендә, кискен-усал сүзләрендә ниндидер бер рәхимсез дөреслек бар иде — мин моны да сизмичә калмадым. Әйе, каршылыклы заман, катлаулы кешеләр!..

...Икенче көнне мин авылдан китеп тә бардым.

* * *

Мин Казанны, эшемне, иптәшләремне сагынып кайттым. Бигрәк тә Хафазам — кара күзкәемне сагындым. Безнең бит әле беренче тапкыр аерылып торуыбыз, ә аерылып тору мәхәббәтне иң нык сыный торган нәрсә инде ул...

...Тормыш кайда да кирәнкә, әмма шулай да безнен шәһәр җирендә сулыш алуы җиңелрәк икән. Аннары хезмәт үзе бик шифалы нәрсә,— кайткач, шуна тагын бер тапкыр инандым. Һәркөнне иртән иртүк сине әлеге каплап куйган иске будильник чәрелдәп йокыннан уята. Өстеңнән авыр йокне селтәп ыргыткандай сикереп торасың, тизрәк салкын су белән бит-күзеңне юасың, шунда ук примуска кип төпле чәйнекне куясың — аның шаулый башлавы бүлмәгә ничектер җан кертеп җибәрә. Куе, кайнар чәйне шикәрләп, ипиләп эчкәннән соң, әйбәт кенә киенеп, әле яктырып та җитмәгән, тапталмаган, пычранмаган кышкы буш, тын урамга чыгасың. Тымызык, таза, салкын һава, дворниклар кыштыр-кыштыр урам көриләр, шәһәр өстендә йөзләрчә төтен баганалары әкрен генә һавага сузыла, тәрәзәләре тулган якты трамвайлар шалтырап уза... Бу вакытта эшкә баруы бик рәхәт. Поны күптән качкан, тән җиңеләеп киткән, аяклар үзләреннән-үзләре ашыгып, рәхәтләнеп атлыйлар... Яшь, таза ат кебек сизәсең үзеңне. Юк, алай гына да түгел. Ходай бирмеш һәр иртәне менә шулай җиңел атлап эшкә бару кешене ничектер янарта — яшәве, уйлавы, хис итүе өр-яңадан башлана кебек... Һәм бу яңаруны син һәр эш иртәсендә татымыйча калмыйсың.

Әнә шулай башланып китте минем аз гына өзелеп торган хезмәт көнем. Цехта да иптәшләр мине бик ачык каршыладылар. Аларның күбесе өчен минем китеп торуым сизелми дә калган шикелле:

— Һи-и, Хәбиб малай, кайттың дамыни әле син?! — дип гаҗәпләнделәр.

Беренче көнне үк яныма ап-ак тешле чалышрак авызы белән елмаеп, Басыйр да килеп җитте.

— Нихәл, саумы, Хәбиб дус! — диде ул миңа, кул биреп.— Кайттың?

— Кайттым,— мин әйтәм.

— Я, ниләр җимертеп кайттың? Авыл чибәрләренең баш-күзләрен әйләндереп бетермәденме?

— Вакыт булмады, малай, авыру әнкәй яныннан бер дә чыгып йөри алмадым.

— Шулаймыни, кызганыч!.. Ну, авыл ничек соң?

— Авыл ничава,— мин әйтәм.

— Гөрлиме?

— Гөрли.

— Ярый,— диде ул гамьсез генә, аннары аз гына тукталып, сорап куйды:— Бүген эштән соң кая барасың?

— Нигә?

— Берәр жиргә кереп, сөйләшеп утырыр идек, күптән авыз чылаткан юк.

— Бүген булмый, Басыйр,— дидем мин.— Башка вакытта.

— Ә-ә, аңлашыла! — диде ул, ияк кагып.— Хафаза гөлкәй белән кавышасың бармы?

Мин дәшмәдем, ә ул миңа дусларча күз кыскандай итте дә китеп барды... Дөрес әйтә, шадра пәри, минем бүгенге кичем бары Хафаза өчен генә, мин Хафазаны үземә алып кайтачакмын. Без әле бүген иртән генә күрештек, кул һәм күзләр белән генә, әмма шунда ук никадәр сагынышуыбызны, тизрәк бергә буласы килүебезне аңлап-тоеп өлгердек. Смена гына бетсен!..

Бу урында шуны әйтеп китәсе килә, Басыйр үзенең «берәр жиргә кереп утырыйк» дигән чакыруын ни өчендер янадан кабатламады. Оныттымы, әллә кирәк тапмадымы, һәрхәлдә, безгә икәүдән-икәү генә «авыз чылатып» утырырга туры килмәде. Дөрес, берме-икеме тапкыр, эштән чыккач, егетләр белән юл өстендәге сыраханәгә кереп, сыра эчкәләдек, ләкин анда да сүз юк-бар уен-көлкедән узмады. Аннары минем кичләрем дә буш түгел иде, кичләрем гел Хафаза белән тулы иде.

Бер уңайдан тагын шуны да әйтеп китәргә кирәк, минем йөреп кайтуым ни сәбәптер мишәр абзыйларда шактый зур кызыксыну уятты. Хәер, мин аларны аңлыйм,— күбесенең бит семьялары авылда, авыл хәлләре аларның уйларын һәрвакыт биләп-борчып тора. Шулай да алар бик сак кына сорашалар. Әле берсе, әле икенчесе яныма килеп башта: «Нихәл, брат, амань гена йөреп кайттыңмы? Анай ничек, саумы? Ярый, ярый, алла мәдәт бирсен!» дип сүз башлый, бары шуннан соң гына: «Я, салада хәлләр ничек соң, брат, колхоз нишли, агайларны абижат итмиләрме?» дип сораштырырга тотына. Күреп торам, миннән аларның бик турысын гына ишетәселәре килә. Ләкин шулай да мин аларга капчыкны төбеннән үк тотып селекмәдем; ышанмаудан яки куркудан да түгел, ә бөтен ишеткән-күргәнне сөйләп, аларны артык борчырга теләмәдем. Борчылыр өчен сәбәп аларга болай да житәрлек иде. Аяк астыннан чыккан бәла дигәндәй, мин югында безнең мехбазада шактый күңелсез бер вакыйга булып алган: көннәрнең берендә ГПУ работниклары килеп, базаның подвалында упаковщик булып эшләүче Гыйльметдин исемле бер татар агаен алып киткәннәр. Баксаң, ул нindидер жинаять эшләп, авылдан качкан зур гына бер кулак, имеш. Чын исем-фамилиясе дә аның бөтәнчәрәк булган диләр. Эшкә дә ул ялган документ белән кергән икән. Кыскасы, тапкан дошман кереп посар урын!

Сортланган каракүлләрне подвалга төшергәндә мин бу кешене күргәли идем. Базык кына, таза гына, карап торырга гади генә бер авыл кешесе. Күп сөйләшми, күп аралашмый, тыныч кына үз эшен эшли бирә, хәтта әбәт вакытында подвалдан чыгып та йөрми, күбрәк шунда түкләр өстенә утырып кына, алып килгән бер шешә сөтен зур түтәрәм кара ипи белән ашый торган иде. Хәтерем ялгышмаса, безнең управляющий аны яхшы эшләгәне өчен бер бүләкләгән дә иде шикелле... Мангаена язылмагач, аның кем икәнен каян беләсең?!

Һәм менә шушы «яхшы» упаковщикның кетмәгәндә, туп-туры эшләгән жиреннән кулга алынуы безнең мехбаза өчен шактый ямьсез бер ЧП — гадәттән тыш вакыйга була. Берәүләрне ул борчуга сала, икенчеләрне куркуга төшерә, ә кайберәүләрнең шик-шөбһәләрен көчәйтеп жибәрә. Мәсәлән, шул ук Басыйр бу вакыйганы миңа сөйләгәннән соң, бик мәгънәле генә итеп: «Бар әле аның койрыклары бездә, бар!» дип әйтеп куйган иде... Тагын шул, бу ЧП өчен безнең Перовка да әзрәк эләккән шикелле, чөнки Гыйльметдин кулак аның кулы аша узган, ә күрсәткән документының ялган булуын бала да танырлык, имеш.

Менә шул. Мин югында булган бер эш булгач, аңа әллә ни зур игътибар да бирмәдем. Безнең көннәрдә аның ише хәлләрнең булгалый торуы бер дә гаҗәп түгел иде. Аннары минем уйларым бөтенләй башкада бит әле...

...Алдан вәгъдәләшкәнчә, мин шул ук көнне Хафазаны үземә алып кайттым. Сменадан соң Хафаза түбәндә эшләремне бетереп, цехтан чыгуымны көтеп торды. Кайтышлый магазинга кереп бер шешә портвейн да алып чыктым,— беренче кичебезне авылдан кайткан күчтәнәчләр белән бәйрәмчәрәк итеп үткәрәсем килде.

Бүлмәгә кайтып кергәч, мин аның пальтосын салдырып, кулыннан гына тотып, өстәл янына китереп утырттым, үзем дә урындык алып, каршысына утырдым... Өстендә кызыл сатин кофта, кара юбка, аякларында кечкенә кара киез итекләр — бик гади, хәтта ярлы дияр идем, әмма үзенә бик килешә, ничектер җыйнак итеп күрсәтә үзен... Менә ул утырган җиреннән генә киерелеп, ике кулы белән тузгый төшкән чәчләрен рәтләргә тотынды... Мин һич орынмыйча аңа — аның алсуланып янган йөзенә, энҗедәй ике генә төртке җемелдәгән зур кара күзләренә, кечкенә, тулы иреннәренә, уртасы чокырлы йомшак иягенә, йомшак, шома муенына карап утырдым... Болар барысы да миңа бик таныш, бик якын, бик тансык... Әгәр теләсәм, менә хәзер үк аны кочагыма кысып, шул йомшак сусыл иреннәреннән үбә-үбә иркәли-сөя алам, ул үзе дә шуңа әзер, шуны көтеп утыра кебек, ләкин мин ашыкмыйм, ашыгасым килми. Юк, бу юри тыелып маташу да түгел, ә ничек дип әйтим, туйганчы бер карап, аны сыныйсым, беләсем, үземә тартасым килә. Ахырда Хафазам түзмәде:

— Карама ул хәтле, оялтасың! — диде дә, йөзен яшерергә теләгәндәй, миңа таба иелә төште.

— Кара чәчәгем син! — дидем мин, аның йөзен иягеннән күтәреп.

— Нигә... кара?..— дип кенә өлгерде аның иреннәре...

...Чынлап та нигә кара чәчәк?.. Әллә моның берәр төрле хәтәр мәгънәсе бармы?.. Юк, мин һичбер нинди мәгънә салмыйча әйттем, бары күзләре, чәчләре кара булган өчен генә шулай назлап әйттем. Кара роза чәчкәсен бик нәфис, бик матур диләр бит... Шулай да һич уйламаганнан гына әйтеп ташлаган бу чагыштыруда хәтәр мәгънә булган икән — тик мин моны бик соңга калып белдем... Әйе, кара чәчәк...

Аннары мин торып, өстәл әзерли башладым. Әнкәйнең хәзинәсеннән кече апа биреп җибәргән бер йомарлам ак майны, калай савыт белән балны, пешкән ярты казны, карарак бодай онынннан пешерелгән тәмле кабартмаларны алып кердем,— Хафаза шуларның барысын да матурлап өстәлгә тезеп куйды... Эмаль чәйнек белән чәй дә кайнатып керттем, портвейнны да, азаплана торгач, пәке очы белән ачып, өстәл уртасына куйдым. Табыныбыз гаҗәп мул, ямьле булып китте. Шуңа сөенеп, Хафазамны кыстап-кыстап, сыйларга тотындым. Безнең әле болай икәүдән-икәү генә «байларча» сыйланып утырганыбыз юк иде. Мин үзем әз-мәз эчкәләгән кеше булсам да, Хафазаның, әйтүенә карағанда, вино дигән нәрсәне моңарчы авызына алганы булмаган икән әле... Шулай да, кыстый торгач, ул да бер ярты стакан чамасы портвейнны бүлгәләп кенә эчеп куйды... Әчми эчкәнгәдер инде, аның йөзе шунда ук комачтай кызарып китте, күзләре дә дымланыбрак елтырый башлады, ә бераздан теле дә чишелде... Ботактагы кошчык шикелле, үзеннән-үзе җанланып һәм юктан да көлә-көлә ул миңа бер атна эчендә мехбазада булган вак-төяк хәлләрне сөйләп чыкты... Мин аны бирелеп тыңлаган булдым, ара-тирә ярты сүзендә бүлеп, тәмле генә үбеп тә алгаладым, ләкин күбрәк сөйләвенә сокланып, карап утырдым. Шул чакта һаман бер уй күңелгә килә торды: аның миңа бу хәтле

ияләшүе, миңа берсүзсез буйсынырга әзер торуы чын яратудан киләме икән соң?.. Нигәдер шушы шик вакыт-вакыт күңелне тырнап куя, шайтан алгыры!.. Ә бәлки ул минем яратуыма җавап рәвешендә генә яратам дип йөри торгандыр. Хатын-кызда нәкъ әнә шундый ярату күбрәк була, диләр. Ягъни, үзе башлап яратудан бигрәк, егет мәхәббәтенә буйсынып, яратып китә, диләр. Иярчен мәхәббәт, күндәм мәхәббәт! Ләкин ни дәрәҗәдә ышанычлы мәхәббәт — анысын белмим, әйтә алмыйм. Дөрес, Хафазаның үзеннән мин: «Яратасыңмы?» дип күп тапкырлар сорап карадым... «Ә син ничек уйлыйсың?» дип аның шаярткан чаклары да булды, «Яратам, бәгырем!» дип, кочагыма сыеныл әйткән сүзләрен дә ишеттем... Бу чынмы? Бәлки чындыр, ә бәлки... каян беләсең, кешенең йөрәген ачып карау мөмкин түгел.

Ләкин ничек кенә булмасын, Хафаза — минем иң якын, иң ышанычлы кешем. Мин инде аны күрмичә, аны сөймичә, аңа бөтен уй-хисләремне ачмыйча тора алмыйм... Сулый торган һавам дисәм дә артык булмас. Әлбәттә, мин аңа шушы беренче кичтә үк авылдан ишетеп, күреп кайтканнарымны түкми-чәчми сөйләп бирдем. Беркемгә сөйләмәсәм дә, мин Хафазама сөйләргә тиеш идем, чөнки бу минем өчен бер зарурият — җан таләбе иде. Авыл тәяп җибәргәннәрнең барысыннан-барысыннан да ничектер бушанырга кирәк иде. Мин агайларның миңа килеп, нидән, нәрсә өчен зарлануларын да, колхоз председателе Хәйруш абзый белән булган авыр сөйләшүне дә бөтен ваклыкларына кадәр җентекләп сөйләдем. Ул гына түгел, мин үземдә туган уйларны да, шикләрне дә, нинди рәк настроение белән кайтуымны да яшереп тормадым — сөйли бирдем. Гүя минем, Хафазага сөйләп, аның аша үземнең уй-шикләремне сынап беләсем килә иде. Сүз дә күбрәк колхозны оештыру эшендә көчләү бармы, булса — кирәкме ул, ярый торган нәрсәме — менә шул хакта барды... Һәм, билгеле инде, безнең сөйләшүне һичкем ишетмәде, белмәде,— барысы да икe арада гына калырга тиеш иде.

Хуш, ә минем акыллы Хафазам мине ничегрәк тыңлады соң? Ничегрәк карады ул мин сөйләгәннәргә, ышандымы миңа, килештеме минем белән, борчылдымы минем өчен? Безнең арада элек тә сүз күп була торган иде, әллә нәрсәләр турында сөйләшеп бетерә идек — гашыйклар теле тик тормый бит инде ул. Күбрәк мин сөйли идем, ә ул тыңлый иде, һәм, әйтергә кирәк, тыңлый белә иде минем Хафазам. Зур күзләрен балалар шикелле миңа хәрәкәтсез төбәп, тулы иреннәрен ача төшебрәк, үзенчә бик игътибар белән тыңлап утыра торган иде. Мин сөйләгәнне ярата иде, ахрысы, еш кына үзе үк: «Хәбиб, сөйләп берәр нәрсә!» дип әйтә торган иде. Һәм мин сөйли идем, бик теләп, рәхәтләнеп сөйли идем,— бу инде минем гадәтемә кереп киткән иде. Ничектер менә үземдә булганны аңа күчермичә тора алмый башладым. Ләкин ни генә турында сөйләшмик, безнең арада бервакытта да бәхәс чыкканы булмады. Ни генә әйтмим, Хафаза алдан ук шуның белән килешергә әзер иде кебек. Вакыт-вакыт бу нәрсә әллә ничек сәер тоелса да, мине гаҗәпләндерми иде. Чөнки ул бик яшь иде әле, белеме дә чамалы гына, үзенчә уйларга, үзенчә аңларга өйрәнеп тә җитмәгән, кыскасы, үзеннән олырак һәм өстенрәк кешеләр авызыннан ни чыкса, аның шуңа ышанып, шуның белән килешеп яши торган чагы иде.

Ләкин бу очракта мәсьәлә бик җитди иде, четрекле иде,— миңа кагылган, минем белән бәйләнгән мәсьәлә иде ул... Биредә инде мин сөйләгәнне тутый кош шикелле тыныч-хәрәкәтсез генә тыңлап утыру җитми, ничектер борчылырга, уйланырга, мәсьәләгә үз мөнәсәбәтеңне билгеләргә кирәк иде. Баштарак мин сүзне дә Хафазам мине аңлар микән, минем белән килешер микән, дип шикләнебрәк тә башлаган идем. Ләкин юкка! Хафазам һаман шул әүвәлгечә күзләрен тутырып миңа караган килеш, иреннәрен ача төшеп, сабыйларча бирелеп дигән-

дэй, мине тыңлап утыра бирде. Гүя аның өчен минем нәрсә хакында сөйләвемнән бигрәк, ничек итеп сөйләвем кызыклырак иде. Агайларның зарларын сөйләгәндә ул көлгәләп тә алды, Хәйрүш абзый белән булган бәрелешне ишеткәндә куркып киткән төсле дә булды. Бер урында: «Әй жаным, нигә андый кеше белән сүз көрәштердең?!» дип әйтеп тә куйды... Әмма мәсьәләнең үзе турында ләм-мим! Мәсьәлә үзе гүя аны борчымый да, уйландырмый да иде.

Мин анардан хәтта:

— Ләкин син әйт, бәгырем, кайсыбыз хаклы бу бәхәстә, минме, әллә Хәйрүш абзыймы? — дип тә сорадым.

Ул ике дә уйламыйча:

— Син инде, жаным, син! — диде.

— Ни өчен мин?

— Син бит, жаным, үзеңне якламагансың, кешеләрне яклагансың. Нигә, яклау гаепмени?

Бу үзенә күрә резонно иде. Ләкин шулай да минем анардан ни кирәген, ин мөһимен ишетәсем килә.

— Сүз бит, бәгырем, кемнәрнедер яклау турында гына бармый,— дидем мин, ничек тә гади генә аңлатырга тырышып,— мәсьәләнең ничек дим, принципиаль ягы бар. Менә мин колхозга күчләп кертергә ярамый дим, бу эштә көчләү булмаска тиеш дим. Менә син шуңа ничек карыйсың, дустым?

— Ничек карыйм? — диде Хафаза, шома маңгаен жыергандай итеп.— Син үзең яхшырак беләсең инде, жаным, ә мин нәрсә әйтим?..

— Шулай да минем белән килешәсеңме син, мине хаклы дип табасыңмы?

— Әлбәттә, килешәм...

— Ни өчен?

— Ни өчен... ни өчен? Син булган өчен...

— Ә бүтән кеше шулай дип әйтсә?..

— Иөдәтмә мине,— диде Хафаза, назлы ялварып.— Сиңа ышанам, тагын ни кирәк?

Әйе, тагын ни кирәк? Ышанам ди ич, син хаклы, жаным, ди ич! Аркасыннан сөеп, рәхмәт кенә әйтәсе... Нишлисең, мәхәббәт дигәнең әнә шулай бер-береңбелән килешеп кенә торырга куша, күрәсең!

Һәрхәлдә, Хафазама сөйләгәч, миңа рәхәт, жиңел булып калды. Бердәнбер сердәшчем бит ул минем! Тыңлап кына утырса да, мин бик канәгать идем. Әнә шулай юандым мин. Шуннан башкасын уйлый да, күрә дә белмәдем...

Мин авылдан кайтып, бер-ике атна үткәч тә Хафаза ничектер үзен сәеррәк тота башлады, ничектер йомыла, сагая төшкән кебек булды, ваемсыз, сәбәпсез көлүләр кимеде, кочагыма алып сөйгәндә дә элекке кебек эреп бармый, әллә ничек менә әчке бер тыелу сиздерә... Аннары, иң гаҗәбе, үзенең һәрвакыт миңа тутырып карый торган хәйләсез саф күзләрен миннән яшерә башлады. Мин күрмәгәндә генә карый, ә күзгә-күз очрашудан кача. Әйтерсең, минем нидер сизүемнән курка... Мин шуңа да игътибар итмәдем. Әллә болар барысы да бик аз вакыт эчендә генә булганга, әллә күңелемдә бер генә бөртек тә шик булмаганга күрә, Хафазамдагы ул үзгәрешләрнең берсе дә мине уйландырмады, сагаерга мәжбүр итмәде.

Ә тагын бер атнадан Хафаза кисәк кенә миңа килеп йөрүдән туктады. Мин анардан: «Бәгырем, сиңа ни булды?» — дип сорадым. Ул түбән карап, боек кына: «Авырыйм»,— диде. Мин борчыла калдым, чыннан да аның йөзе суырылган, саргайган кебек күренде. Ләкин ул эшкә йөрүдән туктамады. Мин аңа бюллетень алырга куштым. Ул,

теләр-теләмәс кенә: «Үтәр әле»,— диде. Тәнәфес вакытларында, миннән яшеренгәндәй, гел кызлар арасына кереп, кысылып утырды, ә эш беткәч, менә көтмичә, ашыга-ашыга китеп бара торган булды.

Ярабби, шул чакта да мин берни дә сизмәдем.

* * *

Бишенче апрельдә, дүшәмбе көн, безнең мехбазада ачык партия җыелышы булды. Мин авылдан март башларында кайткан идем, димәк, бу җыелышка хәтле нәкъ бер ай вакыт үтеп киткән икән.

Бездә моңарчы да төрле җыелышлар еш кына булып тора иде. Без моңа гадәтләнгән идек инде, халык бездә дисциплиналы, җыелышлардан качу юк, чакырган җиргә сәгатендә дәррәү кереп утыра торганнар иде.

Ләкин, шуңа да карамастан, менә бер нәрсә шактый гаҗәпләндерде. Элек, мәсәлән, цехка белдерү элсәләр яки эш бетәр алдыннан цех начальнигы кешеләргә: «Җыелышка керегез!» дип кычкырып бер әйтсә, шул җитә торган иде. Бу юлы исә, көн ахырына табарак, контора дан яшь бер кыз цехка менеп, кулындагы исемлек буенча һәркемнән кул куйдырып, чакырып йөрде. Кешеләр: «Ни өчен болай итәсез?» — дип сорасалар да, кыз: «Белмим, миңа шулай куштылар»,— диюдән башканы әйтә алмады. Бу нәрсә булачак җыелышны ничектер серлерәк итеп җибәрде, кызыксынуны көчәйтте, төрлечә уйлау-юрауларга сәбәп булды.

Әйткәнемчә, мине дә бу хәл бик гаҗәпләндерде. Чыннан да ни өчен болай куллар куйдырып чакыралар? Берәр гадәттән тыш мәсьәлә каралмакчымы, әллә бик мөһим берәр хәбәр бармы? Әмма юрап кына кайдан беләсең?! Тагын шунысы, бу җыелыш хакында белдерү эленмәгән иде һәм аның көн тәртибе дә билгесез иде. Кызык, нәрсә булмакчы соң?

Эш бетәр алдыннан гына мин цехтан узып барган Басыйрны күрдем.

— Карале, Басыйр,— дип туктаттым мин аны.— Бүген нинди җыелыш бездә?

— Нигә, әйтмәделәрмени? — диде ул миңа борылмыйча гына.— Ачык партия җыелышы.

— Анысын беләм. Ә нәрсә каралмакчы, нигә кешеләрне атап чакыралар?

— Белмим, парин, белмим,— диде Басыйр һәм, каядыр ашыккандай, тизрәк китеп тә барды.

Басыйр белән безнең бу араларда юньләп очрашкан да, сөйләшеп йөргән-утырган да юк. Бик эшле кешедәй, ул соңгы көннәрдә ничектер артык җитдиләнеп, эреләнеп китте әле. Еш кына миңа шулай, кешеләргә карамыйча, үрә каткан килеш туп-туры гына үтә дә китә. Мин кайткан чакларда көн дә диярлек Хафаза янына килмичә калмый иде, хәзер аны да нишләптер «күрми» башлады. Бу кешегә бервакытта да ышанып бетмәсәм дә, аның болай «үзгәрүенә» мин әллә ни игътибар итмәдем. Карьера яратучы кешеләр гадәттә шулай я бик ялагайланып, я артык эреләнеп китүчән булалар. Һәм миңа бүген дә аның, миннән качкандай, юньләп сөйләшмичә тизрәк китеп баруы әзрәк ачуымны китерсә дә, күңелемдә бернинди шик яки борчылу тудырмады.

Гөнаһ шомлыгына каршы, бүген цех начальнигы Васильев та авырып эшкә чыкмаган иде. Шуңа күрә сменадан соң миңа, цехтагы вактөяк эшләрне бетереп, җыелышка соңгарак калып керергә туры килде.

Җыелышлар бездә икенче каттагы зур контора бүлмәсендә үткәрелә. Өстәлләрне бер почмакка күчереп куялар да, эскәмия-урындыклар

тезеп, халыкны шунда тутыралар. Кысан жир, ләкин хәзергә башка урын юк.

Мин килгәндә жыелыш башланмаган иде әле. Халык бүген аеруча күп (кул куйдыргач, берәү дә китмәгән), бер-берсенә ябышып дигәндәй, озын эскәмияләргә тезелгәннәр. Башка вакытта Хафаза минем өчен үзе янында урын алып кала торган иде, бүген исә ул үзе дә алгы эскәмияләрнең берсенә, кызлар арасына кереп, кемнәндер поскан шикелле, кысылып кына утырган... Нигә мине онытты икән?.. Хәер, мин ана урын алып кал дип әйтергә өлгермәдем, ә ул кызлар арасында минем өчен урын саклауны килештермәгәндер инде... Ахырда мине Әмин әкә дәшеп алды.

Каршыда, управляющий кабинетына керә торган ишек төбендә генә, кызыл япкан кечерәк өстәл. Өстәл артында ике кеше — партоешма секретаре Перов белән мехбаза управляющие Решевский утыралар. Өстәлнең уң як башына, тезләре өстенә иске кара портфелен куеп, олы гына яшьтәге бер кеше урнашкан. Безгә таныш түгел. Ләкин жыелыш башлангач та белдек: ул райкомнан доклад сөйләр өчен килгән кеше булып чыкты. Фамилиясе әллә Беляев, әллә Белов иде — хәзер ачык кына хәтерли алмыйм инде.

Тагын бер нәрсә минем игътибарымны жәлеп итте. Өстәлдән аз гына читтәрәк, ялгыз урындыкта, аягын аяк өстенә салып һәм залга карап Басыйр утыра. Ул шундый итеп утырган — аны президиумда дип тә уйларга була (чөнки йөзе белән безгә караган), шул ук вакытта өстәлдән бераз читтәрәк тә — теләсәң ничек аңла!.. Аның болай утыруы миңа шактый сәер тоелды.

Минем кереп утырганны гына көткән шикелле, партоешма секретаре Перов шунда ук торып, жыелышны ачык дип тә белдерде. Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә — колхозларның бүгенге хәле турында доклад, диде һәм шул докладны сөйләр өчен райкомнан килгән әлеге кешегә сүз бирде. Докладчы урыныннан торды, портфеленнән бергә теркәгән кәгазьләр чыгарды һәм, шуларга караштырып, ашыкмый гына сөйләргә тотынды. Хәзер дә онытасым юк — аның докладды «Колхозларда икенче большевистик яз» дип аталган иде... Хәер, хикмәт исемдә түгел, мәсьәләнең үзендә. Ә мәсьәлә бик кызыклы, бөтен кешене диярлек кызыксындыра, мине исә аеруча... Дөрес, биредә, ни өчен әле шәһәрдәге бер кечкенә производство коллективына килеп, колхозлар турында сөйләргә кирәк булды? дигән сорау туарга мөмкин. Ләкин бу да бик аңлашыла: ул елларда авылдагы хәлләр белән шәһәр дә бик нык кызыксына торган иде. Шәһәр жирендә авылдан чыккан кешеләр бик күбәйде, аларның күбесе үзенең авылы белән өзелеп тә бетмәгән (безнең шушы мехбазада да андыйлар шактый), шулай булгач, партия оешмаларының шәһәр кешеләренә авыл хәлләре турында сөйләүләре бик табигый иде...

Мин докладчыны бик игътибар белән тыңларга жыендым. Ниндидер бер киеренкелек тууын сиздем үземдә. Нәрсә ишетермен? — дигән көтү иде шикелле бу.

Докладчы башта бөтен ил күләмендә барган каты сыйнфый көрәштән соң колхоз төзелешенең тәмам жиңүе, крестьяннарның иң зур күпчелеге үз язмышларын инде ныклап колхоз белән бәйләүләре турында сөйләде. Авылда социализмның нигезе салынды, диде ул. Шуннан соң колхозларның бүгенге хәленә күчте. Колхозлар икенче большевистик язны каршылыйлар, диде, һәм бу язның алар өчен гаять әһәмиятле булуын сөйләп китте. Минә шунда инде докладчының сүзе, ничек дим, жылы яздан салкын көзгә авыша башлады. Шактый жәелеп ул авылларда кискен сыйнфый көрәшнең һаман да әле дәвам итүе, төрле ярыкларга поскан кулак калдыкларының һәм кулак иярченнәренең колхозларга каршы тыпырчынып, көрәшеп маташулары, халык арасында

һәртөрле коткы таратулары, кайбер җирләрдә хәтта колхоз активларына кул күтәрүләре, кыскасы, сыйнфый дошманның барлык чаралар белән колхозларны ничек тә какшатырга, язгы чәчүне өзәргә, илне икмәксез калдырырга тырышулары турында сөйләде. Бу шомлы, куркыныч хәлләрнең мисалларын да китерде: фәлән районда кулак калдыклары колхоз амбарларын яндырганнар, фәлән авылда колхоз атларын агулап үтергәннәр, фәлән колхоз председателенең тәрәзәсенә төнлә белән таш тондырганнар... Болардан нәтиҗә: сыйнфый уяулыкны һәр җирдә көчәйтергә, кулак агентларын посып яткан җирләреннән казып чыгарырга һәм пролетариат хөкеменә тартырга, һәртөрле дошман коткысын таратучыларны, колхоз төзелешенә яла ягучыларны, гомумән партиянең бөек эшенә шикләнеп караучы елакларны рәхимсез фаш итәргә һәм большевистик тәнкыйть белән беткәнче көйдерергә кирәк. Тагын бер нәтиҗә: мондый бәндәләрнең, авылларда гына түгел, шәһәрдә дә, кайбер коллективлар эчендә дә булуын истән чыгармаска.

...Җыелыш тып-тын. Кешеләр селкенергә дә курыккандай гаять киеренке бер хәлдә утыралар. Бер-берсенә карамыйлар, дәшмиләр, гипнозга эләккәндәй, бары докладчының авызына карап катканнар. Ирексездән минем дә йөрәгемә салкын йөгерде. Әйтерсең, шушы минутта котырып чабып килгән машина сине таптап-изеп китәчәк!.. Моның өчен үзеңне гаепле дип белү дә кирәкми. Гомумән минә шулай рәхимсез көрәшкә өндәп, янап, куркытып сөйләгәнне ишеткәндә кеше дигәнең, минемчә, ничектер бер мәлгә ихтыярсыздан каушап, югалып кала, нindидер билгесез шомлану аның бөтен җанын өшетеп җибәрә. Миндә дә шундыйрак рефлекс булды.

Докладчы сөйләп бетергәч, председатель өнсез тынып калган җыелышка карап: «Я, иптәшләр, кем сөйләргә тели?» — дип сорады. Әлбәттә, залда утыручылардан берәү дә әле сөйләрлек хәлдә түгел иде. Ләкин председательнең әйтүе булды — шунда ук Басыйр торып та басты. Шик юк, бу аның алдан ук сөйләргә әзерләнеп куйган булуын күрсәтә иде. (Бик хәтәр нәрсә әйтергә җыенган кешенекедәй, йөзе дә агарган, кашлары да тартылган, ә сул кулы әзрәк калтырый да кебек...) Гадәттәгедән дә үрә катыбрак һәм кычкырыбрак сөйли башлады ул, һәм, әйтергә кирәк, сөйли белә иде, шактый матур көр тавышы тыңлаучыны ихтыярсыздан үзенә тарта иде.

Ул колхозларның хәле, нәрсәгә мохтаҗ булулары, аларга нинди ярдәм итү кирәклеге турында бер сүз дә әйтеп тормады. Туп-туры сыйнфый көрәштән башлады. Уяу булырга чакырды. Докладчы иптәш бик дөрес әйтте, кулак үзе яки аның агентлары безнең арада да бар әле алар, диде. Шуның мисалы итеп, күптән түгел генә мехбазада Гыйльметдин исемле кулакның табылуын һәм кулга алынуын искә төшерде. Ләкин Гыйльметдин белән генә эш бетте дип тынычлану дөрес булмас, аның койрыклары бездә тагын булырга тиеш әле, диде. Шуларның берсе, диде, һәм, эффект өченме, әллә бер генә секундка кыюлыгы бетепме, аз гына тукталып калды, аннары кычкыра биреп, минем исем-фамилияне әйтеп салды. Мин бер генә мизгелгә сискәнеп киттем, ләкин шунда ук бөтен дөньямны онытып, беркемне, бернәрсәне күрмәс булып, бары Басыйрның авызына карадым да калдым. Ә чалышрак авыз бер ачыла, бер ябыла, ашыга-ашыга минем өчен искиткеч ят, сәер һәм куркыныч сүзләрне чәчә дә чәчә: имеш, мин колхозга каршы, имеш, мин кулаклар җырын җырлыйм, имеш, мин партиянең авылда үткәргән политикасы белән риза түгелмен! Кыскасы, мин сарык тиресе ябынган бүре икәнмен ләбаса! Минә аның дәлилләре дә: « — Ул, — диде әлеге минем күз алдымда өзлексез ачыла да ябыла торган авыз,— күптән түгел туган авылына кайтып килде. Ул анда крестьяннарны колхоздан чыгарга котырткан (?!). Ул, колхоз председателенә барып, нигә сез агайларны колхозга көчләп кертәсез, дип тавыш чыгарган (?!).

Ә монда кайткач, крестьяннар колхозга үзләре теләп кермиләр, барысы да колхоздан качарга гына торалар дип сөйләп йөргән (?!). (Шушы урында минем «Ялган!» дип бик каты кычкырасы килде, ләкин — ни гаҗәп! — кычкыру түгел, селкенә дә алмадым...) Менә кем булып чыкты ул, рабочий битлеге кигән Юлдашев иптәш!.. Я, без андый контр сүзләр таратучы кулак агентын үзебезнең арада тота алабызмы?! Юк, иптәшләр, андый кешегә безнең арада урын булмаска тиеш!

Иң элек бик табигый рәвештә минем күңелгә шундый уй килде: «Хәйрүш абзый язып җибәргән!.. Әйе, әйе, бу бары тик аның эше!» Ләкин шуның артыннан ук икенче бер уй да килде: «Ә ул, Хәйрүш, минем монда кайткач ниләр сөйләп йөрүемне кайдан белә?.. Бусы тагын кемнеке? Басыйрның үз уйдырмасы гынамы?» Һәм менә шул чакта минем башыма, әйтерсең, яшен китереп сукты: «Хафаза!.. Хафаза!.. Я хода-а!» Мин берьюлы коелып төштем, нichектер бөрешеп, кечерәеп калдым, хәтта эчемнән генә — янымда утыручылар ишеткәннәрдерме, юктырмы — ыңгырашып та куйдым... Бу, бу ...аллә нәрсә бу, сүз юк, сүз таба алмыйм, акылга сыймый, ышанасым килми, дөрес булса да һич кенә бер ышанасым килми... Коточкыч!!

Ләкин хәзер үк, шушы минутта ук нидер эшләргә кирәк иде. Мин берни уйлап тормыйча ашыгып кулымны күтәрдем. Перов күреп алды да:

— Сезгә нәрсә? — диде.

Мин тордым. Минем уйлап куйган сүзем юк иде, минем бары бу коточкыч ялганны туктатасым килә иде. Җыелышка мөрәҗәгать итмичә, туп-туры Перовның үзенә әйтергә ашыктым:

— Монда ниндидер бик зур ялгышлык бар, болай ярамый, мин әйтергә тиешмен...

Ләкин Перов миңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде, салкын-коры гына:

— Сез үз сүзегезне соңыннан әйтерсез,— диде.

— Ни өчен соңыннан?.. Мин хәзер әйтергә телим...

— Сез инде, пожалуйста, тәртип бозмагыз... Вакыты җиткәч, без үзебез сезгә сүз бирербез.

— Ләкин бит...

— Бернинди «ләкиннәр» юк,— диде Перов, сабырсызланып.— Тыныч кына утырыгыз!

Җыелыштан «сөйләсен!» дип бер генә тавыш бирүче дә булмады. Җыелыш өнсез иде... Мин утырдым. Дөресрәге, мине баштан ук гаепләнүче сыйфатында утыртып куйдылар. Кагыйдәсе шундый — мин түзә алган кадәр тыңлап кына утырырга тиешмен.

Басыйрдан соң сөйләүчеләр күп булмады — әллә өчәү, әллә дүртәү иде шунда. Араларында мине юньләп белмәгән, минем белән аралашмаган кешеләр дә бар иде. Мәсәлән, Шәрипов дигән берәү чыгып, бик тотлыгып, әйтерсең, оятыннан, бик кызарып сөйләде. Ә бит бу чи тиреләр складында эшләүче, озын кара керфекле матур егетнең минем белән, исәнләшеп узудан башка, туктап ике авыз сүз дә сөйләшкәне юк!..

Алардан соң безнең управляющий Решевский урыныннан торды. Аның сөйләргә җыенуы залда берьюлы зур кызыксыну уятты булса кирәк, кешеләр ничектер аеруча тынып калдылар. Мин инде бөтен барлыгым белән аңа төбәлдем. Шунда ук күңелдә җылы өмет туган-дай булды: ул бит минем иң югары начальнигым, ул мине белә, эшемне дә белә, ә үзе акыллы, төпле, җаваплы кеше — әлбәттә, ул мине болай ансат кына, сәбәпсез-нисез, хур итеп ташларга юл куймас, куярга тиеш түгел!.. Һәм менә ул постау кепкасын кулына тотып, мамык шарфын ике иненнән генә салындырып, өстәл янына туры гына басты да, залга зур салкын күзләре белән беравык тыныч кына карап торган-

нан сон, ашыкмыйча, тигез тавыш белән сөйләп китте... Ләкин ни ишеттем мин, ни ишеттем?!. Уйлап кына карагыз: мәсьәләнең үтә житдилеге, кеше язмышының хәл ителүе турында бер сүз әйтмәстән, ул минем надан, рухи житлекмәгән, бик кечкенә бер кеше булуымны исбат итәргә тотынды. Моның өчен нәрсәне файдаланды диегез? Иблис тә уйлап таба алмас — минем көндәлек дәфтәр тотуымны! Димәк, Хафаза шуны да житкергән булып чыкты!.. Их, егетләр! Һәм менә гомеремдә күрмәгән шул дәфтәр белән Решевский мине тетеп кенә тетә... Янәсе, көндәлек дәфтәр тотар өчен бик зур кеше, бик зур акыл иясе булырга кирәк. Мәсәлән, Лев Толстой кебек. Әнә ул гомере буена көндәлек язып барган, чөнки ул бөек художник, бөек философ — аның язар сүзе, язар фикерләре булган. Ә бу кем? Кичәге рабфак студенты, күкәйдән яңа гына чыккан бер чебеш! Нәрсә генә яза ул? Күп булса, үзенең буталчык, пешмәгән, хата уйларын, өч тиен дә тормас вак зарларын, яшь кызларны гына алдарлык (Ай-һай-һай!) сай, түбән хисләрен язып маташкан. Янәсе, күрегез, мин нинди кеше! Менә шул дәфтәр инде безгә аның черек жанын ачып та бирә. Эшчеләр казанында кайнап ныгыйсы, пролетариат тәрбиясе аласы урында бу егет, элекке елак гимназистлар шикелле, үзенең карангы эчендә казынучы, үзен әллә кемгә санаучы, асылда исә бернигә яраксыз, берни күрми-аңламый торган сукыр эгоист булып кала биргән... Һәм шуның нәтижәсендә әнә нинди политический хата юлга да кереп баткан ул!

Решевскийның бу чыгышы мине шаккатырды дисәм генә аз булыр. Ул мине өнсез итте, һични аңлый алмаслык бер хәлгә китерде. Гүя сүз минем хакта да бармый!.. Чынлап та әллә икенче бер кеше белән бутыймы ул мине?.. Әле кайчан гына, мин авылдан кайткач кына бит, Решевский үзе, үз авызы белән миңа: «Васильев — авыру кеше, цехны алып бара алмас, ахрысы, аның урынына, иптәш Юлдашев, сезне калдырырга туры килер, сез сәләтле егет, эшне тиз белеп алдыгыз, сезгә ышанып була», дип әйткән иде. Ә хәзер кем булып чыктым инде мин? Бернигә яраксыз, булдыксыз, ышанычсыз, череп таркалган сукыр эгоист! Гажәп, гажәп!.. Кичә генә яхшы идем әле мин, бүген исә әнә нинди әшәке кешегә әйләнгәнмен! Ә дәлиле, ә нигезе кайда?.. Ул бит минем шул дәфтәрне төшендә дә күргәне юк. Берәүнең әләгенә таянып кына кешегә шундый коточкыч гаеп тагу — бу бит әллә нәрсә. Юк, сыймый болар берсе дә минем акылга, сыймый, егетләр, теләсәгез нишләтегез!!.

Дәфтәр турында да сүз чыккач, Хафазаның миңа кылган хыянәте аеруча әшәке-жирәнгеч булып тоелды. Дөрес, мин әле бу хыянәтне аңлый да алмыйм, ул хакта уйлый да алмыйм, тик бер нәрсәне бөтен жаным белән тоям: шушы минуттан ул кызый минем өчен үлде, бетте, юкка чыкты... Һәм, тиле кешедәй, бер нәрсәгә сөенәм: ярый әле бүген безнең урыннарыбыз бергә туры килмәде,— нишләр идем мин югыйсә?!

Шулай ук мин тирә-юнемдәге кешеләрне дә күрми дә, сизми дә идем. Алар миңа карыйлармы, карасалар — ничегрәк итеп,— белмим, аңарда кайгым юк. Күзләрем минем каршыдагы өстәлдә генә, шул өстәл янына чыгып басучыларның авызларында гына... Вакыт-вакыт мин башымны түбән иеп тә тыңлыйм, ләкин кемнән дә булса оялудан түгел, ә гел бер хәлдә утырып арудан гына... Соңыннан миңа: «Син тыныч идең, тик, кәгазьдәй, бик агарындың»,— дип әйтүчеләр дә булды. Белмим тагы, тик бер генә нәрсәне беләм — миңа әнә белән чәнечсәләр дә берни тоймас идем шикелле... Нервлар, әйтерсең, тимер чыбыкка әйләнделәр.

Решевскийның шаккатыргыч чыгышы минем мәсьәләгә соңгы нокта куярга тиеш иде, ахрысы. Чөнки ул сөйләп беткәч, председательлек итүче Перов, гүя шуны аңлатырга теләгәндәй, бары: «Бүтән сөйләүчеләр юктыр инде», дип кенә әйтте дә миңа күтәрелеп карады. Хәер

кыстаса да сөйләргә теләүче табылмас иде. Кайдан табылсын андый кеше?.. Кешеләр минем үзем шикелле үк тәмам аптырап, югалып, ничектер төсләре качып, шомланып калганнар иде.

Ләкин шулай да берәү урыныннан күтәрелде. Бу — Вафа Янбулатов иде. Ул сүз сорады һәм өстәл янына чыгып тормыйча, баскан җиреннән бик тыныч, ашыкмыйча гына сөйли башлады. Минем эчкә аз гына җылы кергәндәй булды. Нидер әйтер, читләтеп кенә булса да минем файдага нидер әйтергә тиеш дип көттем мин. Ә ул, мондагы сүзләрне бөтенләй ишетмәгән бер кешедәй, тотты да безнең коллективның язгы чәчү өстендә колхозларга нинди ярдәм күрсәтә алуы турында сөйләп китте. Һәм бик эшлекле итеп, конкрет тәкъдимнәр кертеп сөйләде... Аның бу чыгышы миңа гына түгел, күпләргә шактый сәер булып тоелгандыр дип уйлыйм, чөнки ул кешеләрнең игътибарын мине талкудан әзрәк башка якка борып җибәргәндәй итте. (Асылда бу докладның төп темасына кагылган бердәнбер чыгыш иде.) Җыелышның һавасы да ничектер җиңеләя төшкән кебек булды.

Менә Вафа сөйләп бетте шикелле — артына борылып урындыгына карап алды... Шулай ук бер нәрсә дә әйтмәс микәнни?.. Юк, нидер әйтергә җыена шикелле... Аз гына тынып торды да башын күтәреп, тыныч кына:

— Да, тагын шуны әйтмәкче идем,— диде.— Биредә иптәш Юлдашев хакында күп сүз булды. Ләкин мине шактый гаҗәпләндерде бу сүзләр... Мин дә бит Юлдашевны белән, без кайчандыр бер бүлмәдә дә торган идек. Тик мин әйтергә тиешмен, Юлдашевның андый начар якларын мин беркайчан да сизмәдем, шулай ук анардан нинди дә булса ялгыш, зарарлы фикерләр дә ишетмәдем.

— Димәк, сездә уяулык җитмәгән,— дип кыстырды шул чакта Басыйр, әче генә көлемсерәп.

Вафаның моңа бер дә исе китмәде, һаман шулай тынычлыгын саклап:

— Уяулык, әлбәттә, кирәк нәрсә ул,— диде,— ләкин кешене болай гаепләр өчен дә бик җитди фактлар кирәк, мин менә шуларны күрмим.

Шулай диде дә ул ашыкмыйча гына урынына утырды. Җыелыш гаҗәеп тын иде. Тагын кем нәрсә әйтер дип, бик җигелеп көтеп тору сизелә иде. Әмма ләкин кузгалучы, авызын ачучы булмады.

Ахрысы минем үземә чират житкәндер — Перов бая ук инде миңа карап куйган иде. Нәрсә дип әйтергә, ничек итеп? Күңелдән мең төрле уй, мең төрле сүз өермәсе бөтерелеп узды, ә шулардан сайлап, әзерләп куйган бер нәрсәм дә юк диярлек. Тик акылым миңа әйтә: «Тыныч бул, тыныч бул!» ди. Әйе, һичшиксез, тыныч булырга, каушамаска кирәк. Җылак-җебегәнне бер вакытта да аямыйлар. Мин бит биредә өстемә өелгән нахак гаепләрнең берсе белән дә килешмәскә тиеш — барысын да катгый рәвештә кире кагарга, сөбереп түгәргә!! Бу минем ни кочле теләгем, йөземне аклый алырлык бердәнбер теләгем!.. Тик нервлар гына бирешмәсен иде...

Ниһаять, председатель:

— Инде иптәш Юлдашевның үзен тыңлап карыйк,— диде. Бу миңа ошамады, алдан ук миңа ышанмау белдергән шикелле булып тоелды.

Мин тордым, өстәл янына узмыйча, бары эскәмиядән чак кына читтәрәк чыгып бастым. Башымны иеп, аз гына тынып тордым. Бөтен кешенең күзе миндә генә, бөтен кеше гаять киеренке бер игътибар белән миннән сүз чыкканын көтә... Бу хәл мине тагы да богаулый төште, ләкин каушамадым, кешеләрнең миңа ят-дошман итеп карамауларын ничектер йөрәгем белән сизәм кебек. Башымны күтәреп карагач,

бик табигый рәвештә, иң башлап шуны әйттем: «Монда ишеткәннәрем минем өчен шулкадәр көтелмәгән бер нәрсә булды ки, мин мена хәзер генә ни дип әйтергә дә белмим, иптәшләр!»... Аннары өстәл янында утыручыларга карап: «Мин бик гаҗәпләнәм,— дидем,— сезнең минем белән алдан сөйләшмичә, сорашмыйча, миңа шундый зур гаеп тагып, җыелыш алдында чыгуыгызга... мин моны просто аңламыйм!..»

Болай диюем председательгә бер дә ошамады булса кирәк, ул шунда ук миңа каршы төште:

— Сез, Юлдашев, бүтәннәрне гаепләргә ашыкмагыз... Иң элек үз гаебегез турында әйтегез.

— Нинди гаеп?

— Ник, ишетмәдегезмени?

— Ишеттем,— дидем мин һәм кинәт туган бер катгыйлек белән, хәтта кыза да төшеп туп-туры әйттем:— Минем берниндн дә гаебем юк, монда сөйләгәннәрнең барысы да чеп-чи ялган, берсе белән дә миң килешмим!..

Моның тәэсире булды, ахрысы, кешеләр ничектер кузгалышып куйдылар, ләкин Перов тизрәк шуны сүндерергә теләгәндәй:

— Сез әле авылга да кайтып килмәдем диярсез тагын?! — диде ясалма гаҗәпләнү белән.

— Юк, алай диярга җыенмыйм,— дидем мин.— Ләкин авылга кайткач, минем ни эшләвемне, кемнәр белән нәрсә сөйләшүемне сез беләмисез бит?!

— Ә, бәлки, беләбездер,— дип куйды Басыйр, каядыр читкә карап кына.

Мин аның йөзенә нәфрәт белән кадалдым:

— Беләсез? Ләкин кайдан, кемнән ишетеп?.. Минем үземнән сезнең бер авыз сүз дә ишеткәнегез юк!

Перов, чыраен сытып, алга табарак иелде.

— Сез нәрсә,— диде ул, әкрен-усал итеп,— монда обструкция ясамакчы буласызмы? Барып чыкмас бит ул!.. Мондый юл белән акланырга тырышу берни дә бирмәс сезгә, Юлдашев! Үз гаебегезне честный рәвештә өстегезгә алсагыз, яхшырак булмасмы?

Әйе, мин үземнең хәтәр юлга кереп баруымны, ниһаять, сизеп алдым. Бу рәвешчә үчләнеп каршы тору, әлбәттә, берни дә бирмәячәк. Әмма нинди дөрес юл бар?.. Алар миннән: «Мин гаепле, кичерегез!» дигән сүзне көтәләр, көтмичә хәлләре юк, чөнки миңа гаепне тагып өлгерделәр инде. Ә мин моны әйтә алмыйм, әйтмәячәкмен!.. Инде бөтенесен — авылга кайтуымны, анда ниләр күрүемне, кайткач, кемгә нәрсә сөйләвемне сөйли башласам, бердән, бик озынга китәчәк, икенчедән, һичшиксез, Хафазаны телгә алырга туры киләчәк. Ә мин моны хәзер шушы җыелыш алдында ачарга теләмим. Әгәр ачсам, безнең арадагы бөтен кешегә билгеле дуслык, мәхәббәтне көлкегә калдыру, хур итү генә булачак — юк, мин моны эшли алмыйм, булмый, телем бармый... Һәм шушы гаять киеренке минутта минем башыма кинәт бер фикер килде, бу фикерне мин үземчә бик хаклы дип таптым, шуны тизрәк әйтергә дә ашыктым.

— Сүз бирелдә минем язмышым турында бара, иптәшләр! Мәсьәлә бик җитди. Әгәр минем берәр гаебем булса, мин аны яшереп тормас идем. Ләкин юк ул... Һәм мин үземнең гаепсез булуымны сезгә исбат итәрмен, тик сездән бүген үк ашыгыч нәтиҗә ясамавыгызны, минем мәсьәләне яңадан партоешмада каравыгызны һәм шунда мине яхшылап тыңлавыгызны сорыйм. Кыскасы, миңа вакыт бирегез, мин барысын да сезгә ачыктан-ачык сөйләрмен.

Шулай дидем дә урыныма утырдым.

— Ә нигә мена хәзер сөйләмисез? — диде кемдер.

— Бүген мин әзер түгел, кичерегез! — дидем мин, башымны күтәрмичә генә; дөресрәге, кире чигенәсем килмәде минем...

Җыелыш әүвәлгечә тып-тын утыра. Кемнәр ни уйлый торгандыр — мин аны белә алмыйм, әмма әйткән сүзләремнән канәгать булмауларын ничектер сизәм шикелле... Чыгышым минем, әлбәттә, «уңышсыз» булды. Һәм председательлек итүче Перов үзенең йомгаклау сүзендә моны бик «оста» күрсәтеп тә бирде:

— Без хәзер генә иптәш Юлдашевның сүзен тыңладык,— диде ул, гадәтенчә ашыкмыйча гына башлап, әмма отыры кыза барып.— Үзен аклап, нәрсә әйтә алды ул, нинди дәлилләр китерде?.. Юк, кызганычка каршы, юк бит, бөтен сөйләгәне бернинди дәлилсез коры сүз генә булып чыкты. (Ә нинди дәлил кирәк икән соң?) Киресенчә, ул барыбызны да чеп-чи ялган сөйләүдә гаепләде... Уйлап кына карагыз, иптәшләр, монда утыручылар, шул исәптән хәтта безнең управляющий Решевский да, ялган сөйләүчеләр, тик аныкы гына дөрес, ул гына хаклы... Бу бит демагогия, иптәшләр, кычкырып торган демагогия! Шулай гына бәяләргә мөмкин аның бу чыгышын... Димәк, иптәш Юлдашев биредә аңа карата әйтелгән ачык, таза тәнкыйтьне кабул итми, үзенең бер генә, кабатлап әйтәм, бер генә хатасын да танырга теләми. Димәк, ул әле һаман да үзенең нинди ялгыш юлга кереп киткәнен, нинди оппортунизм сазлыгына кереп батканын аңламый. Яки аңларга теләми... Мәнә шундый гына нәтиҗә ясарга туры килә, иптәшләр!

Мин шаккатып тыңлыйм. Ихтыярсыздан, чынлап та шулай микәнни, дип хәйран калып уйлыйм. Ничек итеп үз хәленне дөрес аңларга соң?.. Алар әйткән сазлыкка мин кайчан, ничек кереп батканмын?.. Гаҗәп бит бу!.. Син үзең шуны белмә, бүтәннәр белсен, имеш! Җитмәсә әле, син үк акланырга да тиешсең! Ай-яй — кая таба китте эшләр!..

Ә председатель шул арада сүзен болай дип дәвам иттерде:

— Монда чыгып сөйләүчеләр дөрес әйттеләр: кулак идеологиясен таратучыны без үз арабызда калдыра алмыйбыз, иптәшләр! Бигрәк тә үз хатасын танырга теләмәгән кешегә карата без либераллык күрсәтергә тиеш түгелбез... Рәхимсез сыйнфый көрәш бездән шуны таләп итә. (Бу урында ул Гыйльметдин кулак вакыйгасын да телгә алды, Вафаның фактлар юк дигән сүзен дә оста гына кире какты. Аныңча, уяулык дигән нәрсә коры фактлар җыюда гына түгел, ә шуның иң кечкенәсеннән дә политик нәтиҗә ясый белүдә күренергә тиеш.) — Шуңа күрә мин үзем,— дип сүзен бетерде ул,— иптәш Юлдашевны эшеннән азат итәргә кирәк, дигән тәкъдим белән тулысынча килешәм. Администрация дә җыелышның бу теләген кабул итәр дип ышанам. Башка тәкъдимнәр юкмы, иптәшләр? Алайса, иптәш Юлдашевның эшеннән азат ителүен администрациядән сорарга дигән тәкъдимне тавышка куям... Кем дә кем...

Һәм ул иң элек үзе башлап кулын күтәрде. Аңа ияреп, өстәл тирәсендә утыручылар, залдагы кешеләргә бик төбәлеп, сынап караган килеш кулларын күтәрделәр. Мин залга, хәтта күршемдә утыручыларга да карый алмадым. Ләкин нәкъ шул чакта, әкрен җил исеп киткәндәй, кешеләрнең ничектер хәрәкәткә килеп, үзара пышылдашып алуларын сизеп калдым. Ни булды дип күтәрелеп карасам, ишектән, ашыгып, бәрелә-сугыла, Хафаза чыгып бара!.. «Түзмәде, мескенкәй!» диде артымда утырган кемдер берәү... Мин, әйтерсең, таш сынга әвереледем — шулкадәр хәйран итте бу хәл минe!.. Бары тик Перовның: «Каршылар юк!» дигән сүзен ишеткәч кенә айнып киттем.

...Җыелыш бетте, кешеләр авыр гына урыннарыннан кузгалдылар. Кысылып, бер-берсенә ышкылып, ашыкмыйча гына ишеккә таба агыла башладылар... Шул чакта кемдер, Әмин әкә булса кирәк, сак кына

минем терсәктән кыскандай итте. Ләкин бу минутта миңа беркемнең жылы карашы да, кызгану ишарәсе дә кирәкми иде. Мин халык арасыннан тизрәк ычкынып, урамга чыгу, күздән югалуны гына теләгән идем. Ахрысы, якын иптәшләр үзләре дә моны сизгәннәрдер — миңа ияргүче, озата баручы булмады.

* * *

Шулай итеп, Бәкер дус, мин — бүген генә әле берни сизмичә цехта рәхәтләнеп эшләп йөргән, барлык иптәшләр өчен дип әйтерлек үз, якын булган кеше — шушы язгы жылымса-жепшек бер кичтә эштән, эштән генә түгел, тормыштан сөрелдем. Сөйгән кызыма, якын дусларыма, бөтен коллективка (ә бәлки бөтен жәмгыятькә) чит-ят кеше булып — очраганда хәтта кул бирергә дә ярамый торган хәтәр бер кешегә әверелеп калдым. Махау (проказа) авыруы йоктырган кеше мин хәзер! Хет үкереп ела, хет тилереп көл!

Ул кичтәге хәлемне мин ничек дип аңлатырга да белмим. Авырмы миңа?.. Белмим. Жиңел түгеллеген беләм, әмма авыр икәнлеген ничектер тоймыйм, тоя алмыйм. Уйлыйммы мин? Белмим. Миемнең бер генә күзәнәге дә эшләмичә тормаганын беләм, әмма конкрет нәрсә уйлавымны аңламыйм, аңлый алмыйм.

Тик бер нәрсәне беләм икән (аны да яткач кына сиздем): башым үземнеке түгел кебек, ул кабак хәтле булып зурайган, эче буш һәм бер өзлексез әкрен генә шаулап тора... Тагын шул, йоклаганда да мин жыелышта ишеткән-күргәннәрдән котыла алмадым — әлеге Басыйр, Решевский, Перовларның чырайлары күз алдымда гел селкенеп, тавышлары колагымнан китмичә азапладыы.

Икенче көнне йокыдан торгач, әйбәтләп боздай салкын су белән юынгач һәм берни ашамыйча диярлек кайнар куе чәй эчкәч, мин иске хәлемә кайткандай булдым. Һәрхәлдә, миңа күпмедер дәрәжәдә сәламәт зиһенем кайтты. Билгеле, мин эшкә барып тормадым (куылган жиргә ни өчен барыйм?), кирәк булсам, үзләре чакырып алырлар дидем... Васильев та чыкмаган булса, цехның бөтенләй күз-колаксыз калуы мөмкин, хәер, анысы хәзер минем эш түгел инде... Шуңа күрә тар бүлмәмнән беркая чыкмыйча иркенләп, үземчә тыныч кына уйларга тотындым. Вакыт — чиксез, беркемнең — адәм заты гына түгел, бер этнең дә — киләсе юк, гарык булганчы уйла да уйла!.. Һәм мин утырып та, ятып та, ишекле-түрле йөреп тә «рәхәтләнеп» уйладым.

Билгеле инде, иң әлек бик табигый рәвештә минем уйларым, экранга төшкән нур көлтәседәй, Хафазага төбәлде. Кечерәк буен да, тулытыгыз гәүдәсен дә, кара жимештәй зур күзләрен дә күрәм мин, ләкин боларның берсе дә хәзер минем сыңар төгемне дә кыймылдатмый, исмасам! Агачка караган шикелле карыйм мин аңа, һәм бөтен акылымны жигеп, тик бер нәрсәне аңларга тырышам: кем булып чыкты ул? Ничек итеп аңларга аның бу эшен?.. Әлбәттә, миңа Хафаза турында тыныч кына уйлау жиңел түгел, бер дә жиңел түгел... Ихтыярсыздан бөтен эчемне тирән ачу-нәфрәт ялкындай каплап ала башлый. Әмма ләкин, вакыт-вакыт әнә шулай ярсып китүемә карамастан, мин аны ничек тә дөрес, гадел аңларга тырышам. Бигрәк тә кичә аның жыелыштан кинәт кубып, бәрелә-сугыла чыгып китүе мине бик нык уйга калдырды. Ничек аңларга аның бу эшен?.. Ни кылганын аңлап алдымы, намусына көч килдеме, әллә минем өчен куркып киттеме? (Ихтимал, ул болай ук булыр дип һич тә уйламагандыр.) Ләкин ничек кенә юрама, аның бу эше ниндидер бик тирән жан газабыннан туган булырга тиеш иде. Шулай сизәм мин моны, һәм шуңадыр инде, бәгырем бик катса да, ничектер меңә рәхимсез хөкем итә алмыйм үзен... Жәлләү дә түгел бу,

гафу итү дә түгел, тик ничек кенә әйтергә?.. Үзе дә бәхетсезлеккә төшкән кешене беркадәр аяу гына.

Баштан ук бер нәрсә миңа бик ачык иде: бу эштә Хафаза үзе генә гаепле түгел, әлбәттә. Кемнәрдер аны бу хаинлык юлына этәргәннәр, көчләгәннәр, мәҗбүр иткәннәр — һичшиксез, ул шулай! Сез беләсез инде Басыйр дигән бәндәнең соңгы вакытларда, миңа тыштан дус булган булып, күбрәк Хафазага елыша башлавын. Моның өчен сылтавы да бар иде — янәсе, алар кайчандыр бер мәктәптә укыганнар. Әлбәттә, Хафазага елышуның төбендә бер генә максат — минем хакта анардан ничек тә күбрәк сүз алу булган дип уйларга кирәк. Мин бит үзем дә ул кешегә ышанмый идем, шикләнә идем. Хафазадан аның турында сорашкан чакларым да булды, ләкин ни сәбәптәндер Хафазаны кисәтеп куя белмәдем. Татарның кәгазьгә язып булмый торган бик шәп бер мәкале бар, мәгънәсе аның шул: мин саф, миндә берни юк, шулай булгач, Басыйр кебекләрдән куркып торуның кирәге дә юк... Мотлака шулай уйлаганмындыр. Ә менә хәзер инде эшнең ничегрәк булганын күз алдына китерүе читен түгел: авылдан кайткач, минем борчылып сөйләгән сүзләремне Хафаза, ачык авыз, аны-моны абайламыйча Басыйрга әйткәләгән булырга тиеш. Ә теге җәсускә шул гына кирәк тә инде: җепнең очын бер эләктереп алгач, ул, ычкындырмыйча, һаман әкрен генә тартып чыгара барган. Шулай итеп, «дус» кыздан шактый суыргач, Басыйр бөтен ишеткәннәрен Перовка җиткергән булырга тиеш.

Ә шуннан соң?.. Шуннан соң Хафазаны Перов бүлмәсенә чакырып алганнардыр да минем хакта бөтен белгәнен сөйләргә кушканнардыр. Анда Перов белән Басыйрдан башка, ихтимал, управляющий Решевский да булгандыр. Мондый «авторитетлар» алдында Хафаза ничек итеп сөйләмәсен ди?.. Билгеле, кызыйдан бар белгәнен сөйләтер өчен аны үгетләү дә, төрлечә юмалау да, ә бәлки оста гына өркетү дә булгандыр. Яшь, тәҗрибәсез, куркак бер кызны сөйләтер өчен күпме кирәк соң? Менә шулай күз алдыма китерәм мин бу эшне... Менә шуңа күрә дә аның сөйләвенә минем ул хәтле исем дә китми һәм әллә ни ачуым да килми — хәтта гафу да итә алыр идем мин аны. Әмма инде аның шушы эшен миңа белдермәве, миннән яшерүе мине соң дәрәҗәдә гаҗәпләндерә. Дөрес, Басыйр аны: «Белдермә!» дип бик нык кисәтеп куйгандыр, ләкин ул барыбер... барыбер миңа белдермичә түзәлмәскә, белдермичә калмаска тиеш иде!.. Бала түгел бит инде, яраткан кешесенә нинди зарар, нинди бәхетсезлек китерүен әзрәк чамаларга тиеш иде ләбаса! Белмим, белмим. Куркак булырга мөмкин, бөтенләй җебегән, ихтыярсыз бер кеше булырга мөмкин, әмма бу кадәр түбән төшәргә, бу кадәр намусыңны буарга мөмкинме соң?! Мәхәббәт хакына кешеләр ни эшләмәгәннәр, нинди генә корбаннарга бармаганнар! Ә ул нишләде? Кылган әшәкелеген эчендә яшереп, соңгы көннәргә кадәр диярлек минем янымда килеп йөрде, минем тезләремдә утырды һәм ләммим дәшмәде! Кичерергә мөмкинме моны? Юк, бервакытта да! Ирексездән кылган хыянәте өчен генә дип әйтмим, ә кешенең ышануын җимергән өчен, иң кабахәт рәвештә алдаганы өчен, ниһаять, мәхәббәт дигән иң изге, якты, кадерле бер хисне таптап, пычратып ташлаганы өчен кичерү мөмкин түгел!

Белмим, мин бәлки аңа карата артык рәхимсезлек күрсәтә торгандырмын! Бәлки болай ук каты булырга ярамыйдыр? Төп гаеп тегеләрдә бит. Әйе, аларның гаебе коточкыч! Алар безнең яратышып йөрүебезне беләләр иде бит. Шул ук Басыйр безне өйләнешергә димләп йөрүчеләрнең берсе түгелме?! Ә нишләделәр алар? Бер яшь, куркак кызны яраткан егете өстеннән әләкләргә, яраткан егетенә яла ягарга мәҗбүр иттеләр. Барлык заманнарда, барлык халыкларда мәхәббәт белән тугрылык аерылгысыз булган. Тугрылыктан башка мәхәббәт

була алмаган. Ә монда нәрсә? Мәхәббәт һәм донос!.. Я хода! Моны бит Басыйр шикелле бөҗәк аңламаса да, теге Лев Толстой дип төкреген чәчкән «интеллигент» Решевский аңларга тиеш иде. Катгый рәвештә: «Ярамый бу, бернинди дә моральгә сыймый бу!» дип әйтергә тиеш иде бит ул... Мин дә көрәшне әзрәк аңлый торган кеше, көрәшнең бик рәхимсез нәрсә икәнен яхшы беләм. Әмма ләкин һәр нәрсәнең чиге булырга тиеш: мәхәббәт һәм донос, ата хакы һәм донос — бу әхлак һәм кешелек кагыйдәсеннән тыш нәрсә!.. Моны кабул итү мөмкин түгел!

Син, Бәкер дус, болар барысы да әле юрау гына, тәгаен ничек булганын ачык кына белмисең бит әле син, дип әйтерсең бәлки?.. Ник тизрәк Хафазаны күрергә тырышмыйсың, ник аңардан барысын да сорашмыйсың, дип әйтәсең киләдер?.. Ләкин аңла, дустым, минем бүгенге хәлемдә бу мөмкин түгел, бүген мин аның йөзенә күтәрелеп тә карый алмыйм... Бер көннән, бер атнадан, бер айдан бәлки минем моңа көчем житәр, әмма бүген... юк, булмый... Артык якын ул миңа... Аннары, спектакль уйналды бит инде, Бәкер дус, шаккатыргыч, ялган, бозык спектакль (кичер, башкача мин аны атый алмыйм) — кем оештырган, ничек әзерләнгән ул — хәзер моның ни әһәмияте бар?!. Ә уйнаучыларын син күрдең инде. Кемнең нинди роль башкаруы да күз алдында... Һәм ни өчен башкаруын да аңлавы читен түгел, минемчә... Мәсәлән, Басыйрның роле һәм ни өчен шуны «уйнавы» миңа хәзер көн кебек ачык: ул карьерист, аңа ничек тә күтәрелергә кирәк. Моның өчен ул теләсә кемне, хет туган атасын да батыра алачак. Бөтен гамәле аның шуны күрсәтеп тора.

Перовны да аңлап була. Гыйльметдин кулак вакыйгасыннан соң аның бер «кылыч ялтыратып» аласы килгәндер. (Бу вакыйганың жиле бераз аңа да кагылганын мин әйткән идем инде...) Моның өчен шарты да туры килә, сылтавы да табыла: миңа берәү (ягъни, мин) авылына барып кайткан; кайткач, колхоз турында ярамаган сүзләр сөйләгән. (Ә сүзне төрлечә бозып, күпертеп була. Әйтик, мин агайлар зарлана дип әйткәнмен икән, аны минем дә үз зарыма әйләндереп жибәрү ни тора?). Житмәсә, болар барысы да Хафаза кебек миңа иң якын кешедән, Басыйр кебек минем «дустымнан» алынган сүзләр... Я, моны игътибарсыз калдырырга ярыймы соң?.. Перов үзе үк бит еш кына «Положение обязывает» дип әйтергә ярата торган иде... Һәм менә бу юлы инде ул, ниһаять, «положение кушканча» эшләп тә куя. Әлбәттә, ул моны минем гаепле, ә үзенең хаклы булуына ышанып эшләгәндер... Хәер,.. бу кадәресе аның өчен әллә ни әһәмиятле дә булмаска тиеш. Монда төп максат әһәмиятлерәк. Ә төп максат шул: хәзерге киеренке шартларда уяулык күрсәтү сылтавы белән менә «фаш иткән» булып, үзенең дәрәҗәсен күтәрү, урнысын ныгыту — бары шулай гына аңлыйм мин аның гамәлен... Чөнки әгәр ул намусы кушканча һәм чын коммунистларча эшләргә теләсә, иң элек чын хакыйкатьне белергә тырышыр иде. Менә болай гына, миннән сорашмыйча-нитмичә, артымнан башыма казык белән китереп ормас иде.

Я, әйт, Бәкер, минем бу юрауларым нигезсезме, минем хәлдә калган кешенең башкача уйлавы мөмкинме? Миңа бик авыр... Бәлки, рәнҗүдән, ялгызлыктан, артык ярсудан мин нәрсәнедер аңлап житкермимдер,ниндидер детальләрне белеп бетермимдер, әмма мин үземнең гаепсез икәнлегемне беләм, мин гаепсез, һәм моңа ышанган кеше минем хәзерге хәлемне дә аңлар дип уйлыйм.

...Көн бик әкрен уза. Эш юк, хәрәкәт юк — нишләргә? Мин моңарчы гомеремнең бер генә көнен дә менә болай эшсез тик ятып үткәргәнем юк иде әле... Үземне белә башлаганнан бирле я эш, я уку! Каникул вакытларында да ял итим дип тик ятмадым: авылга кайтсам, икенче көнне үк жиң сызганып әнкәйнең хуҗалык эшләренә тотындым, шәһәр-

дә калсам. Усиягә төшеп, баржалардан йөк бушатып йөрдем. Инде андый эш таба алмасам, университет китапханәсенә барып, шунда сәгатьләр буенча утыра идем. Гомумән эшсез-хәрәкәтсез тору бу. Тукайга няреп, «әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору»!.. Ләкин күпме генә болай торырга мөмкин?

Ә тышта яз, абзыкаем, яз! «Назланып, сазлар чиртеп, уйныйжырлый яз килә» — ә мин шуны күрми торам... Әнә безнең көрт баскан ишек алдыннан ак ерганаклар сикерә-сикерә уйнаклап урамга таба чабалар. Ике малай актыгы такта кисәгенә чыра кадаган «көймәләрен» абына-сөртенә агызып маташалар. Күрше йортның кояшка караган баскычына зур бер ала песи кырын сузылып яткан — жылыкай рәхәттән тәмам мәлҗерәгән, юньсез, шул тирәдә чыр-чу килгән чыпчыкларда да гаме юк. Ачык капкадан урамда үтеп-сүтеп йөргән кешеләр күренә. Ирләр, хатыннар, егетләр, кызлар — гүя тормыш үзе язгы ташкындай агып тора минем яныннан...

Юк, болай ярамый. Болай яту — сазга бату! Күзгә болытлардай басып, каплап алган бу авыр, караңгы уйлардан ничек тә чыгарга, котылырга кирәк. Аларның очы-кырые булмас. Бүгенге көнем ялгыз чүмәләдәй утырып янды инде, әмма әүвәл-ахырысы шул булсын. Җитте. Тизрәк яңа көн тусын... Тегеләр үз эшләрен эшләделәр, миңа да хәрәкәт итә башларга кирәк. Әйе, кирәк, ләкин ничек итеп? Бу сорау, тимер ыргактай, алдымда селкенеп тора. Башка бөтен уйлардан, нигә, ни өчен дигән газаплы сораулардан котылып булса да, бу — кала, моңардан котылу юк: әйе, ничек, нәрсәдән башлап хәрәкәт итәргә? Моның өчен бит кайдадыр, кемнәрдер алдында Хафаза белән очрашырга туры киләчәк. Кичәге ике гашыйк бүген ике дошман — менә кайда ул фаҗига!

Әйләнәм дә өстәлдәге иске будильникны килеп карыйм. Миңа тавыш биреп торучы бердәнбер «җан иясе»: гаҗәеп бер ваемсызлык белән ашыкмыйча гына минутларны, сәгатьләрне саный тора. Инде бишенче ярты да булган икән. Бездә эш беткән вакыт. Кешеләр өйләренә таралалар бугай... Ә мин борчылам, көтүдән аерылган тай кебек борчылам. Әледән-әле тәрәзәгә килеп карыйм. Кемне көтәм мин! Хафазанымы? Ул бит көн дә эштән кайтып ашагач-эчкәч, кичкырын ашыгып миңа килә торган иде. Шушы бүлмәгә, минем янымга, кулга иялэшеп беткән күгәрченләй, килеп керә иде. Бәхетле идем мин шул минутларда, тавышын гына ишетсәм дә, җинел, куанычлы бер рәхәт татый идем. Нәрәккә керде бу бәхет, канга сеңде бу рәхәт, бәлки шуны онытa алмыймдыр, шуны көтә торганмындыр?.. Авыр, бик авыр барысын да тиз генә йолкып ташлавы!..

Тәрәзәгә бер килеп каравымда мин ишек алдында басып торган ике кызны күрдем. Кемнәр болар? Кемгә килгәннәр? Ләкин минем тәрәзәгә карап торалар бит болар, минем тәрәзәгә! Ничектер тик кенә, кыюсыз гына карап торалар — һичшиксез, миңа килгән кызлар! Тизрәк ашыгып тышкы ишеккә чыктым. Карасам, Бибинур белән Сара! Бер мәлгә аптырап киттем, аннары кычкырып дәштем үзләренә:

— Кызлар!

Ишеттеләр дә йөгереп килделәр. Кызарышканнар, каушаулары йөзләренә чыккан, сүзләрен әйтә алмыйча аптырап миңа карап торалар. Ахырда үзем:

— Нинди җилләр ташлады сезне? — дип сорадым.

Кызлар инде нишлибез, нәрсә әйтәбез дигән төсле бер-беренә карашып алдылар. Азрак ык-мык итеп торганнан соң, ниһаять, Бибинур ашыгып, бер тыннан әйтеп куйды:

— Сезне күрергә килдек...

Мин пигәдер чачемне артка сыпырырга тотындым.

— Без бик борчылдык, Хәбиб абый,— дип өстәде Сара, әкрен генә.

— Шулаймыни? — дидем мин, хәзер генә исемә килгәндәй.— Әйдәгез, алайса керик.

Кызлар тагын карашып алдылар. Сарасы хәтта башын да селеккәндәй итте. Куркалар, ахрысы, куркалар, бичаралар!

— Без сезне тәрәзәдән генә күреп китәргә уйлаган идек,— диде Бибинур, гаепле генә елмаеп.

— Юк,— дидем мин катгый рәвештә,— керегез! Килгәч инде керәсез, кызлар! Әйдәгез.

Кызлар кыюсыз гына бүлмәгә уздылар. Икесенә дә урындык биреп, утырырга куштым,— пальто төймәләрен дә ычкындырмыйча, аякларын кушырып кына болар утырдылар. Үзем тынычланыр өчен ишекле-түрле йөреп алдым, аннары каршыларына басып:

— Борчылмагыз, кызлар! — дидем.— Берни дә булмас, булырга тиеш түгел.

Кызлар дәшмәделәр. Алар әле берни сөйләрлек хәлдә түгелләр иде, тик балаларча күзләрен тутырып, бик сәерсенеп миңа карыйлар,— әйтерсең, мин теге дөньядан әйләнеп кайткан кеше! Әллә ничек аянычта, әзрәк көлке дә булып китте аларның бу чырайлары...

— Я, сөйләгез инде,— мин әйтәм.— Ничек болай кинәт кенә... Үзегез уйладыгызмы, әллә берәрсе куштымы?

— Юк, үзебез,— диде Бибинур, ашыгып.— Бары үзебез, берәү дә белмәде дә.

— Рәхмәт, кызлар, рәхмәт!

— Без бик курыктык,— диде Сара, нигәдер кызарып.

— Кемнән, нәрсәдән?

— Сезнең өчен курыктык. Берәр хәл булмады микән, я авырып китмәдегезме икән дип курыктык. Кичә сезгә бик начар булды бит. Ничек түзәр, Хәбиб абый, дибез, ничек түзәр?.. Үзенә берәр нәрсә эшләп куймасын тагы дибез. Шуннан Бибинур әйтә, әйдә, ди, эштән чыккач барып карыйк, ди. Куй, мин әйтәм, Хәбиб абый күрсә, куып кына җибәрер... Аннары кешеләрдән дә яхшы түгел, белсәләр, әллә ни уйларлар, дим.

Бибинур аның сүзен эләктереп алды:

— Сара шундый инде, үзе миннән дә күбрәк кайгыра, ә үзенең коты чыга.

— Чыкмыйча... ни бит, кичә нәрсә эшләттеләр бит, бөтенләй, әйтергә куркыныч, контр ясап ташладылар.

— Ә сез шуна ышандыгызмы?

— Ышансак, килеп тә йөрмәс идек,— диде Бибинур, кыюланып.

— Юк, мин ул турыда уйламадым да,— диде Сара.— Тик бик капыл булды бит, шулай ярыймыни, бөтен кешене аптыратып.

— Ләкин, кызлар,— дидем мин,— монда ул хәтле аптырарлык эш юк. Тыныч булыгыз, мин алар әйткән кеше түгел, Тиздән моңа бүтәннәр дә ышанырлар. Дөрес, миңа авыр булды, яшермим, ләкин шулай да башны ташка бәрергә җыенмыйм әле... Килүегез өчен сезгә тагын бер тапкыр бик зур рәхмәт! Батыр кызлар икәнсез. Менә миңа да ничектер берьюлы җиңел булып китте. Инде сөйләгез, цехта ниләр бар, кемнәр ни сөйли?

— Цехта барысы да искечә, Хәбиб абый,— диде Бибинур.— Килдек, урыннарыбызга бастык, эшли башладык. Тик сез генә юк. Моны барыбыз да сизеп торабыз, ләкин беркем берни сөйләми, башын игән, эшләвен генә белә.

— Бөтенесендә карангы чырай,— дип өстәп куйды Сара.

— Арттырасың, Сара! — дидем мин.

— Билләһи менә, һич арттырмыйм,— диде Сара, тагын кинәт кенә кызарып.

— Дөрес, Хәбиб абый,— диде Бибинур, иптәшен яклап.— Бигрәк тә приказны укыгач, әллә ничек бик күңелсез, авыр булып китте.

— Нинди приказны?

— Шул инде, сезне эштән чыгару турындагы приказ... цехка кертеп элделәр.

— Шулаймыни? — дидем мин, ни әйтергә белмичә, мыгырданып кына.

Бу хәбәр йөрәкне ничектер әрнетеп, телеп узды. Каядыр күңел төбендә, бәлки эштән үк чыгармаслар әле, дигән кечкенә бер өмет чаткысы яши иде — менә шул кинәт кенә сүнде дә куйды. Бер мәлгә зиһенем чуалып, ничектер югалып та калдым... Ләкин бу хәлне кызларга сиздермәскә кирәк иде. Көчләнебрәк, ясалмарак бер тавыш белән:

— Шулай да, кызлар мине эштән чыгаруның ул кадәр ни әһәмияте бар, искитәрлек? — дигән булдым.

— Ник булмасын,— диде Бибинур, чын ихластан гаҗәпләнеп.— Кичә генә безнең арада эшләп йөргән кешене бүген цехка кертмәсеннәр әле. Сез карак түгел ләбаса!

— Юк, син дөрес әйтмисең, Бибинур! — диде акыллы Сара.— Каракка бәлки тимәсләр дә иде. Әнә, кем, Фәрдәнә дигән кыз икe каракүл тиресе белән тотылган иде дә бит, чыгармадылар ич... Ә монда эш бөтенләй башка. Кичә ишеттең бит, Хәбиб абыйга нинди зур гаеп тактылар, моның өчен, беләсеңме, эштән генә дә чыгарып калмыйлар. Тик кешеләр шуңа ышанып бетмиләр, дөресме соң бу? дип аптырыйлар. Менә эш нәрсәдә.

— Кызык әле бу,— дидем мин, маңгайны кат-кат ышкып.— Кешеләрнең нәрсә уйлаганын кайдан беләсез, үзегез беркем, берни сөйләми дисез?

— Әйе шул, аптыраганга күрә сөйләмиләр. Сезне гаепләп, дөрес эшләделәр дип әйтерләр иде — чынын гына белмиләр, ышанмыйлар. Дөрес түгел бу дип әйтергә дә аптырыйлар, ә бәлки курка да торганнардыр. Аны сизеп була бит инде.

— Беләсезме, Хәбиб абый,— диде Бибинур, тавышын әкренәйтә төшеп,— безнең цехка берничә мәртәбә Басыйр Рәҗәпов кереп чыкты. Әле бераүләр янына барып туктала, әле икенчеләр янына. Безнең янга да килде. Нихәл, кызлар, дигән була, кәефләр ничек, эшләр барамы? имеш. Ярый хәзергә, бара, дигән булдык. Бүтән бер сүз дә әйтмәдек. Ә ул һаман таптана, һаман нидер көтә, ә безнең аңа күтәрелеп карыйсыбыз да килми. Сизәбез инде, сер алырга йөри. Башкалар янына барса да шулай, дәшмиләр-сөйләшмиләр, эшләүләрен генә беләләр. Дөрес бит, Сара?

— Дөрес, Бибинур!

Кызларның бу сөйләгәннәре минем өчен гаять дәрәҗәдә әһәмиятле иде. Миңа, әйтерсең, шифалы су эчерделәр — берьюлы терелеп киткәндәй булдым. Эчемә җылы йөгерде, күңелемдә өмет уяна башлады. Тик әле боларның барысына да ышаныргамы, юкмы дип куркыбрак торам. Әмма ләкин кызлар дөрес сөйли торганнардыр бит, шайтан алгыры?! Аларның кача-поса килүләре үзе үк дөрес сөйләүләрен, чын ихластан сөйләүләрен күрсәтмимени соң?! Бәлки азрак арттырып җибәрә торганнардыр, әмма барыбер дөресен белеп була бит! Ә дөресе, чын дөресе шул: кешеләр минем «контр булуыма» ышанмаганнар, кешеләр мине ансат кына эштән куып чыгару белән килешмәгәннәр!.. Димәк, мин беткән кеше түгел, мин яшәргә хаклы!.. Аннары кешеләрнең үзләренчә, үз намуслары кушканча уйлый белүләре дә гаять мөһим, куанычлы бер хәл бит әле... Димәк, дөньяга ышаныч бар, дөнья вакыт-вакыт караңгыланып китсә дә үзенең туры, якты юлын югалтмаячак!

Шулай уйладым мин бу минутта, шулай кабынып рухландым. Кинәт аяк астымда тигез, каты җир тойгандай булдым. Димәк, аякларны нык терәп басып торырга була икән әле дидем. Ахрысы, шунадыр, кызлардан артык төпченеп сорашасым да килмәде — ишеткән кадәресе дә миңа бик житкән иде. Хәер, кызлар, мин сорашмасам да, бөтен алып килгәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирделәр. Әмин әкәнең болар тирәсендә нидер әйтергә җыенып, ләкин әйтә алмыйча ах-вах килеп йөрүен дә (гомумән исә мишәр абзыйлар бик шым булып калганнар икән), цех начальнигы авыру Иван Васильевичның бүген зур шарфка уранып кына эшкә килүен, ләкин озак тора алмыйча кайтып китүен дә, шуннан соң цехта баш булыбрак Ариф абзыйның калуын да ашыкпошык кына сөйләп уздылар. Миңа бигрәк тә Васильев турында әйткәннәре бик хикмәтле булып тоелды. Иван Васильевич Ариф абзыйга әйткән, имеш (Сара — аның өйрәнчеге, үзе ишетеп торган): «Мин управляющий Решевскийда да, Перов янында да булдым. Нишләдегез сез?» — дип сорадым. Юлдашев — минем ярдәмчем, мин беләм аның кем икәнен, миннән сорашмыйча аны эшеннән куарга сезнең ни хакыгыз бар? дидем. Юк, әллә нәрсә ул! Башбаштаклык!.. Терелеп кенә чыгыйм, бу эшнең төбенә төшәм әле мин» — дигән... Әйтер, Васильевка ышанам мин, намуслы кеше. Ул инде, һичшиксез, гаделлек ягында булачак. Менә кем белән сөйләшеп карыйсы иде, тик кызганычка каршы, бик авыру шул (без инде аның чехотка белән җәфаланганын белә идек), әнә килгәч тә кире кайтып китәргә мәҗбүр булган. Шулай да аның әйткәннәре минем өчен бик әһәмиятле иде.

Кызлар миңа тагын бер көтелмәгән хәбәр әйттеләр: Хафаза бүген эшкә чыкмаган, имеш! Сәбәбен белмиләр. Хәтта миннән: «Ни булды икән аңа, сезнең янга килмәдеме?» дип тә сорадылар. Бу хәбәр мине ирексездән борчып, дулкынландырып куйды, ләкин, күрәм, кызлар безнең арада ни булганын белмиләр, ахрысы. Ничек тә сиздермәскә кирәк иде (андый начар эшне белми торулары яхшырак), шуңа күрә мин аларга, Хафаза, мөгаен, авыргандыр, сез инде аның хәлен белешә күрегез, дип кенә әйттем.

Соныннан алар миңа шактый читен сорау бирделәр: инде нишләргә уйлыйсыз, Хәбиб абый?

Мин күпме генә уйласам да, әйткәнемчә, нишләргә, кайсы очтан башларга кирәклеген белми идем әле. Дөресрәге, ни генә эшләргә җыенсам да, бу эшнең Хафаза белән бәйләнгән булуы мине бик борчый, аптырата иде. Шуңа күрә кызларга да, менә уйлыйм әле, дип әйтү белән генә чикләндем. Кызлар исә үз нәүбәтләрендә бик кайнарланып, бик ихластан миңа: «Хәбиб абый, болай калдырмагыз, зинһар, райкомга барыгыз, кирәксә, аннан да югарырак җиргә барыгыз, тик үзегезне ничек тә аклагыз!» дип киңәш бирергә тотындылар. «Рәхмәт, кызлар, рәхмәт, киңәшләрегез өчен!» дидем мин аларга, ирексездән күңелем белән нечкәреп. Шуннан соң алар, килгәндәге шикелле, сак кына миннән чыгып та киттеләр.

Мин тагын буш бүлмәдә берүзем торып калдым. Ләкин, юк, мин хәзер алай ук ялгыз түгел идем инде, минем хәлемә кешеләр керде, бу караңгы баздан чыгарга алар миңа гүя кулларын суздылар. Әйе, дидем мин, ишекле-түрле кызу атлап, кызлар хаклы, иртәгәдән үк хәрәкәт итә башларга кирәк! Барырга, йөрергә, беркемнән, бернәрсәдән куркып тормаска! Тик бу озын төн тизрәк үтсен дә яңа көн генә тусын!

* * *

Һәм ул көн туды. Ләкин нинди көн булып чыкты соң ул?

Алтыдан торып эшкә чабасы булмагач, мин будильникны кичтә борып, йөзтүбән каплап куймаган идем. Ләкин будильник ут капкан

дай калтыранып чырылдамаса да, мин өйрәнелгән гадәт буенча нәкъ сәгать алтыда күземне ачып җибәрдем. Әмма сикереп торырга ашыкмадым. Халык белән бер вакытта барып, цех ишеге төбендә кешеләрдән аерылып калу минем өчен бик авыр булачак иде, шуңа күрә тар тимер караватымда түшәмгә карап, ялкау гына уйланып ята бирдем.

Шуны әйтергә онытканмын, кичә минем хозяйка Серафима түтәй дә көн буе өйдә булмады,— каядыр Әмәт тавында торучы сеңелесенә киткән иде. Аннан ул бик соң гына кайтты, һәм бер яктан бу яхшы да булды әле — исмасам, минем көн озын бүлмәдән чыкмыйча ни хәлдә ятуымны күрмичә калды. Ләкин бүген инде аның бик гаҗәпләнүе мөмкин: «Хәбиб, сезгә ни булды, нигә эшкә бармыйсыз?» дип, һичшиксез, сораша башлаячак. Ә минем аңа берни дә сиздерәсем килми, аңа гына түгел, үз анама да мин ни булганын хәзер генә әйтә алмас идем... Димәк, болай бүрәнә шикелле сузылып ятарга ярамый, Серафима түтәй торып йөри башлаганчы тиз генә чыгып сызарга кирәк... Һәм, шулай уйлап, җәһәт кенә тордым да, ашык-пошык киенеп, битемне дә юып тормыйча, мыштым гына чыгып та киттем.

Мехбазага барырга иртәрәк иде әле. Кызу-кызу атлап Кольцога төшеп киттем. Анда, Островский урамының башында, бик иртә ачыла торган бер ашханә бар. Эчендә гел пар йөзгән, стеналары һәрвакыт юешләнеп торган бу ашханәгә гадәттә ломовойлар, «барабыз»чылар, толчокчылар, һәр төрле баш төзәтүчеләр керәләр, чөнки анда кайчан гына керсәң дә аракы белән кайнар шулпа була. Менә мин дә шунда кереп, үпкә-бавыр, тозлы кыяр турап пешергән бер тәшаяк кайнар «рассольникны» аракысыз гына әйбәтләп ашап чыктым. Кәеф бердән яхшырып киткәндәй булды. Кем әйтмешли, ашау бөек нәрсә ул — бигрәк тә бер тәүлек «уразадан» соң... Шул үпкә-бавыр җылысы белән мин җиңел генә мехбазага таба атладым.

Хуш, ә нәрсә өчен барам соң әле мин анда? Мехбаза белән минем эшем беткән бит инде. Приказ чыккан, цехка кертмиләр, сөйләшеп аңлашыр кеше дә юк. Һәм гомумән хәзер сөйләшүнең бер мәгънәсе дә калмады кебек — кем, нәрсәне үзгәртә ала? Болай берәр дус күргән кеше белән очрашып сөйләшер вакыт та түгел — барысы да эштәләр. Аннары мин үзем дә ул тирәдә буталып йөрергә, кемнәр беләндер шунда сөйләшеп торырга һич теләмим. Берәүнең дә күзенә күренәсем килеп тормый. Алайса, ни өчен генә барам соң мин? Максатым әлеге приказның күчермәсен алу — ул миңа кирәк булачак. Мин бит үз хакымны монда түгел, башка җирдә дауларга яки якларга тиешмен.

Менә шундый уйлар белән мин мехбаза конторасына барып кердем. Керүемә — кем белән диегез! — партоешма секретаре Перовның үзе белән күзгә-күз очраштым. Һич көтелмәгәндә килеп чыкты бу, һәм мин бер мизгелгә каушабрак та калдым: исәнләшергәме — юкмы? Ләкин шул арада Перов үзе минем белән исәнләште:

— Саумысыз, Юлдашев?

— Саумысыз! — дидем мин дә.

Ул җәһәт кенә миңа сынаулы бер караш ташлап алды:

— Килдегез?

— Килдем,— дидем мин.

Шуннан соң ул аз гына дәшми торып, ни өчендер тирә-ягына карапып алды да, тавышын әкренәйтә төшеп:

— Минем янга keregez әле,— диде һәм минем җавапны да көтмичә кызу гына алдан китеп тә барды.

Болар барысы да бик тиз булды, барысы да бик сәер тоелды, ләкин шулай да аңардан азрак кала биреп (нигәдер шулай кирәктер кебек иде), артыннан иярдем.

Аның кечкенә бүлмәсе коридор очында ук иде. Барышлый, буеннан-буена киң генә барьер сузылган зур бухгалтерия бүлмәсен узарга

туры килде. Барьер эчендә кара күзлекле баш бухгалтер Глеб Ефимович, аның ике ярдәмчесе, тагын күп кенә хисапчы кызлар утыралар. Шулар арасында дус егет Мостафа да утыра. Минем үзганны күбесе шәйләми дә калдылар, ләкин Мостафа күреп алды булса кирәк. Ул кинәт кенә башын күтәрде, болай да зур күзләре тагын да ныграк ачыла төште, һәм йөзенә гаҗәпләнү катыш куркумы, кызганумы чыккан төсле булды. Мин аңа чак кына баш кагып уздым.

Перов кечкенә бүлмәсендә мине көтеп утыра иде инде. Миңа да якынрак килеп утырырга кушты. Менә без икәүдән-икәү генә, ләкин сүзне ул да, мин дә башлап китә алмыйча утырабыз. Мин, әлбәттә, аңардан көтәм — ул чакырды, ул башларга тиеш. Һәм нәрсә әйтмәкче була ул миңа хәзер?..

Аның йөзендә мин усал кырыслык яки мине ачыктан-ачык өнәмәү кебек нәрсәне күрмим күрүен, ләкин ул нигәдер тынычсызлана, миңа туры карамаска тырыша, алдында яткан кәгазьләрне дә анда-монда этәргәли. Шактый сәер иде бу. Ахырда сүз башлар өчен генә булса кирәк:

— Я ничек соң? — дип кисәк кенә сорап куйды.

Мин бу билгесез сорауга каршы бары иңбашымны гына җыерган дай иттем. Хәер, ул минем җавапны көтеп тә тормады, үзенең шул борчылуын әйтергә ашыккандай тагын:

— Да, шактый ямьсез эш килеп чыкты,— дип куйды.— Үзең гаепле, егет!

— Нәрсәдә соң минем гаебем? — дидем мин.

— Аны нигә миннән сорыйсың?.. Синең гаеп, син белергә дә тиешсең.

— Юк, белмим шул,— дидем мин, башымны селкеп.— Менә ике тәүлек инде бер туктаусыз уйлыйм, иптәш Перов, ләкин һич кенә дә белә алмыйм.

— Кызганыч!

— Миңа «кулак агенты» дигән гаеп... тактылар. Әмма ләкин бу гаепне мин ассагыз-киссәгез дә өстемә ала алмыйм, иптәш Перов! Моңа бит берәү дә ышанмый да.

— Анысына мин дә ышанмыйм,— диде Перов, кулын селтәп.— Чепуха бу!

Мин авызымны ачкан килеш каттым да калдым. Нәрсә ишетәм мин?.. «Ышанмыйм», диде! Минем «кулак агенты» булуыма ул, Перов, ышанмыйм диде. Чынмы бу?.. Дөрес, ул моны уйлап тормыйча кызулык белән әйтеп ташлады, әмма чынын әйтте, һичшиксез, чынын әйтте! Хәтта «чепуха бу» дип тә ычкындырды. Димәк, мин аның карашында бүген дә, кичә дә, җыелыш вакытында да андый әшәке кеше булып саналмаганмын икән ләбаса! Бу минем өчен гаҗәеп бер ачыш, әмма бөтенләй көтелмәгән ачыш түгел... Әлбәттә, ул минем «кулак агенты» булуыма ышанмаска тиеш, бернинди нигезе юк аның ышанырга! Ләкин ул чагында ни өчен соң...

Перов минем умарта кучедәй кинәт котырып киткән уйларымны тизрәк бүлде. Ул саксызрак әйтеп ташлаган сүзләренең миндәниләр кузгатканын сизенде булса кирәк, куе кашларын җыерып:

— Ләкин сезнең гаебегез бар, Хәбиб иптәш,— диде,— зур гаебегез бар. Моны инкарь итеп маташу сезгә бары зарар гына итәчәк.

— Нидән гыйбарәт соң минем гаебем, Федор Николаевич? Әйтегез, зинһар, әгәр дөрес икән, мин һич инкарь итеп тормаячакмын.

— Сез бит надан кеше түгел, рабфак бетергән егет, хәзерге ситуацияне үзегез дә аңларга тиешсез. Авылда кискен сыйнфый көрәш бара, кулак калдыклары, кулак нярченнәре бөтен көчләре белән колхоз эшенә аяк чалырга, халыкны колхоздан биздерергә, куркытырга тырышалар... Ә сез шундый чакта авылыгыздан кайткансыз да монда

«крестьяннарны колхозга көчләп кертәләр» дип сөйләгәнсез! Я бу дошман тегермәненә су кою түгелме? Мондый сүзләр өчен хәзер баштан сыйпамыйлар, иптәш Юлдашев!

Миңа ничек тә тыныч булырга кирәк иде, ничек тә чын дөресен генә аңлата белергә кирәк иде — беләм, бу сөйләшү гаять мөһим минем өчен, янадан кабатланмас та ул.

— Федор Николаевич,— дидем мин, сабыр гына,— сез мине яхшылап тыңлагыз әле... Иң элек шуны әйтәсем килә: мин авылдан кайткач, беркемгә дә «крестьяннарны колхозга көчләп кертәләр» дип сөйләп йөрмәдем. Бу дөрес түгел. Мин авылда күргән, ишеткәннәремне бары берәүгә, иң якын кешемә генә сөйләдем. Сез аны беләсез.

— Берәүгә әйтү дә җитә, шуннан тарала ул.

— Ләкин бит минем аңа ниләр сөйләгәнемне сез тәгаен генә белмисез. Сүзне бит аны төрлечә бозып, төрлечә җиткереп була. Шундый зур мәсьәлә кузгалгач, сез башта минем үземне чакырып сорашырга тиеш идегез.

Бу соңгы сүзләрем Перовка бер дә ошамады булса кирәк, аның йөзе кинәт караңгыланып китте.

— Сезнең мәсьәлә инде каралган, беткән, давай без аңа янадан кайтып тормыйк,— диде ул, кырыс кына.— Сез приказны укыдыгызмы?

— Юк әле, ләкин ишеттем.

— Приказ сезне эштән азат итү турында.

— Беләм.

— Шулай булгач, бәхәсләшеп торырга соң инде. Сезгә үз хәлегез турында уйларга кирәк.

Перовның сүзне болай кинәт кенә икенчегә борып, очлап куюы мине бик нык аптырашта калдырды. Мин әле әйтергә теләгәнемнең чиреген дә әйтә алмадым. Приказ чыккан, эш беткән булса да, минем бу олы яшьтәге абзыйга, коллективның рәсми кешесенә, үземнең гаепсез булуымны бик тә аңлатасым килгән иде. Ә аның бу хакта тыңлыйсы да килми... Алайса, ни өчен ул мине чакырып кертте, борчылып сүз башлады? Максаты нәрсәдә? Менә шундый аптырауга төшеп, мин күпмедер вакыт сүзсез калып утырдым. Перов та нидер көткән кебек, үзенекен әйтергә ашыкмый иде.

Ахырда мин, уйлап түгел, ә гаҗизлектән генә сорап куйдым:

— Нишлим соң мин? Нәрсә эшләргә кушасыз?

— Менә күптән сүзне шуңардан башларга кирәк иде,— диде Перов, җиңелчә бер сулагандай итеп.— Мин бит сезнең хәлегезне аңлыйм. Сез яшь кеше, сезнең киләчәк көнегез бар, бу хакта уйламыйча булмый... Кыскасы, минем сезгә, кешеләрчә ярдәм итәсем килгән иде, әгәр кадерен белсәгез... Тик бу ике арада гына калырга тиеш. Инде ничек итеп сезнең положениене төзәтергә мөмкин? Моның өчен бер генә юл бар: сез партоешма һәм дирекция исеменә гариза язарга тиешсез.

— Нинди гариза?

— Әйтеп беткәнне көтегез... Сез үзегезнең гаризагызда яшьлегем һәм политик сизгерлегем җитмәү аркасында зур ялгышлык эшләдем, гаебемне өстемә алам, киләчәктә төзәлергә һәм эшем белән моны исбат итәргә сүз бирәм, тик мине коллективтан аермагыз, кара эштә булса да калдырыгыз дип языгыз... Ә мин управляющий белән сөйләшермен, бәлки приказны үзгәртеп тә булыр. Аңладыгызмы?

— Димәк, сез миңа гариза язып, тәүбә итәргә кушасыз инде?

— Тәүбәме бу, үтенечме — анысын теләсәгез ничек дип атагыз. Ләкин сезнең бүтән чарагыз юк. Иелгән башны кылыч кисми, шуны белегез!

— Федор Николаевич,— дидем мин, ничек тә сак булырга тырышып,— ә шулай да нинди гаепне мин өстемә алырга тиешмен? Җые-

лышта бит миңа «кулак агенты», «кулак коткысын таратучы» дигән гаеп тактылар, ләкин бу гаепкә сез үзегез дә ышанмыйсыз ич!..

— Һай, аллам! — диде Перов, бик ачынып.— Мәсьәлә андамыни? Сезне эштән куалар, аңлыйсызмы? Ә мин сезгә шуңардан котылуның бердәнбер юлын өйрәтеп утырам. Кулак агенты булсагыз, мин моны эшләр идеммени?!.

— Анысы өчен рәхмәт сезгә, Федор Николаевич,— дидем мин, юашланып.— Тик... тик нинди генә гаепне өстемә алыйм икән соң?

— Аптырыйм, укыган кеше ләбаса сез! Неужели, гариза да яза белмисез? «Мин кулак агенты идем» дип язу һич тә шарт түгел бит. Аңламыйча, белмичә сөйләгәнмен дип язсагыз да житә бит.

— Ләкин... сөйләгәнем дә юк ич!

— Минем сүзем бетте,— диде Перов, шактый кискен-дорфа итеп, һәм алдында яткан кәгазьләрен ачу белән тагын күчергәли башлады.

Әлбәттә, минем соңгы сүзем артык иде, эшне генә боза торган сүз иде. Ычкынды, хәерсез! Тезләремә таянып, азрак уйланып утырдым, аннары таш астыннан чыккандай акрын гына кузгалдым.

— Рәхмәт, мин уйлармын,— дидем, бер сүзсез чыгып китүне килештермичә.

Ләкин Перов дәшмәде.

* * *

Мин Перов бүлмәсеннән генә түгел, мехбазадан ук чыгып киттем. Хәзергә эш калмады монда... Каядыр читкәрәк китәргә кирәк. Берәр аулак урынга барып, бу ишеткәннәрне ничектер сеңдерергә кирәктер инде. Ләкин кая барасымны ачык кына белмичә, башта мин Бауман буйлап киттем, аннан ни өчендер Болакка таба борылдым, аны да узып Печән базарына барып чыктым. Базар, әлбәттә, мин эзләгән урын түгел, аның таш кибетләре, тыз-быз чапкан кешеләре арасыннан тизрәк үтеп, Кабан күленә таба киттем. Күл буенда хәрти генә бер бакча кисәге бар, шуңа житеп, чокыр-чакырлы юлыннан эчкәрәк уздым да арты каерылган бер эскәмиягә, ниһаять, килеп утырдым. Көн гажәеп җылы, кояшлы — язны камчылап ашыктыра торган көннәрнең берсе. Ярдан котырып шарлавыклар ага, күлнең читләренә тоташ су җәелгән, тик ярдан-ярга сузылган чана юлы гына сары сыртын кабартып, ярылып ята... Каршы яктагы икешәр катлы иске агач йортларның тәрәзәләре, әйтерсең, утта яна... Шулардан уңдарак, нурлы аяз күккә сузылган кара бармактай, «Спартак» фабрикасының нечкә тимер трубасы күренеп тора.

Ләкин бу күренешләр ничектер күңелгә кермичә, күзләремнән генә чагылып узды,— уйларым минем бөтенләй башкада иде. Бер дә көтелмәгән ситуация туды бит әле. Миңа ансат кына эшне җайларга була икән. Кайларгадыр, кемнәргәдер барып йөрүнең кирәге дә юк, имеш. Шул ук мехбазага гариза гына язып илтәсе — һәм эш җайланачак. Әмма бу хәл мине ни өчендер бер дә куандырмый. Киресенчә, ул мине борчый, бик нык борчый. Иң элек Перовның миңа «изгелек» күрсәтергә теләвенең сәбәпләрен һич аңлый алмыйм. Башта батыра, аннары тартып чыгармакчы була — ни өчен? Изгелекме бу, әллә берәр төрле мәкерлекме? Ягъни миннән «гаеплемен» дигән сүзне әйттерер өчен генәме! Тагын иң нык аптыратканы, уйландырганы шул — хөрмәтле Перов иптәш үзе минем чит, дошман кеше булуыма ышанмый икән, ә бит мине дошман кеше дип эштән кудылар,— ничек килеп чыга соң бу?.. Ышанмагач, кудырмаска кирәк иде, аның бит моңа көче житкән булыр иде. Үз интересың, үз карьераң өчен генә кеше язмышы белән шулай шаярырга ярыймы?! Белмим, белмим, ничек дип атарга да белмим мин моны!

Ярый, бик тирәнгә кермик әле, югыйсә борылып чыгып та булмас. Бу четрекле мәсьәләне калдырып торыйк, болай да башка төшкән йөк бик авыр. Минә минем алга бик конкрет мәсьәлә куелды, шул хакта тыныч, сабыр гына уйларга кирәк... Хуш, мин нишләргә тиешмен? Хөрмәтле Перов иптәш миңа ярдәм кулын сузмакчы, тик бер генә шарты бар: мин тәүбә итәргә тиешмен. Нәрсәдән? Миңа тагылган ялган гаептән: булмаганны булды дип, мин чынлап та ялгышканмын дип, инде, зинһар, кичерә күрегез дип, баш иеп кичерү сорарга тиешмен. Әгәр шулай итсәм, ягъни үземне гаепсез санаган хәлдә өстемә ниндидер гаеп алсам, алар мине кичерәчәкләр. Бүре билеты тоттырып эштән чыгарып җибәрмәячәкләр. Ләкин юк гаепне өскә алып тәүбә итү — бу да ике йөзлелек күрсәтү була түгелме соң? Бу да алдашу юлына басу, тирелне саклау өчен намусыңны таптау — я, шуннан соң мин кем булып калам? Вак җан, бөҗәк, типкән итекне ялаучы эт?!.

Хәер, нигә мин бу кадәр коточкыч әшәке итеп уйлыйм әле? Әгәр юк гаепне өстемә алып, тәүбә итсәм, кешеләр моңа ышаначаклар бит. Минем ике йөзләнәнеп, бары тиремне саклау өчен генә үз-үземә яла ягуымны белмәячәкләр. Хәтта мактап: «Кара, ялгышуын әйтеп бирүдән курыкмады, молодец, честный егет икән!» диячәкләр... Ә инде үз вөҗданыма килгәндә, аны да тынычландырып, юатып булачак: мәҗбүр иттеләр дисең, минем урында һәркем шулай эшләр иде дисең, дөньяда торырга кирәк ләбаса, дисең. Хәйләсез — дөнья файдасыз, диләр ич «акыллы» кешеләр. Аның каравы, син акылга утыртылган тәти егет булып каласың, түбәнлек, ике йөзлелек, ялагайлык бер дә начар нәрсә түгел икән дип, мыштым гына яши бирәсең!

Ходаем,ниләр уйлыйм мин? Гүя ургылып аккан елга уртасыннан чыгар өчен әле бер ярга, әле икенче ярга ташланам. Болай булмый бит, болай ярамый, ике ярның берсенә чыгарга кирәк. Яки — яки!.. Гамлет шикелле озак баш ватарга минем вакытым да, мөмкинчелегем дә юк. Датский принц түгел мин — эшсез бер генә көн дә яши алмыйм. Димәк, яки расчет алырга да, бүре билетын тотып, каядыр чыгып олагырга! Яки инде Перов киңәшен тыңлап, баш иеп карарга, шулай итеп кара мөһердән котылырга — чәнчелеп китсен! Күңел каралса да, исемем «чиста» калыр... Сайларга, сайларга... әмма ләкин кайсын сайларга? Әйтегез инде, әйтегез, туганнар! Мине белүчеләр, мине аңлаучылар, миңа ышанучылар!..

Әйе, мин кемнеңдер акыллы, дөрес сүзенә мохтаҗмын, бик мохтаҗмын. Ни әйтсә дә әйтсен, тик айнык сүзен әйтсен! Кем белә, бәлки мин аңардан иң кирәкле киңәшне ишетермен. Ләкин кемгә, кем алдына бу газаплы аптыравымны күтәреп барырга?.. Иң яхшысы — Вафага, Вафа дуска! Вафа — коммунист. Ул минем белән дусларча ачык сөйләшүдән курыкмаячак. Куркырга тиеш түгел.

Урынымнан тордым — торгач кына аякларымның юеш карда нык кына өшегәнен сиздем. Аксабрак булса да ашыга-ашыга бакчадан чыгып киттем. Хәер, ашыгудан бер мәгънә дә юк иде. Вафа эштә, ә эш бетәргә вакыт бик күп әле. Көнне ничектер үткәрергә кирәк. Кая барырга, нишләргә?.. Татарстан чатында тукталып, үткән-сүткәннәргә, пычрак карны чәчрәтеп чапкан машиналарга, атларга карап тора башладым. Барысы да уза минем яннан, барысының да ниндидер эшемәшәкате, максаты-теләге бар... Бер генә минут та тик тору мөмкин түгел — ташка әйләнерсең!.. Кузгалырга кирәк. Иң элек жылы бер урынга кереп утырасым килде. Мәскәү урамына узып, «Сарай» номерлары астындагы ашханәгә барып кердем. Халык күп иде, шулай да түрдәрәк бер буш өстәл табып, шуңа барып утырдым. Половойлар өстәлләр арасыннан юргалап, кара поднос белән чуар чәйнекләрдә чәй ташыйлар. Мин дә шуларның берсеннән ике шешә сыра китерттем. Монда торганы авыл агайлары диярлек, чөнки күршедә генә алар төшә

торган крестьян йорты. Туннарын салмыйча, бары бүрекләрен генә салып һәм тирләгән муеннарын сузып, тәлинкәдән шөбер-шөбер чәй эчәләр... Минем ашыгыр жирем юк, сыраны әз-мәз генә йотымлап, шуларга карап утырам. Кемнәр алар — колхозчыларымы, единоличникларымы — белмим, ләкин эчемнән генә үзләренә әйтәсем килә: «Менә, эт талаган нәрсәләр, сезнең аркада без — фәкыйрегезне утлы табага бастырдылар бит әле... Сез шуны күрмисез дә, сизмисез дә, бары мышнап чәй чүмерүегезне генә беләсез. Хәер, белсәгез дә яклап бер сүз дә әйтмәс идегез, берни төшенмәгән ангыралар булып кыланыр идегез. Хәйләкәр төлкеләр сез!» ...Әйе, мужик — бик катлаулы, бик четрекле жан иясе. Кем әйтмешли, сукранмыйча жәннәткә дә кермәс ул.

Сыра эчкәч, ашыйсы да килеп китте. Токмач белән кәтлит заказать иттем. Чын булса, нервлары кузгалган кешенең аппетиты бик яман ачылып китә, имеш. Акча барында бу әллә ни куркыныч түгел түгелен... Ярый, токмач белән макаронлы кәтлитне дә ялт иттереп куйдык. Инде моннан кузгалырга да вакыттыр — әдәп дигән нәрсә бар.

Урамга чыккач, тагын шул ук мәсьәлә: кая барырга? Вафаның эше дүрттә бетә, ә хәзер сәгать икенче ярты гына әле. Ләкин кая таба булса да атларга кирәк. Киттем. Атлый торгач, «Чаткы» киносына барып чыктым. Гарри Пил катнашы белән ниндидер Америка картинасы бара икән, сеанс та башланырга гына тора — мин тоттым да билет алып, шуна кереп утырдым. Ике сәгать вакытны үткәрергә ярап куйды бу... Аннары торганы атышлар, куышулар, биек-биек йортларның берсеннән икенчесенә сикерүләр белән тулы картинаны карап утыру жанга әзрәк ял да биргән кебек булды.

Кинодан чыккач та мин туры Вафага киттем. Ул шушы Тукай урамында, моннан ерак түгел бер ялгыз карчыкта тора. Әле кайтып житмәгән булырга тиеш. Мин өенә кермичә, урамда әрле-бирле йөренеп, көтәргә булдым.

Тукай урамында татар кызлары күп очрый, ара-тирә бик чибәрләре дә килеп чыккалый... Нишлисең, яшьлек бит, баш түбәсеннән хәсрәт сөреме бөркелеп торса да, мин шул чибәрләргә кызыксынып карамыйча булдыра алмыйм. Күңелгә сәер уй килә: кешегә бәлки нәкъ менә бик авыр хәсрәтле чагында хатын-кыз иркәләве аеруча кирәктер. Бәлки жан сөйгәненең шифалы кочагында ул барысын да онытa, тынычлана алыр иде. Һай, тиле күңел!.. Нәкъ менә шундый кочакта аны жылан чакканын да онытырга әзер...

Әнә Пеләтән ягыннан эре-эре атлап, кулларын селкә-селкә кайтып килгән Вафа да күренде: мин йөрүдән туктап, аны көтеп алдым. Килеп житкәч, Вафа минем белән кул биреп күреште. Бернинди гажәпләнүсәерсенү сиздермәде, гүя бу очрашуны ул алдан ук белеп кайткан... (Мондый чакта дус кешенең әз генә читенсенүе дә минем өчен, билгеле, авыр булыр иде.)

— Күптәнме? — диде Вафа, борчылгандай.

— Юк, күптән түгел,— дидем мин.

— Әйдә керик, алайса! — диде ул, гади генә.

Без кечкенә кухняны узып, зал сыман иркен генә бер бүлмәгә кердек. Урамга караган ике тәрәзә, тәрәзә төпләрендә гөлләр, стенада ике рәсем: берсе — Ай-София мәчетенең күренеше (карчыкныкы булырга тиеш), икенчесе — Ленин портреты (монысын, билгеле, Вафа элгәндер); уң кулда карсак кына шкаф, уртада чуклы эскәтер япкан түгәрәк өстәл, ә тәрәзәләргә каршы стена буенда ак шарлы киң генә карават, бер сүз белән әйткәндә, Иске бистәнең урта кул татар бүлмәсе. Әйткәнемчә, Вафа ялгыз карчыкта тора, карчык үзе кухня белән янәшә караңгы бүлмәдә ята икән, ә монда Вафа үзе генә хужа. Аннары Казан карчыкларының бер шәп гадәтләре бар — алар өй саклап утырырга яратмыйлар. Ходай бирмеш көн,— алар ниндидер үзләре генә

белгән сылтау табып, кемгә дә булса бармыйча, кемнен дә булса чәен эчеп кайтмыйча калмыйлар. Вафаның да карчыгы нәкъ шундый икән — биләмгә чыкмыйча бер генә көнне дә уздырмый, имеш. Икесенә ике ачкыч эшләтеп алганнар, һәркайсы үзе теләгән вакытта кайтып-китеп йөри... Вафадан минем: «Карчыкның сине болай ташлап йөрүе уңайсыз түгелме соң?» дип сораганым да бар. «Һи, бүйдак егет өчен, киресенчә, бик уңай инде ул!» дип көлә генә Вафа... Кыскасы, карчыктан да, торган җиреннән дә бик канәгать булса кирәк.

Бүлмәгә кергәч тә Вафа миңа:

— Син утырып тор, менә газеталар караштыргала, ә мин өстемне генә алыштырып алыйм,— диде, һәм чөйдән чиста күлмәген, чалбарын, караваттан астыннан йомшак чүәкләрен алып, кухняга чыгып китте. Мин беләм, Вафа — тәртип-пөхтәлек ярата торган егет. Эштән кайткач та һич нигә карамыйча иң элек юынып, өстен алыштыру — бу аның көндәлек кагыйдәсе. Кем генә килсә дә, ул аны бозачак түгел. Сабыр гына көтәргә кирәк.

Бүгенге «Красная Татария» газетасын хәвефләнебрәк кулыма алдым. Газета битләрендә хәзер һәртөрле «фаш итүләргә» күп урын бирелә. Әгәр шуннан минем хакта да берәр фельетон-мазар язылган булса, нишләрсең?! Баш очыңа казык сугып кую белән бер булыр иде бу, әкәмәт! Ярый, шөкер, андый-мондый хәтәр нәрсә юк икән әле. Газета игътибарын җәлеп итәрлек дәрәҗәгә үсмәгәнбез әле без — моның өчен аңа үпкәләп булмый, билгеле.

Вафа юеш чәчен артка тарый-тарый килеп керде. Озынча зур бите алсуланып киткән, өстендә ап-ак күлмәк белән шәп үтүкләнгән кара чалбар, билен тар каеш белән кысып буган — егеткә карап торуы күңелле!

Кергәч тә ул миңа кәефләнеп:

— Ә хәзер без, дус кеше, синең белән аристократларча гына каһвә эчеп җибәрик,— диде.— Дәрт кереп китсен!

Аның болай минем хәлемне белмәгәндәй шаяруга бирелеп ваемсыз, җиңел генә сөйләнүе бер яктан әйбәт тә кебек — ничектер мине дә тынычланырга, онытылырга мәҗбүр итә. Әмма икенче яктан минем өчен бик үк уңай да түгел шикелле, чөнки алда гаять җитди сөйләшү тора. Фикерне таркатмыйча, йомшартмыйча гына дигәндәй аны ничектер башларга кирәк.

Ә Вафа үз эшендә. Менә ул пыяла шкафтан ике стакан, шикәр савытын, кофе тартмасын алып өстәлгә куйды. Аннары кухняга чыгып, бераздан чәйнек белән яңа гына кайнаган су һәм саплы кастрюль белән кайнар сөт алып керде. Шуннан миңа да, үзенә дә сөтне, шикәрне мул салып, нык кына болгатып, хуш исле кофе ясап куйды. Шуны әйтергә кирәк, чын кофе ул — хәзер бер җирдә дә табылмый торган нәрсә. Ә менә Вафада бар. Күрәсең, Ленинградтагы туганнары аңа җибәрә торганнардыр.

Кайнар кофены без әз-әзләп кенә эчәбез. Чынлап та, бик тәмле нәрсә. Арпа кофеен күп эчкәнем бар, ләкин моны, каяндыр эссе илләрдән килгәнен хәтерләмим дә.

Мин Вафадан сүз көтәм. Ни дә булса сорарга тиеш бит ул. Сорамаса, әллә ничек бик сәер булыр иде. Мин дә сүзне ничек итеп башларга белмәс идем...

Юк, сорады. Гади генә итеп:

— Бүген эшкә чыкмадыңмы? — диде.

— Юк,— дидем мин.— Приказ бар бит.

— Күрдем. Безгә дә килгән иде.

— Ә минем күргәнем юк әле. Ишеттем генә. Ничегрәк язганнар?

— Ничегрәкме? — диде Вафа, кофеен ашыкмыйча гына болгатып.—

Шактый хәйләкәр: «Ачык партия җыелышының соравын искә алып, Фәләновны эшеннән азат итәргә», диелгән.
— Начармы бу?
— Ничек дим. Беренче карашка начар да түгел кебек. Һәрхәлдә, приказның үзендә сиңа конкрет гаеп такмаганнар. Ләкин ул приказны кая гына илтеп күрсәтсәң дә, безнең мехбазадан синең хакта кем ул, ни өчен чыгарылды дип сораячаклар. Конверт эчендә җавап барачак. Ә аның эчендә нәрсә язылганын син үзең дә белергә тиешсең.
— Кулак агенты, колхозга каршы коткы таратучы — шулаймы?
Вафа уңайсызланыбрак елмайды.
— Җыелышта сөйләүчеләрнең әйтүенә карагаңда, шулайрак килеп чыга.
— Ә син шуңа ышанасыңмы? — дидем мин, туп-туры аның күзләренә карап.
— Нигә алай дип сорыйсың? — диде Вафа, кинәт җитдиләнеп.— Мин бит җыелышта үз сүземне әйттем инде... Без хәзер сиңа бүтәннәр таккан һәм җыелыш карарына кергән гаепләү турында сөйләшеп утырабыз.
— Кичерә күр, Вафа, мин кызулык белән генә... Ләкин ул «бүтәннәр» минем андый начар кеше булуымны кайдан беләләр?
— Юк, син, дус кеше, аны миннән сорама инде. Мин кайдан белим? Миңа синең бер сүз дә әйткәнең юк бит. Бәлки башка берәр кешегә нинди дә булса ярамаганрак сүз әйткәнсеңдер! Яшермә!
— Вафа, синнән яшерер бер нәрсәм дә юк минем,— дидем мин, бөтен ихласым белән. — Ышан, дус!
— Ышанам!
— Син беләсең, минем бердәнбер яраткан, ышанган кешем ул — Хафаза иде. Менә Япанчыдан кайткач, мин аңа авыл халкына бәйләнгән кайбер, ничек дим, уйларымны, шикләремне сөйләдем. Бүтән бер кешегә, берни әйткәнем булмады.
Вафа бераз дәшми торды, аннары сак кына сорап куйды:
— Хафаза туташка ниндирәк... шикләреңне әйткән идең соң?
Мин Япанчыга кайткач ниләр ишетүемне, кемнәр белән очрашуымны, шулардан туган борчылуымны кыскача гына сөйләп бирдем дә әйттем:
— Хафазага минем сөйләгәннәрем әнә шул иде. Ләкин моны да мин, ничек дип әйтергә, колхоз җитәкчеләрен генә гаепләп, бары агайларны гына яклап сөйләмәдем... Бу минем авылдагы хәлләр турында телдән әйтеп уйлануым иде дисәм, дөресрәк булыр...
— Ә ул нәрсә диде инде?
— Хафазамы? Нәрсә әйтсен. Гадәтенчә, минем һәр сүзем белән килешеп барды. Авыл хәлләрен белми дә ул, аннары үзенчә фикер йөртерлек чамасы да юк аның. Ә менә җиткерә белгән.
— Ул дисеңме?
— Бары ул гына. Дөрес, үзе башлап барып сөйләмәгәндер, монысына ышанмыйм. Сүзне анардан әкренләп алганнар, һәм кем алганын да беләм, ләкин барыбер мин Хафазаның бу эшен каберемдә дә онытачак түгелмен! Бигрәк тә шуны миңа әйтмәвен кичерә алмыйм.
— Син кызма,— диде Вафа, тыныч кына.— Сиңа кызарга ярамый. Кая тагын берне ясыйм.— Ул стаканнарга яңадан кофе ясый башлады.— Хафазаны син алай бик каһәрләп ташлама, интрига корбаны ул, әллә аның үзенә җиңелдер дип беләсеңме? Ничек кенә булмасын, ул сине яратып йөргән кыз бит.
— Менә шуңа күрә дә гафу итеп булмый аны.
— Ашыгыбрак сөйлисең әле, дус кеше, ашыгыбрак! Ярый, Хафаза мәсьәләсен хәзергә калдырып торыйк. Инде үзең нәрсә эшләргә уйлыйсың?

— Менә шул хакта киңәшергә дип сиңа килдем дә, Вафа! Бүген мин Перов белән сөйләштем. Дөресрәге, ул үзе мине бүлмәсенә чакырып, сүз башлады.

— Я, шуннан?

— Иң элек мин аңардан шуны ишеттем: ул минем кулакларны яклаучы, колхозга каршы коткы таратучы кеше булуыма үзе дә ышанмый икән... Аңлыйсыңмы, Вафа, үзе дә ышанмый!

Әмма, ни гаҗәп, Вафаның моңа һич исе китмәде. Бары «аңлыйм» дип кенә куйды.

— Юк, син, Вафа, чынлабрак уйла әле, нәрсә килеп чыга соң? — дидем мин, янадан кайнарлана башлап.— Димәк, ул миңа үзе дә ышанмаган гаепне таккан, мине нахакка политик җинаятьче ясап, эштән кудырган — шулай түгелме! Син менә шуны миңа аңлатып бир!

— Кеше өчен җавап бирүне бер дә яратмыйм, Хәбиб! — диде Вафа.— Ләкин Перов сүзләрен җиңел аңлап була, минемчә... Просто сиңа ул кадәр зур политик гаеп тагар өчен аның дәлилләре җитәрлек түгел, нигезе юк, ничек ышансын?

— Алай булгач...

— ...Нигә эштән кудылар дисең инде? Моның да сәбәбе ачык: «фаш итү» шаукымына бирелеп, алар таякны катырак бөгеп ташладылар. Бары шул гына.

— Бары шул гына!.. Әйтерсең, сүз тәкә башы турында бара!

— Юк, сүз тәкә башы турында бармый,— диде Вафа, житди генә.— Югыйсә, Перов синең кулыңа шундый козырь тоттырыр иде микән?! Монда ниндидер сер бар. Давай, син дәвамын сөйләле, аның әйткәннәре кереш кенә булгандыр — шулайрак сизәм.

— Дөрес сизәсең... Ул миңа «изгелек» эшләмәкче була.

— Ничек итеп?

— Әгәр мин гаебемне өстемә алып, кичерү сорап, партоешма исеменә гариза язсам, ул мине эштә калдырырга вәгъдә итә.

— Так-так! Нинди гаепне өстеңә алырга куша инде ул?

— Ну, янәсе, мин политик сизгерлегем җитмәү аркасында нәрсәнедер аңлап бетермәгәнмен, ниндидер хата фикерләр әйткәләгәнмен — менә шулайрак. Кыскасы, ул минем үземә белеп язарга куша.

— Менә хәзер мәсьәлә ачыкланды инде, Хәбиб дус! — диде Вафа, урыныннан торып.— Перов сиңа килешер өчен кулын суза, аңлыйсыңмы? Әгәр ул синең чынлап та кулак иярчене, колхозга каршы кеше булуыңа ышанса яки шуны исбат итәрлек дәлилләре кулында булса, ул моны эшләмәс иде, әлбәттә. Хафаза сүзләре генә җитми моның өчен, син аларны һәрвакытта кире кага аласың. Ләкин хикмәт анда гына түгел. Алар боткаңы пешерделәр пешерүен, әмма ашаучы юк, ягъни коллективны синең шундый начар кеше булуыңа ышандыра алмадылар. Ә бу партоешма секретаре өчен мактаулы эш түгел. Менә хикмәт нәрсәдә. Хәзер ул үзенең позициясен ничектер ныгытырга тиеш — менә ни өчен аңа синең гаризаң кирәк. Аңлыйсыңмы?

— Ләкин бит мин аның кулына андый гариза язып бирмәячәкмен.

— Тукта, ашыкма. Бусы икенче мәсьәлә.

— Ничек икенче мәсьәлә? — дидем мин, бик гаҗәпләнеп.— Перовның гамәлен аклар өчен мин үз-үземә яла ягыймммы?! Бу бит акылга сыя торган эш түгел.

— Сабыр, сабыр!..

— Җитмәсә әле, кулыңнан алдап гаризаңны алырлар да барыбер эштән дә куарлар. Ышан син.

— Юк, кумаслар. Перов сүзендә торыр. Торырга тиеш. Аның өчен сине чыгарып җибәрмәү файдалырак — инцидент шуның белән бетәчәк. Беләсең килсә, синең хәлне төзәтү өчен бу иң ансат юл.

— Гариза язымы?

— Әйе. Гариза язу.

— Неужели син миңа шуны эшләргә кушасың?

— Мин кушмыйм. Язасыңмы, язмыйсыңмы — анысы синең эш. Тик минем сиңа бер нәрсәне төшендерәсем килә. Бел, сине ачык партия җыелышының соравы буенча эшеңнән азат итәләр — приказда шулай диелгән. Димәк, аны беркем дә үзгәртә алмый.

— Туктале, Вафа, ни сөйлисең?! Хәзер генә үзең коллектив минем гаепле булуыма ышанмый диден...

— Әйе, дидем. Ләкин, шуңа карамастан, җыелышның карары бар.

— Көчләп тагылган карар ул.

— Теләсәң ничек ата, әмма бар ул. Акка кара белән язылган, һәм аны бары синең гаризаң гына үзгәртә алачак.

— Юк, юк, Вафа дус! — дидем мин, башымны кат-кат чайкап.— Дөнья әле бер мехбаза белән генә бетми, мин әле райкомга, обкомга, кирәксә, Мәскәүгә чаклы барып җитә алам. Бер гөнаһсыз кеше булуымны мин әле исбат итә алачакмын!

— Белмим шул,— диде Вафа, сүлпән генә,— белмим шул.

— Нигә? Бөтен җирдә дә Басыйр да Перов ишеләр түгелдер бит?

Вафа чыраен сытып куйды, күрәсең, ошамады аңа бу сүзләр. Бераз дәшми торды.

— Син, Хәбиб, бер нәрсәне аңларга теләмисен,— диде ул, ниһаять.— Сыйнфый көрәш гаять кискенләшкән хәзерге шартларда политик гаепне өстеңнән төшерү бик авыр эш ул. Монда алиби юк... Әгәр синең Хафазага әйткән бер генә кыек сүзең расланса да, ниндидер гаепләүгә урын кала. Ярый, син кардан ак, сөттән пакь булуыңны исбат та итә алдың ди, ләкин моның өчен бит башта Хафазаның чеп-чи ялганчы, әшәке рәвештә яла ягучы икәнен күрсәтергә кирәк булачак. Онытма, ул хәзер ялгыз түгел, аның әнә Перов, Решевский кебек таза терәкләре бар. Билгеле, алар барысы да бер сүздә булачак. Менә шундый нык фронтны «өзәргә» синең көчең җитәчәкме?.. Тагын шуны да исеңдә тот: алар гаепләүче, син акланучы, ә аклануы һәрвакытта авыррак...

— Димәк, синеңчә, инде аклану мөмкин түгел?

— Юк, мин алай дип әйтмәс идем. Гаделлек ахыр чиктә җиңеп чыгарга тиеш. Ләкин ничек булачак ул?.. Син бик тырыша торгач, Хафазаның бөтен җиткергән сүзләрен юкка чыгардың ди, син гаепсез, син яла корбаны... Ниһаять, сине аkладылар, ләкин сине аклау — Хафазаны батыру дигән сүз, чөнки ул яла ягучы гына түгел, партоешманы да алдаучы булып калачак.

— Ләкин бит аны ул эшкә мәҗбүр иткәннәр! — дидем мин, ярсып.

— Җүләр сатма, зинһар! — диде Вафа, ачуланып.— Кайда синең дәлилең?

— Ул үзе әйтер... Әйтергә тиеш.

— Тиеш!.. Тиле син... Мәҗбүр иттеләр дигән нәрсә недоказуемый абсурд ул, беләсеңме шуны? Авызыннан чыккан сүзгә бары Хафаза үзе генә җаваплы... Бала түгел бит ул... Озын сүзнең кыскасы шул, син күпмедер дәрәҗәдә акланырсың. Басыйр белән Перовка чүп тә булмас, хәер, таякны катырак бөгеп ташлаган өчен Перов бәлки шелтә алыр, ә менә Хафаза туташ бу быкырдыкның бердәнбер корбаны булып калыр... Син шуңа ризамы?..

Вафаның бу сүзләреннән мин әллә ничек бөгелеп төшкәндәй булдым. Әйтерсең, иң авырткан сөялемә китереп басты ул! Ыңгырашырга җитеп, мин:

— Вафа, ник алай дип әйтәсең? — дидем.— Мин бит Хафазадан үч алырга җыенмыйм. Ачуым никадәр генә көчле булмасын, күпме генә рәнҗемим мин аңа, әмма кичә генә әле миңа шундый якын, кадерле булган бер кеше белән бүген ерткычлардай дошманлашу, шул зәгыйфь, куркак җан белән күзгә-күз очрашу, аңа нәфрәт белән карау, аның

йөзенә гаеп ыргыту, ниһаять, аны хур итеп, пычратып ташлау — бу минем теләгем түгел, Вафа, аңла син! Бик түбән чирканыч эш бу минем өчен... Башта ук шуны уйлап, мин күпме борчылып, газапланып йөрмәдем... Минем бөтен ачу-нәфрәтем тегеләрдә, безне аерган, безнең мәхәббәтебезне җимергән әнә шул шымчы Басыйр белән Перовларда. Мәнә кемнәрнең явызлыкларын фаш итәргә, менә кемнәрдән үч алырга тиеш идем мин... Ә син Хафаза дисең!..

— Их, Хәбиб! — диде Вафа, ачынып.— Мин әйтәммени аны, логика әйтә, логика!.. Ә бу эштә логика шуннан гыйбарәт: син «тегеләргә» пычак та эшли алмаячаксың, ә Хафазаны, үзең әйткәнчә, хур итеп ташларга мәҗбүр булачаксың. Һичбер нинди благородный теләкләреңә карамастан! Менә шулай!

Әйе, Вафаның логикасы рәхимсез иде. Мине тәмам гаҗизлеккә төшерде ул. Бәхәсләшер урын да калмады кебек. Ләкин шулай да бу каһәр суккан хәлдән ничектер чыгарга кирәк ләбаса!.. Соңгы өмет белән дигәндәй тагын Вафага карыйм:

— Нишлим соң, Вафа, нинди киңәш бирәсең, әйт, зинһар! Шул кара мөһер белән калыйммыни инде мин?..

— Читен мәсьәлә! — диде Вафа, авыр сулап.— Нинди генә киңәш бирә алыйм мин сиңа, Хәбиб? Әгәр Хафазаны бутыйсың килмәсә, монда ике генә юл кала: яки расчет аласың да чыгып китәсең, яки Перов тәкъдимен кабул итәсең.

— Мин моны беләм.

— Белсәң, сайла инде.

Мин бик нык уйга калдым. Сайларга, сайларга... Икесенең берсен — бүтән чара юк, күрәсең... Шуларның кайсын куша миңа акылым һәм вөҗданым?.. Хафазаны аяп түбәнлеккә барунымы, әллә аны корбан итеп булса да, аклануымы?.. Әгәр минем өчен дөреслек, гаделлек, ниһаять, йөз аклыгы кадерлерәк булса, соңгысын сайларга тиеш түгелме мин?.. Чынлап та үзе явызлык эшләгән кешене ни өчен аяп торырга?.. Бу нинди филантроплык?! Кем моны эшләр иде?.. «Явызлыкка каршылык күрсәтмәү!» — юк, бу кагыйдә белән кешеләр яши алмаганнар, яшәү мөмкин түгел... Хафаза да, ниһаять, моны белергә тиеш.

Инде безнең арадагы мәхәббәт әнә шулай адәм хуры булып, дошманлыкка әйләнеп бетә икән, моның өчен кешеләр мине гаепләмәсләр. Сәбәпчесе билгеле.

Кыскасы, менә шулай... Һич икеләнмичә миңа үземне аклау өчен хәрәкәт итә башларга кирәк. Ин дөресе шул булачак.

— Вафа дус,— дидем мин, яңадан телгә килеп.— Мин сайладым.

— Хуш, нәрсәне?

— Мин Перов тәкъдимен кире кагам... Иртәдән үк үземне аклау чарасына керешәм. Ни булса шул!

— Ярый, хәерле сәгатьтә! — диде Вафа, ничектер битараф кына.— Әлбәттә, син бу эшнең бөтен ягын да уйлагансыңдыр инде?

— Уйладым... Миңа гаделлек кирәк, мин акланырга тиешмен... Инде Хафазага авырлык килә икән, үзенә үпкәләр, минем башка чара юк.

— Син хаклы,— дип куйды Вафа.

— Тик син миңа тагын бер киңәш бирсәң иде,— дидем мин, аз гына дәшми торып.

— Нинди киңәш?

— Кая барыйм, кем исеменә языйм икән?..

— Син хәзергә берни дә язмый тор,— диде Вафа.— Башта сөйләшергә кирәк. Мин сиңа райкомга барып, анда Мангушев дигән бер иптәш белән сөйләшергә кушар идем. Уйлап эшли торган төпле егет... Барысын да аңа ачыктан-ачык сөйләрсең... Шуннан ул үзе сиңа кемгә, ничек итеп язарга кирәклеген әйтеп бирер. Аңладыңмы?..

— Әйе, аңладым... Ләкин ул миңа ышаныр микән соң?
— Ник ышанмасын — ышаныр... Син бит хәзергә мәсьәләнең яңадан каралуын сорыйсың — шулай түгелме? Бу бик хаклы таләп.
— Әйе, хаклы таләп,— дидем мин, үйланып.— Тик ул ялгыз минем таләп кенә булып калмаса иде.
— Ә син анысы өчен борчылма! — диде Вафа, мине юатырга ашыккандай.— Мәсьәлә бер кузгалгач, куәтләүчеләр дә табылыр. Менә мин үзем дә Мангушевка әйтермен әле... Аннары синең Васильев белән араң ничек?
— Моңарчы яхшы иде... Ул теге җыелышта булмады бит. Соныннан белгәч, карт бик борчылган дип әйттеләр. Хәтта, мин бу эшне болай гына калдырмыйм диеп тә әйткән, имеш.
— Әнә күрдеңме,— диде Вафа, җанланып.— Бу бик важно. Васильевны райкомда яхшы беләләр, хөрмәт тә итәләр, аның сүзенә, һичшиксез, колак салачаклар. Беләсеңме, Перов үзе дә аңардан әзрәк шүрли,— карт кыек эшне бер дә яратмый бит.
— Беләм мин аның ул гадәтен...
— Аннары тагын сер итеп кенә әйтим, синең урынга Басыйр Рәҗәповны куярга чамалап торалар...
— Шулаймыни? — дидем мин, бер дә гаҗәпләнмичә.— Басыйр үзенекен алыр, юкка гына тырышмагандыр...
Аннары әллә ничек үйламастан гына сорап куйдым:— Ә Хафазаны нишләтерләр икән, мин аклана калсам, аны эшеннән чыгармаслармы?
— Борчылма, чыгармаслар,— диде Вафа, тыныч кына.
— Ләкин син аңа начар булачак дидең бит?
— Мораль яктан — әйе... Ышанычын югалтыр, кешеләр күзеннән төшәр, ихтимал, шелтә бирелер... Ә эшеннән чыгармаслар — кечкенә кеше бит әле ул, бары өйрәнчек кенә... Сез әле, егетем, яңадан бергә эшләрсез, бәлки яңадан дуслашып та китәрсез.
Мин аңа, нәрсә бу — үртәп әйтәме, әллә чынлапмы дип, бик гаҗәпләнеп карадым. Ләкин Вафа бик гади бер нәрсә әйткәндәй һич исе китмичә көлемсерәп кенә тора!
— Ничек син моны әйтә аласың, Вафа? — дидем мин, тәмам аптырап.
— Нигә? — диде Вафа, ваемсыз гына.— Мәхәббәт бит ул, әгәр чын икән, тиз генә үтеп китә торган нәрсә түгел. Бигрәк тә яраткан кешең гел янында булып торган чакта. Барысы онытылыр, ә мәхәббәт әкренләп терелер...
— Чынлап әйтәсеңме син моны?
— Бик чынлап.
— Һәм син минем Хафазаны кичерә алуыма да ышанасыңмы?
— Ничек кенә әле! — диде Вафа, бу юлы рәхәтләнеп көлә-көлә.— Тиле, мәхәббәт нәрсәне генә кичерми ул!..
Һәм кинәт минем күз алдыма Вафа әйткәннәр чын булып килде дә басты. Ирексездән хәтта тетрәнеп киттем... Булуы бик мөмкин бит моның, бик мөмкин! Нишләп соң әле бу нәрсә бер генә тапкыр да минем уема килмәде?!. Килмәде, әмма күңелем нидер сизенә иде түгелме?.. Бу куркыныч бар икән ләбаса, бар икән, тамыры бөтенләй үк корымаган икән!.. Ләкин мондый тирән ярадан соң минем мәхәббәтем терелергә тиешме, кирәкме, ярыймы ул?.. Терелә калса, мин үземне гомерлек газапка, бәхетсезлеккә дучар итмәммме?.. Мәхәббәт ышанудан башка була алмый бит, була алмый, ә мин ул ышанычны яңадан ничек итеп кайтарыйм соң?!.
— Юк, бу булачак түгел,— дидем мин, тешләремне кысып,— булачак түгел!!.
— Ә син алдан кычкырырга ашыкма, дус кеше! — диде Вафа, сабыр гына.— Тормыш бу, кешене кырыкка бөгә...

— Әйтмә, әйтмә, Вафа, минем бөгеләсем килми! — дидем мин, башымны кат-кат чайкап.

Вафа сынагандай беравык миңа житди генә карап торды, аннары йомшак кына әйтте:

— Менә нәрсә, Хәбиб, син аргансың, нервыларың да кузгалган, сиңа хәзер ял кирәк. Бүгенгә житәр. Сөйләшәсен сөйләштек, хәзергә шуның белән бетерик.

Әйе, Вафа дөрес әйтә. Мин хәзер үземне кыйнап ташланган эт шикелле тоям. Зиһенем дә әллә ничек чуала башлаган кебек... Житте, ахрысы, бик житте... Кайтырга кирәк. Авыр гына сулап мин урынымнан тордым.

— Ярый, Вафа,— дидем, аңа кулымны сузып,— бөтен әйткән сүзләрең, биргән киңәшләрең өчен рәхмәт! Бел, синнән башка минем бүтән килеп төртелер кешем юк иде.

Ул «аңлыйм» дигәндәй башын гына какты һәм мине ишеккә чаклы озата чыкты. Аерылышкан чакта гына шулай да әйтеп куйды:

— Хәбиб, син давай бу хәлне артык зур трагедиягә әйләндермә, ашыгыч нәтижәләр ясама, үзеңне тыныч тот!

— Рәхмәт, Вафа!

Мин тагын бер мәртәбә аның кулын кыстым.

Урамда күз бәйләнерлек караңгы иде инде. Кич ничектер тымызыкмонсу, томанлы, фонарьлар да кабынмаган — аяк астын шәйләп бу-лырлык та түгел. Мин чокыр-чакырлы иске тротуар буйлап, тәрәзәләрдән төшкән яктыда бик тонык кына чагылган суларга басмаска тырышып, шулай да әледән-әле суның нәкъ күзенә баскалап, китеп бардым. Трамвайга утырасым килмәде. Каюм Насыйри урамына борылдым, аннан Татарстанга килеп чыктым. Монда яктырак иде, һәм кызулап, туры гына үзем торган Куйбышев урамына таба атладым.

Мин кайтып кергәндә Серафима түтәй кухняда ялгыз гына үзенең зур таш чәшкәсеннән чәй эчеп утыра иде. Мине күрүгә:

— Хәбиб, син бүген эшкә бармадыңмыни? — дип сорады.

— Нигә? — дидем мин, аптырабрак.

— Фая килгән иде, сезне бик озак көтеп утырды.

Мин бусагага ябышкандай катып калдым.

— Хафаза?!.

— Әйе инде...

— Күптәнме?

Серафима түтәй миңа бик сәерсенеп карады, гүя ул минем тавышымны танымый иде.

— Әле бик күптән түгел,— диде ул, күзләрен миннән алалмыйча,— китүенә бер ун минут булыр.

Мин шул секундта ук кире борылып чыгып та киттем. Ак-караны күрмичә, ашыга-ашыга Хафазалар торган якка — Болак буена таба атладым. Кичке томан эчендә селкенгән шәүләләрне, аңа охшаса-охшамаса да, куып житәм дә узып китәм, куып житәм дә узып китәм... Хәер, мин әле ни өчен болай йөгерә-атлый баруымны да аңлап житкермим... Аны куып житәр өченме, күрер өченме?.. Ләкин хәзер бу мөмкин түгел бит инде — ун минут эчендә ул өенә кайтып житкән булырга тиеш. Әллә минем бу берни белештермичә ашыгуым ирексездән туган бер рефлекс кынамы?

Шулай бара-бара мин адымнарымны ничектер һаман әкренәйтә башладым. Болак чатына житкәч, ниһаять, тукталып калдым... Хафазаны куып житү яки артыннан өенә барып керү — бу, беләсезме, ни белән бетәчәк?!. Юк, зиһенем әле сау чакта, үземә-үзем әле хужа чакта миңа туктарга кирәк, туктарга!.. Шәүлә куып барудан мәгънә юк, мәгънә калмады... Мин кире борылдым. Абына-сөртенә кире киттем... Әгәр шушы минутта мин үксеп жибәрсәм, моңа берәү дә гажәпләнмәс

иде... Ул, Хафаза бәгыркәем, миңа килгән, көткән, озак көткән!.. Ә мин анын ялганын фаш итмәкче булам, кемнәрдер алдына барып, үземне акламакчы, аны гаепле итеп калдырмакчы булам. Мин тап-таза ир башым белән шул кечкенә, зәгыйфь җанга каршы көрәшмәкче булам... Ниндидер бер ярсу-тәвәккәллек йөрәгемне ялкындай каплап алды, шушы җепшек, томанлы төнгә кычкырып әйтәсем килде: «Юк, булмас бу, булмас, кичәге мәхәббәтемне мин бүген аяк астына салып таптамаячакмын!.. Бөтенесен үз өстемә алам — тәүбә дә юк, аклану да юк!.. Бер селтәнүдә барысын өзәргә, бетерергә, ташлап китәргә — бары шул гына».

...Икенче көнне мин торып, әйбәт кенә юынып, чиста күлмәк, яңа костюмымны, шулар өстеннән зәңгәр плащымны киеп, соңгы тапкыр мехбазага киттем. Көн бик җылы — йомшак, бик якты иде. Фәрештә канатыдай... Шунын шифасыдырмы, минем дә җаным гаҗәп тыныч иде, кичәге газаплардан берни дә калмаган, гүя барысы да үз урынына кайткан, утырган... Хәтта киләчәгемне дә мин бүгенге көн шикелле япякты итеп күрәм сыман...

Мехбазада эшем тиз бетте. Бухгалтерия миңа расчетны әзерләп үк куйган икән. Үткән айның ике атнасы, бу айның биш көне өчен хезмәт хакын, шуның өстенә сигез ай эшләгән өчен тиешле отпуска акчасын бирделәр. Һәртөрле тотып калулардан соң кулыма йөз егерме сум тиде. Бу бик зур акча иде. Торып була икән әле, дидем мин, хуҗаларча салкын исәп белән. Аена ун тәнкәгә дә торып өйрәнгән кеше без.

Кулыма приказ күчермәсен дә бирделәр. Акчаларны бик эчкәрә җыйдым, ә бу күчермәне бөгәрләп тышкы кесәгә генә тыккан булдым. Ул миңа кирәкми иде.

Мостафаны тагын күрә алмадым — ниндидер эшләр белән мехкомбинатка киткән, диделәр. Шулай итеп, берәү белән дә күрешмичә диярлек, янадан бер вакытта да аяк басарга туры килмәячәк мехбазадан мин чыгып киттем. Минем өчен күңелле җир, яхшы җир иде бу мехбаза... Шушында сигез ай эшләп, мишәр абзыйлардан каракүл бизәкләрен «укырга» өйрәндем, шушында Басыйр кебек чүпләрдән башка, әйбәт иптәшләр таптым, шушында, ниһаять, беренче яратуның үкенечле ләззәтен татып карадым, инде менә... Ярый, сынмыйк, сыкранмыйк!.. Илдә чыпчык үлми, дигәннәр безнең агайлар.

* * *

Бәкер дус, минем хикәям шушының белән бетте, инде нокта куйсам да ярый торгандыр. Ләкин синдә: шуннан соң ни булды? дигән сорау туарга мөмкин. Бик кыска белешмә рәвешендә генә әйтеп китим, булмаса.

Башта язганымча, максатым бер ел эшләп, кая да булса укырга китү иде. Хәзер инде бу минем өчен бердәнбер теләк һәм чара булып калды. Ләкин кая китәргә? Баштарак мин Казан университетына керү турында уйлана идем. Эшләр болай булып киткәч, минем Казанда һич каласым килми башлады. Саф һавага сусагандай, күңел өзелеп яңа җир, яңа кешеләр тели иде. Аннары миндә кинәт кенә энергетика белгечлегенә укыйсы килү теләге туды. Әледән-әле Ленинның электрификация турында әйткән даһи сүзләре искә төшә дә тора. Минем өчен хәзер, бәлки, нәкъ менә шул баганалы юлга чыгу кирәктер дә. Мәскәүдән кала тагын Иваново шәһәрендә дә энергетика институты бар икән. Тыныч кына, бирелеп кенә укыр өчен шушы кеше таптамаган аулак шәһәрне сайларга булдым. Ләкин көзге имтиханнарга бик ерак иде әле... Ана чаклы нишләргә, вакытны кайда үткәрергә? Серафима түтәйдә булмә биләп, эшсез тик яту мөмкин түгел. Гомумән тик ята алмыйм мин... Дөрес, миңа хәзер институтка керер өчен нык кына әзерләнергә

кирәк, ләкин монда түгел, чөнки күп хатирәләр саклаган бу бүлмәдә һич тә каласым килми иде. Серафима түтәй дә тора-тора да: «Фая нигә килми, ни булды?» дип сорап куя. Юк, моннан китәргә кирәк, китәргә!

Иделнең тулып, җәерәп ташыган чагы. Беренче пароходлар төште. Аларның сузып-сузып кычкырткан тавышлары күңелләрне җилсетеп, әллә кайларга чакыра — дәшә кебек... Җанны кая куярга белеп булмый... Бер Әстерханга төшеп китәргә дип тәмам җыенып та беткән идем, ләкин тыелып калдым — акча кызганыч, акчаны сакларга кирәк иде. Шуннан соң тоттым да Май бәйрәменең икенче көнендә ат-арбалар тәяп йөртә торган иске «Волгарь» паромына утырып, үзебезнең Югары Осланга чыгып киттем. Ул елларда әле Казан халкы шул якка күпләп дачага чыга торган иде. Мина да бу нәрсә харам булмас дип, шундагы бер түтәйдән арзан гына почмак табып, торып калырга булдым. Кайтып, барлы-юклы әйберләрем һәм китапларым белән күтәренеп тә килдем. Шулай итеп, уйламаган җирдән генә Югары Осланда тора башладым. Ерак түгел генә Печище тегермәне бар, ә минем нык-таза чак, һәм менә ара-тирә шул тегермәнгә барып, бар-жага он төяшә идем. Белешмә-мазар сорамыйлар, акчасын шунда ук түлиләр, иш янына куш дигәндәй, бу миңа ярап куя торган иде.

Югары Осланда мин июль урталарына чаклы тордым. Аннары бер атна-ун көнгә генә Япанчыга кайтып килдем. Ә август башларында инде мин тәвәккәлләп Иваново шәһәренә китеп бардым.

Имтиханнарны уңышлы гына биреп, әлеге шул энергетика институтына укырга кердем. Яңадан студент булдым. Еллар авыр иде. «Лаеш шулпасын» шактый эчәргә туры килде. Аннары татарлардан мин бер үзем генә идем. Шәһәри Казанны, милләттәш туганнарны ирексездән инрәп сагынган чакларым булгалады. Әйе, ирексездән... Кайчагында онытылып: «Хәмдиягә сүз әйтмәгез, зиһене таралган чагы...» дип җырлый башлый идем дә аннары кинәт өзелеп, үз-үземә: «Син, Хәбиб, бозау булма!» дип бармак яный идем һәм күзгә килгән яшьләрне селтәп ыргыта идем.

Дүрт елдан соң мин институтны тәмамлап, инженер булып чыктым. Дәүләт комиссиясе мине Үзбәкстанга билгеләде. Икедә уйламыйча риза булдым. Кайчандыр миңа кояшын һәм икмәген биргән юмарт илгә үземне бик бурычлы саный идем. Белемемне, дәртемне, өметләремне куш учыма салып дигәндәй, киттем мин шул эссе-аяз илгә! Бу 1936 ел иде. Шул елдан минем озын хезмәт юлым башланды.

Инде менә ике елдан миңа алтмыш яшь тулачак. Бәкер дус! Гомер узды... Исте җилләр, күчте комнар... Өметләрнең кайсылары үтәлде, кайсылары юк... Ә мин эшләдем дә эшләдем. Айлар артыннан айлар, еллар артыннан еллар үзем суздырган электр чыбыгы буйлап китә торды. Тулаем алганда, мин канәгать. Үзбәкстанда хәзер Ильич нуры кермәгән өй калмады... Шулай итеп, үземә тигән эш агачының җимешен әкренләп өзеп бетереп килэм. Дөресен әйтергә кирәк, татлысы да, әчесе дә күп булды. Табигый хәл!.. Тик менә мин үзем генә җимешсез, кысыр агач булып калдым. Син беләсең инде, минем хатыным да, балам да юк. Вакытында өйләнә алмадым. Моның сәбәбен бер Хафазага сылтасам, һич тә дөрес булмас иде. Әйе, Хафаза минем йөрәгемә кадалган шырпы булды, ләкин ул күптән ит белән үрелде, күптән онытылды. Дөрес, баштарак мин хатын-кыздан, ничек дим, гайрәтем чигеп, бизеп йөрдем. Аннары тора-бара бу ятлашу, бу чиркану бетте, басылды. Мин бит тап-таза ир идем, шулай ук әскет тә, ханжа да түгел идем, һәм яшермим, хатын-кызсыз да тормадым. Ләкин ни хикмәттер, шуларның берсенә дә чын, тирән мәхәббәт миндә яңадан уяна алмады. Ә чын мәхәббәттән башка өйләнүне ничектер җаным кабул итмәде... Кыскасы, ычкындырдым мин өйләнү вакытын, ә инде олыгаюга киткәч, әйтик, утыз биштән соң, тәвәккәлләү бик читен

икән. Әлбәттә, бу мәсьәлә мине һәрвакытта борчып килде, картлык якынлаша башлагач, аеруча нык уйландырды, әмма, нихәл итәсең, булмый менә, мәҗбүр итә алмыйм үземне, ялгызлыгыма өйрәнеп яшим, тем, ә ахрын уйламаска тырышам.

Сине бәлки Хафаза язмышы кызыксындырадыр, кайда ул, ни булды аңа дип сорыйсың килә торгандыр. Нәрсә әйтим? Мин үзем дә бик озак вакыт аның турында хәбәрсез яшәдем. Башта Иваново, аннары Ташкент дигәндәй, аралар да бик ерак булды, еллар да күп үтеп китте. Яшермим, баштарак мин аны еш кына исемә төшереп, кайда, нишли икән? дип уйлана торган идем. Онытты дисәм дә, Бәкер, ул кызый күңелнең әллә кайсы гына төшендә һаман яшеренеп ята бирде...

Сугыштан соң мин Ташкентта һич көтмәгәндә генә элек мехбазада бергә эшләгән бер кызны очраттым. Билгеле, Хафаза турында сорашмыйча түзә алмадым. Ул кыз (хәер, бу вакытта инде ул ханым иде) миңа шуны сөйләде: Хафаза миннән соң мехбазада бер ел чамасы эшләп йөргән, шул арада techинститутны бетергән бер башкорт егете белән танышкан һәм шул егет аны үзе белән Уфага алып киткән. Хәзерге вакытта да шунда яшиләр ди... Хафаза бик әйбәт кенә тора, имеш, өчме-дүртме баласы да булган икән инде, кыскасы... әнә шулай... Хатын булыр өчен генә яратылган кыз иде ул, ниһаять, үзенә кирәкне тапкан... Бу хәбәрне сөйләгән ханым белән минем яңадан очрашасым килмәде.

Бетте шикелле. Арыдым да бугай. Син инде, Бәкер дус, миннән: «Ни өчен бу нәрсәне яздың?» дип сорама. Нәтиҗәне үзең яса. Ә минә язмыйча мөмкин түгел иде, иртәме, соңмы мин аны барыбер язарга тиеш идем. Каберемә алып китә алмыйм мин аны!..

Әгәр Ташкентка килергә уйласаң — көз яхшы. Көзен тәмле исләр дә күбрәк була, арыклардан сулар да чистарак ага. Җылы, тымызык, рәхәт вакыт. Мин үзем гомер буе ялгыз яшәгән кеше булгач, аш-суга тәмам өйрәнеп җиттем диярлек. Үзбәкчәләп әйткәндә: «Плауны җедә һәм саз кыламыз да... Безгә һәм миһман болеп килең ахыр, җүрә-җан, килең!»

Хуш, бигайбә!

*1966—68 ел.*
*Казан.*

◇◆◇

**Тәүфыйк Сәгыйтов**

# ӨЛКӘН ДУСЛАР ЯРДӘМЕ

**ОЧЕРК**



Инде чыгып китәргә дип, утырган урындыкларын өстәл янына якынайтып куйгач, Мөҗәһит Габдрахманов кинәт кенә әйтеп куйды.

— Җәмәгать, ашыкмагыз әле, киңәшәсе бер мөһим мәсьәләне оныта язганмын.

Партия оешмасы секретаре да, комсомол комитеты секретаре да, хәтта директор үзе дә сагаеп калдылар.

Кадрлар бүлеге начальнигы:

— Район Советы Башкарма Комитетыннан шалтыраттылар,— дип сүзен дәвам итте.— Яшүсмерләрне эшкә урнаштыру комиссиясе безгә унбиш яшьлек бер малайны бирергә уйлый икән, фамилиясе Кручинин, ди...

— Туктагыз, алай булганда профсоюзны да чакырыйк әле,— диде директор һәм кнопкага басты. Шул секундта ук ишек ачылды һәм саргылт чәчле, урта яшьләрдәге секретарь керде:

— Нәрсә, Мирсәет Мөхәммәтович?

— Завком председателе керсен әле.

Бөтенесе дә җыелды, директор бүлмәсендә киңәшмәнең алдан планлаштырылмаган дәвамы башланды. Җиңел генә хәл итәргә ярамый, ни әйтсәң дә, кеше язмышы. Ул гына да түгел, яшүсмер егет тормышының олы юлына беренче адымын ясый. Бусы бер. Икенчедән, Габдрахмановның аңлатуынча, Николай Кручинин яшьли әти-әнисез калган, аннан балалар йортында тәрбияләнгән, хәзер Киров районы интернат-мәктәбендә укый икән. Җиде классны да тәмамламаган әле, ә үзе эшкә урнаштыруларын таләп итә. Анысы шулаен шулай, ләкин егет үз-үзен ничек тотар: ул эшләгән «ЧП»лар өчен җавап бирәсе булмасмы? Ак күлмәктә кечкенә генә тап та ерактан беленеп торган кебек, андый чакта кечкенә генә фактлар да зур булып күренә ул... Ләкин, ничек кенә итмә, каршы килеп тә булмый. Шундый зур коллектив бер яшүсмерне кабул итеп аякка бастыра алмады, шүрләде, диярләр.

— Тулай торактан берәр урын таба алабызмы? — диде директор, сораулы караш ташлап. «Тырышып карарга кирәк булыр», дигән җавапны ишеткәч, сүзен тагын дәвам итте:— Үзе ошаткан һөнәргә өйрәнер. Шулай да, иптәшләр, берәр олырак яшьтәге коммунист аны шефка алса, яхшырак булыр иде. Әтисе кебек кеше. Кемгә тукталабыз?

Төрле тәкъдимнәр әйтелде.

— Осипук?! Петр Михайлович! Заводта кырык еллап эшли. Яшьләр алдында дәрәҗәсе дә зур,— диде Габдрахманов.

Аның белән килештеләр. Әле хәзергә бары тик исем-фамилиясен генә белсәләр дә, Николай Кручинин өчен бөтенесен дә алдан кайгырттылар.

Заводка яшьли ятим калган, ил канаты астында үскән яңа кеше килде...

* * *

Группа зур түгел. Группадагыларның һәрберсе дә әле күптән түгел генә мәктәп партасы артыннан торып килүчеләр иде.

— Сез укуны биредә дә дәвам итәрсез,— диде Габдрахманов,— теория буенча белем алу өчен махсус класслар, дәреслекләр бар. Практиканы станок янында үтәрсез. Өйрәтүче эшчеләр үзләренең бай тәҗрибәләрен сезнең белән уртаклашырлар... Кем нинди һөнәр алырга тели?

— Кайсы яхшырак соң? — диде арадан берсе.

— Без берегезгә дә син шул һөнәргә өйрән дип әйтмибез. Хәзер сезгә заводны күрсәтеп чыгарбыз. Цехлардагы бөтен төр станокларда эшләүче кешеләр белән очрашканнан соң гына, үзегезгә ошаганын әйтерсез, килештекме?

Группа цехларга юнәлде.

— Биредә конвейерлар ясыйлар. Менә алдынгы токарь Камил Бәйрәмов...

— Канат юллары ясау цехы. Монда токарь һөнәренә Фәрит Әхмәдуллин өйрәтәчәк...

— Инструментлар цехы. Сез иптәш Низаметдинов янында. Ул кырык елга якын инде шушы заводта фрезерчы булып эшли. Дистәләрчә кешеләрне өйрәтте. Әгъзам ага, яшьләргә берничә сүз әйтегезче?..

Заводның бөтен участокларында булып, олы яшьтәге эшчеләр белән таныштырганнан соң, Мөҗәһит Габдрахманов аларның барсына да берьюлы сорау бирде:

— Я, кайсы һөнәр яхшырак?..

* * *

— Фрезерчы булырга теләдем дисең инде, ә?.. Ярый, брат, ярый... Бик белеп сайлагансың. Менә мин чирек гасыр инде фрезерчы, әмма бу һөнәргә өйрәнүемә үкенгәнем юк әле. Бик белеп сайлагансың.

Шәүкәт Гомәровның үз һөнәре, үз эше белән шулай горурлануы Кручининга да ошады. «Димәк, теләсә кайсы заводка барсаң да ике куллап каршы алалар! Ярый торган нәрсә ул. Бер дә куркып торасы түгел икән».

Остаз аңа станок турында кыскача гына сөйләп үтте, фрезәләр күрсәтте:

— Тимерне кырдыргач, әнә нинди матур деталь килеп чыга, күр әле!

Сүзне кинәт кенә ишетелгән сәлам тавышы бүлдерде.

— Эшләр ничек бара, Шәүкәт Алиуллович? Яңа егетең бар икән?

— Әйе шул, таныш булыгыз.

— Осипук, Петр Михайлович.

— Кручинин, Коля...

Алар кул биреп күрештеләр. Ул, детальләрне карап, нәрсә турындадыр киңәште. Тагын бераз сөйләшеп тордылар. Петр Михайлович Коляны заводның китапханәсенә ияртеп китте.

— Бик яхшы кешегә эләккәнсең,— диде Петр Михайлович китапханәгә барышлый.— Дистәләрчә яшьләрне кеше итте ул. Син утызынчы яисә кырыгынчысыдыр. Һәрберсе менә дигән фрезерчылар булып чыктылар.

— Менә безнең заводның булачак яңа эшчесе,— диде Петр Михайлович, китапханәгә кергәч.— Аны да укучы итеп языгыз.

Алар тагын очрашырга булдылар. Коля инде аның эш бүлмәсендә дә булып алды.

— Кем соң ул «начальник ОТК»? — дип сорады Коля остазыннан.— Ишегенә шулай язылган.

— Техник контроль бүлеге начальнигы. Икенче төрле итеп әйтсәк, биредән озатыла торган бөтен продукциянең сыйфатын үз күзеннән кичерә. Аз гына шикле булса да уздырмый,— диде Гомәров.

— Алай булса бик начар, усал кеше инде ул.

— Һе, кем ничек аңлый бит,— диде Шәүкәт абыйсы, бераз көлемсерәп.— Әйтик менә синең кесәңдәге авторучкаң. Әгәр дә аны заводта, берәрсенең үз эшенә салкын каравы аркасында, нинди дә булса кимчелек белән ясыйлар, ди. ОТКада моны белег

алалар. Синеңчә уйласак, баш контролер үз каршысындагы кешене кызганып, бу ручканы кабул итәргә әмер бирде, ди. Магазиннан барлы-юклы акчаңны түләп алганда шул ручка сиңа эләгә, ди. Я, ничек?!

Коля уңайсызлануыннан колагына кадәр кызарды.

— Менә шулай шул. Әгәр безнең заводта ясалган канат юллардагы брак рудникларда, шахталарда, химия комбинатларында гына беленде, ди. Күпме зыян! Бу бөтен ил алдында оят бит. Менә Петр Михайлович шул хәлне булдырмаска, житешсезлекне заводта ук күрергә тиеш.

Шәүкәт абыйсының гади, аңлаешлы итеп сөйләве ошады Колягa. Цехтан чыгасы килми иде аның. Әмма бу күтәренкелек күпкә бармады...

Аның сүлпәнлеген Гомәров берничә көннән үк сизеп алды.

— Болай таркау булмыйлар, егет кешегә ут уйнатырга кирәк,— дип кисәткәләп торды ул. Юк, файдасы тимәде. Коля һаман станок янынннан китә, заводны аркылыга-буйга иңләп йөри иде.

— Син миңа улым кебек кеше,— диде остаз, эчтән ачуланганын сиздермәскә тырышып,— турысын әйтәм, станок янында мондый сирәк «кунак»ка әйләнсәң, синнән рәтле эшче чыгар микән? Соңыннан үзеңә авырга туры килмәсен, дим...

— Юк, мин йомыш белән генә киткән идем.

Һәрбер киткәне өчен сәбәп табып кына торды ул:

— Тәмәке тарттым...

— Газлы су эчәргә бардым...

«Һе, ишетергә, тыңларга теләмәгән кешедән дә саңгырау кеше юк диләр, дөрес, ахрысы», дип борчылды Шәүкәт Гомәров. Ул еш кына егет турында уйлана торган булып китте.

Әллә фрезерчы Гомәров үз һөнәренең ләззәтен Николайга йоктыра алмадымы? Тора-бара Кручинин цехтан бөтенләй бизде, эшкә үк чыкмый башлады.

Тулай торакка бардылар. Ни күрсеннәр: Коля урынына сузылып яткан, кулында «Хезмәт турында законнар» китабы.

— Нәрсә, урам аркылы гына чыгып та эшкә керергә иренәсеңме әллә? Прогул өчен заводтан куулары бар ич,— диделәр аңа.

— Мин дә шуны укыйм әле, безне эшкә урнаштырган комиссия рөхсәтеннән башка заводтан китәргә ярамый икән.

— Бурычларыңны белмәсәң дә, хокукларыңны эзләп тапкансың,— диде Габдрахманов, аңа рәнҗеп,— яшүсмерләр бүлеген генә түгел, эшчеләрнең җаваплылыгы турында язылган битләрне дә укып кара.

Кручинин өске киемнәрен дә салмаган килеш, керүчеләргә күтәрелеп тә карамыйча урын өстендә ята бирде, әллә аңа, әллә стенага әйтәләр.

Эх, Мөҗәһит Габдрахманов, алты бөртек мыек та чыгарырга өлгермәгән Кручинин алдында аз гена ихтирамга да лаек түгелмени соң син?! Борын асты да кипмәгән шул малайны эләктереп ал идең дә, үзеңнең изге киңәшләреңне әйткәнче гена булса да, каршыңда аягүрә бастырып тор идең! Син аның кебек вакытта ил азатлыгы өчен көрәшеп кан койдың, ике мәртәбә авыр яраландың, аннан соң 13 ел буе КПССның Киров райкомы аппаратында эшләдең, хәзер зур гына коллективның кадрлар бүлеге белән житәкчелек итәсең... Янсә янында гына торган Осипук! Петр Михайлович та гомере буе шушы предприятие өчен тырыша... Әнә ВЛКСМ комитеты членнары. Производствода һәм комсомолда үзләрен үзләре аямыйча көне-төне эшләүчеләр бит алар. Ә Кручинин борынын тартып һаман ята бирә... Кем соң ул?! Дөньяга әзергә бәзер туган, ата-ана кадерен күрмәсә дә, тулаем дәүләт җилкәсендә үскән, ашаган, киенгән, укыган... Бер килограмм металл ватыгы җыеп та игелек күрсәткәне юктыр әле!..

— Әйдә, хәзер үк тор да кадрлар бүлегенә кер әле, Коля,— диде Габдрахманов, тыныч кына. Инде аннары да Кручининның игътибарсыз ятканын күргәч, тавышын үзгәртә төште.— Шушы минутта ук керергә дигәнне ишеттеңме? Сиңа ике әйтелмәс! Киттек, иптәшләр...

Керерме, юкмы?

Ниһаять, Мөҗәһит Габдрахманов бүлмәдә үзе генә калгач, тавышсыз гына ишек ачылды:

— Рөхсәтме?
— Кер, Коля, котәбез.
— Нигә чакырдыгыз, орышыргамы?
— Башыңнан сыйпарлар дисеңме? Нигә эшкә йөрмисең?
— Бүтән калмам.
— Кичә кемнәр белән эчтең?
«Анысын да җиткерергәннәр!»
— Ни... мәктәптә бергә укыган идек, без алар белән...
— Алар кая эшлиләр? Нинди акчага эчтегез?
«Бу бөтенләй стенага тери бит әле...»
— Кая эшләүләрен белмим.
— Трай тибәләр, шулаймы?
— Без алар белән урамда сирәк кенә очрашабыз. Шуңа күрә белеп тә бетермим.
— Ә мәнә синең акча алган көнеңне алар белеп алганнар. Бер тиенсез калдырганнар бит үзеңне. Яшереп утырасың тагын...
Мөҗәһит Габдрахмановның сүзләре хак иде. «Дуслары» аның өйрәнчек булып эшләгән акчасына «авыз чылатканнар». Менә шуннан бирле ул ачлы-туклы йөри икән. Егетне кызганып, үзе белән әбәт ашатучылардан бу турыда ишетүгә үк, Габдрахманов директор янына кереп киңәшкән иде.
— Менә кәгазь, ручка,— диде ул Кручининга,— гариза яз!
«Үзем теләп эштән китәм дип, гариза яздыра... Комиссия белән дә сөйләшеп куйганнардыр әле. Дурт ягың кыйбла, диярләр инде».
Бер эссе, бер суык булып китте аңа. Шулай да үз-үзен кулга алырга тырышып, начальникка карады. Габдрахманов әйтеп тора башлады:

**«Урак һәм чүкеч» заводы директоры**
**иптәш Рәхимкуловка**
**КРУЧИНИН НИКОЛАЙДАН**

## ГАРИЗА.

**Әгәр мөмкин булса, миңа материаль ярдәм күрсәтсәгез иде».**

Габдрахманов кәгазьне алып укыгач, кашларын җыерып куйды:
— Ике юлга алты хата,— диде дә ашыгып кына чыгып китте.
Ике-өч минут та үтмәде, ул әйләнеп тә керде:
— Кассага барыйк әле, кул куй.
Анда Коляга ун сум акча бирделәр.
«Һәй, шәп булды бит әле бу! Туйганчы ашыйм да бер ярты алам»,— дип уйлап та бетермәде егет.
— Коля, китер акчаны монда,— диде Габдрахманов. Һәм Коляны яңадан үз бүлмәсенә алып керде.
— Акчаны миңа бирделәр түгелме соң? Әллә икебезгәме?
— Юк, юк, синең тиенеңә калмаган мин. Менә, монысына, хәзер үк кереп, туйганчы ашап ал. Кара аны, аш та салдыр. Ә смена ахырында тагын минем янга керерсең. Кич һәм иртә беләнгә җитәрлек акча бирермен. Калганы менә шул өстәл тартмасында торыр. Көн саен кереп алырсың. Шулай итеп еш рак очрашырбыз, акча тотарга да өйрәнерсең...
Бер көнне эштән соң начальник аны тагын үз бүлмәсенә чакырды.
— Берәр туганың юкмы соң синең, Коля,— диде ул.— Бәлки эзләп табарбыз, ә?!
Завод исеменнән хатлар яза-яза, туганнан туган абыйсының Горький шәһәрендә, ө үз абыйсы Александрның Казанда ук эшләгәнлеге беленде.
Габдрахманов башта Николайның үз абыйсы белән очрашты.
Бер карауга бөтенләй якын да түгелләр кебек. Бик яшьли аерылганнар, төрле шәһәрләрдә балалар йортында тәрбияләнгәннәр. Туганлык якынлыгы бер-беренә тартыр микән?

— Беләсеңме, Саша, ике туганның бер-берен табышуына без бик шат. Сез дә шулайдыр. Безнең сиңа зур бер үтенечебез бар: Коляга күз-колак булуга син дә ярдәм итмәссеңме? Аның үз-үзен тотышы, шикле кешеләр белән йөрүе, алган көнне үк акчасын эчеп бетерүе бик борчый безне.

— Нәрсә тәкъдим итәсез соң?

— Бергәләп уйлашыйк. Эшкә дә мөнәсәбәте әйбәттән түгел. Ярый, анысы өчен участок мастеры, өйрәтүчесе белән үзебез җәфаланабыз инде. Менә тулай торакта синең кебек якын кешесе булса иде.

— Баргалап кайтырмын.

— Баргалап кайту суга сәнәк белән язу диген сүз ул. Безне андый юл гына канәгатьләндерми. Әгәр Коля янына эшкә дә урнаштырсак, ә?

Саша Кручинин — трамвай-троллейбус идарәсе слесаре. Ул яхшы гына хезмәт хакы ала, тулай торакта яши иде.

— Мине җибәрмәүләре дә бар бит,— диде Саша, уңайсызланып.

— Кайгырма, анысын үзебез җайларбыз. Шәһәр партия оешмасы да ярдәм итәр,— дип ялгап китте Габдрахманов,— тик, Саша шунысы бар: торакка урнашу бик кыен бездә, әлегә бер генә дә буш урын юк. Ләкин завод җитәкчеләре белән килешенгән: тиздән бер егет квартира алачак, аның урыны сиңа калыр.

— Алайса, башта Коля белән икебезгә бер койка булыр. Әле безнең беркайчан да бергә йоклаганыбыз юк...

Мөҗәһит Габдрахманов, завод исеменнән хат язып, трамвай-троллейбус идарәсенә барды. Анда үзләре өйрәткән кешене ычкындырырга теләмәсәләр дә, хәлне тулырак итеп аңлаткач, килештеләр.

Саша Кручинин токарь һөнәрен сайлап алды.

* * *

Кручинин өчен партком утырышында берничә мәртәбә кызарган Осипук та, кадрлар бүлеге начальнигы Габдрахманов та һәм фрезерчы Гомәров та җиңел сулап куйдылар. Хәзер Коля буш вакытларын гел абыйсы белән икәү уздыра. Берәр сумлап кына акча бирү мәшәкате дә бетте. Иң мөһиме: абыйсына карап, эшкә булган мөнәсәбәте үзгәрде Коляның.

Саша өченче разрядлы токарь, Коля икенче разрядлы фрезерчы булды. Инде, бер уйлаганда, борчылыр урын да калмады: хезмәт хакы алалар, киенәләр, икесе бер бүлмәдә яшиләр, койкалары да рәттән... Әмма тынычланырга иртәрәк икән шул.

Саша Совет Армиясе сафларына чакырылды. Коля, үзе генә калгач, кая барып бәрелергә дә урын тапмады.

Яңадан иске «дуслар»ы күренә башлады. Тагын эшкә соңга калулар, бөтенләй килмәүләр...

— Мин Горькийга китәм, бөтенләйгә,— диде ул, кадрлар бүлегендә.— Мөҗәһит Мәсгыйтович, яшүсмерләр комиссиясе белән үзегез сөйләшерез инде?

— Ни булды? Анда нишләмәкче буласың? Китмә, Коля, һәр тәвәккәллек батырлык түгел ул.

— Әти урынына калган абый этеп екмас әле. Аларда яшәрмен.

Габдрахманов яшүсмерләрне эшкә урнаштыру комиссиясе членнарына бу турыда озак сөйләде. Ышандырды.

Коля Кручининны пароходка кадәр озата бардылар. Ул киткәч, цехта кайберәүләр иркен сулап куйды.

* * *

«Әй, син абый кеше, абый кеше! Әгәр яшәү дәверендә Сашаның улы очрасын иде әле миңа, күтәреп йөртер идем мин аны. Ә синең мин килүдән туган шатлыгың бер сәгатькә дә бармады. «Сиңа унсигез яшь тә юк, эшкә тыгасы авыр булыр», дисең. Яшем җитсә, мин сиңа килеп абыныр идеммени? Безнең заводта кешегә унсигез тулса, аны котлап директорның махсус приказы языла, проходной янындагы тактада ике-өч көн буе эленеп тора ул. Әнә конвейерлар цехындагы Юсуповка унсигез яшь

тулган көнне Мәскәүгә Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә бер атналык бушлай путевка бирделәр. Анда күргәннәрен сөйләгәндә авызыңны ачып тыңлыйсың! Ә Хватов белән Ястребованы завод үз исәбеннән Кара диңгез буена ял итәргә җибәрде. Әле бүгеннәрдә дә кемгәдер унсигез яшьтер, аны бөтен завод котлыйдыр, бүләкләр бирәләрдер. Ә мин, юләр, шуннан киттем, абый янына, имеш. Карап торырга рәтле генә, пәһлевандай ир кеше, ә үзе — хатынының сүзеннән чыкмый. Анысы да явыз икән, я мин, я энең, ди. Ә теге сакаллы сабый шуннан курка, тезләре калтырый... Эх, Горький, Горький! Матур шәһәр, зур шәһәр икәнсең син. Тик, аяк киемнәрең кысан булса, дөнья киңлегеннән ни файда?!»

* * *

Мөҗәһит Габдрахманов үз күзләренә үзе ышанмады. Ни күрсен: Кручинин лабаса! Ояла. Бусаганы атлауга ук тукталган да, башын түбән иеп, ике кулы белән баш киемен бөтәрли. Чәчләре, бик озак юмаганга, тырпаеп торалар. Муены, битләре тузанга баткан. Өстендәге ак күлмәге дә керләнгән.

— Коля, ни булды, кара әле кыяфәтеңне,— диде Габдрахманов һәм утырган урыныннан торып, аңа каршы атлады.

— Юкка киткәнмен мин анда. Булмады... Хатыны да бик зәһәр кеше икән.

Коля, кулын селтәп, яңадан читкә карады. Үзе, күз керфекләренә килеп җиткән яшен чыгармаска тырышып, иреннәрен чәйни иде... Күренеп тора: беркая да барып төртелер урыны булмаганга монда килгән инде ул.

Мөҗәһит абыйсын аның белән әйбәт итеп сөйләшер дип күз алдына китермәгән иде Коля. «Син хәзер безнеке түгел, китмә идең, әлегә без эшчеләр кабул итмибез, теләсәң кая бар, дүрт ягың кыйбла», дияен генә көткән иде ул. Ләкин шулай да күңел дигәнең туп-туры үзен җибәрергә теләмәгән «Урак һәм чүкеч» заводына, Мөҗәһит абыйсы янына тартылды. Ялгышмаган икән, әнә ничек аталарча кайгыртып сөйләшә. Телефон аша «Мирсәет Мөхәммәтович, ашыгыч йомыш бар иде»,— дип, директор белән бәйләнешкә дә кереп алды, шунда гына тор дип, чыгып та китте.

Берничә минут та үтмәде, кадрлар бүлеге начальнигы ашыгып килеп керде дә сегетне директор янына алып китте. Рәхимкулов Коляны үзе күрергә теләгән икән.

Шушы заводта чирек гасырдан артык эшләп, директор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән Мирсәет Рәхимкулов Кручининның кичерешләрен бер карауда аңлап алды.

Коля елга портыннан туры бирегә кайткан, әгәр шушы минутта ук аны канат астына алмасаң, иртәгә соң булуы бар. Яшүсмернең мондый чакта нинди генә бәлаләргә юлыкмавы мөмкин!

— Коля, хәзер син яңадан безгә эшкә керергә телисеңме? — дип сорады директор.

— Кая барыйм инде мин.

— Әгәр алсак,— диде Габдрахманов,— моның өчен комиссия рөхсәте кирәк. Аннан шунысы да бар: кайда яшәр ул?

Коля бу сүзләрне ишеткәч, ничектер, сискәнеп китте.

— Тулай торакта бер дә буш урын юк,— дип тә өстәде кадрлар бүлеге начальнигы.

Директор әңгәмәгә чик куйды:

— Тулай торакка өстәмә бер койка куярлык җай табарга кирәк,— диде ул.— Коляга завод исәбеннән ярдәм күрсәтергә туры килер.

Бөтенесе дә аның белән килештеләр һәм ул чаралар шул көнне үк тормышка ашырылды.

* * *

Кызганучы күбәйсә, аз гына кызарып, кычытып торган бармак башы да көне-төне тынгы бирмичә сызлаган яман шеш кебек тоела бит ул. Кручинин белән дә шулай булды. Ул үзен бик авыр җәфа чигүчедәй хис итә башлады. Әкертенләп, яңадан элеккеге Кручининга әйләнеп калды. Бәлки аңа абыйсы кебек берәр кешенең һәрвакыт

кинәш биреп торуы кирәктер,— кадрлар бүлеге начальнигы шул турыда уйлады. Бу мәсьәлә буенча ул завод парткомы секретаре Петр Михайлович белән дә киңәште.

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде партком секретаре.— Бездә Вәлиев дигән бер егет бар. Элек ВЛКСМ шәһәр комитетының оештыру бүлегендә эшләгән. Хәзер дә безнең комсомол оешмасына бик зур ярдәме тия. Тулай торакта яши...

— Кручининны аңа беркетик дип әйтергә телисезме?

— Вәлиев — КПСС членлыгына кандидат, партия порučениесе итеп бирербез. Өстәвенә, аның да барып йөрерлек туган-тумачалары юк бугай. Ялларын да бергә үткәрерләр.

— Шәп кандидатура,— диде Габдрахманов, уйга калып.— Тик ул егет укый, вакыты бик чамалыдыр... Әгәр Вәлиев үзе ризалык бирсә, мин бу вариантка бик теләп кушылыр идем.

Вәлиев тәкъдимгә каршы килмәде.

Азатка бирелгән поручение турында Коля үзе белми иде. Азат бу турыда аңа сиздермәскә тырышты. Баштарак исәнләшеп, узган-барганда хәл-әхвәл сораштырудан узмады. Ләкин иркенләп бер сөйләшеп утырырга кирәк иде. Бер тулай торакта яшәгәч, моңа бик тиз җай чыкты. Бер көнне ул коридорда Коляны очратты. Кулына шахмат тоткан да ул:

— Кемгә мат куярга? — дип йөри.

«Эх, вакытның җайсыз чагына туры килдең килүен, шулай да бу очрактан файдаланырга кирәк», дип Азат аны үз бүлмәләренә чакырды.

Өстәлдәге махсус тактада — дүрт читеннән дә беркетелгән ватман кәгазе, аның өстендә линейка, сызым приборлары. Өстәлнең буш калган читендә дә, тумбочка һәм кием шкафы өстендә дә — китаплар. Шуңа күрә шахмат тактасын да буш урындыкка гына куярга туры килде.

Уен кызып кына барганда, Азат сәгатенә карап алды.

— Нәрсә, ашыгасыңмы әллә? — диде Коля.

— Дәрескә барасы бар. Аңа кадәр берәр ашханәгә кереп ашап аласы иде.

— Ә син кая укыйсың соң?

— Химия-технология институтында. Ә син? Шунда ук түгелдер бит.

— Юк, булса очрашкалар идек,— диде Коля.

— Туры да килмәвең бар, анда меңләгән кеше бит.

— Шулай укмыни?! Шах, королеңне качыр.

— Юл бар, монда йөрибез. Ә син кайда укыйсың соң?

— Беркайда да түгел.

— Ничек инде ул алай? — Азат гаҗәпләнгән булды.

— Тагын шах, юлың бетә,— диде Коля, Азатның соравына җавап бирмичә.

— Башлы егет икәнсең син, яхшы гына ходлар ясыйсың,— дип, Азат аны мактап та куйды.— Шулай да, дус кеше, киңәш бирәм: укы, көнең мәгънәсезгә үтмәсен. Мин сиңа үз абыең да, мастерың да түгел, күрше булырак кына әйтәм. Менә укыр өчен Кара-Калпакиядән килдем. Эшем дә начар түгел иде.

— Яхшы эшеңне ташлап килдеңме, вәт, җүләр,— диде Коля, көлеп.

— Максатың булса, килерсең дә. Ә яраткан эшне кайда да табып була.

— Менә минем эшем начар, шуңа күрә ошамый да.

Азат сагая төште. Ашарга вакыт калмаса да, дәрескә соңгару куркынычы туса да, сүз көрәштергән булып, ул һаман сораштырды...

...Тәҗрибәле эшчеләр үзләре ясый торган детальләргә шундый күнеккәннәр, икенче төрле әйткәндә, күз белән карап үлчәмен белә алалар. Ә Кручинин кебекләр җайланмаларны озак көйлиләр, детальне ясаган вакытта да станокны еш туктатырга туры килә: артык кырылмадымы? Еш кына фрезә сына, аның өчен түләргә туры килә... Өстәвенә, мастеры да: «Синең нормаң үтәлми, көнлек заданиене тутырмыйсың»,— дип җанга тия.

Азат икенче көнне үк Габдрахманов Осипук белән бу турыда сөйләште. Алар өчен бу яңалык түгел иде, билгеле. Унҗиде яшьлек өйрәнчек сынау тапшырып разряд алдымы, димәк, ул инде — эшче. Андый яшүсмерләр өчен ярым норма билгеләнмәгән. Кимрәк иткәндә дә бик яхшы булыр иде дә, ләкин ул министрлыкның барлык заводларында бер төрле. Фрезәләрне дә бик түләтмисе иде, ләкин тәртибе шул: һәр

эшче инструмент белән сак кайнашырга тиеш. Материаль яктан бәйле булгач, хуҗаларча караш та арта. Бу тәртипләр яшүсмерләр өчен аерым каралмаган... Шулай дәвам иткәндә, яшь эшченең үз һөнәренә карата карашы үзгәрүе бик ихтимал шул.

— Күпчелек яшүсмерләребез бер-ике айдан, авырлыкны җиңеп, аякка басалар, әмма Кручинин ишеләр дә булгалый,— диде Мөҗәһит Габдрахманов.— Токарь булып күчәргә сорый ул.

Бәлки, минем янга ярымавтомат станскларда эшләргә билгеләрсез...

Габдрахманов Азат фикере белән килешмәде:

— Юк, анда эшчеләр җитәрлек,— диде.— Аннан соң шуны да онытма: күпмегә кадәр өйрәнчек булып йөрергә мөмкин?!

Инде Коля үзе дә кереп үтенгәч, кадрлар бүлеге начальнигы Кручининны канат юллары ясау цехына токарьлыкка өйрәнчек итеп күчерде.

* * *

Комсомол оешмасының чираттагы җыелышы ачык булачак иде. Анда заводта эшләүче бөтен яшүсмерләрне дә чакырдылар.

— Бирედә заводның хезмәт ветераннары да катнаша. Аларны аягүрә басып хөрмәтлик әле,— диде ВЛКСМ комитеты секретаре Марсель Исмәгыйлов, җыелышны башлаганда.

Зал аягүрә басты. Шул вакытта президиум өстәле янына заводта озак еллар эшләүче өлкән яшьтәге коммунистлар кереп утырдылар. Аларны алкышлап каршы алдылар.

Сүз пенсионерлар советы председателе Николай Васильевич Проухинга бирелде. Ул бер төркем яшьләргә комсомол билетлары тапшырды.

— Сезгә карыйм да сокланып туя алмыйм,— диде ул,— искиткеч чорда яшисез. Без бу заводны илле-алтмыш еллар элек хәтерлибез әле. Ишелеп бара торган агач цехларда ат сабаннары ясый идек. Безнең буын кешеләренә аны яңабаштан, таштан салырга туры килде. Әнә нинди ул хәзер! Илебездә канат юллары чыгара торган бердәнбер заводка әверелде, җитештергән продукциясен дистәләрчә чит илләр сатып ала.

Сөйләшү озак дәвам итте. Бөтенесенә дә ошады бу кичә. Тик Коляның гына хәтере калды: «Комсомолга керүчеләрне почетлы урыннарга утырттылар. Диләрә Булатова, Василий Агапов, Коля Ключников... Минем кай җирем ким алардан. Миңа комсомолга кер дип әйтүче дә юк...»

Икенче көнне, Марсель белән очрашкач, ул аңа үпкәсен белдерде:

Эшкә Виктор Тихонов белән бергә кердек бит без. Ничек аны кешеләрдән алда кабул иттегез соң әле?

— Улмы? Менә ике ел инде яхшы итеп эшли, тырышып укый. Әнисенә булыша. Ә синең прогулларыңны бергә тезсәң, сөлге буе булыр иде. Белдеңме?

Шулай да ул аңар ВЛКСМ уставы тоттырды.

— Менә Устав,— диде Марсель.— Укы, өйрән. Рекомендациянең берсен Азат Вәлиев бирәм, ди. Икенчесен, карарбыз, я үзем бирермен...

Коляның да комсомолга керәсе, бөтен зал алкышлап торганда, иң арттагы урындыктан торып, горур гына атлап барып, хезмәт ветераны кулыннан комсомол билеты аласы килә иде. Шунда алгы рәттә генә, я булмаса президиумда, Петр Михайлович, Мөҗәһит Мөсәгыйтович, Азат Ахметовичлар утырыр. Алар да бу минутта шатлыклы елмаеп: «Молодец, Коля, котлыйбыз», диярләр. Ә ул, алар ягына таба борылып, баш кына селкер. Юк, барып кулларын кысса҃ң да ярый...

Шулай хыялга бирелеп утырганда, Марсель тагын сүз башлады:

— Коля, комитет утырышы булачак. Анда сине дә чакырабыз.

— Ник?

— Архипов белән нигә бәйләнештегез?

«Азат кына түгел, монысы да белә икән. Азаты ярар инде, бу бит бөтенләй башка подъездда яши. Каян ишетә диген, ә. Малайлар белән очратып, ул Архипов дигәнне бүген-иртәгә дөмбәсләсәк тә, шунда ук белерләр болар».

— Нигә эндәшмисең?

— Сез аны барыбер яклыйсыз.
— Анысын карарбыз әле. Тик син керергә тиешсең, Азат әйттеме?..
Комитет утырышына килгәч, Коля үз колакларына үзе ышанмады. Әй, пешерепме пешерделәр Архиповны. Барысы да Коля яклы булып чыкты.
— Коля,— диде Марсель, кырыс кына.— Сөйлә, сәгатеңә нәрсә булган.
— Мин бераз кызмача кайтканмын,— дип сүз башлады Коля. Үзе «ник эчтем» хәленә төшкән, колакларына кадәр кызарган иде.— Архипов минем сәгатьне, ун сум акчаны алган. Икенче көнне каты итеп сорагач, бер сәгать бирде. Ә ул минеке түгел, минеке яңарак иде.
— Дөрес түгел, акчасы юк иде, эчеп бетергәндер. Ә сәгатен ватмасын дип салдырып алдым,— дип акланды Архипов.
— Ни өчен йокыдан торуга ук бирмәдең?
Комитет әгъзасының бу соравыннан Архипов югалып калды.
— Ни... бераздан бирермен дип уйладым.— Аннан ул гаепне Коляга аударырга тырышты:— Нигә Кручинин һаман эчә, тавыш куптара?
— Һаман түгел, бер генә тапкыр. Анысы өчен аерым сөйләшербез, син үзеңә бирелгән сорауга җавап бир,— диде Марсель.
— Акчасы юк иде, сәгатен бирдем. Үзе танымый ул.
Үзе яклы кешеләр күп булгангамы, таянычының имән баганадай нык икәнен сизепме, Коля да батыраеп китте:
— Ярар, акча алуыңны бу юлы мин берничек тә исбат итә алмыйм, ди. Ә абыйны армиягә озатканда, киркәле азык-төлекне үзем алырмын, бергәләп бүлмәдә утырырбыз дип, абыйдан 70 сум акча алдың, утыз сумын каядыр туздыргансың, кырык сумын көчкә генә кире бирдең...
Коляның бу сүзләре һәркем өчен яңалык иде.
— Ул бүлмәдән сине алабыз. Анда бары тик яшүсмерләр генә калыр. Каян урын табылыр — шунда күчәрсең. Ике көн срок белән Кручининның акчасын кире кайтарып бирәсең. Югыйсә, бу җепнең очына чыгарга милицияне дә чакырырбыз...
Комитет членнарын да, Марсельне дә, Азатны да, абыйсы белән курешкәндәге кебек каты итеп кысып кочаклыйсы, һәрберсенә кычкырып рәхмәт әйтәсе килде Коляның. Тик яхшысынмады, оялды ул.

* * *

Азат бүлмәдәш егетенең кинәт кенә әйтелгән сүзенә уянып китте:
— Тор, Азат, аяктан егарлык яңалык,— диде ул, ашыга-ашыга.— Бүген төнлә синең Кручининны кулга алганнар.
— Кит әле,— дип сикереп үк торды Азат. һәм тиз-тиз киенеп, Коля яшәгән бүлмәгә кереп китте.
Төн уртасында милиционер килгән дә Коляны алып киткән — Азат анда шуны гына белә алды. Ашыгып заводка китте. Комсомол комитетына, кадрлар бүлегенә хәбәр итәргә кирәк. Нәрсә эшләде икән? Нигә бу турыда Азат берни дә сизмәде соң?
Кич кырын милициядән Кручининны алып кайттылар. Габдрахманов үз бүлмәсенә Петр Михайловичны да чакырды. Азат белән Марсель шунда иде инде.
— Азат та килеп хәбәр итте, эше белән милициядә дә таныштырдылар, шулай да Коля үзе сөйләсен әле,— диде Габдрахманов.— Нәрсә булды, Коля?
Шатлыгы ташып торса да, уңайсызланып кына сүз башлады ул:
— Мин дәрестән кайттым. Азат юк иде әле. Башкалар йокларга җыенгач, мин дә яттым. Утны сүндерергә кирәк иде, берсенең дә торасы килмәде. Кинәт каты итеп ишек шакыдылар. «Кем булыр бу?» — дибез. Шунда кемдер:
— Бөтенебез өйдә, читләрне кертмибез,— дип кычкырды. Тегеләр һаман кагалар. Мин Азат түгел микән дип уйлаган идем, кылт итеп искә төште: ул бүген соң кайта. Аннан ул алай каты дөбердәтми, исемне әйтеп эндәшә. Тыныч кына ята бирәм. Инде, тиз генә туктамагач, кем якын, торып ачыгыз, дидем. Ике кеше керде. Берсе урта яшьләрдә, таза, икенчесе минем кебек. Анысы инструментлар заводында эшли.
— Кем,— дип сорап куйды Габдрахманов.
— Нигә ул?
— Кирәк. Ул сине каян белә?

— Зәки. Бер интернатта укыган идек. Әлегрәк мин аны урамда очраткалый идем, соңгы вакытларда күргәнем юк.

— Ул синең биредә яшәгәнеңне белә идемени?

— Бер мәртәбә озата кайткан иде. Шуннан хәтерләп килгән. Олысы, анысын беренче тапкыр күрәм, керү белән, як-ягына каранды да, гел яшүсмерләр генә икәнен белгәнгәме, өстәл янына килеп басты. Ә Зәки, миңа кул гына селтәде дә, туп-туры кием шкафына юнәлде. Безнең бер кием шкафы буш тора. Ул анда ниндидер бүктәрләр куйды, аннан биклэп ачкычын үзе белән алды. Беркемгә берни әйтмәделәр, тиз генә чыгып тайдылар. Без аптырап калдык. Малайлар миңа карыйлар, миңа уңайсыз. Стенага таба әйләндем дә яттым.

Төнлә тагын ишек шакыдылар. Бөтенесе миңа кырын карап алалар. Без яңадан килделәр, дип белэбез бит инде. Шунда ишек янында ятучы торып ачты да яңадан урынына барып ятты. Ни күрик, милиция! Беребезгә дә кузгалмаска куштылар. Койка асларын, тумбочкаларны, кием шкафларын карадылар. Биклесенең ачкычын сорыйлар. Озак баш ватып тормадылар, ачкычсыз да ачтылар. Әй, бер заман матур-матур бәйләгән ирләр күлмәкләре чыга башлады. Яңалар, пакетлары да шытырдап тора. Исебез китте, чөнки безнең беребез дә андый күлмәк алу бәхетенә ирешкәнебез юк әле. Ә милиция һаман урыннан кузгатмый. Санадылар, яздылар. Соңыннан:

— Кемгә китерделәр? — диделәр. Шып булдык. Бөтенесе миңа карый.

— Әйдә, киен,— диделәр... Менә шул.

Коля сөйләп туктагач та бүлмәдәгеләр беравык сүз дәшми тик утырдылар. Тынгыкны беренче булып Габдрахманов бозды.

— Бүген дәрескә барасыңмы соң? — дип сорады ул.

— Бүген дәресләре юк аларның,— дип, Азат Коля өчен җавап бирде.— Кичәдән үк киного барырга җыеналар.

Сүзара сүз чыккач, «кем белән барасыз» дип тә кызыксындылар. Коляның йөзенә кызыллык йөгерде.

— Ярарыгыз инде,— дип, Марсель аны «коткарырга» ашыкты.

— Шулай да кем ул, кайдан ул,— дип сорады Петр Михайлович.

— Техникумда укый. Клава исемле... Сигезне бетергәч мине дә шунда керергә чакыра.

Бүлмәдәгеләрнең йөзендә эчкерсез елмаю балкыды.

* * *

Еллар үтәр, тормыш дулкыны үзен кайсы гына ярга илтеп куйса да, бу «Урак һәм чүкеч» заводы коллективын Николай Кручинин гомере буена да онытмас. Олы тормыш юлының беренче адымнарын ул биредә атлады, беренче мәхәббәт хисләрен ул биредә кичерде, үзенә карата ул биредә аталарча игътибарлы карашны күрде. Биредәге кешеләрнең акыллы киңәшләре, укытучылар биргән үгет-нәсихәт белән бергә үрелеп, Кручининның гомерлек маягы булыр, күп юллар кушылган урында да, кирәклесен генә сайлап алырга ярдәм итеп, көчле прожектор сипкән яктылык кебек, гел балкып торыр!

## С. Радзиевская

# СУ ХУҖАСЫ

ОЧЕРК



Ул урындыктан торды да ике куллап минем белән күреште. Күзләре яшьләрнекечә очкынланып тора, сакалына да бөтенләй диярлек чал кунмаган, бары тик йөзе генә үзенә килешле вак җыерчыклар белән капланган. Җыерчыклары күз тирәсенә килеп тоташканлыктан, хәтта җитди сүз сөйләшкәндә дә аны елмаеп торган шикелле күрсәтә иде.

— Барысын да рәттән сөйләргәме? — диде ул, гаҗәпләнеп һәм елмаеп.— Алайса, әйдә, туныңны сал да чәй янына рәхим ит! Сөйлисе сүз озын. Ник дигәндә, беренче буаны буганда миңа ун яшьтән артык булмагандыр.

Тышта суык, ә өйдә җылы, бигрәк тә сөйлисе сүзең, сөйләшер кешең булганда, чәй янында утырудан да рәхәт эш юк инде. Юл кыенлыклары хакында сөйләшүдән башланып киткән сүз безнең телне бик тиз чишеп җибәрде. Мин күбрәк Хәйретдин картның үзен сөйләтергә тырыштым, чөнки үз башыннан кичергән тормышны кеше үзе генә тулы итеп исенә төшерә ала. Ә Хәйретдин картның истәлекләре иртәнге чәйгә дә, төшке ашка кадәр дә җитәрлек булды. Хәтта кичке ашка да байтак калган иде. Ул сөйләгән хәлләрнең кайберләрен мин дә сезгә сөйлим әле.

* * *

— Әй, аллам! Нинди юньсез малай икән бу? Бәрәңге бакчасын тагын су белән тутырган бит, ә! Кая соң таяк? Сания, бир әле бер таяк, җанын алыйм әле шуның!

Ә ул арада малайдан җилләр искән: елга аша чыгып, күптән теге як ярдагы таллыкка кереп посканы ул. Малайның кәефе бик начар, чөнки балык үрчетер өчен дип буып куйган буасы киткән аның. Матур гына күтәрелә башлаган су, белмим, ни хикмәттер, тулып җитә дигәндә генә буаны ерган да Хәйретдиннәрнең үз бакчаларына җәелгән. Бар үрчетеп кара инде хәзер балык!..

Шулай уйланып утыра торгач, малайның үлеп ашыйсы килә башлады. Әнисе төшкә пешергән тәмле токмач исе хәтта елга аркылы бу якка чаклы сизелеп тора кебек тоелды. Их, кайтып бер туйганчы ашыйсы иде дә бит... бакчага җәелгән су һаман саркып бетмәгән шул әле. Аннары әтисенең дә ачуы басылмагандыр... Аның кулына эләксәң...

— Хәйретдин!

Бу тавышка сискәнеп үк китте малай. Бары тик үз апасы эндәшкәнен һәм аның теге як ярда үк икәнен күргәч кенә тынычлангандай булды. Ләкин барыбер атылып чыгарга ашыкмады.

— Хәйретдин!

Апасы яр читенә үк килде дә, кояшта чагылмасын өчен, күз өстенә кулын куеп, нәкъ Хәйретдин поскан таллыкка төбәлде. Кара син апасының хәйләкәрлеген! Каян эзләргә кирәклеген ничек белгән ул!

— Әни сиңа дип ипи биреп җибәрде, курыкма, чык инде, Хәйретдин! — диде апасы.

Малай таллар арасыннан үрелеп карады. Апасы, чыннан да, бер телем икмәк тотып тора иде. Нишләргә соң? Алдап кына чакыруы түгелдер бит?.. Әйдә, ни булса — шул, ачка үләр хәл юк монда дип, малай яр читенә йөгереп килде. Әмма бирге якка чыгарга шикләнде.

— Ыргыт бу якка, тотып алам мин аны!

Ләкин икмәк аның кулына түгел, яр буендагы суга килеп төште. Хәер, талымлап торыр чагы түгел иде малайның, юеш дип тормады — шундук алып ашарга кереште. Бары телемнең яртысын ялмап йотканнан соң гына:

— Әй, апа, апа, шуны да рәтләп ыргыта алмадың! — дип мыгырданып алды. Әмма моны ул, хәтере калудан бигрәк, апасы белән сүз башлар өчен әйтте.

— Тәмле түгелме әллә? Ошамаса, кире ыргыт! — дип көлә-көлә, апасы ыштан балакларын күтәрде. Аннары тез тиңентен суга керде.— Карале суның җылылыгын! Хәйретдин, әни сиңа кичкә хәтле, әти Нияз абыйларга киткәнче, шушында утырырга кушты. Аннары кайтыр да качып кына ятып йоклар, иртәнгә кадәр атаңның да ачуы басылыр, диде.

— Ә басылмаса? Син аның таягын берәр җиргә яшереп куй әле, апа, яме? — диде Хәйретдин, ипинең соңгы кисәген йотып җибәреп.— Шул ипине дә күбрәк алып килә алмагансың! Ә үзең токмач ашап, чәй эчеп килгәнсеңдер әле. Җитмәсә, шикәрләптер!

— Кара син аны! — диде Сания, энесенә үпкәләп.— Рәхмәт әйтәсе урында, ачу китереп торган буласың тагын. Бүтән вакытта монысын да алып килмәм атуй! Утыр шунда бер үзең каңгырып. Әнә, ачыксаң, бака тотып аша!

Сания кинәт судан чыкты да, балакларын тиз генә төшереп, өйгә кайтып китте.

Хәйретдин сөмсерен коеп карап калды. Апасын ачуландырырга теләмәгән иде бит ул... Хәер, ачу саклап йөри торган кеше түгел ул, менә күрерсең, соңыннан үзе үк берәр әйбер алып килер әле. Атасының да ачуы озакка бармый... Шулай да таягын ераграк яшереп куйганда шәбрәк булыр иде...

Малай текәрәк һәм биегрәк урынга күчте. Яр читенә ятып, суга текәлде. Кесмәс суының бу җирдә төбе күренми — тирән. Бик тирән. Нәкъ балык оясыдыр инде бу. Их, төбенә төшеп, шундагы көмеш тәңкәле зур балыкларны туйганчы карап торсаң иде!

Дөрес, Хәйретдиннәр бакчасы буеннан ага торган чишмә суында да балыклар күп күбен. Тик алар вак шул. Әмма җитез дә соң үзләре! Ук урынына атылып кына йөриләр. Ә менә Кесмәснең бу чоңгылындагы балыклар алай түгелдер. Иплән кенә, ашыкмыйча гына йөзә торганнардыр... Әй, буасыннан да рәт чыкмады ичмаса. Тау буеннан күпме таш ташыды Хәйретдин, күпме балчык өйде... барыбер файдасы булмады — балык үрчетә елмады. Җитмәсә тагын суы бакчага басып керде... Кем уйлаган алай булырын!

Хәйретдин кичке караңгы төшкәч кенә өйләренә кайтты. Атасы кул белән тимәде, әмма:

— Әгәр тагын шулай шаярганыңны күрсәм, таш бәйләп үзеңне суга салырмын! — дип, шактый каты кисәтеп куйды.

Ләкин Хәйретдиннең моңа әллә ни исе китмәде: таяк эләкмәгәч, кисәтүгә түзә инде ул!

Буасы китсә дә, Хәйретдин өметен өзмәде. Ул, бер атна тырышып, чишмә суы буена зур гына чокыр казыды. Аннары шул чокырга чиләк белән су ташырга тотынды. Чокыр тулгач, шунда вак балыклар җибәреп, аларны зур булганчы үстерергә ниятләгән иде ул.

Әмма бу максатына ирешә алмады: Хәйретдин ташыган су минуты белән чокырга сеңеп, юкка чыга торды. Бәлки, инде монысы сеңмәс, дигән өмет белән рухланып, көз аллары караңгылана башлаганчы ташып та чокырны тутыра алмагач, чиләген ташлады да, яр буена утырып, уйга калды. «Әнә бит Кесмәс суы ага да ага, бер дә алай җиргә сеңми. Ә чокырда ник бер тамчы су торсын ичмаса! Нилектән болай икән соң бу?»

Шушы соравына үзе җавап таба алмагач, әтисеннән яки абыйсыннан сорарга уйласа да, көләрләр дип шикләнде Хәйретдин. Әнисенә әйтеп карады. Тик әнисе дә өзеп кенә җавап бирмәде:

— Биш агай-энеңнең бишесе дә акыллы бит. Нигә син болай беркатлы икән, Хәйретдин? — диде ул.

Һәрвакыт буа, балык үрчетү турында гына хыялланып йөрүе өчен Хәйретдин үзе дә кайчакта уңайсызланып куя торган иде. Инде менә әнисе дә беркатлы син дигәч, бөтенләй читен, оят булып китте аңа. Әмма барыбер буа буып, балык үрчетү уеннан кайта алмады.

— Башка малайлар ичмаса балык тоталар да базарга илтеп саталар,— диде аңа әтисе бервакыт.— Ә син күзеңне тондырып шул балыкларга карап йөрүдән башканы белмисең!

Хәйретдин сискәнеп китте: бу уй ничек аның үз башына килмәгән соң?

Ниһаять, бер көнне, тәвәккәлләп, әтисенең иң олы һәм иң усал абыйсы Нияз картларга китте малай. Ул килеп кергәндә, нидер мыгырдана-мыгырдана, Нияз карт капка төпләрендәге такталарны сарайга ташып йөри иде.

Борынын тарткалап бераз карап торганнан соң, Хәйретдин дә кыяр-кыймас кына бер тактаның башыннан күтәреп:

— Нихәл, дәү әти! Мин дә булышыйм әле, яме? — диде.

Карт күзен әйләндереп бер карап алды да, җавап биреп тормастан:

— Сиңа ни калган монда? — дип сукранып куйды.

Ләкин бу төрпәлеге озакка бармады һәм алар икәүләп такталарны урнаштырып та куйдылар. Аннары карт бөтенләй ачылып китте һәм Хәйретдинне үзе белән балыкка, балык куарга алып барырга да ризалык бирде.

Хәйретдин бик тырышып куды балыкны. Әйбәт кенә барган җиреннән чоңгыллы урыннарга туры килеп, батып-чумып чыкса чыкты, тик кулындагы дәмбесен һич ычкындырмады. Ә эш беткәч, Нияз абыйсы башта, буең кыска, юньләп куа алмадың дип, орышты аны, аннары, иртәгә дә килергә кушып, бер куш уч вак балык биреп җибәрде.

Хәйретдин, куанычыннан кая басканын да белмичә, йөгереп өйләренә кайтты һәм ишектән керешли ук:

— Булды, әни! Балык апкайттым! — дип кычкырды.

Хәйретдин күлмәк итәгенә төреп алып кайткан вак балыкларны тәлинкәгә китереп салгач, әнисе хәтәр генә тузынып китте:

— И, аллам! Шушы маймычларны алып кайтыр өчен шулай пычракка батып, юешләнеп йөрергә кирәк булдымыни? Чистартып торырлыклары да юк лабаса боларның!

Хәйретдин шаккатып телсез калган иде. Нияз картның ятьмәсенә эләгеп чыкканда көмештәй ялтырап сикергәләгән һәм шактый зур булып күренгән балыклар хәзер, чыннан да, кечерәеп, бөрешеп калганнар иде.

— Балыкларын мәчегә ташла да муен тамырына кундыр син аның! — диде Хәйретдиннең атасы.— Кулыннан килерлек булмагач, гомер уздырып, ыштан туздырып йөрмәсен икенче!

Хәйретдин тынсыз калып, җыерылып куйды: суккан чакта иелеп калсаң, ул кадәр авыртмавын белә иде ул. Әмма эш сугуга барып җитмәде — Сания апасы Хәйретдинне якларга кереште:

— Кая, балыкны үзем чистартам да ашка салырбыз,— диде ул һәм куркуыннан үзе дә кызарып чыкты. Чөнки атасы бер кызып китсә, кыз бала дип тормый, аңа да эләктергәли иде.

Бәхетләренә каршы, эш зурга китмәде. Әтисе кулын гына селекте дә үз эшенә тотынды. Әнисе дә артык бәйләнеп тормады. Хәтта балыклы ашны ашаганда малайны саран гына мактап та алдылар әле.

Икенче көнне Хәйретдин тагын балыкка барды. Нияз абыйсының кәефе әйбәт чагы туры килдеме, әллә балык күбрәк тотылган булгандырмы, әмма ул көнне Хәйретдин җепкә тезеп зур-зур унлап балык күтәреп кайтты. Әнисе аны ачык йөз белән каршылады. Кыяфәте гадәттәгечә җитди булса да, әтисе дә теш агартып сүз әйтмәде. Ә Сания апасы исә шатлыгыннан сикергәләп, бүлмә җепсәсенә кыстырган пычакны алды да балык чистартырга тотынды: боларын атасыннан сорап тормыйча да чистартырга була иде.

Тик балык һәрвакыт күп эләкми иде шул. Чөнки Кесмәстәге эре балыкларны инде

күптән, әле Нияз карт яшь егет булган елларда ук, тотып бетергәннәр, ә вакларына үсәргә бирмиләр — ятьмә белән дә, мурда белән дә, кармак белән дә тотып бетереп баралар иде. Малайлар яз көннәрендә капчыктан ятьмә ясап та бик күп вак балыкның башына җитәләр. Аннары шул ук кешеләр:

— Бу ни тамаша инде, кая икән бу зур балык! — дип гаҗәпләнәләр иде.

Әгәр ятьмәгә эләккән кечкенә балыкларны кире суга җибәрсәң? Алар үсмәс идемени? Зурайгач та тотарга була ич аларны? Бу фикерен Хәйретдин бер көнне Нияз абыйсына да әйтеп караган иде, әмма карт тыңларга да теләмәде.

— Ахмак! Эләккән балыкны кире җибәрәләрмени? Без җибәрсәк тә башкалар тотып ашый бит аны! Аңладыңмы? — дип, Хәйретдиннең тап-такыр итеп кырылган башына каты гына чиертеп тә куйды әле.

Картның бу фикере белән һич килешә алмаса да:

— Аңлады-ым! — дигән булды Хәйретдин.

...Бер көнне әниләре кичке аш бүлә башлады. Урыны кырыйгарак туры килгәнлектән, Хәйретдин тәлинкәсенә иң соңыннан салырга туры килде һәм шунда аңа аш башкаларныкыннан азрак калган булып чыкты.

— Зуррак табак юнәтәсе иде бит, Габдулла,— диде әнисе, атасына эндәшеп.— Балалар үсә, ә табак гел шул килеш.

— Табакның зурысын алганга карап кына җиребез артырмы икән соң? — диде әтисе һәм каш астыннан гына Хәйретдингә карап куйды.— Ашаучысы алтау булса да, эшләүчесе юк бит бу балаларның. Әнә, Ибраһимның ике малае Уралга алтын казый бармакчылар. Акчаны бик шәп эшлиләр икән анда. Күзгә күрәп акча алып кайтмакчылар. һәм апкайтырлар да. Ибраһим арендага җир алыр. Аның малайлары үнган шул. Безнекеләр кебек балык куып, чалбар туздырып йөрми.

Бу сүзләрне әтисе тагын Хәйретдингә текәп әйтте.

Озак та үтмәде, ирексездән тәгәрәп аккан күз яшьләрен сертә-сертә, Хәйретдиннең әнисе биштәр капчыгы текте. Аңа икмәк, тоз һәм суган тутырдылар. Юлга диган акчаны һәм паспортын Хәйретдин тула оек балтырына кыстырып бәйләде.

— Өйдә барыбер рәтләп файда китерә торган кеше түгел ул,— диде атасы.— Буйга да кечкенә, көче дә ташка үлчим генә. Әйдә, бераз акча эшләп кайтмасмы.

Шулай итеп, Ибраһим малайларына ияреп, Хәйретдин Урал ягына чыгып китте. Анда алар карурман эченнән ага торган Тур елгасы буенда «ак алтын» — платина чыгару эшенә ялландылар. Күксел төстәге үзле балчыктан платина алу өчен, башта җирнең ике-өч метр калынлыкта өске катламын казып ачасы икән. Аннары үзле балчыкның үзен казып чыгарырга кирәк. Бу эшләр барысы да көрәк белән эшләнә, бернинди машина да юк. Кич эштән кайткан вакытларда Хәйретдиннең күз аллары әлҗемәлҗә килә, аяк атлар хәле дә калмый. Шуның өстенә туган авылы да һаман исенә төшеп, үзенә тартып тора. Кыскасы, күңеле нидер тели, каядыр омтыла егетнең. Әмма мондый кыен шартларда кая барасың? Башкалар аракы эчеп күңелен юата. Ибраһим малайлары да бу яңа тормышка бик тиз ияләнеп киттеләр һәм:

— Син шундый тырышасың, малай, әйтерсең, казыган платинаң хуҗага түгел, ә үзеңә эләгәчәк! — дип, яшүсмер Хәйретдиннән көләргә тотындылар.

Әмма Хәйретдин дә аптырап калмады:

— Ә сез шундый күп эчәсез, әйтерсең, ул аракы үз акчагызга түгел, ә хуҗа акчасына килә! — дип җавап бирде һәм һәр алган акчасын әлеге тула ояк балтырына кыстырып бара бирде: башка куяр җире юк иде аның.

Ак алтынны казу һәм юу ничек кенә авыр булса да, Хәйретдин бу эшне яратып эшли, чөнки, ни дисәң дә, су буе лабаса! Ә Хәйретдиннең хыялы суны буып балык үрчетү. Уралда да буа буып караган иде ул. Әмма бу юлы да теләгенә ирешә алмады: кура җиләк аланын су бастырасың дип, хатын-кызлар башта пыр тузынышып Хәйретдинне орыштылар, аннары буасын җимерделәр.

...Уралда биш ай эшләп, Хәйретдин күзгә атасына йөз сум акча алып кайтты. Киләсе елны әти акча эшенә мине түгел, энемне җибәрер дип өметләнгән иде Хәйретдин. Ә мине, бәлки, өйләндерер дип уйлаган иде. Чөнки ике абыйсы өйләнгән, хәзер Хәйретдин чираты иде. Очрашып сөйләшкәннәре булмаса да, аның күзе төшеп йөргән кызы да бар иде. Кечкенәдән бергә уйнап үскән һәм шул елларда ук күңеленә кереп калган Гыйлембаянны ярата иде егет. Башка берәрсенә ярычылап куйганны, шул

кызны әләктереп калырга ниятли иде. Әмма тагын ул теләгәнчә булып чыкмады. Теге йөз сум акча, зур семья кулына эләккәч үк, бик тиз таралып бетте дә Хәйретдин тагын артык кашыкка әйләнеп калды.

Платина чыгаруда гына түгел, йорт эшендә дә бик тырыш иде Хәйретдин. Әмма нигәдер аның бу эшләренә әтисе артык әһәмият бирмәде. Кыш үтеп, язга чыгу белән, йортка акча эшләп кайту өчен Хәйретдинне тагын читкә чыгарып җибәрде. Ул җәйне дә әйбәт кенә эшләп, шактый акча алып кайтты егет. Тик атасы тагын өйләнү хакында сүз кузгатмады, алдагы елны тагын читкә, акча эшләргә җибәрде.

Биш-алты ел рәттән шулай эшләп кайтканнан соң гына өйләндерергә булдылар аны. Әмма кемне алу мәсьәләсен Хәйретдин түгел, бәлки атасы хәл итәргә тиеш иде. Дөрес, Гыйлембаян әле кияүгә чыкмаган. Әмма атасы кемне яучылар бит?

Әнә шулай ут йотып йөри торгач, ниһаять, мәсьәлә ачыкланды. Улының күзе төшкән кыз булуын сизенгәндерме, әллә очраклы рәвештә генә аны үз киленә итмәкче булгандырмы — анысын өзеп кенә әйтүе кыен — Хәйретдингә әтисе Гыйлембаянны яучылап алып бирде. Бу хәлгә егет шатланып бетә алмады. Хәтта һәрвакыт ачулы йөри торган атасы да бик ягымлы кешегә әйләнеп киткәндәй булды.

Бу яктан дөньясы түгәрәкләнсә дә, кечкенәдән килә торган хыялы тынгылык бирмәде Хәйретдингә. Авыл картлары Кесмәс елгасындагы чоңгылларда бүрәнә юанлыгы җәен, самавыр кадәрле сазан балыклары эләккән заманнарны искә алып сөйләшеп утырган чакларда Хәйретдиннең күзләре очкынланып китә торган иде.

Аннары революция чыкты. Бу эшнең асылына бик үк төшенә алмыйча, теге якка да, бу якка да катнашмыйча, үз көенә йөрсә дә, соңыннан Хәйретдин кинәт айнып китте һәм, атасыннан аерылып, совет ягына күчте.

Гыйлембаян да иркен сулыш ала башлады: кайнатасы алдында тел яшереп, аның әйткәнен ишетми калган чакларда кабатлап сорый алмыйча борчылып йөрисе юк иде хәзер.

Шулай итеп тормышлары көйләнеп барганда, 1921 ел килде һәм дөньяны корылык, ачлык каплап алды. Хәтта Кесмәс суы да бөтенләй саегып калды. Хәйретдин тагын елганы буып балык үрчетү турында уйлана башлады. Әмма балалары өйдә ач утырганда бу уен тормышка ашыру мөмкин түгел иде шул. Иң элек аларны ашатырга кирәк иде. Ә монда, авылда яшәсәң, аларны ашатып булмаячак. Нишләргә соң?

Уйлады-уйлады да, яшьлек елларын искә алып, өч баласын җитәкләп, Семипалатин ягына чыгып китте Хәйретдин. Ә ике кечкенә баласы белән Гыйлембаян өйдә калды. Тизрәк барып җитеп, бераз эшләргә дә авылда калган хатынына һәм балаларына азык җибәрергә ашыкты ул. Тик анда барып җитү дә шактый кыен булды. Омскига җиткәч, өч баласы да тиф белән авырдылар. Алар терелгәнче шунда торып торырга туры килде. Ярый әле, бәхетенә каршы, авыру үзенә эләкмәде. Югыйсә...

Омскида карантин беткәч, Хәйретдин әлеге балаларын ияртеп, Павлодарга килеп җитте һәм шундук эшкә кереште — итек баса башлады. Аннары, бераз акча юнәтү белән үк, авылга ярты пот он салды. Шулай итеп, ачтан үлеп бара торган хатынын һәм балаларын коткарып калды.

Меңнәрчә кешеләрнең башына җиткән ачлык ел үткәннән соң янә авылына кайтты Хәйретдин. Әмма бала чактагы хыялын тормышка ашырганчы тагын байтак еллар көтәргә кирәк булды әле. Башта алар, унтугыз кеше бергәләшеп, үзләренең Казаклар авылында «Мәгариф» исемле колхоз төзеделәр. Аннары колхозга башкалар да керде. Шулай күмәкләшеп колхозны аякка бастырганнан соң гына үзенең максатын председательгә сөйләп бирде. Председатель — Газиз Хәйбуллин исемле бик игле кеше иде — Хәйретдиннең ниятен хуплап каршы алды һәм шул ук көнне буа буар өчен уңайлы урынны да билгеләп кайттылар.

Ә икенче көнне «Мәгариф» колхозы колхозчылары Кесмәсне буарга тотындылар...

Гасырлар буе бушка агып яткан Кесмәсне буунын файдасы Хәйретдин көткәннән күп мәртәбә артыграк булды. Иң элек колхоз сугу машинасын су көче белән эшләтүгә көйләде. Аннары сугылган ашлыкны да шул ук су көче белән җилгәртә башладылар. Аннары, ниһаять, Хәйретдиннең дә күптәнге планы чынга ашты. Питрәч балык питомнигыннан алып кайтып, ул буага карп маймычлары җибәрде. Шул көннән алып, Хәйретдиннең бөтен тормышы буа тирәсендә балык карап үтә башлады...

С. РАДЗИЕВСКАЯ ◆ СУ ХУҖАСЫ ◆

һәм аның тырыш хезмәте бушка китмәде. Алып кайтканда шырпы буе гына булган маймычлар көзгә яртышар килолы симез карплар булып үстеләр һәм, аларны сатып, колхоз шактый зур табыш алды.

— Рәхмәт сиңа, Хәйретдин абзый! — диде аңа председатель, табыш колхоз кассасына килеп кергәч.— Әйдә, тагын Питрәч питомнигына барып кайт инде. Тик бу юлы маймычлар алма. Үзләре уылдык чәчә торган зур балыклар, нәсел балыкларын алып кайт!

Хәйретдин бер ана, ике ата карп алып кайтты һәм аларны буаның аерым бер җиренә кышлыкка урнаштырды. Болар нәкъ теге вакытта Хәйретдин Кесмәс чоңгылында күрергә теләгән алтын тәңкәле чын зур балыклар иде.

Хәйретдин башлаган эш тора-бара һаман киңәя-үсә барды. Симертелә торган балыкларга да, бер яшьлек балыкларга да, маймычларга да, уылдык чәчә торган нәсел балыкларына да көздән аерым урыннар булдырылды.

Яз көне, суның җылылыгы унҗиде градуска җиткәч, уылдык чәчү буасына елгадан су керттеләр һәм, кышлау урыннарыннан алып чыгып, уылдык чәчәргә тиешле теге өч балыкны шунда җибәрделәр. Хәйретдин, бик нык дулкынланып, чиста суга җибәрелгән ул балыкларны күзәтә торды. Буаны ошатырлармы? Уылдык чәчәрләрме? Аны менә шул уйлар борчый иде.

Башта бу яңа урынга сәерсенгәндәй аптырап, барысы бергә җыелып торсалар да, нәсел балыклары бераздан акрынлап йөзә, уйный башладылар. Ә икенче көнне исә суның сай урыннарындагы үләннәр арасына кереп түшләре белән ышкынырга — уылдык чәчәргә керештеләр. Ана балык чәчкән алтын сыман уылдык бөртекләре ата балык сипкән «сөт» белән кушылды, һәм дөньяга йөз меңләгән яңа җан иясе ярала башлады.

Үрдәк-каз яки бака-фәлән буаның уылдыклар бүлегенә кереп, уылдыкларга зыян китермәсен дип, Хәйретдин биш көн буе буа янынннан китмичә саклап торды. Ә алтынчы көнне уылдыклар кечкенә генә тере җан ияләренә әверелде. Дөрес, алар әле йөзеп йөри алмый, үләннәргә ябышып кына торалар иде. Әмма, ничек кенә булмасын, болар инде булачак балыклар бит. Дөрес, аларның барысы да исән-сау үсә алмаячак. Һәй, алай булса! Бер ана карп җиде йөз мең данә уылдык чәчә. Шул җиде йөз мең уылдыктан яралган маймычлар барысы да исән калса, аларны үстерү өчен генә дә утыз биш гектарлы буа кирәк булыр иде. Инде шуларның барысын да кышлауга калдырам дисең икән — тугыз гектарлы, ә икенче җәйгә симертергә җибәрү өчен йөз илле гектарлы буа кирәк. Әгәр ул маймычларны көзгә кадәр үстерсәң, бер ана уылдыгыннан үскән барлык балыкларның авырлыгы өч йөз алтмыш тонна булыр иде: бер яшьлек карпның уртача авырлыгы ярты кило була.

Әмма чынлыкта алай булмый шул. Хәтта иң алдынгы балыкчылык хуҗалыкларында да бер ана уылдыгыннан үскән балыкларның саны егерме меңнән артмый. Башкалары үсү һәм кышлау чорында һәлак булып бетә. Бу — балык хуҗалыкларында шулай. Ә табигый шартларда бер ана балык уылдыгыннан үскән балыкларның саны бик күп мәртәбә аз була. Чөнки анда уылдыкның да, маймычларның да дошманнары бетәсе түгел: кош-корт та, балыклар да, бакалар да тотып ашый аларны. Әнә шул җидешәр йөз мең уылдык чәчүе аркасында гына нәселен саклап килә икән ул балык. Югыйсә инде күптән кырылып беткән булырлар иде...

Алтынчы көнне җан иясенә әйләнгән уылдыкларга тора-бара бөтенләй балык кыяфәте керде. Үзләре солы буе гына булсалар да, хәйран тиз йөзә башладылар. Әмма алар барыбер ярдәмгә мохтаҗ — каз-үрдәк һәм бака кебек дошманнарыннан качып котыла алырлык түгелләр иде әле. Хәйретдин маймычларны күз карасы кебек саклады. Аннары аңа ярдәмчеләр дә табылды. Рузалин һәм Мостафа исемле балык «җене кагылган» ике малай, һәр көн иртән аның янына килеп, төнлә маймычлар буасына кергән бакаларны тотыша, каз-үрдәкләрне куыша башладылар. Ә көзен, җәйләгән маймычларны тоту ансатрак булсын өчен, буа төбендәге үләннәрне чабыштылар. Маймычларны тотып махсус урынга җыярга һәм берәмләп санап, аларны кышлау буасына җибәрергә булыштылар...

* * *

Хәйретдин чәй янында миңа менә шул турыда сөйләп утырганда өстенә сырма киган бер яшүсмер егет килеп керде.

— Хәйретдин абзый,— диде ул, артык нык дулкынланганлыктан исәнләшергә дә онытып.— Кышлаудагы балыклар кузгалган бит!

— Җәнлек-мазар куркытмагандыр бит? — диде Хәйретдин карт, аптырабрак калып. Һәм тиз генә стенадагы чөйгә эленгән тунына үрелде.

— Юк, Хәйретдин абзый. Кар өсте чип-чиста, бернинди эз дә юк анда!

Сәламәтлеге бик үк шәптән булмаса да, Хәйретдин карт җәлт-җәлт атлап балыклары янына китте.

Кышлау буалары янында үзе көн дә йөри торган сукмактан башка бернинди эз дә юк. Тирә-юньдә сихри тынлык хөкем сөрә иде. Чип-чиста су арыклар аша бер буадан икенчесенә үз җае белән генә агып тора һәм, барлык буаларны да үткәч, Хәйретдин малай чакта буа буган җиргә барып чыга. Кышлау буаларының берсендә, яр буендагы талларга ышыклап кар шалашы ясалган урында, боз катмаган. Шуннан нәсел балыкларының тыныч кына йоклап ятуы аермачык күренә иде. Ә менә аларның күршесендәге маймычлар кышлавында тынычсызлык хөкем сөрә: су астында әледәнәле көмеш сыман сызыклар ялтырап китә — маймычлар нигәдер йокыларыннан уянганнар иде.

— Улакны киңрәк ач! — дип боерды Хәйретдин теге егеткә. Аннары миңа мәсьәләнә аңлатып бирде:

— Һава җитми. Сулышлары кысыла балыкларның. Кыш кенә ашамый бит алар. Әгәр шушылай йөзеп йөри башласалар, язга тикле чыдый алмаслар. Хәлләре бетеп үләрләр. Алар хәзер йокларга тиешләр. Шуңа суны арттырырга кирәк.

Сырма киган егет улакны ачкач, су шыбырдап һәм күбекләнеп маймычлар буасына агарга тотынды. Буаның суы күзгә күренеп күтәрелә башлагач, Хәйретдин канәгатьлек белдереп башын селкеп куйды да:

— Яхшы! — диде.— Күрәсеңме, ничек чәчрәтеп ага? Чәчрәве яхшы, суга һава күбрәк керә алай. Маймычлар тиздән тынычланырга тиеш. Әгәр тынычланмасалар, улактан агып төшә торган суга тәгәрмәч куярга туры килер. Алай суны ныграк чәчрәтә ул.

— Без киттек, Мостафа,— диде ул, улак буенда торган әлеге егеткә эндәшеп.— Кунакны суыкта озак тоту ярамас. Ә син күзәтеп тор. Тынычлансалар да, тынычланмасалар да, ике сәгатьтән миңа килеп әйтерсең, ямә! Саклагыз, ничек тә исән саклагыз маймычларны!

— Ярар, Хәйретдин абзый, әйтермен. Син артык борчылма! Без үзебез дә бер дә үтермәскә тырышабыз. Хәтта төнлә дә торып карап керәбез,— диде егет, мөлаем елмаеп.

— Бу теге сез сөйләгән балык «җене кагылган» Мостафа түгелдер бит, Хәйретдин абзый? — дидем мин, картның чәй янында сөйләгән сүзләрен искә алып.

— Шул үзе! — диде Хәйретдин абзый.— Картлык менә шушы була торгандыр инде ул: әйтергә дә онытып торам икән. Әйе, шул Мостафа инде бу. Бик акыллы, бик уңган егет булып үсеп килә.

— Әле без караган буада ике мең маймыч бар анда,— диде карт, без кайтырга чыккач.— Уылдык чәчә торган балыгыбыз бер генә безнең. Әгәр Бәдриев эшне бозмаган булса, унау булачак иде алар.

— Нинди Бәдриев соң ул? — дидем мин, картның тел төбен аңлап җитмичә.

— Ә-ә,— диде карт, кеткелдәп көлеп җибәреп.— Мин аның турында сөйләдем дип торам. Әй, бу карт кешенең хәтере! Бар иде бездә бер бәндә. Әнә анда,— диде ул таягы белән төбәп күрсәтеп,— балык үстерү буасы безнең. Хәзер күренми, кар астында калган ул. Ә аннан арырак — көтүлек буасы, анысы бер еллык балыклар өчен. Хәзер ул буаларның берсендә дә су юк. Сулары җибәрелгән, ә балыклар кышлау урынына күчерелгән. Һәр елны шулай эшли идек без. Тик менә сугыш башлангач эшләр кинәт чуалып китте. Минем малайлар да, балык хуҗалыгында эшләүче бүтән ирләр дә, председателебез дә сугышка киткәч, авылда җыен карт-коры да хатын-кызгына калды. Председатель итеп әлеге Бәдриев дигән кешене куйдылар. Менә шул

кеше, ничек кенә итеп әйтсәм дә, мине тыңламады, балыкларны кышка да җайге урыннарында калдырттты. Ә язын, су күтәрелгәч, бөтен балыгыбыз Кесмәскә агып китте. Нәсел балыклары да, бер еллыклары да акты. Шулай итеп, бөтен хезмәтебез җилгә очты.

Сөйләшә торгач, тагын шунысы да мәгълүм булды: ул елгы язгы су колхоз балыкларын гына түгел, Хәйретдин абзыйның сәламәтлеген дә агызып алып киткән икән. Балыкларны саклап алып калырга тырышып йөргәндә, бил тиңентен язгы суга чумып чыккан карт. Ничек итсә иткән, ике нәсел балыгын тотып алып калган. Әмма сәламәтлеге шуннан соң бик нык какшаган аның. Әледән-әле буылып ютәлләве дә шул чакта суык тиюдән калган чир икән...

Хәйретдин абзыйларга кайтып киемнәребезне салырга да өлгермәдек, тагын бер кеше килеп керде. Пәһлевандай зур һәм таза бу кеше — колхоз председателе Габдрахман Әхәтов булып чыкты. Үзара сөйләшеп киттек. Русча укыганы булмаса да, Габдрахман минем белән чатнатып русча сөйләште: сугышта гел руслар арасында йөргән, шунда өйрәнеп кайткан икән. Берничә тапкыр яраланган. Әмма яшь, нык организмы үлемгә бирешмәгән һәм ул савыгып туган авылына кайткан.

Сөйләшә торгач, колхоз тормышы хакында да сүз булды.

— Ирләр булса, колхозны тизрәк аякка бастырыр идек тә, ирләр азрак шул,— диде Габдрахман.— Шулай да тырышкан булабыз инде, кулдан килгәнчә.

— Габдрахманга үпкә юк,— диде Хәйретдин абзый да, сүзгә кушылып.— Председатель дип тормый, бөтен эшенә үзе башлап йөри. Әле менә узган җәйдә генә атлар кәнүшнием бик әйбәтләп яңарттылар, чәчүлек бәрәңгене саклар өчен яңа подвал казыдылар. Габдрахман үзе дә шунда җиң сызганып эшләп йөрде. Тик менә җәйнең коры килүе генә эшне бераз бозды. Югыйсә, колхозны тәмам аякка бастырган булыр иде.

— Шулайрак булды шул,— диде Габдрахман.— Нишлисең бит, бер безгә генә килгән каза түгел инде. Ярый, ничек тә түзәрбез. Әле менә бүген районга барып, чәчүлек орлыкка ссуда алып кайттым. Тик аны нәрсә белән түләрбез инде!

— Борчылма, Габдрахман,— диде Хәйретдин абзый,— акча белән түләрбез. Акча, әнә, буада йоклый. Киләсе көзгә буаның һәр гектарыннан кимендә унбиш центнер балык алырбыз дип уйлыйм. Балык сатарбыз да бурычны түләрбез.

Габдрахман, кәрәк кадәр кулы белән чәй тәлинкәсен тоткан килеш, бераз уйланып торды да:

— Ә үрдәкләр мәсьәләсенә ничек карыйсың син, Хәйретдин абзый? — диде.— Озакка сузмаска иде.

Хәйретдин картның йөзе кузгә күренеп караңгыланып китте.

— Ни дип тә әйтергә белмим, Габдрахман, үрдәк үрчетеп караганым юк! — диде.

Председатель чәй тәлинкәсен кире куйды һәм дулкынланып сөйләргә тотынды:

— Ә мин менә ул эшнең барып чыгарына ышанам,— диде ул.— Син, Хәйретдин абзый, беләм, үрдәкләр балыкларыңны ашап бетерер дип шикләнәсең инде. Борчылма, бер балыгыңа да тимәсләр, без үрдәкләрне маймычлар буасына кертмибез аны. Симерту буасына, бер яшьлек балыклар янына җибәрербез. Аларны үрдәкләр ашый алмый. Мин сиңа Мәскәү тирәсендәге бер совхоз турында язылган китап алып килермен. Алар балыкларга түп ашатмыйча да буаның һәр гектарыннан ун центнер балык һәм ун центнер үрдәк ите алалар икән. Шул ит янына үрдәкләр салган йомыркаларны һәм үрдәк йонын да кушсаң — бик шәп табыш була бит ул! Ә балыкларга ашатырга дигән түпне сыерларга бирербез. Аларның да сөте артыр. Ашатмагач, ничек ул кадәр балык үстерәләр икән соң? диярсең инде син. Үстерәләр икән шул менә, хикмәте бар икән аның, Хәйретдин абзый. Мәсьәлә шунда, үрдәкләр буадагы балыкларга зыянлы булган үләннәрне ашыйлар, шулай итеп суны бозылудан саклыйлар икән. Аннары шул ук үрдәкләр балыклар ризыгын ашаучы төрле кортларны, бакаларны һәм чукмарбашларны ашап баралар. Ә үрдәкләр үзләре балыкка азык әзерлиләр: үрдәк тизәгеннән балыкка кирәкле азык хасил була икән. Сезнеңчә эшнең кая барганын?

Үз сүзләреннән үзе дәртләнеп китеп, председатель сикереп тормакчы булган иде — башы шык итеп матчага бәрелде.

— Интектерде инде шушы буемның озынлыгы! — диде ул, авырткан башын

тотып.— Сугышта йөргәндә дә траншеяга сыя алмыйча аптырый идем. Башны яшерер өчен бөкрәеп утырган чакларда билнең сызлавына һич такать булмый торган иде. Ә хәзер я ишек өстенә, я матчага баш бәрелеп аптырата.

Хәйретдин абзый әле һаман үрдәк үрчетү мәсьәләсе хакында уйлана иде булса кирәк, председательнең башы бәрелүгә бөтенләй диярлек игътибар итмәде.

— Ярый әле лампаны бәреп төшермәдең,— дип куйды да:— Ярар инде, алай булгач, әйдә, үрдәк дисең икән, алып карыйк үрдәген дә. Мин карышып кына эш чыкмас. Син хуҗа кеше — үзең беләсеңдер. Я, тагы нинди планнарың бар, ниләр эшләмәкче буласың? — диде.

— Планнар бар инде ул, Хәйретдин абзый. Балыкларның кышлау буасы аша ага торган чишмәгә водопровод ясап, фермага һәм атлар конюшнена су кертергә иде бит. Насослар куеп торасы юк, су үз агымы белән киләчәк. Ә аннары...— Габдрахман шунда тукталып, бераз уйланып торды.— Аннары Кесмәс елгасына колхозга электр станциясе кору турында да уйларга кирәк, минемчә. Синең балыклар быел әйбәт кенә табыш бирсә, тормышка ашырып булмастай эш түгел бу, шулай бит?

— Ниятең әйбәт синең, Габдрахман! — диде карт, ничектер яшьләрчә рухланып китеп.— Быел ук булмаса да, уйларга кирәк бу хакта. Картайган көндә бер рәхәтләнеп электр яктысында утырып калсаң, зыян итмәс иде ул...

Шул чак Хәйретдин абзыйларга Мостафа килеп керде.

— Балыклар йөзеп йөрүдән туктады, Хәйретдин абзый,— диде ул, шатлыгыннан елмаеп.— Тынычландылар. Без тагын су җибәрдек алар буасына.

— Су! — диде Габдрахман, эчке бер күтәренкелек белән.— «Кайда су бар — шунда тереклек!» Сугышта йөргәндә бер үзбәк шулай дип әйткән иде миңа. Ул хаклы булган бит, әй! Әгәр әле мин әйткән эшләрне тормышка ашырсак, Кесмәс суы бөтен Татарстанда иң бай колхоз итәчәк безне! Тик иренмәскә, эшләргә генә кирәк.

— Яса әле, карчык, тагын берәрне! — диде Хәйретдин абзый, Гыйлембаян апага чынаягын сузып.— Чәй дә шул ук су лабаса! Су — зур байлык ул. Юкка гына кечекечкенәдән су дип, балык дип хыялланып йөрмәгәнмен икән!

Габдрахман рәхәтләнеп көлеп куйды. Аннары урыныннан торып өстенә туның киде дә:

— Син суның хуҗасы, Хәйретдин абзый! Ул суда син колхозга тере акчалар үстерәсең! — дип, саубуллашып чыгып китте.

**ВАКЫЙФ НУРУЛЛИН**
тәрҗемәсе.

## *ТАТАРСТАННЫҢ ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП*

# РЕВОЛЮЦИЯ СОЛДАТЫ

*Быел Шамил Усмановка 70 яшь тулган булыр иде. Быел китап киштәләрен аның дистәләрчә романнары, повестьлары, хикәяләре, киносценарийлары, пьесалары бизәп торыр иде. Һәм, һичшиксез, быел аның турында «татар совет әдәбиятына нигез салучы» дип кенә чикләнмәс идек. Чөнки ару-талуны белмәс, ачык фикерле, бертуктаусыз эзләнүчән әдипнең планнары зур булган. Башлап та тәмамламый калган эшләре санап бетергесез күп булган.*

*Татар совет әдәбияты үзенең иң алдагы рәтләрдә айдап баручы әдибен иҗатының чәчәк аткан чорында югалтты. Усманов моннан утыз ел элек кырык яшендә безнең арабыздан китте.*

*Ләкин әсәрләренең язып бетергән кадәресе өчен генә дә быел Шамил Усмановның юбилеен талантлы язучы дип, зурлап үткәргән булыр идек. Шулай итәбез, чөнки ул гражданнар сугышының иң дәһшәтле елларында кулыннан мылтыгын төшермичә, бер-бер артлы өч пьеса язган кеше.*

*«Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» сугыш дәверендә эшче-крестьян гаммәсе арасында зур бер дикъкать белән каралып, сөелеп, Россиянең төрле почмакларында сәхнәдән төшми килде»,— дип язды «Безнең юл» журналы үз вакытында.*

*Ул сүзләр Шамил Усмановның беренче пьесалары турында әйтелгән сүзләр. Ә бит Усмановның аннан башка да меңнәрчә тапкыр куелган «Бай кызы» һәм бүгенге көндә дә зур театрлар сәхнәсен бизәрлек «Кичеккән фәрман» исемле пьесалары бар әле.*

*Профессор И. Баруздин «Татар Фурмановы» дип бәя биргән кеше дә Шамил Усманов иде. Бу сүзләр әдипнең проза әсәрләренә карата әйтелгәннәр. Усманов асылда гражданнар сугышы темасына язган өчен генә әйтелмәгәннәр. Шамилнең дә тормыш юлы бөек рус язучысы Фурмановныкы кебек үк*



*үзе бер тарих. Һәм ул тарих эчендә язар өчен бетмәс-төкәнмәс тормыш материалы бар.*

*Күп әсәрен Усманов батырлыгы белән тирә-юньдә шөһрәт казанган татар-башкорт батальонына багышлады. 19 яшьлек Шамил ул батальонның комиссары иде.*

*Әдип күп милләт гаскәриләреннән төзелгән интернациональ полк көрәше турында повесть язды. 19 яшьлек Шамил ул полкның комиссары иде.*

*Әдип миллионер Акчуринның мөселман фабрикаларында татар эшчеләренең революцион аңы үсүе турында драма һәм хикәяләр иҗат итте. 17 яшьлек Шамил бу фабрикадагы партия комитетын оештыручыларның берсе иде.*

*Әдип Сызрань хәрби гарнизонының революция ягына чыгуы һәм анда большевикларның эшчәнлеге турында хикәяләр язды. Яшь егет Шамил Казан хәрби округ комитетының большевиклар фракциясе председателе иде.*

*Революция солдатларының фидакарь көрәше, аларның матур уйлары, өметләре, шатлыклары, борчылулары турында берсеннән-берсе матур әсәрләр язды Усманов. Үзе шул көрәшнең уртасында торса да, үзе турында бер генә юл да калдырмады. Ләкин аның әле дөнья кадәр файдаланмаган материалы калды. Атап әйткәндә, легендар Беренче укчы татар бригадасының төзелүе һәм яшь Совет власте дошманнарына каршы каһарманнарча көрәшеп, сугышчан байрагына йөзләрчә данлыклы җиңүләре язылган татар гаскәриләре турында ул әле бер генә зур әсәр иҗат итмәс иде. Шамил Усманов — 20 яшьлек егет бу бригаданың комиссары иде.*

*Бәлки Сызрань Совдепында татар большевикларының эшчәнлеге турында да зур әсәр туар иде. Сызрань Совдепының беренче председателе шулай ук большевик Шамил Усманов иде.*

*Китап киштәләрендә Усмановның язылачак китап урыннары буш калды. Әмма ул буш урыннар тиздән тулырлар һәм Шамил Усмановның үзе турында язылган китаплар белән тулырлар дип ышанасы килә. Чөнки татар халкының горурлыгы һәм шөһрәте булган Шамил Усмановның якты образы тормыштагы матурлыгы, әһәмияте, сафлыгы ягыннан монументаль коммунист образында күрәсе килгән сыйфатларга тулысы белән тәңгәл килә.*

**А. ЯХИН.**

**Илдус Гыйззәтуллин**

# ШАМИЛ УСМАНОВ — КОМИССАР

**Комиссарларга Кызыл Армияне тәзүнең бөтен авырлыгы йөкләнә. Шуңа күрә хәрби комиссар чын революционер һәм аеруча сәләтле кеше булырга тиеш.**

*Партия в период иностранной военной интервенции и гражданской войны. Мәскәү. 1962 ел. 53 бит.*



Партиябезнең XX съездыннан соң Шамил Усмановның тормыш юлы, иҗтимагый-политик һәм хәрби эшчәнлеге, әдәби иҗаты ныклап өйрәнелә башлады [1]. Аның исеме әдәбият дәреслекләренә керде, татар совет әдәбияты тарихында үзенең хаклы урынын алды. Ләкин әлегә кадәр Ш. Усмановның хәрби-политик эшчәнлеген чагылдырган күп кенә документлар киң катлау укучыларыбызга мәгълүм түгел. Төрле архивларда сакланып калган бу документларда аның күпкырлы хәрби-политик эшчәнлеген яктырта торган байтак материал бар. Бу мәкалә Ш. Усмановның гражданнар сугышы елларындагы хәрби-политик эшчәнлеген яктырту максаты белән язылды. Мәкаләдә файдаланылган архив документларының байтагы белән укучы беренче тапкыр очраша.

...Билгеле булганча, Бөек Октябрь казанышларын дошманнардан саклау өчен эшче-крестьян Кызыл Армиясе төзелә. Төрле милләт хезмәт ияләреннән торган гаскәри бүлекләр белән беррәттән, Кызыл Армия составында аерым милли бүлекләр, шул исәптән татар бүлекләре дә, барлыкка килә. Татар кызыл гаскәри бүлекләре оештыру буенча Үзәк мөселман комиссариаты һәм аның җитәкчесе Мулланур Вахитов зур эш алып баралар. Үзәк мөселман комиссариатының хәрби бүлеге Петроград һәм Мәскәү завод-фабрикаларындагы татар эшчеләре, Германиядән кайткан әсирләр, иске армиядә татар гаскәри бүлекләрендә хезмәт иткән солдатлар арасында зур агитация эшләре алып бара, төрле өндәмәләр бастырып чыгара. Кыска гына вакыт эчендә хәрби бүлек Мәскәүдә Беренче татар-башкорт батальоны оештыра, Икенче мөселман социалистик батальонын төзүгә керешә. Мөселман комиссариаты Россиянең татарлар яши торган губерна һәм өязләрендә җирле мөселман комиссариатлары төзи. Бу комиссариатлар илнең төрле районнарында татар гаскәри бүлекләре оештыруга турыдан-туры катнашалар.

1918 елда Казан губерна мөселман комиссариаты ирекчеләрдән Беренче социалистик мөселман дружинасы төзи. Дружинаның командиры һәм җитәкчесе Нурмөхәммәт Алимов [2] була. Үзәк мөселман комиссариаты председателе М. Вахитов күрсәтмәсе нигезендә, 1918 елның 15 апрелендә дружина өч батальонлы Беренче социалистик мөселман полкына әверелә [3]. Полктагы кызылармеецларның саны 31 майга 5917 кешегә

---

[1] Гыйниятуллина А. Татар совет язучылары. Казан. 1958 ел; Татар совет әдәбияты тарихы. Казан. 1960 ел; Яхин А. Шамил Усманов. Казан. 1963 ел; Яхин А. Шамил Усмановның иҗаты (кандидатлык диссертациясе). 1964 ел; История татарской советской литературы. Мәскәү. 1965 ел; Сагайдак А. Усманов Шамиль Хайруллович (Борцы за счастье народное. 1967); Халит Г. Герои, рожденные революцией. Казан. 1968 ел. һ. б.

[2] Н. Алимов турында кара: Хафизов С. Совет власте өчен көрәшкәндә. «Совет Татарстаны» газетасы. 1957 ел. 21 август; Газизов Н. Беренче татар кызыл гвардия дружинасы командиры. «Татарстан яшьләре» газетасы. 1957 ел. 30 июнь.

[3] Совет Армиясенең үзәк дәүләт архивы (САҮДА). 17 фонд. 1 тасвирлама. 148 саклану берәмлеге. 35 бит.

китә[1]. Шул ук елда Пермь шәһәрендә Егерме беренче укчы мөселман полкы һәм Урал буе кызыл татар коммунарлары батальоны, Астраханьда Касыйм Туйбактин исемендәге татар полкы, Оренбургта татар-башкорт батальоны һәм башка урыннарда аерым татар роталары төзелеп, алар фронтка озатылалар. Бу татар бүлекләре ак чехларга һәм дутовчыларга каршы сугышларда зур батырлыклар күрсәтәләр. Ә инде 1919 елның башында, Колчак гаскәрләре Совет республикасына каршы һөҗүм башлагач, аерым оператив бурычларны да хәл итәргә сәләтле гаскәри бүлекләр — татар бригадалары төзү мәсьәләсе көн тәртибенә куела.

Татар бригадасы төзү идеясен беренче булып Ш. Усманов күтәрә. Шул тәкъдимен тормышка ашыру нияте белән ул үзе үк Мәскәүгә китә, Милләтләр эше буенча халык комиссарнатында, Республиканың революцион хәрби советында, Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә һәм башка югары оешмаларда була. Үзенә 20 яшь кенә булуга карамастан, бу вакытта инде ул шактый зур хәрби-политик чыныгу алган бер кеше була.

Укучылар беләләрдер: 1917 елның март аенда ук Шамил Усманов большевиклар партиясе сафына керә. 1917 елның апреленнән август аена кадәр ул Сызрань депутатлар советы председателе һәм Сызрань шәһәренең хәрби коменданты, шул ук елның август аеннан ноябрена кадәр шәһәрдәге революцион штабның секретаре булып эшли. 1917 елның 14 ноябрендә Ш. Усманов Казан хәрби округын идарә итүче коллегия члены булып сайлана[2] һәм Казан хәрби округы комитетының большевиклар фракциясе председателе[3] булып эшли. Озакламый ул яңадан Сызраньга кайта һәм Кызыл Гвардия отрядларын оештырып, аларны дутовчыларга каршы сугышка җибәрә. 1918 елның маенда үзе төзегән отрядларның берсе белән Усманов Оренбург ягына фронтка чыгып китә[4]. Отряд Оренбургта Кариб Хәйруллин[5] житәкчелегендә төзелеп яткан татар-башкорт батальонына кушыла. Ш. Усманов бу батальонның комиссары итеп билгеләнә. Оренбургка бәреп кергән Дутов бандаларына каршы сугышларда катнашып, батальон үзенең данлы көрәш юлын башлап җибәрә. Тургай далаларында сигез ай буе барган сугышларда батальон тиңдәшсез батырлыклар күрсәтә. Тагын күпмедер вакыт узгач, К. Хәйруллин һәм Ш. Усманов житәкчелегендәге татар-башкорт батальоны Кызыл Армия сафларында сугышучы немец һәм мадьяр батальоннары белән кушыла һәм шулай III интернационал исемендәге легендар легион барлыкка килә. Менә шул төрле милләт хезмәт ияләреннән торган, чын мәгънәсендә интернациональ легионның комиссары итеп Ш. Усманов билгеләнә. Сүз уңаеннан әйтеп үтәргә кирәк: Ш. Усмановның «Легион юлы» исемле әсәрендә бу интернациональ легионның сугышчан юлы шактый тулы яктыртыла[6]...

1919 елның 10 мартында Республика революцион хәрби советы аерым Идел буе татар укчы бригадасы төзү турында карар кабул итә. Шушы карарга нигезләнеп, 1919 елның 24 мартында Идел буе хәрби округында өч полк составында татар бригадасы төзү турында приказ бирелә. Бригаданың идарәсе, беренче полк һәм шулай ук элемтә ротасы Казанда, икенче полк Самарада, өченче полк Алатырьда төзелергә тиеш була[7]. Полкларны оештыру эше Казан, Самара һәм Сембер губерналары хәрби комиссариатларына йөкләнә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе бригаданы оештыруны Ш. Усмановка тапшыра[8] һәм ул, коллегиянең инструктор-оештыручысы хезмәтеннән азат ителеп[9], 20 мартта Идел буе хәрби округы комиссариаты приказы белән бригаданың

---

[1] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы (ТҮДА). 592 фонд. 2 тасвирлама. 89 саклану берәмлеге. 8 бит.
[2] Ежов Н. Военная Казань в 1917 году. Казан. 1957 ел. 77 бит.
[3] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 14 саклану берәмлеге. 37 бит.
[4] Шунда ук.
[5] Байчура Ш. Кариб Хәйруллин. «Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел. 2 сан.
[6] Ш. Усмановның 1917—18 еллардагы эшчәнлеге А. Яхин һәм А. Сагайдак иптәшләренең югарыда күрсәтелгән хезмәтләрендә шактый тулы яктыртылган. Шуңа күрә без күп нәрсәләрне санап үтү белән генә чикләндек.
[7] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 14 саклану берәмлеге. 62—63 битләр.
[8] Шунда ук, 37 саклану берәмлеге. 20 бит.
[9] Ш. Усманов 1919 елның 28 февралендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә инструктор-оештыручы итеп билгеләнә. (Яхин А. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе һәм татар язучылары. «Совет әдәбияты» журналы. 1959 ел. 10 сан. 118 бит.)

комиссары итеп билгеләнә[1]. Хәзер инде бригаданы оештыруның иң зур авырлыгы Ш. Усмановка йөкләнә.

Ш. Усманов үзенең эшен бригада составына кергән полкларга командирлар һәм комиссарлар сайлаудан башлый. 1919 елның 27 мартында Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә ул түбәндәге телеграмманы җибәрә: «Казанда һәм Самарада формалаша торган полкларның идарәсен төзергә керештем, өченче полкның урыны хәзергә билгеле түгел...» Шушы ук телеграммада бригаданың командиры итеп Үзәк мөселман хәрби коллегиясе вәкиле, элекке прапорщик Миргазиян Крымовны билгеләргә кирәклеген күрсәтә[2]. 1919 елның 19 апрелендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең мөселман коммунистик оешмалары Үзәк бюросы катнашында уздырылган утырышында Ш. Усманов бригада төзүнең барышы турында доклад ясый. Үзенең әлеге докладында ул Оренбург мөселман полкын (Оренбург татар-башкорт батальоны бу вакытка инде полкка әйләнгән була) да бригада составына кертү турында тәкъдим кертә. Аның бу тәкъдиме берсүзсез кабул ителә[3].

1919 елның маенда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Мәскәүдән Казанга күчеп килә. Бирегә килүгә хәрби коллегия бригаданы төзүгә турыдан-туры үзе катнаша башлый. Бригаданың беренче җитәкчеләре дә коллегия хезмәткәрләре арасыннан сайлап алына. Бригаданың командиры итеп Үзәк мөселман хәрби коллегиясе члены Иосыф Ибраһимов[4] билгеләнә. 26 апрельдә бригаданың вакытлыча командиры Миргазиян Крымов бригаданың команда эшләрен И. Ибраһимовка тапшыра. Коллегиянең инструктор-оештыручыларыннан Ильяс Ахмеров[5] I нче полкның командиры, Әхмәт Алимбеков III нче полкның командиры[6], Самарада төзелә торган II нче полкның командиры итеп губерна мөселман комиссариаты председателе Әхмәт Хәиров билгеләнә[7]. Бригаданың политик җитәкчеләре дә күренекле татар коммунистлары арасыннан сайлана. Бригада комиссарының урынбасары итеп Кәрим Хәкимов[8] билгеләнә (аны бераздан Хөсәен Мәүлүдов алмаштыра[9]). Беренче полкның комиссары итеп Казан губерна партоешмасы члены Әхмәтша Сабиров[10], II нче полкка Самара губернасы партоешмасы члены Гафар Мостафин[11], III нче полк комиссары итеп Галиулла Касыймовлар билгеләнә[12].

Бригада җитәкчеләре сугыш шартларында бригаданы даими рәвештә татар кызылармеецлары белән тулыландырып тору кирәк булачагын да алдан ук кайгырта башлыйлар. 1919 елның 5 маенда бригада командиры И. Ибраһимов һәм Ш. Усманов Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә бригада каршында запас татар полкы төзү кирәклеге турында махсус рапорт язалар[13]. Яшь социалистик дәүләтнең революцион хәрби советы татар бригадасы оештыруга зур әһәмият бирде һәм татар бригадасы оештыруны ул вакыттагы иң мөһим политик бурычларның берсе итеп карады. Реввоенсовет 1919 елның 6 маенда Казан округы хәрби комиссарнаты, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе, Татар бригадасы командиры, Көнчыгыш фронтның Сембердәге оештыру бүлеге һәм Бөтенроссия баш штабына җибәргән телеграммаларында һич кичекмәстән Казан-

---

[1] ТҮДА. Сборник приказов Приво. 1919 ел.

[2] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 30 саклану берәмлеге. 122 бит. М. Крымов турында кара: Гыйбадуллин М. Революционер, хәрби җитәкче. «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 9 сан. 87—95 битләр.

[3] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 12 саклану берәмлеге. 24 бит.

[4] Шунда ук, 14 саклану берәмлеге. 66 бит, 29 саклану берәмлеге. 14 бит; Шакир С. Кызыл командир. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1967 ел. 15 март.

[5] САҮДА. 17 фонд. 12 саклану берәмлеге. 14 бит һәм 147 саклану берәмлеге, 27 бит.

[6] Шунда ук, 11 саклану берәмлеге. 75 бит.

[7] Шунда ук, 147 саклану берәмлеге. 45 бит.

[8] Шунда ук, 11 саклану берәмлеге. 80 бит; Газизов Л. З., Гумеров Ф. Х., Кәрим Хәкимов. Уфа. 1966 ел.

[9] Исхаков В. М. Хусаин Мавлютов. Пермь. 1961 ел.

[10] Ә. Сабиров турында аның тормыш иптәше Гөлсем Камская истәлекләрен укырга була. Кара: ТҮДА. 4921 фонд. 1 тасвирлама. 194 саклану берәмлеге. 4—7 битләр.

[11] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 147 саклану берәмлеге, 45 бит.

[12] Шунда ук, 40 бит; Касыймов С. Батыр комиссар. «Совет әдәбияты» журналы, 1960 ел. 10 сан.

[13] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 14 саклану берәмлеге. 67—68 битләр.

да 4 роталы запас батальон төзергә тотынырга күрсәтмә бирде[1]. Көнчыгыш фронты революцион хәрби советына татар бригадасы һәм аның запас батальонын мөмкин кадәр тизрәк оештыруда нык ярдәм итәргә һәм бу эшкә Көнчыгыш фронтына кергән хәрби округларны тартырга тәкъдим итте[2]. Запас татар батальонына Казан губернасыннан Кызыл Армиягә чакырылган татарлар да, Казан губернасындагы башка гаскәри бүлекләрдә хезмәт итүче татар кызылармеецлары да җибәрелә. Аларны батальонда хәрби хезмәткә өйрәтәләр, киендерәләр, коралландыралар һәм татар гаскәри бүлекләрен тулыландыру өчен фронтка озатып торалар. Беренче татар бригадасының полклары да кызылармеецларны күбрәк запас татар батальоныннан ала. 1919 елның 29 маенда Алатырьда оештырыла башлаган III нче полкка 1800 татар кызылармеецы, 1 июньдә Самарада формалаша торган II нче полкка 1520 татар кызылармеецы җибәрелә[3]. Батальон бер ел эчендә генә дә, төрле фронтларда сугышучы татар гаскәри бүлекләрен тулыландыру өчен, һәрберсе 250 кешедән торган 19 маршевый рота хәзерләп җибәрә[4].

1919 елның 13 маенда бригаданың Казанда формалашкан Мулланур Вахитов исемендәге беренче полкы фронтка озатыла[5]. Полк белән бригаданың комиссары Ш. Усманов та сугышка китә. Ул 16 майда Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә җибәргән телеграммасында болай ди: «Мин татар гаскәрләренең авангарды булган Беренче полк белән фронтка китәм. Әдәбият белән тәэмин итү һәм әлемтә тоту өчен бөтен чараларны күрегез...»[6]

I нче полк Көнчыгыш фронтның М. В. Фрунзе командасындагы көньяк группасы составында бер ай дәвамында авыр сугышларда катнаша һәм, шактый зур югалтуларга дучар булып, Самарага кайта. Бу вакытта бригаданың штабы да Казаннан Самарага күчеп килгән була. 1919 елның 27 июнендә бригада командиры И. Ибраһимов һәм Ш. Усманов Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә полкның 500 ләп кешесенең исән калуын хәбәр итәләр һәм полкны тулыландыру өчен Казандагы запас татар батальоныннан 1000 кеше җибәрүне сорыйлар[7].

1919 елның июль урталарына бригада нигездә формалашып бетә. Бригадада политик тәрбия, культура-агарту эшләре дә җайга салына. Бригаданың 1919 елның 15 июлендә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә җибәргән политик сводкасында бригада полкларындагы кызылармеецларның кәефе канәгатьләнерлек, барлык полкларда да наданлыкны бетерү мәктәпләре, культура-агарту комиссияләре, иҗтимагый судлар оештырылуы, китапханәләр ачылуы, митинглар, җыелышлар, лекцияләр уздырылуы, гомумән, политик эшнең яхшы куелуы турында хәбәр ителә[8]. Ш. Усманов татар кызылармеецлары арасында политик тәрбия эшләре алып баруда бригаданың политик бүлегенең гаять әһәмиятле булуын яхшы аңлый һәм аны оештыруга зур көч куя.

1919 елның җәендә, Уралда Колчак гаскәрләренең төп көчләре тар-мар ителгәч, дошман боҗрасында калган Совет Төркестанына ярдәм кулы сузарга мөмкинлек туа. Шул максат белән, 1919 елның 13 августында Көнчыгыш фронттан мөстәкыйль Төркестан фронты бүленеп чыга. Фронт командующие итеп М. В. Фрунзе, фронт революцион хәрби советы члены итеп В. В. Куйбышев билгеләнә. Беренче аерым Идел буе татар укчы бригадасы Төркестан фронтының I нче армиясе составына керә. Каты сугышларда җиңеп чыгып, 1919 елның 13 сентябрендә бу армия гаскәрләре Ташкент тимер юлының Мугоджар станциясендә Төркестан гаскәрләре белән очрашалар. Шулай итеп, Совет Төркестанына юл ачыла...

Февраль революциясеннән алып берничә ялсыз эшләү, зур киеренкелек таләп итә торган гаять җаваплы эшләр башкару, каты сугышларда катнашу Ш. Усмановның сәламәтлеген нык какшата. Ул, врачлар кушуы буенча, 1919 елның сентябреннән бер айлык отпуска алып Казанга кайта. Ләкин эшсез тик ятырга теләми: үзен Казандагы

[1] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 13 саклану берәмлеге. 38 бит; ТҮДА. 592 фонд. 2 тасвирлама. 266 саклану берәмлеге. 1 бит.
[2] ТҮДА. 592 фонд. 3 тасвирлама. 276 саклану берәмлеге. 14 бит.
[3] ТҮДА. 592 фонд. 2 тасвирлама. 176 саклану берәмлеге. 101 һәм 105 битләр.
[4] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 57 саклану берәмлеге. 359 бит.
[5] ТҮДА. 592 фонд. 2 тасвирлама. 146 саклану берәмлеге. 102 бит.
[6] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 132 саклану берәмлеге. 1 бит.
[7] Шунда ук, 5 бит.
[8] Шунда ук, 560—561 битләр.

команда курсларына комиссар итеп билгеләүне сорап, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә үтенеч яза [1]. 1919 елның 23 сентябреннән хәрби коллегия аны Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политик бүлекчәсенә вакытлы җитәкче итеп билгели һәм бу турыда бригаданың штабына хәбәр итә [2].

1919 елның октябренда Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политик бүлекчәсе политик бүлеккә әйләндерелә. Республика революцион хәрби советының 8 октябрь приказы белән аның яңа штаты расланa. Политик бүлектә хезмәт итүче кешеләр саны (нәшрият бүлекчәсе белән берлектә) 63 тән 158 гә кадәр җиткерелә. Политбүлек составында, аның төрле юнәлештәге эшләрен алып бару өчен, түбәндәге бүлекчәләр оештырыла: гомуми бүлекчә, культура-агарту бүлекчәсе, оештыру-инструкторлык һәм агитация-информация бүлекчәсе. Һәр бүлекчә, үз чиратында, аерым секцияләргә бүленә. Мәсәлән, культура-агарту бүлекчәсендә театр, мәктәп, библиотека, клуб, кинематография секцияләре була. Политик бүлек үзенең төп бурычын мөселман пролетариатының сыйнфый аңын үстерүдә һәм ныгытуда, аны коммунизм идеяләре рухында тәрбияләүдә күрә. Политик бүлекнең эшчәнлеге республиканың татар-башкорт кызылармеецлары булган барлык гаскәри бүлекләренә тарала. Аның йогынтысы татар-башкорт һәм башка төрки халыклар яши торган Урта һәм түбән Идел буена, Вятка, Кама, Агыйдел бассейннарына, Башкортстанга, казакъ далаларына, Төркестанга, Көнбатыш һәм Көньчыгыш Себергә җәелә. Политик бүлеккә Кызыл Армиянең гаскәри бүлекләре өчен политик һәм культура-агарту кадрлары әзерләү, нәшрият эше, армияне татар телен белүче кадрлар һәм татар телендәге әдәбият белән тәэмин итү, җирле мөселман халыкларына партия эшен оештыруда, милләтләр бүлекләрендә мөселман бүлекчәләре төзүдә ярдәм итү кебек күп төрле вазифалар йөкләнә [3].

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Ш. Усмановны политик бүлекнең гаять киң эшчәнлеге белән җитәкчелек итә алырга сәләтле дип таба һәм 1919 елның 22 октябрендә аны политик бүлекнең җитәкчесе итеп билгели [4]. Шулай Ш. Усманов биографиясенең гаять кызыклы һәм вакыйгаларга бай яңа сәхифәсе башлана. Политбүлек татар телен белүче хәрби-политик кадрлар әзерләүгә һәм Кызыл Армия бүлекләрен, губерна-өязләрне шундый кадрлар белән тәэмин итүгә зур әһәмият бирә. Бу өлкәдә Ш. Усманов 1919 елның 25 июнендә һәлак булган Камил Якубовның (политбүлекнең аңа кадәрге җитәкчесе була) эшен дәвам иттерә. Билгеле булганча, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Казанга күчеп килгәч, политик бүлек каршында Камил Якубов тырышлыгы белән татар хәрби-политик работниклары әзерләү курслары ачылган иде. 1919 елның азагынна бу курслар Кызыл Армиягә 150 татар политработнигы әзерләп бирә. Болардан тыш, 1919 елда Республиканың Казанда урнашкан запас армиясе каршындагы партия мәктәбен политбүлек җибәргән 13 кеше тәмамлый һәм алар да гаскәри бүлекләргә озатыла. 1919 елның май аеннан декабрьга кадәр генә дә политбүлек Кызыл Армиягә 332 татар политработнигы җибәрә [5]. 1920 елның февралендә Казанда политбүлек каршында татарлар өчен партия мәктәбе ачыла.

Политбүлек татар кызылармеецларын даими рәвештә төрле курсларга җибәреп тора. 1920 елның беренче яртысында гына да бүлек төрле курсларга 574 кеше җибәрә. Шуларның 238 е политик курсларда, 104 се укытучылар әзерләүче курсларда укыйлар. Болардан тыш, төрле курсларга керү өчен кандидат буларак, 175 татар кызылармеецы вакытлыча татар запас батальонына хезмәт итәргә җибәрелә [6]. Татар запас батальонында, хәрби, политик курсларга керергә теләүче һәм билгеле хәзерлеге булган кызылармеецларны группаларга оештырып, алар белән рус теле һәм арифметика буенча дәресләр алып барыла. Бу группаларда шулай ук география, тарих һәм табигать белеменнән дә кайбер мәгълүматлар бирелә. Дәресләрне Казан шәһәре укытучылары алып бара. 1920 елның 1 июненә батальонда 8 кешелек шундый бер группа була. Тиздән андагы кызылармеецларның саны 15 кә җитә. 8 июньдә 19 кешелек икенче группа,

---

[1] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 132 саклану берәмлеге. 448 бит.
[2] Шунда ук, 131 саклану берәмлеге. 93, 96 битләр һәм 132 саклану берәмлеге. 463 бит.
[3] «Красная Армия» газетасы. 1920 ел. 8 март.
[4] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 146 саклану берәмлеге. 31 бит.
[5] «Красная Армия» газетасы. 1920 ел. 8 март.
[6] САУДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 92 саклану берәмлеге. 55—56 битләр.

12 июньдә 18 кешелек өченче группа, 2 июльдә 14 кешелек дүртенче группа эшли башлый. Шулар арасыннан, бары икенче группада гына укыган 19 кызылармеецның 11е мөселман пехота курсларына, 5се радио-телеграфистлар курсларына, 1 се рабфакка, 1 се кавалерия курсларына керә [1].

Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлеге эшендә нәшрият мәсьәләләре зур урын тота. Татар телендә басылган газеталар, күп санлы брошюралар, Совет хөкүмәтенең карарлары һәм өндәмәләре, политик плакатлар ярдәмендә политбүлек татар кызылармеецлары арасында гына түгел, бәлки Урта Азия республикаларында да зур эш алып бара, көнчыгышта Совет властеның ныгуына ярдәм итә. Политбүлекнең нәшрият бүлекчәсенең 1918 елның ноябреннан 1920 елның июленә кадәрге вакыт өчен язган отчетына караганда, бүлекчә бу вакыт эчендә 330 санда «Кызыл Армия» газетасы чыгарган (гомуми тиражы 6,5 млн. артык). Газетаның тиражы башта 1000—10 000 булса, соңгы вакытларда ул инде 30 000 житкән. Шушы вакыт эчендә 56 исемдә 950 меңгә якын брошюра, 11 мең открытка, 24 исемдә 550 500 данә өндәмә һәм листовкалар, татар кызылармеецлары өчен 31 исемдә 1,2 миллионнан артык дәреслек чыгарылган [2].

Политбүлек шулай ук урыннардагы партия-совет оешмаларына да зур ярдәм күрсәтә. Бу оешмаларның соравы буенча татар телендә әдәбият җибәрә, үзенең хезмәткәрләрен, халыкка Совет властеның политикасын ана телендә аңлату өчен, командировкаларга чыгара. Политбүлек Колчак гаскәрләреннән азат ителгән районнарда эшләүгә аеруча зур игътибар бирә. Аның вәкилләре Самара, Уфа, Вятка, Екатеринбург (хәзерге Свердловск), Пермь губерналарында һәм Себердә губерна-өяз милләтләр һәм халык мәгарифе бүлекләре каршында мөселман бүлекчәләре, секцияләре оештыралар, партия оешмаларын, милли матбугатны торгызуга ярдәм итәләр [3].

Үзәк мөселман хәрби коллегиясе һәм аның Ш. Усманов җитәкчелегендәге политбүлеге татар кызылармеецлары арасында наданлыкка каршы көрәштә дә зур эш башкардылар. Революцион хәрби советның 1919 елның 4 сентябрендә кабул ителгән 1415 номерлы приказы нигезендә [4], наданлыкка каршы көрәш, кызылармеецларны укыйязарга өйрәтү, аларның гомуми белем дәрәҗәсен күтәрү Кызыл Армиядә массовый төс алды. Хезмәт йөкләмәсен үтәү йөзеннән, бик күп укытучылар мәҗбүри рәвештә кызылармеецларны укыту эшенә тартылдылар. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политик бүлеге татар кызылармеецлары арасыннан укый-яза белмәүчеләрнең исәбен алуны оештыра, мәктәпләр ача, аларны укытучылар һәм дәреслекләр, язу кирәк-яраклары белән тәэмин итә. 1920 елның мартында политбүлек Төркестандагы Беренче татар бригадасына 6 укытучы, бик күп китаплар җибәрә [5], апрель аенда запас армиянең 4, 5, 6 нчы полкларында татар кызылармеецлары өчен мәктәпләр ача [6]. 1920 елның 27 апрелендә коллегия татар кызылармеецларын укыту өчен татар телендә әлифба чыгару мәсьәләсен карый һәм бу эшкә 20 000 сум күләмендә аванс бирү турында карар чыгара.

Коллегия үзенең эшенә татар интеллигенциясенең Совет власте платформасында торган алдынгы вәкилләрен дә тарта. 1919—20 елларда политбүлектә күп кенә татар галимнәре, язучылар, артистлар эшли [7]. Архивларда татар интеллигентларын политбүлеккә эшкә чакырган бик күп документлар саклана. Менә шуларның берсе. Ул 1920 елның 5 январенда Ш. Усманов тарафыннан запас армиянең политбүлегенә җибәрелгән. Бу язуда Ш. Усманов запас армиянең 5 нче полкында 4 нче ротада хезмәт итүче студент Урманчеевны коллегиянең политбүлеге карамагына җибәрүне сорый. Язуда Урманчеевның Казанда бердәнбер татар художнигы икәнлеге әйтелә һәм аның тылдагы, шулай ук фронттагы татар гаскәри бүлекләренең сәнгать өлкәсендәге ихтыяҗларын үтәү өчен, календарьлар чыгару һ. б. өчен политбүлеккә бик кирәклеге

---

[1] Шунда ук, 84 саклану берәмлеге. 120 бит.
[2] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 57 саклану берәмлеге. 545 бит һәм 86 саклану берәмлеге. 37—38 битләр.
[3] «Красная Армия» газетасы. 1920 ел. 8 март.
[4] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 76 саклану берәмлеге. 16 бит.
[5] Шунда ук, 61 саклану берәмлеге. 99 бит.
[6] Шунда ук, 119 саклану берәмлеге. 47 бит.
[7] Яхин А. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе һәм татар язучылары. «Совет әдәбияты» журналы. 1959 ел. 10 сан.

әйтелә[1]. Ш. Усмановның үтенече канәгатьләндерелә, һәм хәзерге вакытта Татарстанның күренекле художнигы Бакый Урманче шул чакта Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең политбүлегенә эшкә алына һәм бераздан 1 политбүлек каршындагы сәнгать мастерское мөдире булып эшли башлый.

Ш. Усманов югарыда саналган эшләр белән генә чикләнеп калмый. Ул һаман яңага омтыла, яңа эшләр эзли. Политик эшнең яңа формаларын табарга омтыла. Менә ул татар телендә, татарлар тормышын чагылдырган һәм революцион эчтәлекле кинофильмнар эшли башлауны оештырырга рөхсәт сорап Республиканың революцион хәрби советына мөрәҗәгать итә. Үзенең мөрәҗәгатендә ул политбүлек чыгарачак андый фильмнарны башка мөселман халыклары арасында да таратырга мөмкин булачагын да билгеләп[2] һ. б. һ. б.

Ш. Усмановның гражданнар сугышы елларындагы хәрби-политик эшчәнлеге Үзәк мөселман хәрби коллегиясе җитәкчеләре тарафыннан югары бәяләнә. Коллегиянең 1920 елның 10 февралендә кабул ителгән карары нигезендә, Республиканың революцион хәрби советы исеменнән Ш. Усманов сугышчан татар гаскәрләренең беренче оештыручысы һәм фронтларда дан казанган 1 нче татар бригадасының элекке комиссары буларак, сугышчан шәхси батырлыклары һәм бригаданың сугышчан хәрәкәтләре белән оста җитәкчелек иткән өчен алтын сәгать белән бүләкләнә[3]. Соңрак күренекле татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылган Шамил Усманов үзенең легендар хәрби хезмәт юлын әнә шулай башлап җибәрә. Бу талантлы хәрби оештыручы, батыр сугышчы, ялкынлы комиссар — үзенең рухи туганнары Дмитрий Фурманов, Аркадий Гайдар кебек талантлар белән бергә — гражданнар сугышы елларында шундый данлы юл уза. Соңрак ул үзенең бу юлда үткәннәрен укучыларыбыз тарафыннан яратып укыла торган хикәяләренә һәм повестьларына нигез итеп ала.

---

[1] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 103 саклану берәмлеге. 3 бит.
[2] Шунда ук, 119 саклану берәмлеге, 433—434 битләр.
[3] САҮДА. 17 фонд. 1 тасвирлама. 59 саклану берәмлеге. 5 бит.

Сафа Сабиров

# КАЙНАР ЙӨРӘКЛЕ КӨРӘШЧЕ

Хөррияттә син, Шәһит, ай-яй күп эш кырдың, бугай,
Ярлыны ярдан алырга бик тырыштырдың, бугай.

ш. БАБИЧ.

Буржуазия һәм алпавытлар дәүләтен нигезеннән тетрәткән беренче рус революциясе рәхимсез рәвештә бастырылды. Әмма аның куәтле дулкыннары илнең үзәк өлкәләреннән бик еракларга таралды, ярым колониаль хәлдә яшәгән милли окраиналарга барып җитте. Реакция күпме генә котырынмасын, урыннарда эшче-крестьян массаларының сыйнфый аңы һәм активлыгы өзлексез үсә барды, күп гасырлар буена изелгән хезмәт ияләре арасыннан кыю көрәшчеләр үсеп чыкты. Аларның алдынгылары, күп санлы катгы бәрелешләрдә чыныга, милли чикләнгәнлек күренешләреннән арына барып, марксизм-ленинизм өйрәткән бердәнбер дөрес юлга — сыйнфый көрәш юлына бастылар, Бөек Октябрь революциясе көннәрендә һәм Совет власте елларында танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре булып җитлектеләр.

Күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, ялкынлы журналист һәм язучы Шәһит Әхмәдиев тә туган халкының бәйсезлеге, хезмәт ияләренең бәхетле киләчәге өчен көрәш юлында күп көч куйган һәм озак еллар армый-талмый эшләгән кешеләрнең берсе. Шушы елның декабрендә Ш. Әхмәдиевнең тууына 80 ел тулды. Татарстан хезмәт ияләре бу датаны зурлап билгеләп үтәләр һәм аны ихтирам белән искә алалар.

* * *

Шәһит Әхмәдиевнең тормыш юлы бик авыр һәм шактый катлаулы. Ул 1888 елның 29 декабрендә элекке Чистай өязенең Татар Ялтаны авылында дөньяга килә. Үсә төшкәч, аны авыл мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул кечкенәдән белемгә омтылучан, зирәк бала була һәм бик тырышып укый. Әмма күп тә үтми, аның әтисе һәм әнисе үлә. Шәһит туган-тумача кулында ятим бала булып кала. Берәр приютка эләгеп яки малайлыкка ялланып булмасмы дип, 1901 елның җәендә ул бер тиен акчасыз туган авылыннан чыгып китә. Оренбургка килә һәм андагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә керә. Шәһиткә гаять авыр шартларда укырга туры килә. Ул бай шәкертләргә самовар куеп, кер юып көн итә. Бераз үсә төшкәч, башка шәкертләр җәйге каникулга ялга таралган айларда тимер юл төзелешендә һәм башка урыннарда эшләп, ас-башын бөтәйтергә, кышка бераз акча әмәлләргә тырыша.

1905—1907 еллардагы революция давыллары торгынлык һәм схоластика хөкем сөргән иске мәдрәсәләрне дә ията. Алдынгы шәкертләр иске тәртипләргә каршы көрәшкә күтәреләләр: коры дин генә өйрәтә торган программа, искелеккә нигезләнгән, мулла, мәзин һәм хәлфәләр генә әзерләп чыгара торган мәдрәсәләрне ташлап китәләр яки укыту программаларын үзгәртүне, дөньяви белем бирүне таләп итәләр.

Бу елларда инде яшь егет булып үсеп җиткән, иптәшләре арасында үзенең кыюлыгы, алдынгы карашлы булуы белән танылган Ш. Әхмәдиев Оренбургта да, соңрак Уфага килгәч, «Галия» мәдрәсәсендә дә шәкертләр хәрәкәтенең башлап йөрүчеләреннән була һәм шуның өчен ике мәдрәсәдән дә куып чыгарыла. Аның бергә укыган сабакташы һәм якын иптәше Галимҗан Ибраһимов «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле беренче хикәясендә әнә шул вакыйгаларны сурәтли.

Кара реакция еллары килеп, илдә эзәрлекләүләр башлангач, Шәһит Әхмәдиев Себергә китә. Иртыш буендагы авылларда балалар укыта, үзлегеннән белемен күтәрү өстендә эшли, рус, француз һәм гарәп телләрен өйрәнә. Павлодар шәһәрендә яшәүче Хөсәен ага Рамазанов күптән түгел генә «Казан утлары» журналы редакциясенә җибәргән хатында Ш. Әхмәдиевнең ул еллардагы укытучылык эшен зур ихтирам белән искә ала[1].

Шәһит Әхмәдиевнең белемгә ашкынуын бернинди эзәрлекләүләр һәм кыенлыклар да тоткарлый алмый. Балалар укытып бераз акча җыйгач, 1910 елның җәендә ул Казанга кайта һәм, университетка укырга керү максаты белән, үзлегеннән әзерләнә башлый. Монда ул Оренбург һәм Уфа мәдрәсәләрендә бергә укыган дусты Галимҗан Ибраһимов белән очраша. Алар, Суконный урамындагы бер ярлы гаиләгә фатирга кереп, бик авыр шартларда яшиләр. Соңыннан Ялтадан Ш. Әхмәдиевкә җибәргән хатларының берсендә ул еллар турында Г. Ибраһимов болай дип язган иде: «Син минем гомерне беләсең: күпме ачлык, ялангачлык; күпме начар, юеш, сасы квартирларда калтырап кыш чыгулар; күпме көн-төн тырышып укулар, язулар; менә шулар һәммәсе җыелып килеп мине аяктан ектылар, туган...»

Тиздән, балалар укытып җыйган барлы-юклы акчасы беткәч, Ш. Әхмәдиев типографиягә хәреф җыючы, корректор булып керә, аннары газета-журналларда төрле информацияләр, спектакльләргә, әдәби әсәрләргә рецензияләр бастыра, публицистик мәкаләләр яза, тәрҗемәче булып эшли. Шул елларда ук әдәби иҗат өлкәсендә дә тәүге адымнарын атлый. Вакытлы матбугат битләрендә аның беренче очерклары, нәсер һәм хикәяләре басыла башлый.

Әдәбиятта беренче адымнарын атлаганда аңа иҗади ярдәм күрсәтүче һәм әсәрләренә дөньяга чыгарга юл ачучы кеше Галимҗан Ибраһимов була. Байтак еллардан соң чыккан бер мәкаләсендә Фатих Сәйфи-Казанлы бик хаклы рәвештә болай дип язды: «Галимҗан «Аң» журналының командиры булу белән татар дөньясының ул чагындагы рәвештә баруына протест ясап йөрүчеләрне үз ягына тартты. Хәснетдин Кәримов, Шәһит Әхмәдиев... шул көннәрдә татар әдәбияты дөньясында чәчәк ата башладылар».

Шул чорның башка демократ язучылары кебек үк, Шәһит Әхмәдиев тә үз әсәрләрендә татар җәмәгатьчелеген дулкынландырган актуаль проблемаларны күтәрә, хезмәт ияләренең авыр тормышын сурәтли, сыйнфый гаделсезлеккә каршы чыга. Мисалга «Ике төрле тормыш» исемле хикәядән кешеләргә утын кисеп көн итүче Хәйрулла картны алыйк. Адәм түзә алмаслык кышкы суык көннәрнең берсендә, ятим оныгын үлемнән саклап калу өчен, ул бөтен шәһәрне бетереп эш эзләп йөри. Әмма берни дә таба алмыйча йөдәп бетә...

Беренче рус революциясе һәм аннан соңгы елларда хатын-кызларны иҗтимагый һәм семья коллыгыннан азат итү, аларга ирләр белән тигез хокук бирү өчен демократик хәрәкәт кузгала. Прогрессив язучылар татар хатын-кызларын буып торган шәригать законнарына, фанатизмга каршы чыгалар. Ш. Әхмәдиевнең «Суга баткан килен» исемле хикәясендә акчага табынып яшәүче Габдрахман карт кызы Кәлимәне 500 сум акча бәрабәренә яратмаган кешегә кияүгә бирә. Елап-ялварып та әтисен тыңлата алмаган бәхетсез кыз, туйлар булып кияү өенә кайтып барганда, пароходтан суга ташланып, үзен-үзе һәлак итә. Мондый фаҗигане тудырган иҗтимагый чынбарлык хикәядә көчле нәфрәт һәм зур осталык белән сурәтләнә, укучы күңелендә кыргый гореф-гадәтләргә, фанатизмга каршы кискен протест уята. Әлеге тема аның башка әсәрләрендә дә дәвам иттерелә. «Сүз истигъмаль итмәдем», «Сагыш», «Шагыйрь моңая», «Тур тавында» исемле хикәя һәм нәсерләрендә автор чын дуслыкка һәм тигезлеккә нигезләнгән саф мәхәббәткә дан җырлый. Бу әсәрләрдәге геройларның

[1] Яшь мөгаллимнең тырышлыгын мактап, ата-аналар исеменнән рәхмәтләр әйтеп язылган бер хат заманында «Вакыт» газетасында да басыла.

язмышы, якты киләчәккә омтылган уй-хисләре укучы күңелендә озак саклanырлык итеп бирелгән.

Шәһит Әхмәдиев әсәрләрендә үз халкының теленә, әдәбиятына кимсетеп караучы типларны да, туган халкының мәдәниятен, аң-белем дәрәҗәсен үстерү юлында армый-талмый тырышучыларны да күрәбез. «Мөгаллим» исемле әсәрнең героена күп төрле кыенлыклар кичерергә туры килә: ул бик аз хезмәт хакына эшли, җитмәсә, авыл байларына ошамаган өчен, кыш уртасында эшеннән куыла. Ләкин бу изге юлга басуына ул һич тә үкенми, караңгы авылда крестьян балаларын укытуын дәвам иттерә, сөйгән дусы гади авыл кызын да, үзе укытып, мөгаллимә итә, халык арасында мәдәният яктысы тарату юлына алып чыга.

«Аэропланда» хикәясендә без бөтенләй бүтән теркем вәкилләрен күрәбез. Бу фантастик хикәянең геройлары Шамун белән Мансур сыйныфлар көрәшенә катнашырга, байларны һәм эксплуататорларны да, ачлыктан тилмерүче фәкыйрьләрне дә күрергә теләмиләр: шау-шулы җир тормышын ташлап, аэропланда галәмгә очып китәләр. Ләкин галәм бушлыгында алар озак яши алмыйлар, яңадан реаль тормышка, җиргә әйләнеп кайтырга мәҗбүр булалар. Беренче карашка фантастик жанрда язылган кебек булса да, бу әсәрдән шул чордагы иҗтимагый хәрәкәтнең аерым күренешләрен, тормышның реаль картиналарын төсмерләргә мөмкин. Революция күтәрелешкә барган елларда халыкка хезмәт итү турында сөйләнеп йөреп тә, кара реакция һөҗүмгә күчкәч, Шамун һәм Мансур кебек көрәш мәйданыннан куркакларча качып киткән хыянәтчеләр аз булмады.

Югарыда китерелгән мисаллардан без Ш. Әхмәдиевнең ике революция арасында реакцион искелеккә каршы күтәрелгән демократик көчләрне дөрес сиземли белгәнлеген һәм чынбарлыкның реаль сурәтләрен биргәнлеген ачык күрәбез. Шул ук вакытта Ш. Әхмәдиевнең гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм каршылыклы бер чорда яза башлавын да онытырга ярамый. Әдипнең идея-эстетик эзләнүләре гел туры юлдан гына бармады. Эзләнүләр процессында, бигрәк тә иҗатының беренче чорында, ул кайбер тайпылышлардан да котылып бетә алмады. Аның аерым әсәрләрендә очрый торган мәхәббәт культы, үткән тарихны идеаллаштыру мотивлары әнә шуның белән бәйле. Әмма ни генә булмасын, демократик әдәбият рухы Ш. Әхмәдиев әсәрләрендә үзәк лейтмотив булып тора. Аның иҗаты татарның шул чордагы прогрессив язучылары Г. Тукай, Г. Камал, Г. Ибраһимов һәм башка алдынгы әдипләрнең идея-эстетик карашлары белән чын мәгънәсендә авазлаш.

Ш. Әхмәдиевнең барлык әдәби әсәрләре нигездә 1912—1917 елларда язылган. Шуннан соң ул бөтен көчен революцион көрәшкә, дәүләт һәм җәмәгать эшләренә багышлый һәм совет вакытлы матбугатында актив эшләвен, газета-журнал битләрендә ялкынлы публицистик мәкаләләр белән чыгуын дәвам иттерә.

* * *

Яшьләй нужа күреп үскән һәм һәрвакыт халык интереслары белән яшәгән Шәһит Әхмәдиев Октябрь революциясен шатланып каршылый. Бераз вакыт максималистлар арасында чуалса да, тиздән ул бу вак буржуаз партия белән элемтәсен бөтенләйгә өзә, большевиклар белән бергә, Казан эшчеләре арасында революцион агитация алып бара, массаларны буржуазиягә каршы яңа көрәшләргә әзерләүдә актив катнаша.

Бу көннәрдә ул атаклы революционер Мулланур Вахитов белән якыннан таныша. Алар төрле җыелыш һәм митингларда чыгышлар ясыйлар, татар буржуазиясе һәм руханилары оештырган **Мөселман комитетына** каршы бергәләшеп көрәш җәеп җибәрәләр [1].


---

[1] Атаклы революционер белән якыннан очрашу һәм бер сафта көрәшү Ш. Әхмәдиевкә күп нәрсә бирә. «Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» исемле җыентыкта басылган истәлегендә бу хакта ул болай дип яза: «Мулланур иптәшнең бөтен сүзеннән, хәрәкәт-адымнарыннан аның революциягә мәгълүм бер план белән өлгереп тотынганлыгы сизелә иде... Ул бик тиз Казан демократиясенең сөекле революционеры булып китте... Аның сүз-нотыклары һәрвакыт тирән мәгънәле һәм фәнни булалар иде. Ул җыелышларда үз мохалифларын демагогия, хәйлә, ялган белән җиңәргә тырышмый, бәлки хакыйкатьне төрле яктан күрсәтеп, халыкка тәэсир итеп җиңә иде».

Февраль революциясе булуга Ш. Әхмәдиев профсоюз хәрәкәтендә актив катнашып китә. Ул Казан сәүдә хезмәткәрләре һәм конторщиклары бюросын оештыра. Кыска гына вакыт эчендә бу бюро зур эш җәеп җибәрә, коммунист эшчеләр белән элемтәгә керә һәм «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг астында «Аваз» исемле газета чыгара башлый. Газетаның оештыручысы һәм редакторы Ш. Әхмәдиев була.

Характеры белән вак буржуаз газета булуына карамастан, «Аваз» үзенең битләрендә вакытлы хөкүмәткә, империалистик сугышка каршы юнәлдерелгән мәкаләләр бастыра, властьны Советларга бирүне таләп итә, татар хезмәт ияләрен революцион рухта тәрбияләүдә большевикларга зур ярдәм күрсәтә. В. И. Ленинның «Новая жизнь» газетасына җибәргән хатын, татар теленә тәрҗемә итеп, Ш. Әхмәдиев «Аваз»да бастыра. Менә шуңа күрә дә Казан большевиклары чыгара торган «Рабочий» газетасы «Аваз» турында: «Хәзерге вакытта бу газета татар пролетариаты интересларын яклаучы бердәнбер орган булып тора», дип яза. Татар хезмәт ияләре арасында пропаганда һәм агитация эшләре алып баруда Казан большевиклары «Аваз» газетасыннан да уңышлы файдаланалар.

Шәһит Әхмәдиев Мөселман социалистлар комитетын оештыручылардан һәм аның актив җитәкчеләреннән була. 1917 елның ноябрендә Казан губернасы мөселманнар съезды Мулланур Вахитов белән Шәһит Әхмәдиевне Уфада үткәреләчәк Милли


Российская
Социалистическая Федеративная
Советская Республика

Народный Комиссариат
по
Делам Национальностей

Отдел
Сентября дня 1918 г.
№ 1914

Москва.
Поварская 32
Телефоны: общий 1-85-51, секрет 1-51-62.


МАНДАТ.

Настоящим удостоверяется, что предъявитель сего тов. Шагит АХМАДИЕВ является Членом Чрезвычайной Комиссии по делу объединения Мусульманских Пролетарских Организаций и борьбе с контр-революцией среди мусульманского населения в пределах Поволжья, Приуралья и Сибири. Тов. Шагит АХМАДИЕВ уполномочен по заготовлению мусульманской пролетарской печати.

Предписывается всем учреждениям Рос. Соц. Фед. Сов. Республики и отдельным лицам оказывать содействие тов. Ш. АХМАДИЕВУ в передвижениях и исполнении им своих обязанностей.

Заместитель Народного Комиссара по Делам национальностей

Делопроизводитель



*А. Луначарский һәм Ш. Әхмәдиев.*

мәҗлескә делегат итеп сайлый. Татар буржуазиясе, милләтчеләр һәм руханилар тарафыннан оештырылган бу мәҗлес яшь Совет властена каршы көрәшкә кара көчләрне туплау максаты белән чакырылган була. Ш. Әхмәдиев мәҗлеснең беренче утырышында ук трибунага чыгып:

— Мин бу мәҗлеснең көн тәртибенә беренче мәсьәлә итеп Совет властен таныр-га, РСФСР Халык Комиссарлары Советын һәм иптәш Ленинны тәбрикләп Петроградка телеграмма җибәрергә тәкъдим кертәм,— дип сөйли башлый. Аның кыю чыгышы буржуаз делегатлар арасында курку һәм каушау тудыра.

Октябрь революциясеннән соң, Ш. Әхмәдиев Казан губерна советы башкарма комитеты члены булып сайлана һәм губерна мәгариф комиссары итеп билгеләнә. Революцион штабның председатель урынбасары буларак, ул татар буржуазиясенең контрреволюцион үзәге «Болак арты республикасы»н тар-мар итүдә актив катнаша.

1918 елның январенда ул РСФСР Халык Комиссарлары Советы каршында төзелгән Эчке Россия мөселманнары комиссариатының үзәк коллегиясе члены һәм Бөтенроссия мөселманнарының мәгариф халык комиссары урынбасары итеп билгеләнә. 1918 елның сентябрендә РСФСР Милләтләр Халык комиссариаты Ш. Әхмәдиевне Идел буе, Урал һәм Себер өлкәләрендә контрреволюциягә каршы көрәшү һәм мөселман пролетар матбугатын оештыру буенча Гадәттән тыш комиссия вәкиле итеп җибәрә.

1919 елның көзендә Колчакны куач, сугыш хәрәкәтләре Урта Азиягә күчә. Анда җирле халык арасында эшләргә, Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасын тормышка ашырырга сәләтле кадрлар кирәк була. Партия Үзәк Комитеты Шәһит Әхмәдиевне Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының «Кызыл шәрык» исемле агитацион поездына политбюро члены һәм газета редакторы итеп җибәрә. Шул поездда йөргән вакытта ул төрле җыелышларда, митингларда партия һәм Совет хөкүмәтенең политикасын аңлатып күп тапкыр чыгышлар ясый. Кызыл армия Бохараны азат итү өчен авыр сугышлар алып барган көннәрдә Ш. Әхмәдиев М. В. Фрунзе җитәкчелегендәге революцион штаб члены булып эшли.

Урта Азиядә Совет власте урнаштырылгач, Ш. Әхмәдиев Төркстан республикасының мәгариф халык комиссары итеп билгеләнә. Ул Төркстан мәгариф работниклары профсоюзы председателе итеп сайлана, үзбәк, казакъ, кыргыз, төркмән халыкларының орфографиясен камилләштерү буенча зур эш алып бара. 1921 елның январенда бу мәсьәлә буенча аның җитәкчелегендә культура работникларының Бөтентөркстан съезды үткәрелә.

1921 елда Урта Идел буе өлкәләрендә каты ачлык башлана. Ачлыкка каршы көрәш бөтен ил күләмендә гаять мөһим эш булып әверелгән бу авыр вакытта, партия Үзәк Комитетыннан сорап, Ш. Әхмәдиев туган-үскән ягына — Татарстанга кайта һәм Мәгариф халык комиссары булып эшли башлый. Ул сугыш елларында тәрбиячесез

калган, ачлыктан интеккән ятимнәр өчен балалар йортлары, һөнәр мәктәпләре, производство мастерскойлары оештыруга, республикада мәгариф эшләрен юлга салуга күп көч куя.

Республикада Совет мәгарифен үстерүнең дөрес юлларын билгеләү, эшче һәм крестьян хөкүмәтенә турылыклы педагогик кадрлар туплау өчен көрәш барган бу катлаулы чорда Ш. Әхмәдиев һәрвакыт принципиаль большевистик позициядә тора, татар хезмәт ияләрен тугандаш рус халкыннан аерырга маташучы буржуаз милләтчеләргә, яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү эшенә аяк чалучы һәртөрле бәндәләргә кискен каршы чыга. 1924 елның ноябрендә Татарстанда уку-укыту эшләре белән якыннан танышканнан соң, РСФСР мәгариф халык комиссары А. Луначарский Ш. Әхмәдиевнең бу эшчәнлеген югары бәяләп болай диде: «Татарстан, һичшиксез, бер үзе өчен генә эшләми, шунлыктан мин бу мәсьәләдә Татарстан җөмһүрияте җитәкчеләре, бигрәк тә мәгариф халык комиссары Әхмәдиев белән бер төсле уйлыйм».

Бу елларда Ш. Әхмәдиев партиянең Татарстан өлкә комитеты члены һәм СССР Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана. Ул 1917 елның март аеннан бирле коммунистлар партиясендә член булып тора һәм партия йөкләгән һәр эшне бөтен тырышлыгын биреп башкара, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ленинчыл коммунистлар партиясенең актив көрәшчеләре сафында бара.

* * *

Шәһит Әхмәдиевнең журналистика өлкәсендәге эшчәнлегенә аерым тукталмыйча үтү мөмкин түгел. Ул — татар совет вакытлы матбугатына нигез салучыларның, аны үстерү юлында озак еллар армый-талмый эшләгән энтузиаст журналистларның берсе. Аның бөтен дәүләт һәм җәмәгать эшчәнлеге, бөтен әдәби иҗаты вакытлы матбугат белән аерылгысыз бәйле. Ул һәрвакыт халык интереслары белән яшәүче, җәмәгатьчелек алдында торган актуаль проблемаларны хәл итүдә актив катнашучы ялкынлы публицист иде. Аның бу гүзәл сыйфаты иҗатының башлангыч чорында язылган мәкаләләреннән үк ачык күренә. 1913 елда «Аң» журналында чыккан бер мәкаләсендә ул балалар әдәбияты өлкәсендә яшәп килгән җитди кимчелекләргә туктала, күпчелек әсәрләрнең коры үгет-нәсихәт, акыл сатудан гыйбарәт икәнлеген күрсәтеп үтә; балага укыр өчен мавыктыргыч, образлы итеп язылган, аның зиһенен ачарга, табигатьне, тормышны танып белергә ярдәм итә торган әсәрләр кирәк, ди. «Бездә сәнагъ нәфисә» исемле зур мәкаләсендә (1914 ел) ул композиторларыбыз, скульпторларыбыз, рәссамнарыбыз булмавыннан, сәнгатьнең башка тармаклары акрын үсүгә борчылып яза, татар драма театрын оештыручы Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина, театр сәнгатенең беренче пионерлары Колалаев, Мортазин, Болгарская, Тинчурин, Сәмитова һәм башка артистларның иҗади уңышларына шатлана, аларга файдалы киңәшләр бирә. Шул ук вакытта ул үзе дә театр эшендә якыннан катнаша. А. Н. Островскийның Г. Кариев тарафыннан сәхнәгә куелган «Төшемле урын» комедиясен Ш. Әхмәдиев тәрҗемә итә. Ф. Әмирханның һәм С. Рәмиевнең «Сәйяр», «Нур» труппалары тарафыннан куелган сәхнә әсәрләренә тирән эчтәлекле рецензияләр язучы кеше дә Ш. Әхмәдиев була. Аның бу рецензияләре татар драма театры тарихын өйрәнү өчен хәзер дә әһәмиятле материал булып хезмәт итәләр, шул чор сәхнә осталарының иҗади эшчәнлеген дөрес аңларга мөмкинлек бирәләр.

Шәһит Әхмәдиев үзе эшләгән газета-журналлар тирәсендә алдынгы язучыларны, публицистларны туплый, аларның реакцион матбугат битләрендә басыла алмаган әсәрләрен дөньяга чыгара. Фатих Сәйфи-Казанлы югарыда телгә алынган мәкаләсендә: «...Миңа үземнең «Яшь йөрәкләр» романы турындагы тәнкыйть мәкаләләремне, әгәр ул чагында Шәһит Әхмәдиев карамагында чыга торган «Хокук вә хәят» журналы булмаса, басарлык урын юк иде», дип күрсәтеп үтә. «Аваз» газетасында редактор булып эшләгән вакытта ук әле Ш. Әхмәдиев революцион көрәштә хезмәт ияләре сафына баскан яшь талантларга иҗади үсәргә ярдәм итә, аларны газетада актив катнашырга, халык интересларын яклап язарга чакыра. 1917 елның җәендә ул вакытта әле яшь шагыйрь Сәйфи Кудашка җибәргән бер хатында менә нәрсә яза: «...Шигырьләрең «Аваз»да бертуктаусыз басылып киләләр. Моннан соң да чын күңелле

шагыйрь, мөхәррирләргә ул халык мәйданы ачыктыр. Җырлагыз, иптәш! Мәңге изелгән эшче, фәкыйрьләрнең керфекләрен күтәреп, йөрәкләрен йомшартыгыз һәм яңадан күңелсез тормыш кайтмасын өчен мәгънәви кораллandырыгыз».

Бөек Октябрь революциясеннән соң Ш. Әхмәдиевнең журналистик эшчәнлеге тагы да киң колач ала. Ул эшче-крестьян арасыннан күтәрелгән яшь журналистларны, элекке интеллигенция арасыннан чыгып Совет власте платформасына баскан талантларны тәрбияләп үстерү юлында күп эшли, матбугатны халыкка җиткерергә, хезмәт ияләрен газета-журналлар эшенә тартырга тырыша. «Эш», «Кызыл Армия», «Кызыл шәрык» газеталарында редактор булып эшләгән елларда кызылармеецларны совет дошманнарына каршы батырларча сугышырга, хезмәт ияләрен сугыш чорында җимерелгән хуҗалыкны торгызуга туплый торган күп санлы чыгышлар ясый, промышленностьта һәм транспортта эшчеләр инициативасы белән үткәрелгән кызыл өмәләрне, завод-фабрика коллективларының игеннәрне урып-җыюда авыл халкына ярдәм итүләрен тәбриклəп мәкаләләр яза. Ул — «Мәгариф» (хәзерге «Совет мәктәбе») журналын оештыручылардан һәм аның беренче редакторларыннан. Журнал битләрендә аның республикада халык мәгарифен дөрес оештыруга, яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүгә, уку-укыту эшләрен юлга салуга юнәлдерелгән мәкаләләре бер-бер артлы чыгып тора. Аның публицистик чыгышлары ил, халык алдында торган мөһим проблемаларга багышланган, мәсьәләне принципиаль югарылыкка күтәреп, һәрьяктән нигезләп язылган була. Әдәби әсәрләре кебек үк, аның ялкынлы публицистикасы да хәзер, безнең көннәрдә дә әһәмиятле һәм татар совет матбугаты тарихында мактаулы урын били.

Шәһит Әхмәдиев озак дәвам иткән каты авырудан 1930 елның 12 августында 42 яшендә үлә һәм Казанда Туганнар зиратында күмелә. Галимҗан Ибраһимов аның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында бик хаклы рәвештә болай дип язды:

«Әхмәдиев татар буржуазиясенә һәм милләтче оешмаларга каршы озак еллар һәм батырларча көрәшүче зур җәмәгать эшлеклесе, сугышчан журналист иде. Әхмәдиев пролетар революциясенең фидакарь работнигы һәм бөек Ленин партиясе сафларында турылыклы көрәшче булды».

Тормыш һаман алга бара. Шәһит Әхмәдиев яшәгән давыллы көрәш еллары да инде шактый еракта калды. Бу вакыт эчендә туган илебез танымаслык үзгәрде, күп алга китте. Кайчандыр патша Россиясенең иң артта калган, иң караңгы крайларыннан саналган иске Казан губернасы тугандаш халыклар семьясында куәтле экономикалы, югары культуралы Социалистик Татарстан республикасы булып чәчәк атты. Кайчандыр рәхимсез җәберләнгән һәм изелгән татар хезмәт ияләре Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә бәхетле тормыш юлына бастылар.

Халкыбыз ирешкән бу тарихи җиңүләрдә Шәһит Әхмәдиевнең дә өлеше бар. Аның әсәрләре безнең белән бергә яши. Аның иҗаты һәм героик көрәш юлы туган илгә, коммунистлар партиясенә турылыклы хезмәт итү үрнәге булып тора.



Габдрахман Таһирҗанов

# ФИРДӘҮСИ ҺӘМ КОЛГАЛИ

*Габдрахман Таһирҗанов Ленинград университеты доценты. Ул университетның көнчыгышны өйрәнү факультетында эшли. Татарстанда туып үсеп, үз туган телен практик яктан да, фәнни яктан да бик тирән белгән шикелле, ул рус теленең дә шундый ук остасы: бу телдә лекцияләр укый, җитди фәнни хезмәтләр яза һәм бастыра. Шушылар өстенә ул күп төрки телләрне, шулай ук гарәп һәм фарсы телләрен дә практик яктан да, фәнни яктан да камил белә. Ул университетта нәкъ менә гарәп һәм фарсы телләрен, фарсы әдәбияты тарихын укытучы галим дә. Габдрахман аганың шушы телләр, шушы әдәбиятлар хакында басылып чыккан күп санлы фәнни хезмәтләре бар. Ул борынгының фарсы телендә иҗат иткән бөек шагыйрьләр иҗаты белән Идел буеның борынгы төрки, борынгы татар шагыйрьләре арасындагы тыгыз һәм тирән бәйләнешләрны да фәнни яктан җитди өйрәнә. Габдрахман ага 1946 елда ук Низами Ганҗәви белән Котбинең «Хосрәү вә Ширин» исемле поэмаларына чагыштырмалы анализ ясаган һәм шул хезмәтен кандидатлык диссертациясе дә итеп яклаган иде. Соңгы елларда исә ул бөек фарсы-таҗик шагыйрьләре турында зур тикшеренү язды. Бу хезмәт хәзер басылып ята һәм аның докторлык диссертациясе итеп яклануы көтелә.*

*Хәзерге көндә Габдрахман ага «Шаһнамә» әсәрен иҗат иткән бөек Фирдәүси турында яңа монографик хезмәт тәмамлап килә. Түбәндә аның бу хезмәтеннән безнең татар әдәбияты тарихына мөнәсәбәте булган бер өзек басыла.*

«Кыйссаи Йосыф» әсәре XIII гасыр башында язылган. Елын-вакытын поэманың бетем өлешендә шагыйрь Колгали үзе ук теркәп калдырган. Дөрес, күчерүчеләрнең ялгыштыруы аркасында, хәзерге көнгә кадәр сакланган кулъязмаларда язылу елы төрлечәрәк күрсәтелә: берсендә һиҗрична 609 (1212) ел, икенчесендә 630 (1233) ел диелсә, өченчеләрендә 635 (1238) ел күрсәтелә. Калганнарындагы даталар шушы еллар арасында күчеп йөри.

Шагыйрь тарафыннан, кызганычка каршы, әсәрнең язылу урыны күрсәтелмәгән. Шуңа карап, аны татарга түгел, көньяктагы төрки халыкларга нисбәт итәргә омтылу да бар. Ләкин без мондый омтылыш нигезле түгел дип карыйбыз. Безнең поэма Болгар шәһәрендә язылган, ул болгар халкы әдәби традицияләренең борынгы бер үрнәге диярга тулы хакыбыз бар. Бердән, бу әсәр үзбәк, төрекмән һәм әзербайҗан халыклары арасында билгеле түгел. Үз заманында Төркиягә барып җиткән булса да, анда

да ул тик шагыйрьләргә генә билгеле булып калган, халык арасында таралмаган: халыкка аңлаешлы булсын өчен, аны төрекчәгә тәрҗемә итәргә мәҗбүр булганнар.

Әсәр Харәземдә язылмады микән, дип гөман кылучылар да очрый. Бусы да нигезле түгел. Әгәр анда язылса, шул замандагы башка әсәрләр кебек ук, ул да Урта Азиядә билгеле булыр иде. Хәлбуки, аның анда билгеле булуын раслаган бер генә тарихи дәлил дә юк. Яки менә Төркия әдәбиятчысы Куприле-задә фикерен алыйк. Ул «Кыйссаи Йосыф»ны, Харәземгә басып кергән монголлардан качып китеп, Идел буена килеп чыккан шагыйрь язгандыр, ди. Әгәр бу гөман дөрес булса, соңрак, Харәзем Алтын Урда дәүләтенә кереп, анда тынычлык урнашкач, шагыйрь үз әсәрен ватанына алып кайткан һәм анда тараткан булыр иде. Эшнең болай булуына шулай ук һичнинди дәлил юк.

Башка җирләрдә билгеле булмавы, борын-борыннан ук тик татар халкы арасында тына киң таралган булуы — шушы хәл үзе — «Кыйссаи Йосыф»ның Болгарда язылган булуына һәм татар халкының үз әдәби мирасы икәненә иң яхшы дәлил. Бу поэманы шәһәрләрнең укымышлы кешеләре генә түгел, авылларның аз белемле кешеләре дә гасырлар буенча укыган, яки укучылардан тыңлаган һәм шуна охшатып бәетләр дә чыгарган.

Йосыф белән Зөләйха турындагы хикәяләр, бик борынгы заманда ук туып, күп гасырлар буена телдән-телгә сөйләнә килгәннәр, ә язучылар бу хикәяләр нигезендә күп санлы проза әсәрләре, шулай ук поэмалар язганнар. Шуңа күрә төрле заманнарның төрле авторлары әсәрләрендә кабатлана торган нәрсәләр дә күп. Ләкин шуның белән бергә аларның һәрберсендә аңа гына хас оригиналь яклар да бәйтак. Бу яктан алганда, Колгалинең «Кыйссаи Йосыф»ына нинди бәя бирергә? Моны ачыклар өчен, беренчедән, Йосыф һәм Зөләйха сюжетына Колгалигә кадәр кайда нинди әсәрләр язылганын билгеләргә, икенчедән, Колгали алардан ни дәрәҗәдә файдаланган да һәм ни дәрәҗәдә үзеннән яңалык өстәгән, өченчедән, Колгалидән соң булган шагыйрьләргә аның әсәре ни дәрәҗәдә йогынты ясаган — әнә шуларны барлап чыгарга кирәк.

Йосыф һәм Зөләйха хакында Сирия шагыйрьләре IV—VI гасырларда ук зур-зур поэмалар язганнар. Бу уңайдан, мәсәлән, Балаи (430 ел), Нарсаи (410—505), Яков Серуги (450—521), Романос (560) кебек шагыйрьләрне искә төшереп үтәргә мөмкин. Соңрак мәйданга чыккан авторлар, «Кыйссасел әнбия» (Пәйгамбәрләр турындагы хикәя) китапларын язганда, шушы авторларның әсәрләреннән күп кенә легендаларны күчергәннәр. Һәр автор, әлгәреләреннән күчерү белән генә чикләнмичә, үзеннән дә эпизодлар өстәгәнгә заманнар үтү белән Йосыф һәм Зөләйха кыйссасы кызыклы вакыйгаларга бик баеган. Ниһаять, IX—X гасырларда яшәгән бөек иран шагыйре Фирдәүси дә «Йосыф һәм Зөләйха» исемле зур поэма язган. Ул да әлек язылган әсәрләрдән нык файдаланган һәм кыйссага үзеннән дә күп нәрсәләр өстәгән.

Без болгар шагыйре Колгалинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын югарыда күрсәтелгән авторларның әсәрләре белән дә, Фирдәүси поэмасы белән дә сүзгә-сүз чагыштырып, тикшереп карадык. Нәтиҗәдә бик әһәмиятле хакыйкать ачылды: безнең шагыйрь үз әсәрен язганда Фирдәүсинең «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасыннан бик нык файдаланган икән.

Фирдәүси үз поэмасының баштагы үндүрт бүлегендә, башка кайбер «Кыйссасел әнбия»лардагы кебек, Якубның тууыннан башлап, Йосыфның төш күргәненәчә булган хәлләрне дә язган. Колгали исә бу өлешне төшереп калдырган. Ул Йосыфның төш күрүеннән башлый. Анда да гел Фирдәүсидән күчереп кенә бармый. Ул әлек язылган әсәрләрдәге һәм Фирдәүси поэмасындагы эпизодларны бер бөтенгә җыя, үзеннән өсти һәм вакыйгаларга баетылган рәвеш кертә. Әлбәттә, сюжетның төп элементлары, легендаларның күпчелеге «Кыйссасел әнбия»ларда да, Фирдәүсидә дә булганга, Колгалинең аларны үз поэмасына кайсы чыганактан алуын әйтүе кыен. Мәгәр тегеләрнең берсендә дә булмыйча, тик Фирдәүси белән Колгалидә генә булган эпизодлар да бар. Мәсәлән:

Йосыф әтисе итәгендә йоклаганда төш күрә. Уянгач, әтисеннән төшен юрауны сорый. Әтисе, патша булырсың, ди. Бу сүз Йосыфның туганнарына ишетелә...

Ул патша булса, безгә гарьлек... Үтерик үзен, яисә еракка олактырыйк, диләр туганнары.

Якуптан сорап, Йосыфны хәйлә белән кырга алып китәләр. Аталары, Йосыфны җавү йөртмәгез, нәүбәтләшеп күтәрегез, Йосыфны яхшы саклагыз, дип кала.

Шәмгун пычак күтәреп Йосыфны үтерергә килә, аны Яһуда коткара...

Йосыфны коега ташлау... Кәрван белән узып баручы сәүдәгәр Малик бине Дагир үзенең Бәшир һәм Бәшрә исемле колларына, чиләк төшереп, коедан су алырга куша. Йосыф чиләккә ябышып коедан чыга... Йосыфның туганнары, качкан җирләреннән чыгып, энеләрен Маликка сатып җибәрәләр...[1]

Бу эпизодлар Фирдәүсинең үзендә ничек тасвир ителгән дә, Колгали ничек аны иркле рәвештә тәрҗемә итеп алган — шуны күзәтү, бәлки, кызыклырак булыр.

Фирдәүсидә:

دگر باره گفت ای گرامی پسر
حذر کن از اینخواب گفتن حذر

Юлга юл тәрҗемәсе болай: «Тагын бер әйтте: и кадерле улым, саклан, бу төшеңне сөйләүдән саклан!»

Колгалидә:

Вәләкин әманәттер, җаным угыл:
Бу дөшеңне һич кемсәя сән әйтмәгел[2].

Кардәшләре Йосыфны сахрага алып китәргә сорагач, Якупның эчке кичерешләрен Фирдәүси мондый юлларда тасвирлый:

پدر چون ز اسباط اینها شنید
دلش روی ایجاب ایشان ندید
تو گفتی همی زد دلش را گمان
که آید بلاها زمان در زمان
دیگر آنکه در خواب خود دیده بود
دلش سخت از آنخواب ترسیده بود

Юлга юл тәрҗемәсе: «Балаларыннан моны ишеткәч, бу сүзләрне кабул итәргә атаның күңеле тартмады. Әйтерсең, кайчандыр бәла киләчәген сизенде, өстәвенә шуны төшендә дә күргән, ул төшеннән дә бик курыккан иде».

Колгалидә:

Ягъкуб, аны ишедүб, сакыйнч санды,
Госса берлә кайгырды бәгъре янды,

---

[1] Бу турыда әсәрнең үзеннән укырга мөмкин: «Борынгы татар әдәбияты». Казан. 1963. 97—101 битләр.

[2] Колгали поэмасы татар халкында төрле күчермәләрдә таралган, ә инде 1839 елдән башлап Казанда күп тапкырлар басылып чыккан. Аларда аермалар да очрый. Бирелә өзекләр 1839 елгы Казан басмасыннан китерелә. Беренче өзек — 5 биттән.

Кәндү бер дөш күрмеш иде, аны анлы,
Йосифа дәстүр вирмәз, кумаз имди [1].

Уллары, Йосыфны алып, кырга чыгып китәр алдыннан Якуп аларга киңәшләр бирә. Мәсәлән, Фирдәүсидән бер строфа:

که دارید هرده مر اورا نگاه
نداریدش اورا پیاده براه
بنوبت کشید ش یکا یك به پشت
نه باریست سنگین نه چیزی درشت

Юлга юл тәрҗемәсе: «Уныгыз да аны саклагыз, юлда аны җәяү йөретмәгез, нәүбәт белән берәм-берәм иңбашыгызга күтәрегез; авыр йөк түгел, каты нәрсә түгел ул».

Колгалидә:

«Әманәтдер: Йосифны саклаясыз,
Нәүбәтләшү инегезгә күтәрәсез,
Җөмләңез игү, тимар сез кыйласыз»,—
Бу сүз илә Йосифны күндерер имди [2].

Кырга, сахрага чыккач, абыйлары Йосыфны үтермәкче булалар. Фирдәүсидә бу хәл түбәндәгечә тасвир ителгән:

چو شمعون چنین دید برپای جست
چو شیر دژم گشت وچون پیل مست
بدان خشم وکین سوی یوسف دوید
یکی خنجر آبگون برکشید
که ازتن سرش راجدائی دهد
روانرا زبند ش رهائی دهد

Юлга юл тәрҗемәсе: «Шәмгун, моны күреп, сикереп торды, ачулы арыслан, котырган фил кебек булды. Шул ачу белән Йосыф янына йөгереп килде, ялтыраган хәнҗәрен чыгарды, башын тәненнән аерырга, җанын тәненнән чыгарырга теләде»,

[1] Шул ук басма. 7 бит.
[2] Шул ук басма. 10 бит.

Колгалидә:

Моны ишедеп, Шәмгун яулык ачигланды,
Пычак тартып, Йосиф үзрә хәзер кәлде,
Пычак илә үлтермәгә хәмлә кыйлды...[1]

Йосыфны коега ташлар алдыннан туганнары күлмәген салдырып алалар. Йосыфның ялваруы Фирдәүсидә болай бирелгән:

چین گفت زنهار پیرا هنم
بمن بحش و عریان مگردان تنم
کسی کو بمیرد کنند ش کفن
کفن گیر بر من تواین پیرهن

Юлга юл тәрҗемәсе: «Әйтте: зинһар, күлмәкне үземә калдырыгыз, тәнемне ялангач итмәгез. Берәү үлсә, аңарга кәфен ясыйлар, бу күлмәкне миңа кәфен итегез».
Колгалидә:

Йосиф әйдер: кәрендәшләр боны кыйлмаң...
Бәнем тәнем горъян кыйлып, туным суймаң...
Бу көн үлсәм, кани бәңа кәфен кирәк,
Инди бәңа кәфен улсун ушбу куңләк[2].

Фирдәүси белән Колгали поэмаларындагы сүзгә сүз диярлек туры килгән мондый строфаларны тагын байтак китерергә мөмкин булыр иде. Безнеңчә, Колгалинең Фирдәүси поэмасыннан файдаланган булуын дәлилләр өчен, китерелгән кадәресе дә җитсә кирәк. Кабат искәртик: югарыда китерелгән, шулай ук монда китерелмәгән, ләкин эчтәлекләре белән югарыдагыларга турыдан-туры бәйләнгән строфаларда тасвир ителгән вакыйгалар тик Фирдәүси белән Колгалидә генә бар. Аларга кадәр язылган «Кыйссалар»да бу эпизодлар юк.

Һәр ике шагыйрь үз әсәрләренең төп сюжетларын, андагы легендаларны Фирдәүсигә кадәр үк, тагын да борынгырак заманнарда чыккан «Кыйссасел әнбия»лардан алып төзегәннәр. Аерма шунда: Фирдәүси аларны бик тәфсилле язган, Колгали исә кыскартып алган. Шулай да Фирдәүсидә булган легендаларның байтагысы Колгалидә юк, һәм, киресенчә, Колгалидә булганнарның байтагысы Фирдәүсидә юк. Бу факт үзе Колгали нигездә Фирдәүси әсәренә таянса да, гел анар гына ияреп бармаганын раслый, Фирдәүсигә кадәр язылган «Кыйссасел әнбия»лардан да аның мөстәкыйль, үзенчә файдаланган булуын күрсәтә.

Кайбер легендаларны Колгали, бүтән чыганаклардан алса да, үз тасвирының максатларына карата киңәйтеп тә җибәрә. Мәсәлән, Йосыфның Нил елгасына кереп юынуы турындагы легенданы ул нәкъ шулай эшләгән: Йосиф суга керү белән андагы терекләкләр, балыклар аңа хезмәт күрсәтергә керешәләр. Балыклар патшасы Йосыфка аеруча кече күңеллелек белән булыша. Фирдәүси балыклар патшасын сыйфатлаганда, ул Юныс пәйгамбәрне йоткан, дию белән чикләнә. Колгали вакыйгага җанлылык кертергә тырыша: аның тасвирында Йосиф балыклар патшасының аркасында басып юына, Йосыфтан патша: «Балам юк. Дога кыйл!» — дип үтенә. Йосиф дога кыла, соңрак балыклар патшасының ике баласы була һ. б.

[1] Шунда ук. 12 бит.
[2] Шунда ук. 16 бит.

Колгали «Кыйссаи Йосыф»ында «Кыйссасел әнбия»ларның берсендә дә булмаган легендалар да бар. Мәсәлән, шундый легендалар:

Йосыфны күрер өчен коега төшеп утырган габид.

Малик бине Дагирнең төш күрүе, Мисырга барышлый төрле шәһәрләргә кереп, андагы халыкларны мөселман диненә күчерүе, бер пәри шәһәренә керүе.

Йосыфны сатып алырга теләгән Бинт Табиюн исемле кызның иман китереп, малын дәрвишләргә өләшеп, калган гомерен саумагада (монастырь) кичерүе.

Зөләйханың яшь вакыты. Төшендә өч тапкыр Йосыфны күреп, Мисыр газизенә иргә чыгуы.

Йосыфның гөнаһсыз икәненә гуаһлык биргән бишектәге баланы соңыннан, үсеп житкәч, Йосыфның йортсыз-җирсез гарип хәлендә очратуы һәм аның үзенең министры итүе.

Бу легендалар «Кыйссасел әнбия»ларда да, «Тәфсир»ләрдә дә, Табари тарихында да юк.

Уникенче гасырның икенче яртысында Мөхәммәт Җәүәйри дигән кеше фарсыча проза белән «Кыйссасел әнбия вә Сперемелүк» исемле әсәр язган. Бу китап безгә кадәр килеп житкән. Фирдәүсидә һәм Колгалидә булган кайбер легендаларның кыскача яки башка төрлерәк язылганы бу әсәрдә бар. Ләкин монда да Зөләйханың яшь чагы турында бернәрсә дә язылмаган. Димәк, Колгали үз әсәренең ул өлешен чыганагы хәзергә безгә мәгълүм булмаган легендалардан алып язган дияргә туры килә.

Гарәпчә, фарсыча һәм төркичә язылган «Кыйссасел әнбия»ларда Йосыфны пәйгамбәр итеп күрсәтүгә зур әһәмият бирелгән, шуңа күрә аларда һәртөрле могжизаларны тасвирлау күп урын ала. Фирдәүси белән Колгали поэмаларында да байтак кына могжизалар күрсәтелә. Шулай да бу ике шагыйрь искитмәле күренешләрдән хорафатчыл (мистик) идея чыгарудан бигрәк, гыйбрәтле сурәт күрсәтергә омтылалар, укучының хисен, фикерен кузгатырлык үзенчәлекләргә басым ясыйлар. Әмма бу өлкәдә ике шагыйрь арасында һәрберсенең үзенә генә хас үзенчәлекләре дә күренеп тора. Мәсәлән, Фирдәүси үз поэмасында төрле мөнәсәбәтләр белән гаскәри парадларны, анда катнашкан гаскәри бүлекләрне тасвирлауга әһәмият бирә. «Шаһнамә»дагы кебек, арага хикмәтле сүзләр кыстыра. Колгали исә «Кыйссаи Йосыф»ына күп кенә нәрсәләрне фольклордан, халык иҗатыннан алып кертә. Ул түбән катлау, базар әһелләренең рухи халәтен гәүдәләндергән эпизодларга да урын бирә. Мәсәлән, Малик Йосыфны Мисырга алып кайткач, халык арасында Йосыфның искиткеч матур кеше булуы турында сүз тарала. Аны күрергә телиләр. Малик моңардан файда итеп калырга уйлый, ул Йосыфны акча түләгән кешеләргә генә күрсәтә. Халвәчеләр, икмәк пешерүчеләр арасыннан Йосыфны сатып ук алырга теләүчеләр дә чыга. Хәтта карчыкларда Йосыфны сатып ук алырга теләүчеләр дә чыга. Хәтта карчыкларда да өмет туа:

> Бер карчык бер киләп йип алып килде,
> Йосыфны алмаклыкка касд кылды,—

ди шагыйрь, карчыкның Йосыфны бер киләп җепкә алмашып алырга хыялланyын тасвирлап, комик элемент та кертә.

Бу күренешләрне Колгали халык тормышыннан, халыкның үз теленнән сөйләнгән вакыйгалардан алып керткән. Болар тик аның әсәрендә генә бар, башка авторларның берсендә дә юк.

Йосыф тугач, Якуп, үз улына сөт күп булсын дип, кол хатынның Йосыф белән бер вакыттарак туган баласын ятлар кулына сатып җибәрә дә, Йосыфка баласыз калган кол хатынның сөтен имездертә. Якупның бу кешелексезлеге җәзасыз калмый; тиздән аның үз баласы кол итеп сатыла, теге хатын үз баласы белән күп еллар күрешмәгән кебек, Якупка да үз Йосыфын күрү насыйп булмый. Бу мотивны да без тик Колгали әсәрендә генә күрәбез, ул борынгы «Кыйссасел әнбия»ларда да, Фирдәүсидә дә юк. Колгали аны да халык иҗаты мотивларыннан алган булырга тиеш.

Тик Колгалидә генә булган эпизодларның кайберләре тормышта шагыйрьнең фәкать үзе күргән, үзе күзәткән хәлләрдән генә алынган булсалар кирәк. Алар бик әһәмиятлеләр. Сәнгать ягыннан да, тарихи яктан да бик җитди игътибарга лаеклы өзекләр. Аларны да аерым билгеләп үтик. Әсәрнең «Җиденче фасыл»ында Йосыфка

гашыйк булган Зөләйха үз серен Даясенә (сөт анасына) сөйли. Дая Зөләйхага бик матур сарай салдырырга, анда искиткеч зиннәтле тәхет залы төзетергә, соңыннан залга, тәхеттә утырып, Йосыфны чакыртырга киңәш бирә. Мондый зал эшләтү турында «Кыйсасел әнбия»ларда да, Фирдәүсидә дә язылган. Ләкин алар тасвиры белән бер-берләреннән бик нык аерыла. Тегеләр сарайны түшәме дә, идәне дә, стеналары да — көзгедән; Йосыф, Зөләйхага туры карамыйча, йөзен-күзен кая гына борса да, һәр җирдә Зөләйха шәүләсен күреп торырга мәҗбүр, диләр. Колгали исә залның архитектура сәнгатен җентекләп тасвирлауга зур игътибар биргән: залда колонналар, һәртөрле сәнгать сыннары; ул боларны безнең Идел-Чулман яклары, Болгар иле табигатеннән, тормышыннан алган күренешләр белән баетып җибәргән. Бу урында баштанаяк аның үз оригиналь иҗаты булган кайбер строфаларны китереп үтик. Колгали «Колонна» дигән сүзне дә биредә, әлбәттә, хәзер без куллана торган итальянча «колонна» дип алмаган, чын төркичә «терәк» дип алган. Залның:

Бернәчә терәкләре бәллүр улсун,
Бернәчәсе (аның) дөрре-мәрҗән улсун,
Ул терәк төбендә үкүз улсын,
Ул үкүзләр көмештән улсун имди;
Саф кызыл алтыннан ат әйләсен...[1]

Колонналар төбендә алтыннан һәм көмештән коелган үгез, ат сыннары, фонда — стеналарда урман, агач, киек кош сурәтләре — болар барысы да тик Колгалидә генә бар, тик аның гына оригиналь иҗаты. Шагыйрь зиннәтле залны да, бәлки, болгар ханнарының сарайларыннан күчергеч алып тасвирлагандыр, ат, үгез, киек кошлар, урман, куаклар дөньясын да безнең бу як табигатеннән эсәрләнеп иҗат иткәндер, дип фараз кылырга нигез бар.

«Кыйсса»да Колгалинең сәнгатькә мөнәсәбәтен аңлатырдай оригиналь эпизодлар да бар. Мәсәлән, «Унөченче фасыл»да Йосыф туганнарының ачлык елны Мисырга азык алырга килүләре тасвир ителә. Йосыфны туганнары танымыйлар, ул исәндер дип бөтенләй уйламыйлар да. Йосыф туганнарын сый мәҗлесенә чакырырга була. Махсус сарай салдырта, кунак залының стеналарын рәсемнәр белән бизәтә. Рәсемнәрдә Йосыфны туганнары тарафыннан коллыкка сатылу күренешләре гәүдәләндерелгән була. Йосыфның кунак итеп чакырылган абыйлары, аш өстәле янына утыргач та, әлеге рәсемнәрне күреп, чиксез куркуга төшәләр, ашка куллары бармый, елый башлыйлар. Колгалинең бу тасвирында сәнгать гаделлеге кеше күңелендәге иң тирән серләрне дә ача ала дигән идея гәүдәләнә булырга тиеш. Бу тасвир да Колгалигә кадәр чыккан «Кыйссасел әнбия»ларда да, шулай ук Фирдәүсидә дә юк. Бу да Колгалинең асыл үз сәнгате.

Колгалинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре үзеннән соңгы заманнарда үсеп киткән татар әдәбиятына бик тирән тәэсир ясаган. Әсәр халык арасында киң таралган булганга һәм аны олысы-кечесе бердәй яратып укыганга, аның шигъри үзенчәлекләрен һәр буын кечкенәдән үк үз иткән, күңел хәзинәсендә саклаган, шуңа күрә аның традицияләре һәр яңа буын мәйданга чыгарган шагыйрьләр иҗатында үзенчә үстерелгән.

Колгали әсәре шулай ук башка төрки халыклар әдәбиятына да житди тәэсир иткән. Мәсәлән, Колгалидән соңрак, XIII гасырның икенче яртысында яшәгән төрек шагыйре Шәяд Хәмзә «Кыйссаи Йосыф»ны «Йосыф вә Зөләйха» исеме белән төрекчәгә тәрҗемә иткән. Без Фирдәүси, Колгали һәм Хәмзә әсәрләрен шулай ук бергә китереп чагыштырып чыктык. Колгали әсәрен тәрҗемә иткәндә Хәмзә Фирдәүси әсәрен дә күз алдында тоткан. Колгали ташлап калдырган кайбер кисәкләрне Хәмзә, Фирдәүсидән алып, үз тәрҗемәсенә кертеп, өстәгән. Шул ук XIII гасырда Мәхмүд исемле Кырым шагыйре Колгали әсәренең кыпчакча вариантын язган булган, аны Хәлил углы Гали төрекчәгә тәрҗемә иткән.

Тагы да соңрак, XIII гасырның ахырында, икенче төрек шагыйре Сули Факых, Колгали һәм Хәмзә әсәрләреннән файдаланып, шулай ук «Йосыф-Зөләйха» поэмасын язган, 1491 елда өченче төрек шагыйре Хәмди Чәләбә да шул ук исемдә яңа әсәр иҗат иткән. Гомумән, Колгалидән соң бу тема күпләр тарафыннан яктыртылган.

---

[1] Шунда ук. 60 бит,

Мәсәлән, XV гасыр фарсы-таҗик шагыйре Җами, XV гасыр үзбәк шагыйре Дүрбек, XVI гасыр әзербәйҗан шагыйре Физули шул ук бер исемдә зур-зур поэмалар иҗат иткәннәр.

Татар әдәбиятында Колгали поэзиясенең телдән төшкән чагын әйтүе кыен. Соңгы 2—3 гасыр эчендә дә аның исеме татар поэзиясе тарихының үзәгендә булып килде. XVIII гасыр ахырында һәм XIX гасыр башында яшәгән татар шагыйре Г. Утыз-Имәни «Кыйссаи Иосыф» кулъязмаларының җыйнама критик текстын төзеде. XIX гасырның беренче яртысында иҗат иткән Г. Кандалый лирик әсәрләрендә Иосыф белән Зөләйханы үзенең яраткан геройларыннан итте, XX гасырда Колгали әсәре Г. Тукай телендә булды, совет заманында шушы поэма нигезендә К. Әмири «Иосыф-Зөләйха» исемле трагедия язды. Бөек Ватан сугышы елларында Колгали традицияләре Моабит төрмәсеннән яңгырадылар. Борынгы шагыйрь әсәрендә баласын югалту хәсрәтеннән елый-елый сукырайган Якуп тасвир ителә. Менә Бәшир Иосыфтан хәбәр китерә, сүзенең дөреслегенә дәлил итеп, Иосыфтан салдырып алган күлмәк алып кайта. Сукырайган Якупка —

> Сәлам вирде Бәшир, күнләкне сону вирде,
> Йөзенә сөрде, ике күзе ачылыр имди,
> Күзен ачты Исраил...[1]

Муса Җәлилнең «Ана бәйрәме» шигырендә Ватан өчен сугышларда өч улыннан беренчесе һәм икенчесе һәлак булгач, ананың хәсрәттән сукыраюы, ләкин өченче улы илгә җиңү алып кайткач, мондый хәл булуы тасвир ителә:

> Калдырсам да күмеп еракта
> Абыйларның батыр гәүдәсен,
> Алып кайттым данлы байракта
> Каннарының алсу шәүләсен.
> Ана алды алсу байракны,
> Күзен сөртте, күзе ачылды...

Шагыйрь сүзе, гасырлар кичеп, яңа заман җырчылары телендә яңа мәгънә ала. Аның үлемсезлегенә шушы үзе тагын бер дәлил.

---

[1] Шунда ук. 115 бит.



Зәки Әхмәтҗанов

# МӘҢГЕ ШИҢМӘС ЧӘЧӘКЛӘР

Латвиянең Лудза шәһәре паркында тәбәнәк кенә ак таш коймә белән әйләндереп алынган туганнар каберлеге бар. Аның өстенә тимер-бетоннан һәм мәрмәрдән эшләнгән зур, мәһабәт һәйкәл куелган.

Бөек Ватан сугышы үткән юлларда андый һәйкәлләрне күп очратырга була. Шулай да карт агачлар күләгәсендәге бу һәйкәл башкалардан аерылып тора. Аның алгы ягындагы мәрмәр тактага алтын хәрефләр белән: «Геройларга мәңгелек дан» һәм «Советлар Союзы Геройларына» дигән сүзләр язылган. Ике ягында да батырларча һәлак булган ун герой сугышчының исемнәре чокылган. Менә ул исемнәр: Хәким Әхмәтгалин, Петр Сыроежкин, Яков Шакуров, Федор Ашмаров, Чутак Уразов, Тукумбай Тайгараев, Тишибай Карабаев, Урун Абдуллаев, Матвей Чернов, Михаил Шкураков.

Бу һәйкәлне беренче тапкыр күргән һәр кешедә: «Монда төрле җирдә һәлак булган Советлар Союзы Геройлары күмелгән икән»,— дигән уй туа.

Чынлыкта ул алай түгел. Анда күмелгән ун баһадир, барысы да бер үк сугыш операциясе вакытында соңгы сулышларына кадәр батырларча сугышканнар. Алар йөрәкләренең соңгы тибешенә кадәр күп санлы фашист илбасарларына каршы торып, туган илгә, хәрби антка турылыклы булып, геройларча һәлак булганнар. СССР Верховный Советы Президиумы 1945 елның 24 мартында аларга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирү турында Указ чыгарган...

Халкыбыз безнең хәзерге бәхетле тормышыбыз өчен үзләрен корбан иткән батыр улларын һәм кызларын бервакытта да онытмый.

Лудза паркындагы геройлар кабереннән дә кеше өзелеп тормый. Һәйкәл янында һәрвакыт чәчәк бәйләмнәре күрәсең. Аның яныннан үткән бар кеше азга гына булса да тукталып кала. Пионерлар салют белән, хәрбиләр честь биреп, ә өлкән яшьтәгеләр баш киемнәрен кулларына тотып үтәләр.

Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен тормышларын да кызганмаган бу геройлар кемнәр соң алар?

Легендар Брест крепосте оборонасын оештыручыларның берсе, Советлар Союзы Герое Петр Михайлович Гаврилов Казанның 74 нче мәктәп укучылары белән очрашуда ул каһарманнарның берсе — Яков Савельевич Шәкуровның татар кешесе булуы турында әйткән иде.

Шулай булгач, ни өчен аның исеме бүгенгә кадәр бездә билгеле түгел? Бу мактаулы исем кайда һәм нинди батырлык күрсәткән өчен бирелгән?

Әнә шул сорауларга җавап табу һәм аның батырлыгы турында халкыбызга сөйләү теләге мине СССР Оборона министрлыгы архивына алып килде.

* * *

Менә аның бүләкләү кәгазе.

Әйе, архивтагы бөтен документларда да аның татар милләтеннән булуы әйтелгән. Ни өчен Яков Савельевич булуын, кайдан икәнлеген соңрак, Казанга кайткач ачыкларга калдырып, батырлык эпизодларын, гомумән ул үткән сугыш юлын өйрәнергә керештем. Кулда 219 нчы укчы дивизиянең 375 нче укчы полкы тарихы, сугыш юлы турында сөйләүче, инде шактый саргаеп өлгергән калын-калын томнар. Аларны актара башлагач, үзеңне янәдән шул утлы елларга, алгы сызыктагы окопларга кире кайткандай итеп сизәсең. Чөнки анда саклана торган кайбер кәгазьләр әле дә ут чәчеп торалар шикелле.

Барыннан да элек, кызыл ледерин тышлы калын альбом күзгә ташлана. Ул Берлинда эшләнгән. Бәлки аны немец солдаты Россиядә үзләре эшләгән ерткычлыклар — җимерелгән шәһәрләр, яндырылган авыллар, совет кешеләре асылган дар агачлары рәсемнәрен җыйнар өчен алып килгәндер. Ә безнең сугышчылар ул альбомга әнә шул явызлыкларны эшләгән фашистларны юк итүдә аеруча зур батырлыклар күрсәткән иптәшләренең геройлык эпизодларын язып, исемнәрен мәңгеләштергәннәр. Кайсыдыр һәвәскәр солдат, сугышлар тынып торган арада булса кирәк, бронзадан кисеп «Книга Героев» дигән сүзләрне һәм Алтын йолдыз сурәтен беркетеп куйган. Өске уң як читенә «Мәңге сакларга» дип язылган.

Альбомның тышын ачу белән, гаҗәеп әйбер күрәсең. Тышлыкның эчке ягына алсу лента белән ун сабак кыр чәчәге беркетелгән.

Хәзер инде табигый төсләрен дә югалткан, орынгач ук уалырга торучан бу чәчәкләр 1944 елның июль аенда шул ун герой һәлак булган үлемсез калкулыктан өзелгән. Мәңге шиңмәс чәчәкләр алар!

Бу чәчәкле альбом тулысы белән Лудза паркында күмелгән геройларга багышланган. «Алар кебек ук геройлар булыйк» дигән баш астында геройлар взводының бары ике тәүлек эчендә күрсәткән батырлыклары һәм тапкырлыклары турында сөйләнелә. Һәр сугышчыга багышланган аерым язмалар да бар. Бу язмаларда аларның Советлар Союзы Герое исеменә чыннан да лаеклы булуларын тасвирлый торган эпизодлар саналган.

...1944 елның эссе июль көннәре. Чигенүче дошманны эзәрлекләп шактый талчыккан 375 нче укчы полк сугышчылары берничә көнгә ялга туктадылар. Һәр солдат үз эшенә кереште. Кайсы тузлы тир белән каткан киемен юа, кайсы полк мастерскоенда аяк киемнәрен төзәтә. Кайберләре корал чистарта. Кыскасы, һәр солдат, һәр офицер яңа һөҗүмгә әзерләнә.

Иртәгесен Шәкуров, гадәттәгедән иртәрәк уянып, озак кына уйланып ятты. Ерак Себердә калган нәни кызлары — алты яшьлек Фәүзия белән өч яшьлек Сания бу юлы да аның күз алдында уйнап йөрделәр... Дөрес, әле сагынырга иртәрәк тә кебек. Чөнки семьясыннан аерылганга әле күптән түгел гена ике ай тулды. Әйе, ул Днепр кичкәндә алган авыр ярадан соң, алты ай буена өендә булды. Азрак савыга башлагач, хәрби предприятиедә эшләде. Ләкин солдат йөрәге монда үз урынын таба алмады. Яралары төзәлгәч үк ул, үзе теләп, янәдән фронтка, керәшнең алгы сызыгына юл тотты...

Һәм менә өзлексез һөҗүм сугышларында ике ай үтеп тә китте.

Шәкуров тын гына киенеп землянкадан чыкты. Еракта тагы урман артыннан әле яртылаш кына күтәрелгән алсу кояш нурлары астында чык бөртекләре ялтырый. Ул,

гомерендә беренче тапкыр җәйгә таң атканын күргәндәй, бөтен тирә-якка сокланып карады. Аннан соң, гимнастерка кесәсеннән алып, хатыны һәм кызлары белән төшкән рәсемгә карап торды да берничә көн элек алган өчпочмаклы хатны яңадан укырга кереште. Ләкин укып бетерә алмады, арттан: «Нәрсә, якташ, таң каршылыйбызмы?» — дигән тавыш ишетелде.

Соңгы сугыш вакытында һәлак булган взвод командиры лейтенант Бобровскийны алыштырган Уфа егете өлкән сержант Хәким Әхмәтгалин тавышы иде бу.

— Әйе, якташ,— диде Шәкүров, кояшка таба күрсәтеп,— сугыш вакытында да нинди матур таңнар ата икән, моңарчы ничек күрелмәгәндер.

— Күрмәссең дә шул. Таң бит ул көнчыгышта, кояш чыгышында туа. Ә без һаман көнбатышка, Берлин ягына карыйбыз.

Туган якларны искә төшереп, бик озак сөйләшеп утырдылар алар бу иртәдә.

*
* *

10 июньдә полк яңадан һөҗүмгә күчте. Офицер Буримов батальонына немецларның алдан ук яхшы ныгытылган оборонасын өзү бурычы куелды. Һәрвакыттагыча, беренче булып артиллеристлар «эшкә» кереште. Һәр минутта атакага күтәрелергә әзер торучы автоматчылар окоплары өстеннән, иртәнге тынлыкны ярып, дошман оборонасы сызыгына снарядлар оча башлады. Фашистларның алгы позициясе төтен һәм тузан белән капланды. Немецлар «кара үлем» дип йөрткән кызыл йолдызлы «Илюшиннар» да алар өстенә бомба коеп киттеләр.

Артиллерия атышы кинәт башланган кебек үк кинәт туктап та калды. Шуны гына көткәндәй, позиция өстенә яшел ракета күтәрелде. Ул сүнәргә дә өлгермәде, автомат тоткан уң кулын өскә күтәреп, окоптан рота командиры өлкән лейтенант Павел Новайдарский сикереп чыкты.

— Ватан өчен, алга!

Бу команданы күптән көтеп торган сугышчылар, окоплардан чыгып, командирлары артыннан йөгерделәр.

Өлкән сержант Хәким Әхмәтгалин автоматчылары беренче булып миналы нейтраль зонаны үттеләр. Пулялар сызгыруы астында үрмәләп, Бруно спирале һәм күп катлы чәнечкеле тимер чыбыклар белән уралган окопларга якын ук килеп җиттеләр.

Автоматчылар немецлар траншеясына бәреп керде, батальонның уң флангысын җиргә ятарга мәҗбүр иткән ике пулемет оясы, шуннан аткан фашистлар белән бергә, юк ителде. Шәкүров бу бәрелештә өч немец солдатын дөмектерде. Батальон яңадан атакага күтәрелде.

Полк дошман оборонасын өзеп, чигенүче дошманны эзәрлекләп, туктаусыз алга барды.

Безнең гаскәрләрнең алга баруын туктату өчен немецлар ашыгыч чаралар күрә башладылар. Полк разведчиклары аларның Даугавпилс — Рига участогында яңа оборона сызыгы әзерләүләре, чигенүче танклар һәм артиллериянең дә шунда тупланыуы турында хәбәр итеп тордылар. Бу «күчену»не каплап тору өчен, үзйөрешле орудиеләр белән көчәйтелгән яңа частьлар килүе дә билгеле булыр.

Ләкин немецларның зур өметләр баглаган бу оборонасы да озакка чыдамады. Совет Армиясенең көчле удары гитлерчыларны бу окоплардан да куып чыгарды. Алар тагын да артка, Литва, Латвия җиренә чигенә башладылар.

Латвиянең көнчыгыш өлешендәге күп санда күлләр, вак урманнар һәм сазлыклар һөҗүм сугышлары алып баруны кыенлаштырды. Ләкин сугышның теләсә нинди авырлыкларына күнеккән, аның окопларында чыныккан совет солдаты өчен болар гына киртә була алмадылар. 375 нче укчы полк акрынлап Рундене дигән латыш шәһәрчегенә якынлашты. Шул шәһәрчек аша үтә торган шоссе юлы белән генә Лудза, Зилупе шәһәрләренә, аннан соң Даугавпилс һәм Ригага үтәргә мөмкин иде. Рундене га 25 чакрымнар ара калгач, укчылар, немецларның каты каршылыгына очрап, оборонага туктарга мәҗбүр булдылар. Немецлар командованиесе бу участокны ныгытуга бик зур игътибар бирә. Чөнки фронт белән тылны бәйләүче бу бердәнбер юлны кулдан ычкындыру алар өчен һәлакәт белән бер иде. Шуңа күрә алар чигенүче бөтен сугыш

техникасын — танкларны, орудиеләрне, башка кирәк-яракларны шул юл аша үткәреп, яңа оборонага урнаштырырга ашыктылар. Җәяүле разведка һәм һавадан ясалган күзәтүләр юлның танклар, машиналар, обоз белән һәрвакыт тулып торуын күрсәтте. Ләкин һава шартларының начар булуы авиация кулланырга мөмкинлек бирми иде. Җәяүле гаскәрләрнең алга таба тиз хәрәкәт итүе һәм юлларның начар булуы аркасында артта калган артиллерия белән дә 15—20 чакрымнан әллә ни зыян китереп булмый. Нишләргә?

Полк көне буена бары берничә йөз метр алга үтте. Сугышчыларны тагын да атакага күтәреп карарга мы? Юк. Болай эшләү артык югалтулардан башка берни дә бирмәячәк...

Үзенең күзәтү пунктында әнә шул турыда уйланып әрле-бирле йөргәндә полк командиры подполковник Бочаров янына кара-зәңгәр комбинезон кигән генерал килеп керде.

— Барысы да аңлашыла, иптәш Хәрби Совет члены, безгә беренче чиратта бу юлны капларга кирәк,— диде полк командиры, монда килеп чыккан хәл турында сөйләшеп алгач.

— Бик дөрес уйлыйсыз, иптәш подполковник, ул юллар аша хәрәкәтне туктатмыйча торып, һөҗүмне дәвам итү, алга бару мөмкин түгел. Ә ничек аны туктатырга? Менә шуны тизрәк хәл итәргә иде.

— Минемчә, иптәш генерал, бердәнбер дөрес юл — бер группа сугышчыларны рация белән дошманның тылына җибәрү,— дип, полк командиры снаряд гильзасыннан ямьшәйтеп ясалган сукыр лампадан яртылаш коелган папиросын кабызды,— алар мәгълүматлар алып кайткач, колонналарны артиллерия утына тотарга.

Йөзләрчә кешеләрнең язмышына җаваплы бу ике сугышчан командир, авыр хәлдән чыгуның башка мөмкинлекләрен эзләп, бик озак баш ваттылар. Ләкин таба алмадылар.

— Әйе, подполковник, башка юл юк,— дип, генерал урыныннан торды.

...Озак та үтмәде, полк командиры землянкасына өлкән лейтенант Новайдарский белән бергә кыска итеп кыркылган кап-кара чәчле, киң күкрәкле өлкән сержант Әхмәтгалин килеп керде. Менә шунда Әхмәтгалин взводына: «Дошман тылына үтеп керергә, юлдан дошманның һичнинди транспортын үткәрмәскә!» дигән сугышчан бурыч куелды.

— Яшерен-батырын түгел, иптәш Әхмәтгалин, бу бурыч чиктән тыш авыр һәм катлаулы, үзегез белән шуны аңлаган кешеләрне генә алырга кирәк булыр,— дип, генерал сынаулы караш белән өлкән сержантка борылды.

— Аңлыйм, иптәш генерал, бөтенесе дә ачык, безнең әйләнеп кайтмавыбыз да бик мөмкин,— диде Әхмәтгалин,— Шикләнмәгез, тормышыбыз хакына булса да приказны үтәрбез.

...Караңгы төшү белән, дошман тылына китәсе группа аерым блиндажга җыелды. Взвод командиры группа алдына куелган бурычның әһәмияте, походның планы турында җентекләп сөйләде. Юл өстендәге күлләр һәм миналар куелган сазлык аша үтүнең аеруча авыр булачагы гына азрак борчыды аларны. Күп тә үтмәде, сигез милләт вәкилләреннән торган унбер сугышчы, мөмкин кадәр күбрәк патрон һәм гранаталар алып, төн караңгылыгына кереп югалдылар.

* * *

Группа, немецларның алгы сызыктагы траншеялары алдында сузылган төрле-төрле буш консерв банкалары, снаряд гильзалары һәм калай кисәкләре эленгән чәнечкеле чыбыкларны, аннан соң оборона сызыгын тавышсыз-тынсыз гына үтеп, Савино авылы ягына юл тотты. Таңны алар урманда каршыладылар. Яктыра башлагач, урман кырыена чыгып, чабылмаган үлән һәм куакларга яшеренеп, еракта күренеп торучы Рундене шәһәрчегенең чиркәү гөмбәзләренә таба юнәлделәр. Озакламый, чигенүче колонналар белән тулган юл — Рунденега бара торган юл күренде. Бу юл гүләп торган умарта оясына охшаган иде. Гитлерчылар, һава шартларының начар булуы аркасында безнең авиациянең килә алмавыннан файдаланып, мөмкин кадәр гаскәрләрен, техникасын чыгарып калырга тырышалар. Сугыш кирәк-яраклары төягән төрле марка-

лы машиналар, орудиеләр таккан тракторлар һәм танкларның мотор тавышы тәүлекләр буенча туктамый. Алар тирәсендә баштанаяк пычранып беткән, чигенүдән талчыккан солдатлар мәш килә. Тирә-якта аларның карлыккан тавышлары, офицерларның сүгенүләре ишетелеп тора.

Эфир дулкыннары разведчиклар мәгълүматын безнең командованиегә җиткергәч озак та үтмәде, авыр снарядлар колонналар тыгылган юлның уртасында ук шартлый башлады. Эреле-ваклы җир кисәкләре белән бергә, төрле зурлыктагы металл ватыклары күккә күтәрелде. Тирә-якта ут капкан машиналардан чыккан төтен җәелде. Дары һәм бензин исе таралды.

— Бу биеклектән беркая да китмибез, егетләр,— диде Әхмәтгалин беренче уңыштан шатланып киткән иптәшләренә.— Ике якка ике пулемет куярга, түгәрәк оборона ясап урнашырга кирәк.

Ул арада немецлар янган, җимерелгән машиналардан юлны чистартып, снарядлар ярылудан хасил булган чокырларны күмеп өлгерделәр. Ләкин колонналар кузгалу белән, тагын снарядлар ява башлады.

Немецлар, көтелмәгән бу залпларның корректировка буенча атылуына төшенделәр, билгеле. Шартлаулар сирәгәю белән, бер взвод автоматчылар, аяк өстендә атаата, тирә-яктагы куаклыкларга атладылар. Биеклек итәгендәге һәр метр җирне тикшереп берни дә таба алмагач, егерме кешедән торган бер төркем фашистлар, башкалардан аерылып, разведчиклар урнашкан калкулыкка менә башлады. Үзләренең туктаусыз атуына каршы бернинди дә җавап ишетмәгәч, гитлерчылар, барысы да бергә җыелып, нидер сөйләшеп алдылар. Аннан соң, бөтен автоматларыннан көчле ут ачып, тауның сыртына йөгерделәр. Бары йөз метрлар ара калгач, алар өстенә разведчиклар бердәм ут яудырдылар. Бу көтелмәгән хәлдән югалып калган фашистларның берсе дә кире кайтмады.

Тынлык озакка бармады. Калкулык өстендә мина һәм снарядлар шартларга кереште. Шуңа ышыкланып, бер батальон солдат, калкулыкны ике яктан ярымбоҗрага алып, тагын өскә үрмәләде. Тиздән дәһшәтле, тигезсез сугыш башланды. Безнең батыр разведчиклар урнашкан калкулык өсте дары төтене һәм тузанга төренде.

Сугышчыларның хәле минут саен кискенләшә барды. Немецлар, бернинди югалтулар белән дә исәпләшмичә, разведчикларның окопларына таба шуышуларын дәвам иттеләр.

Үзләре биеклеккә урнашканнан бирле шоссеган бер машина да үтә алмавын күргәч, безнең батырларга көч өсталгәндәй булган иде, ләкин күп санлы гитлерчыларның төрле юнәлештән ясап торган атакаларына рух күтәренкелеге белән генә каршы тору мөмкин түгел иде. Патрон һәм гранаталарның минут саен кими баруы да хәлне катлауландырды. Алар дошманны мөмкин кадәр үзләренә якын җибәреп, пуляның бушка китмәвенә ышанып кына ата башладылар.

Тиз генә ярдәм килүгә ышаныч булмаган кебек, моннан чигенү мөмкинлеге дә бөтенләйгә киселде. Биеклек фашистлар боҗрасы эчендә калды.

* * *

Бары унбер кешедән торган кыюлар взводы кичкә кадәр немецларның бик күп атакаларын кире какты. Йөзләрчә солдатларын кырды. Ләкин күп югалтулардан ярсыган гитлерчылар һаман да өскә үрмәләүләрен дәвам иттеләр.

...Шәкүров үз окобы каршына шуышучы өч фашист белән «исәп»не өзде дә Михаил Шкураков яшеренгән агач төбенә күз салды. Алар икесе, биеклекнең Сунуплява авылы ягындагы итәген саклап, атышлар тынган араларда бер-берсенең хәлен сорашып торалар иде.

— Миша,— дип кычкырды ул бар көченә, аның окобына дүрт яктан дүрт немец үрмәләвен күргәч,— тирә-ягыңа кара!

Аларның берсен, үз ягындагысын, Шәкүров үзе дөмектерде. Калган өчесе Шкураков пуляларыннан хәрәкәтсез калды. Шул ук минутта Михаил Шкураков үзе дә агач төбендәге окопка бөгелеп төште. Шәкүров аңа ярдәмгә ашыкты. Ләкин соң иде инде.

...Немецларның тагын бер атакасы тончыкты. Шәкүров окоптан башын күтәреп тирә-якка карады. Беренче булып аның күзенә озын агач саплы гранатасын Әхмәтгалин өстенә ташларга әзерләнгән немец күренде. Ул яшен тизлеге белән аңа төзәп автоматыннан очередь бирде. Немец шунда ук киселгән агачтай җиргә ауды. Ләкин Хәким дә ул ташлаган граната тәтенен күмелеп калды. Шәкүров берничә сикерүдә командир окобына барып җитте.

Сержант Петр Сыроежкин белән бергәләп алар Хәкимнең яраларын бәйләп, өстенә плащ-палатка ябып куйдылар. Сыроежкин, алдан сөйләшкәнчә, командирны алыштырды һәм Әхмәтгалин окобына кереп урнашты. Шәкүров, йокысызлыктан ялкынсынган күзләренә ирексездән килгән яшь тамчыларын җиңе белән сөртеп алды да, тагын Хәким өстенә иелде. Флягасын ачып, аның иреннәренә китерде. Ләкин флягадан бары бер генә йотым җылынып беткән су чыкты. Шулай да Хәким берничә секундка күзләрен ачты.

— Якташ,— диде ул, караңгы төшеп килә торган күккә карап алгач,— төн тагын да авыррак булачак. Трофей кораллар җыегыз, бирелмәгез. Тагын шуны онытма: Өчиле районы, Сәфәр авылы. Рахим минем әти. Яз, онытма. Әнием Фәхерниса. Хәким боерыгын Сыроежкинга әйтеп килгәч, Шәкүров бер мәлгә баскан урынында катып калды. Өлкән сержантның күзләре баягыча күкнең бер ноктасына төбәлеп хәрәкәтсез калганнар. Агарып киткән йөзен салкын тир тамчылары каплап алган... Хәким Әхмәтгалинга бу вакытта 21 яшь иде.

Сержант Сыроежкин, тын калган һәр минуттан файдаланып, трофей коралларын җыярга боерык бирде. Беренче булып Тишибай Карабаев белән Василий Андронов бәхет сынап карарга булдылар. Берничә мәетнең автоматларын, патрон сумкаларын алу белән, алар өстендә пулялар сызгыра башлады.

— Күрделәр кабахәтләр,— диде Андронов, немецлар ягына күз төшереп алгач һәм үлеләрдән алган автоматларны өстерәп, кирегә, үз окобына борылды.

Аларның тирә-ягында мәетләр арасында миналар төшеп ярыла, җир кисәкләре, металл ярчыклары оча иде.

Пычрак җирдән шуыша-шуыша инде үз окопларына килеп җиткәндә, Андронов белән Карабаевтан аз гына алдарак тагын бер снаряд төшеп ярылды. Кайнар тимер кисәге Андроновның сул як иңбашына батып керде. Тишибайның аягы яраланды. Ләкин алар авырту сизмәделәр.

...Бу вакытта егерме дүрт яшьлек, гадәттән тыш таза гәүдәле үзбәк егете Чутак Уразов, бөтен дөньясын онытып, калкулык читендәге кечкенә генә печән сараеның чормa тәрәзәсеннән каршы яктагы куаклыкны күзәтә иде. Калкулык өстенә менәргә тырышып караган күп кенә фрицларны аның пулеметы каршылады.

Фашистларны калкулыктагы иптәшләре ягына үткәрмәү белән Чутак шулкадәр мавыккан иде, секунд саен үзенә якынлашып килгән фаҗигане күрә дә, сизә дә алмады. Күзләренә ачы төтен керә башлагач кына, үз хәленең котылгысыз икәнен аңлап, артка борылды да, шуышып кирегә китеп баручы ике немецның өстенә граната ташлады. Үч алынды. Ләкин аларны үтерү генә Уразовның хәлен җиңеләйтмәде. Сарайны төрле яктан ялкын телләре ялый башлады. Туктаусыз ата-ата, немецлар да шунда ашыктылар. Әмма аларның күбесе Чутакның пулемет утына очрап егылдылар. Икенче яктан Сыроежкин белән Шәкүров аңа ярдәмгә ташланды. Ләкин соң иде инде. Сарайны камап алган гитлерчыларга автоматтан берничә озын очередь бирделәр дә, алар яңадан калкулык сыртына үрмәләделәр.

Шул минутта ук, тирә-якка очкын кәлтәләре чәчеп, сарай җиргә гөрселдәде. Таҗикстанда туып үскән, Шахринау колхозының мамык кырларында яшьтән эшләп чыныккан комсомолец Чутак Уразов әнә шулай көрәште һәм җиңеп һәлак булды.

Кичке эңгер-меңгер җиткәч, урман артыннан кинәт килеп чыккан болыт калкулык өстенә яңгыр сибәләп китте. Бу көзге салкын яңгыр хәлдән тайган сугышчыларга аңа көч өстәгәндәй булды. Һәркайсы снаряд чокырларыннан каскасы белән алып болганчык су эчте.

Немецлар яңа атака башладылар. Калкулык өстен тагын ут өермәсе чолгап алды.

Сыроежкин жиргә сеңәрдәй булып алга үрмәләүче немец автоматчыларына пулеметыннан кыска очередьлар белән ата иде. Сул флангны саклаучы Шәкуров аның янына ашыкты.

— Иптәш сержант, Петро, ни булды сиңа?

Үзе дә сизмәстән бу сорауны биргәч, Шәкуров уңайсызланып куйды. Ни булганы болай да ачык иде. Аның окобы янында ук снаряд шартлаган. Үзен яртылаш җир күмгән. Окоп янында ук теткәләнгән пулемет ята.

— Болай зыян юк кебек, азрак аякны тырнады, ахры,— дип, Сыроежкин күзен ачты. Авыртудан булса кирәк, чыраен сытып туфрак астыннан бер аягын тартып чыгарды.

Шәкуров, кулы белән Ашмаровка безне каплап тор диган ишарә ясады да эчке күлмәген умырып алып, сержантның аягын бәйләде.

Разведчиклар гитлерчыларны тагын чигенергә мәҗбүр иттеләр. Калкулык өчен һәлак булган гитлерчыларның саны тагын берничә дистәгә артты. Гадәттәгечә, караңгы төшү белән, немецлар атудан туктадылар...

* * *

Караңгылыктан һәм атышлар тынудан файдаланып, Урун Абдуллаев, Яков Шәкуров, Федор Ашмаров, Токымбай Тайгәраев һәм Матвей Чернов сержант Петр Сыроежкин окобы янына җыелдылар.

— Караңгы төннән файдаланып калырга кирәк, егетләр,— дип башлады сүзен Сыроежкин,— мөмкин кадәр күбрәк патрон, гранаталар җыегыз. Бож радан чыгу мөмкин түгеллеген барыгыз да аңлыйсыз. Ярдәмнең дә кайчан киләчәген белмибез. Безнең бары бер генә юл бар. Ахыргача сугышырга, әйе, үлгәнче сугышырга, әмма бирелмәскә. Сугышу өчен безнең кораллар да, запас та юк. Димәк, дошманның үз коралы белән кыйнарга кала. Гранаталарны саклап тотыгыз, чиратлап кына ташлагыз.— Сержант тагын нидер әйтергә теләгән иде, ләкин аның сүзен Андронов окобыннан ишетелгән ату тавышы бүлдерде.

— Киттек, егетләр,— диде Тайгәраев,— тагын башлана.

Сугышчылар, яннарындагы бөтен гранаталарны Сыроежкинга калдырып, үз окопларына ашыктылар.

Яков Шәкуров берничә дискасы белән автоматын да Сыроежкинга калдырды. Үзе окобына түгел, соңгы атака вакытында үтерелгән немец солдатлары янына корал җыярга китте. Менә ул мәетләрнең берсеннән-берсенә йөреп, противогаз сумкасын патрон белән тутырды. Муенына ике автомат элде. Күтәрә алган кадәр озын агач саплы гранаталар алып, үз окобына таба атлады. Төн караңгы иде. Барысы да аягүрә басып йөрделәр, үле немецлардан корал җыйдылар. Ара-тирә генә төшкән снарядларга, автомат пулялары сызгыруга игътибар итүче дә булмады.

Ниһаять, дошманны каршыларга барысы да әзер. Автоматлар корылган. Гранаталар кул астында. Шәкуров окобын тагын да тирәнәйтебрәк казыды. Аны түгәрәк оборонага җайлаштырды.

Шул вакыт көтелмәгән гаҗәеп бер хәл килеп чыкты. Немецлар ягыннан күтәрелгән ракета яктысында Шәкуров, җиргә сеңәрдәй булып, үз окобына шуышучы хатын-кызны күреп алды.

— Бу ни булыр икән тагын,— диде ул үз-үзенә һәм автоматын тотып көтә башлады. Икенче ракета яктыртканда аның шактый якынайганын һәм кулындагы немец автоматын күргәч түзмәде, өскә таба кыска очередь бирде дә:

— Тукта, селкенмә,— дип кычкырды.

— Тукта, солдат, атма, мин үзебезнеке. Кил, булыш әзрәк,— диган хатын-кыз тавышы ишетелде.

— Ташла коралыңны, югыйсә атам,— дип кычкырды Шәкуров.— Урыныңнан кузгалма!

Үзе, бармагын автомат курогына куеп, ике кулын күтәреп торган хатын янына килде.

— Син кем, ник килдең, нәрсә кирәк, тизрәк әйт, күзәтергә килдеңме, немецлар җибәрдеме!

— Юк, солдат, мин менә шушы Сунуппявадан. Иртәдән бирле сезнең сугышуыгызны күзәтәбез. Бабай йорт саен йөреп ризык җыйды. Мин сезгә шуны китердем,— дип, яшь кенә кыз шактый зур капчыкка күрсәтте.

Шәкүров, бер ягы бозау тиресе белән тышланган немец капчыгын алды да, кызны ияртеп, Сыроежкин окобына китте.

— Немецларның көче бик күп, һаман яңалары килеп тора,— дип сүзен дәвам итте кыз.— Әйдәгез, мин сезне бу боҗрадан алып чыгам. Бабай шулай кушты. Курыкмагыз, мин юлны беләм. Кипкән ерганак төбеннән авылга ук барып чыгабыз. Файдасызга һәлак булмасыннар, чыксыннар, диде бабай.

— Барысы өчен дә рәхмәт, кызый. Һәлак булсак та без моннан китә алмыйбыз. Приказ шундый. Юлдан бер машина да үтәргә тиеш түгел,— диде Сыроежкин, сынаулы караш белән кызның күзләренә карап торгач.

— Син үзең тизрәк китү ягын кара,— дип өстәде Шәкүров.— Югыйсә, немецлар кыймылдый башлады, һәр минутта һөҗүм башлануы мөмкин.

Аның сүзен раслагандай, төн тынлыгын ярып калкулык түбәсенә берничә мина төшеп ярылды. Күккә бер-бер артлы ракеталар очты. Шәкүров алар яктысында үзеннән шактый ераклашкан кызның чокырга таба үрмәләвен генә күреп калды.

Ләкин бу юлы һөҗүм булмады. Атышлар тыну белән, янган сарай ягындагы куаклыклар арасыннан көчле репродуктор сөйли башлады.

— Солдатлар, каршылык күрсәтүнең файдасыз икәнен үзегез дә яхшы аңлыйсыз,— диде репродуктор рус телендә.— Нигә кан түгәсез, нәрсә өчен күрә торып үлемгә барасыз. Коралларыгызны ташлагыз, бирелегез. Без сезнең тормышыгызны сакларга вәгъдә бирәбез, яралыларыгызга һич кичекмәстән ярдәм күрсәтәчәкбез. Соңгы тапкыр кисәтәбез, бирелегез! Ун минут срок бирәбез, уйлагыз. Шул срок үткәндә ак флаг күтәрелмәсә, шәфкать көтмәгез...

Тавыш тынгач, төрле яктан сирәк кенә өткәләп торган автомат тавышлары да туктап калды. Күк гөмбәзенең көнчыгыш ягында таң нурлары сызылды. Биеклекне шомлы тынлык басты. Шәкүров окоптан окопка тиз генә йөреп латыш кызы китергән кукуруз ипиен һәм кабыклы бәрәңгене таратып чыкты. Иптәшләрен бирелергә өндәп йөри дип булса кирәк, немецлар аның һәр хәрәкәтен күреп торсалар да, атмадылар. Ул әйләнеп кайтканда, Сыроежкин янында комсорг Тайгәрәев утыра иде.

— Немецларга җавап шул, Токымбай, бер адым да чигенмәскә, тере килеш бирелмәскә! Кыскасы, калкулыкны соңгы сулышкача кулда тотарга! Бәлки озакламас, ярдәм дә килеп җитәр.

— Ярдәм киләме, юкмы, ә сугышырга кирәк, егетләр,— дип, Шәкүров та сүзгә кушылды.— Ләкин минем бер тәкъдимем бар.

— Нинди тәкъдим, әйтеп кара.

— Менә бу кызыл яулыкны калкулыкның иң түбәсенә кадарга кирәк.— Ул әлеге кыз бәрәңге төреп китергән яулык турында әйтте.

— Менә бу идея,— диде Сыроежкин.— Тагын биш минут вакыт калды. Бар, әйткәнеңне эшлә.

Немецлар биргән ун минут тулды дигәндә, биеклек өстендә кызыл флаг җилфердәде.

Әйтерсең, шуны гына көтеп ятканнар немецлар, шул минутта ук кул астындагы бөтен төрле кораллардан — автоматлардан, пулеметлардан, минометлардан шашынып ут ачтылар. Калкулык өстендә тагын җир һәм төтен баганалары күтәрелде.

Бернинди яңа боерык алынмаса да, үз частьларыннан аерылып, инде тәүлек буена боҗра эчендә сугыш алып баручы бу кечкенә гарнизон солдатлары һәркайсы ике-өч тапкыр яралануга да карамастан, кулыннан коралын төшермәде, сафта калды, үз окобына илле-кырык, хәтта егерме метрга кадәр якын җибәреп, фашистларны кыруын дәвам итте.

Окобы башкаларныкыннан алдарак урнашкан Урун Абдуллаев атыш тынган арада үз позициясе каршында үлеп калган немецлар янына шуышты. Сыроежкин белән Шәкүров аның һәр хәрәкәтен күзәтеп тордылар. Менә ул берсеннән-берсенә үрмәләп берничә немецның патрон сумкаларын үзенең противогаз сумкасына бушатты. Гранаталарын алып каешына кыстырды. Ватык кул пулеметының патрон тезелгән

лентасын иңенә киде, аның затворын алып читкә ыргытты. Аннан соң бөтен гәүдәсе белән салкын, юеш җиргә сыенып, кирегә, үз ягына борылды.

Нәкъ шул чакта аның янында, берсен-бере куып килгәндәй, миналар шартлый башлады. Баш өстеннән үк пулялар сызгырып үтте. Урун өстенә эреле-ваклы балчык кисәкләре яуды. Шинеле аша тәненә мина ярчыклары батып керде... Ул аңын югалтты...

Шуннан соң үзе белән һәм гомумән бу калкулыкта нинләр булганын Абдуллаев күп еллар узгач кына белә алды. Бу турыда А. Бакалов һәм Д. Тимофеев иптәшләрнең «Үлемсезләр калкулыгы»[1] китабында болай язылган: «Ул моннан ерактa, тузанлы юлда грузовик кузовы идәнендә һушына килде. Күзен ачкач та үз өстендә мамык сыман ак, сирәк болытлар йөзгән зәңгәр күкне күрде. Бөтен тәне сызлый иде. Машинаның аз гына селкенүе дә авыртуны көчәйтә. Иреннәренә дә, сакал-мыек баскан битенә дә ябышып кан каткан. Урун, үзе дә сизмәстән, башын күтәрде. Бу нәрсә? Машина бортына сөялеп, җилкәләренә автоматлар аскан немецлар басып тора. Баш күтәргәнен күргәч, арадан берсе, мыеклысы, Урунга: «Тик ят, селкенмә»,— дип тибеп тә куйды».

Абдуллаев шул вакытта гына кайчан да булса үз тормышында кичерү мөмкин булганнарның иң куркынычлысы белән күзгә-күз очрашуын аңлады».

Авыр контузия алып һушсыз егылгач, аның тормышы һәм язмышы өчен иптәшләренең ничек сугышуын Урун бөтенләй белми иде әле. Алай гына да түгел, геройларның берсе, аны коткару өчен, үз тормышын бирде.

Абдуллаевның хәрәкәтсез ятып калганын күргәч, ике немец, пленга алу нияте белән, аның янына шуышты. Сыроежкин автоматы аларның юлын тиз кисте. Ләкин үлгәннәр урынына төрле яктан башкалар үрмәләде. Аңсыз һәм ярдәмсез хәлдә үзе генә калган сугышчыга әсиргә төшү куркыныч минут саен якынлаша иде.

Сугышның күп маҗараларын бергә күргән дустының бу хәлгә калуы белән Шәкүров килешә алмады. Башта ул, Сыроежкин белән бергә, яралы иптәше янына килүче гитлерчыларны чигенергә мәҗбүр итте.

— Әгәр мин шул ук хәлдә калсам, Урун мине коткару өчен бөтенесен эшләр иде. Немецларны үтерү генә аз мондый вакытта. Ничек кенә булмасын, дусны коткарырга кирәк,— дип уйлады ул эченнән.— Мин артык чыдый алмыйм, сержант, ярдәмгә барам,— диде аннары, Сыроежкинга борылып.

— Үзем дә шул турыда уйлыйм, Яша, аяк җибәрми, хәерле юл сиңа, дус, бар!

Тулы обойма белән корылган немец автоматын уң кулына кысып, Шәкүров ярдәмгә ашыкты. Ара якыная бара. Менә аның алдында әле бер сәгать кенә элек җиңү турында сөйләшкән, сугыштан соңгы тормыш турында хыялланган дусты — Кара-Калпак республикасының «Кызыл Байрак» колхозы члены 32 яшьлек Урун Абдуллаев. Аларны бары өч метр ара аерып тора. Шәкүров инде аның авыр ыңгырашуын һәм саташып сөйләнүен дә ишетә.

— Ульбинә, Ульбинә, су бир, су,— дип кабатлый ул.

Әйе, Ульбинә, Ульбинә. Ул — Урунның хатыны. Буш вакытларда Урун хатыны Ульбинәнең тезгә кадәр җиткән шомырт кара чәч толымнарын, эшкә уңганлыгын, аның җырын тыңларга ярты кышлак җыелуын сөйли иде.

Шәкүров, бөтен рух көчен туплап, Урун янына барып җитте. Аны җилкәсенә салырга дип, терсәгенә таянды. Шул вакыт, җир астыннан ярып чыккан кебек, Шәкүров каршысында өч автомат көпшәсе күренде.

— Рус, сдавайся,— дип кычкырды немецларның берсе, җирдән аз гына башын калкытып.

— Мәгез, кабахәтләр! Шәкүров шулай автоматта патроны беткәнче очередь бирде. Аннан соң Урун янына чалкан әйләнеп төште. Аның күкрәген дисталәгән немец пулясы челтәрләгән иде...

Һаман да һушына килмичә кан эчендә ятучы Урун Абдуллаев янына төрле яктан немецлар ташланды. Сыроежкин гитлерчыларның ашыга-ашыга Урунны өстерәп авыл кырыендагы куаклар арасына кереп киткәннәрен генә күреп калды...

---

[1] А. Бакалов, Д. Тимофеев. «Үлемсезләр калкулыгы». Башкнигоиздат. Уфа. 1959 ел. 86—87 битләр.

Шәкуровның үлеме турында СССР Оборона министрлыгы архивының 33 фонд документлары арасында махсус язылган бер кәгазь саклана. Анда болай диелгән:

«Өч тапкыр яралануына, яраларыннан туктаусыз кан саркып торуга да карамастан, Яков Шакуров, иптәшләре белән бергә, соңгы сулышынача сугышырга, фашистларны рәхимсез кырырга ант итте. Бу сугышта үзен чын герой итеп танытты. Ул безнең социалистик Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен тигезсез көрәштә һәлак булды. Ләкин аның исеме безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр. Шакуровның батырлыгы безне тагын да тизрәк алга, көнбатышка, барырга, фашист ерткычларын үз оясында кыйнарга рухландыра».

* * *

Калкулык итәген төтен сыман ак томан белән каплап, икенче таң атты. Ләкин бу таңны геройлар взводының бары дүрт кенә сугышчысы каршылады.

Таң атарга бер сәгать чамасы вакыт калганда, Ульяновск өлкәсенең Малая-Якушка авылы егете Матвей Черновның да йөрәге тибүдән туктады. Хәзер, Федор Ашмаров белән Василий Андронов кына, өч-дүрт тапкыр яралануларына карамастан, азрак хәрәкәтләнә алалар иде.

...Рунденедән көнчыгышта ату һәм шартлау тавышлары һаман сәен көчәя, якыная бара. Андронов җиргә колагы белән ятып озак кына тыңлап торды да, ярым күтәрелеп, бар көченә:

— Безнекеләр килә, иптәшләр, безнекеләр,— дип кычкырды.

Ләкин немецлар биредән китәргә ашыкмыйлар иде әле. Күп булса 10—15 минуттан фашистларның психик атакасы башланды. Калкулык итәгендә йөзләрчә солдатларын югалткан немецлар, һич нәрсә белән исәпләшмичә, бөтен төр кораллардан ут сиптереп, кыюлар позициясенә ташландылар. Ләкин мондагы дүрт батыр, соңгы көчләрен җыеп, бу юлы да аларны гранаталар белән каршылады. Ә Андроновның тәз атуы аларны тагын кире борылырга мәҗбүр итте.

Бу штурм вакытында чуваш халкының батыр улы гражданнар сугышында ук үлемнең күзенә туры караган, Буденный белән данлы юл үткән 47 яшьлек колхозчы Федор Иванович Ашмаров һәлак булды. Петр Сыроежкин тормышының да соңгы минутлары Василий Андронов күз алдыннан үтте.

Комсорг Токымбай Тайгәрәев белән коммунист Василий Антонович Андронов немецларның бу дәһшәтле һөҗүменнән соң да биеклекне бер сәгать буена үз кулларында тоттылар...

* * *

Кинәт барысы да берьюлы тынып калды. Дүртенче тапкыр каты яраланган Андронов, аңын югалтып, салкын җиргә егылды. Шул хәлендә күпмедер яткач, ул аңына килеп, акрын гына күзен ачты, башын күтәреп тирә-якка карады. Калкулык өстенә йөгерүче кызыл йолдызлы каска кигән солдатларны күргәч, нишләргә дә белмичә, бөтен җирне берьюлы кочардай булып, ике кулын җәеп җиргә ябышты. Кычкырып-кычкырып елыйсы килә иде аның. Ләкин күзләрдән яшь чыкмады. Полкташлары аны әнә шул хәлендә табып алдылар.

Әйе, бу калкулыктагы кыюларга ярдәмгә, соң булса да, Новайдарский ротасы килеп җитте.

Бер сәгатьтән соң карт имән күләгәсендә тугыз геройны җир-ана мәңгегә үз кочагына алды, аларны данлап өч тапкыр залп яңгырады...

Ни өчен тугыз? Лудзадагы һәйкәлгә ун исем язылган ич? Әйе шул. Ләкин ул ялгышлык булган, һәм бу хәзер төзәтелде. һәлак булган дип исәпләнгән Урун Абдуллаев хәзер дә исән. Ул фашистларның үлем лагерьларын һәм америкалыларның «күчерелгән кешеләр» лагерьларының коточкыч фаҗигаләрен кичереп, 1946 елда туган иленә кайтты. Хәзер Кара-Калпак АССРда яши һәм колхозда эшли. Исән калган икенче батыр Советлар Союзы Герое Василий Антонович Андронов та сугыштан соңгы елларда үзенең туган ягына кайта, ләкин әнә шул сугышта алган берсеннән-берсе авыр дүрт яра, аңа чынлап савыгырга мөмкинлек бирми. Ул 1953 елда Мари АССРның Покровское авылында озак һәм каты авырудан соң вафат була.

* * *

СССР Оборона министрлыгы архивының 375 нче укчы полк фондында саклаучы бер документта болай диелгән: «Бу геройларның исеме безнең йөрәкләрдә мәңге яшәр. Алар эшләгән геройлык безне яңа батырлыкларга, фашист басып алучылардан рәхимсез үч алырга чакыра. Без тагын да ашкыныбрак алга барырбыз. Совет Балтик буе халыкларын түземсезлек белән безне, азат итүчеләрне, көтәләр.

Советлар Латвиясен азат итү өчен үзләренең тормышларын биргән геройларга мәңгелек дан!

Герой полкташларыбыз каберә янында армый-талмый алга барырга, явыз дошманны тәмам юк иткәнче кыйнарга ант итәбез».

2 нче Балтик буе фронтының 3 нче удар армия газетасы үзенең бер битен махсус бу батырларга багышлап чыгарды. Фронт командующие Советлар Союзы Маршалы Андрей Иванович Еременко да «Алга, Ригага» дигән мәкаләсен шул унбер каһарманга багышлаган иде. Менә аннан бер өзек:

«Өлкән лейтенант Павел Новайдарский ротасыннан унбер герой эшләгән батырлыкны бары тик коммунистлар партиясе тарафыннан тәрбияләнгән совет кешеләре генә күрсәтә алалар.

Унбер герой, дошманның хисапсыз атакаларын кире кайтарып, ике йөздән артык солдат һәм офицерын юк итте. Бу участокта немецларның чигену планнарын җимерде»...

* * *

СССР Оборона министрлыгы архивында 375 нче укчы полкның сугыш юлы язылган кәгазьләрдән бу батырлар турында мин әнә шуларны белдем. Ләкин кем соң ул Яков Савельевич Шәкуров?

Мин, Казанга кайту белән, Шәкуровны эзләргә тотындым. Гадәттәгечә, беренче чиратта геройның архивтагы бүләкләү кәгазендә күрсәтелгән адрес белән Омск шәһәренә, Яковның хатыны Зөләйха Шәкурова исеменә хат салдым. Озак та үтмәде, ул хат, өстенә бер кәгазь кисәге ябыштырып, кире кайтты. Анда: «Омск шәһәрендә Татарская урамы юк, хәзер ул урам Батумская урамы дип атала. Ләкин анда сез күрсәткән номерлы йорт юк», дип язылган иде.

Архивта язылган, ләкин өстеннән сызылган икенче бер адрес бар иде. «Омск шәһәре, 5 армия урамы, 74 нче йорт» дигән бу адрес белән тиз генә икенче хат җибәрдем. Бу хат та, шундый ук «анда тормый» дип язылган кәгазь кисәге ияртеп, кире кайтты.

Өченче хатны Омск шәһәренең хәрби комиссариатына яздым. Аннан бөтенләй җавап килмәде. Дүртенче хат өстенә Элемтә министрлыгының бланкасы беркетелгән. Анда Омск өлкәсе адреслар бюросының «Омск шәһәрендә һәм өлкәнең районнарында прописькада тормый» дигән штамп басылган иде.

Шулай итеп Омск өлкәсендә эзләнүләр киракле нәтиҗә бирмәде.

Узган елның апрель аенда мин, Татарстан язучылар союзы командировкасы белән, Төмән өлкәсенә бардым. Анда моңа кадәр исеме бездә билгеле булмаган Советлар Союзы Герое Тамерлан Ишмөхәмәтов[1] белән берничә көн үткәрдем дә Новосибирск шәһәренә, татар халкының икенче бер батыры — Советлар Союзы Герое Хәмзә Мөхәмәдиев янына, юл тоттым. Мин аларда биш көн тордым. Искиткеч кунакчыл бу семьяда күбрәк мине сөйләтергә тырыштылар. Аларны Татарстан, Казан һәм Татарстан кешеләре, аларның тормыш-көнкүрешләре бик кызыксындыра иде.

Шундый әңгәмәләрнең берсендә мин аларга билгесез татар геройларын эзләүнең кыенлыгы турында сөйләдем. Яков Савельевич Шәкуровны эзләү белән бер ел шөгыльләнеп тә семьясын таба алмавымны искә алдым.

— Тукта, тукта, Зәки туган,— диде Хәмзә абый, бу фамилияне ишеткәч.— Ул Якуб Салихович Шакиров түгелме икән?

---

[1] Тамерлан Ишмөхәмәтов турында «Октябрь яшьтәше» дигән очерк «Казан утлары» журналының 1967 елгы унберенче санында басылган иде.

— Юк, Хәмзә абый,— мин әйтәм,— татарларда андый герой гомумән юк.

— Ничек булмасын,— диде Хәмзә абый,— минем белән бергә үскән егет Якуб Шакиров — Советлар Союзы Герое бит. Ул миңа туган тия, яшьтән үк бер әби тәрбиясендә үстек. Анжеро-Судженскида шахтада бергә эшләдек, соңыннан алтын прискаларында бергә булдык. Үзе кайтмады ул, һәлак булды. Аңа Герой исеме үлгәннән соң бирелде.

— Әйе, Шакиров дигән герой бар, без Омскида бергә яшәдек, күрше генә идек,— дип Хәмзә абыйның хатыны Сафаут апа да сүзгә кушылды.

— Нәрсә монда сөйләшеп утырабыз бу турыда,— диде Хәмзә абый.— Әйдәгез, баҗа янына барабыз. Ул барын да белә.

Бер сәгатьтән соң без Новосибирскиның икенче башында, Һади абый Әсәнов квартирасында идек.

Якуб Шакиров турында Һади абыйга караганда аның хатыны Әһликамал апа күбрәк сөйләде.

— Якубның хатыны Зөләйха белән без бик якын дуслар идек,— диде ул,— Томскида бергә яшәдек. Якубның Советлар Союзы Герое булуы турындагы хәбәр аңа 1945 елда килде.

— Адресын табарга кыен түгел,— дип, Һади абый да сүзгә кушылды.— Уфадагы җырчы Габдрахман Хәбибуллинны ишеткәнең бардыр бәлки.

— Бик яхшы беләм,— дидем мин.

— Белсәң шул,— диде Һади абый,— аның хатыны Мәрьям Якуб хатынының апасы була. Алар, һәрхәлдә, элемтә тоталардыр. Ә Габдрахман адресын Уфадан, Фәнил Әсәновтан сора. Ул минем улым була.

Казанга кайтып җитү белән, әтиләреннән дә күп сәламнәр әйтеп, башкорт язучысы Фәнил Әсәновка хат җибәрдем. Бер атна дигәндә, Фәнилдән Хәбибуллиннар адресы язылган хат килде. Шул ук көнне мин дә Мәрьям исеменә хат язып салдым.

РСФСРның халык артисты Габдрахман ага Хәбибуллин җавапны тиз язды. Менә аның хатыннан бер өзек:

«Хөрмәтле Зәки туган!

Хатыгызны укыгач ук җавап язарга булдым. Сугыш елларында халкыбыз күрсәткән батырлыкларның әлегә кадәр билгесез булган яңа битләрен ачу, билгесез геройларыбызның исемнәрен халыкка җиткерү кебек авыр һәм мактаулы хезмәтегездә чын күңелдән уңышлар телим. Мин сезгә бу мәсьәләдә булдыра алганым кадәр булышырга әзер торам. Әйе, Якуб Шакиров минем баҗам була. 1931 елга кадәр без Томскида бергә яшәдек. Шул елдан бирле күрешкәнебез юк. Хатлар белән генә сөйләшәбез. Семьясы-балалары белән хатыны Зөләйха хәзер Омск шәһәрендә яшиләр».

Кыскасы шул: Габдрахман ага җибәргән адрес буенча Омскига язган хатыма геройның семьясыннан җавап килеп җитте. Аны Якуб Шакировның олы кызы Фәүзия язган иде. «Безнең әти,— дигән ул хатында,— Казан ягыннан бәхет эзләп Нижний-Новгород шәһәренә күчеп килгән семьяда туган. Үзе Якуб Салихович Шакиров булса да, нигәдер аның бөтен документлары Яков Савельевич Шакуров дип тутырылган. Ул һәрвакыт шул исем-фамилия белән йөрде.

Хәзер Омск шәһәрендә Совет районының яңа төзелгән кварталларының берсе әти исеме белән йөртелә».

Әйе, Ватаныбыз, халкыбыз батырлыкны һәм батырларны беркайчан да онытмый. Хәзер бер Омск шәһәрендә генә түгел, күп кенә районнарда һәм авылларда урамнар, колхозлар, пионер дружиналары батыр якташыбыз исемен йөртә.

# ШИНЕЛЬСЕЗ СОЛДАТЛАР

Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар»[1] дигән повесте, исеме үк күрсәткәнчә, бүгенге 33—35 яшьлек ир-егетләребезнең сугыш елларына туры килгән балачакларына багышланган.

Ул чор (әйе, вакыт үлчәвендә бик кыска булса да ул — чор) турында татар әдәбиятында да, илебез һәм дөнья әдәбиятларында да әсәрләр бик күп. Без, сугыш вакытында, я сугыштан соң туганнар, ул әсәрләрнең шактыен укып, күңелдән генә булса да, үзебезне сугыш кырында, фронтның икенче алгы сызыгында булган тыл хезмәтендә итеп тойганыбыз бар. Бу тойгыларга әти-әниләребезнең, абый-апаларның әрнеп сөйләгән барлык үз күргәннәрен, аларның күз төпләренә, маңгайларына артык тирән сырылып калган җыерчыкларын да өстәсәң!..

Кыскасы, безнең аңыбызда ул еллар турында шактый тулы гомуми мәгълүмат бар һәм бу мәгълүматка принципиаль яңа детальләр өстәү җиңел эш түгел.

Дөресен генә әйткәндә, «Шинельсез солдатлар» әнә шул безгә билгеле булган бихисап күп детальләрдән хасил әсәр.

Билгеле, детальләр белән эш итүнең ике ягы бар: берсе — укучыда «мин боларны күптән беләм инде» дигән фикер уятып, әсәрнең кызыклылыгын алдан ук киметеп кую; икенчесе — әсәрнең ышандыру көчен арттыру. Гасырлар дәвамында гел бер төрле генә йөреш ясаган шахмат фигураларыннан кызыклы комбинация оештырып булган кебек, Вакыйф әнә шул мәгълүм детальләрдән мавыктыргыч һәм ышандыргыч сюжет кора алган.

Таякларга атланып тарихның дәһшәтле чорына килеп кергән малай-шалайларга ияреп, без дә көчәнмичә генә, кая юл тотканыбызны абайламыйча гына повестьның сюжет юлларына кереп китәбез.

«— Герман безгә каршы сугыш ачкан! Аннары кайсы кайда кырда эшләүче ир-атлар да, җиккән атларын чаптырып, авылга кайттылар.

Барысының йөзләре җитди, борчулы иде. Ә без, малайлар, бу хәлгә бераз сәерсенеп тордык та, берни булмагандай, янадан уеныбызны дәвам иттек. Чөнки кайда сугышалар, кемнәр сугыша дип соравыбызга каршы, Миңлеәхмәтнең атасы:

— Ерак ул, оланнар, моннан күренми,— дигәч, безнең өчен ул сугышның кызыгы беткән иде инде». Повестьның эчтәлеген сөйләп торуны кирәк тапмыйча, алда китерелгән өзек турында гына берничә сүз әйтәсем килә. Игътибарны җәлеп иткән беренче нәрсә — Миңлеәхмәт атасының портреты. Әнә ул кисәк кенә бозылган кәефен авырлык белән тезгенләп, малайларның ачу китергеч беркатлы сорауларына җавап бирергә көч таба. Бу җавапта, аның әйтелеш формасында, Миңлеәхмәт атасының агарып калган йөзендә, шомлану катыш нәфрәттән караңгыланып киткән күзләрен дә, нишләргә белмичә аптыраудан, дулкынланудан бүртеп типкән чигә тамырларын да күреп була. Миңлеәхмәт атасының кыяфәте турында

[1] Вакыйф Нуруллин. Шинельсез солдатлар. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1968 ел.

ләм-мим әйтмичә, В. Нуруллин бу портретны ничек безнең күз алдыбызга китереп бастыра алган соң? Минемчә, ул безнең аңыбызны, күңел күзебезне әлеге дә баягы мәгълүм, күптән таныш детальләргә бик оста итеп юнәлтә белгән һәм безнең күз алдыбызда һәрберебез үзенчә төсмерләгән гомуми образ калкып чыккан.

Икенчесе — сугыш башлану хәбәрен ишеткән малайларның үз-үзләрен тотышлары. Миңлеәхмәт атасының җавабыннан тулысынча канәгатьләнеп, алар «ат-ат» уйнап йөрүләрен дәвам иттерәләр, чөнки алар уеннан туктамаганга карап кына сугышның тукталмаячагын ниндидер эчке, самими сиземләү белән тоялар. Монда инде Вакыйф тышкы күренешләрнең нечкә психологиясенә үтеп керә алган.

Повестьның сюжеты эченә кереп, персонажларның вакыйгаларда яшәвен күзәтсәк тә Вакыйф Нуруллинның мәгълүм детальләр белән шактый оста эш итүен күреп була. Председатель Саматның хатын-кыз белән чуала башлавы да, ире югалган хәбәр килгәч кенә Нәсиханың «тән теләкләренә» ирек куюы да, колхозчыларның гомуми җыелышында Шәйхи картның үз-үзен тотышы да, Мәгъсүмә апаның Равилне мәктәпкә җибәрмәскә теләве дә табигый итеп бирелә һәм берсүзсез ышандыра. Бу персонажлар автор тарафыннан җентекләп сурәтләнмәсәләр дә, укучының тормыш тәҗрибәсе белән баетылып, сюжет эчендә тулы канлы образлар булып яшиләр. Бу инде әлеге дә баягы әдәби алымның сюжет белән дә, персонажлар язмышы белән дә органик бәйләнештә булуын ачык күрсәтә.

Әлбәттә, сюжет кору һәм сюжетта персонажларны табигый тормыш белән яшәтә белү иҗади осталыкның бер ягы гына. Аның икенче, мөһимрәк ягы — шул сюжет һәм вакыйгалар аша тормышның бүгенгесенә кирәкле идея-фикерләр белән укучы аңын сугара белү. Җөмлә артыннан җөмлә, бит артыннан бит, бүлек артыннан бүлек тезелеп, китап, ниһаять, укучыга үзенең максатын ирештерә. Вакыйфның повестен укып чыккач әнә шул максат беравыкка билгесезлеккә күмелеп тора. Ләкин мидә бер уй бөтерелә башлый: «Сугыш кешеләрнең тормышын, күңелен пычратты, тәннәрен җәберләде һәм сабыйларга аларның табигый үсешләре өчен беркиге кирәк булмаган йогышлы әшәкелекләр, гаделсезлекләр күрсәтте!..» Дөрес, бу фикер әдәбиятта яңалык түгел, ләкин аны кешеләргә, кешелеккә әледән-әле кабатлап тору, төрле материаллар нигезендә әледән-әле исбатлап тору — бүгенге әдипнең шәфкатьле миссиясе. Билгеле, повесть бары тик алда әйтелгән фикер өчен генә язылган дип әйтсәк, акыллы да, дөрес тә булмас иде. Повестьның һәр вакыйгасы, тормышның һәр факты кебек үк, гыйбрәтләр чыганагы. Повестьтагы вакыйгалар (сурәтләнгәннәре дә, сөйләнгәннәре дә) аңда конкрет, төгәл фикерләр уяталар.

Ул фикерләрне, тәэсирләрне логик җепкә тезүне автор 13—14 яшьлек Равил образына йөкли. Бу инде повестьны берничәләтә отышлы итә: бердән — кабул итәргә җиңел, күрер күзгә стихияле, табигый булып күренгән, ләкин тәгәл чикле сюжет барлыкка килә, икенчедән — иярчен персонажларның тулы объемлы, габаритлы герой булып җитмәүләрен аклый (чөнки аларны автор сурәтләми, ә алар турында Равил сөйли), өченчедән — повестька ниндидер самими, бер карасаң — беркатлырак, шул ук вакытта шактый тирәнлеккә ия колорит бирә.

Равилгә бәйләп тагын шуны да әйтәсе килә: повестьны язганда автор үзен тулаем 13—14 яшьлек Равил итеп тоя алган. Шул яшьтәге малайлар психологиясенә хилафлык китермичә, 13—14 яшьтәгеләр күрә һәм уйлый алырлык нәрсәләр турында гына язган һәм язганын аларга хас кичерешләр белән генә сугарган.

«Шинельсез солдатлар»ның китап вариантын журнал варианты белән («Казан утлары» № 3, 1968 ел) чагыштырып карасаң, китапта кайбер уңай һәм тискәре үзгәрешләрне күреп була. Журнал вариантындагы «Әти белән очрашу» бүлегендәге «Гамлет»ны хәтерләткән төш эпизоды хаклы рәвештә алып ташланган. Ләкин аның бәрабәренә журналда булмаган (колхозчыларның гомуми җыелышында райком секретаренең чыгышы) җитешсезлек килеп кергән. Бу очракта Вакыйф, тормыш чынбарлыгына артык бирелеп китеп, әдәби чынбарлыкка, әдәби гомумиләштерүгә кирәгенчә игътибар итеп җиткермәгән.

Соңгы сүз итеп, Вакыйф Нуруллин каләменнән уңышлы әсәрләр өмет итеп булганны әйтәсе килә.

РЕНАТ ХАРИСОВ

# КЫСКАЛЫКТА ОСТАЛЫК

Сирәк-сирәк кенә журнал редакциясенә кереп чыга ул.

— Идрис абый, исәнмесез,— дип хәлен белүгә, берсенең дә башына килмәгән тапкыр сүз белән җавап кайтара. Аптырап каласың: чынлап сөйлиме карт, уйнапмы? Тик аның гөрелдәтеп көлеп җибәрүен күргәч кенә үзең дә рәхәтләнеп, күзеңә яшь килгәнче бер көлеп аласың.

Үзе зур, сүзе салмак, йөзе тыныч. Карап торсаң бер дә шаян кешегә охшамаган, каян табып бетерә ул бу кадәр тапкырлыкны?

Идрис Туктаровның яшь чакта язган юмористик хикәяләрен укучылар әле дә булса хәтерлиләрдер. Алар күләм ягыннан кыска, фикергә бай, образлары онытылмаслык. «Кечкенәнең эче — төш кенә» ди татар халык мәкале. Идрис аганың хикәяләренә ул бик туры килә. Менә дәфтәр калынлыгы гына бер китап — «Батырлыкта матурлык». Шулай да кырык өч хикәя сыйдырган ул. Кырык өч хикәя, кырык өч вакыйга. Кырык өч төрле хикмәт. Автор бик гади генә нәрсәләр турында яза. Хәтта аларның кайберләре турында инде башка язучыларның китапларыннан да укыганыбыз бар. Чыннан да, йомгак күк йоп-йомшак, йоп-йомры песи баласын кайсы гына халкыбызның әдәбиятыннан укымадык икән без. Бу китапта да «Ике йомгак» дигән хикәя бар. Ике йомгакның берсе — әбинең оекбаш бәйләргә дигән йон йомгагы, икенчесе — Гөлкәйнең песи баласы. Автор аларны шундый итеп сурәтли — хәтта әбинең йомгагы сүтелә барып, Гөлкәйнең оекбашына, бизләнә әйләнгәч тә аны нәкъ песи баласы сыман йомшак, аның шикелле үк ап-ак итеп күз алдына китерәсең. Хәтта аны сыйпап куясы килә, җылысын тойгандай буласың. Я булмаса, «Җем-җем!.. Чвик!..» дигән хикәяне алыйк. Эчтәлеге бик гади. Әмма автор кошлар авазын шундый оста итеп бирргән, хикәяне укыганда ирексездән үзең дә кош булып сайрый башлыйсың. Ә менә «Абыем бүреге». Курыкмаучың сере бүректә дип ышанган нәни малай усал ата казны куып җибәрә. Моны күреп, аның иптәшләре барысы да я әтиләренең, я абыйларының бүрекләрен киеп чыгалар. Балаларның шул самимилеген күреп, хикәяне укыганда ничек елмаймый түзәсең ди.

Җыентыкка кергән хикәяләр төрле темаларга язылган. Биредә әхлакый хикәяләр дә, патриотик темаларга язылганнары да, табигатьне танып белергә өйрәтүчеләре дә һ. б. бар. Арада «Бәхет белән шатлык», «Ай», «Акмаңгай белән Алтынкойрык», «Асыл чыпчык» шикелле хикәяләр дә бар. Бу әсәрләрендә автор Абдулла Алиш традицияләрен дәвам итә. Хайваннар дөньясыннан бер хикмәт алып язган бу әкиятләрнең һәркайсында балаларга адресланган бер хикмәт була: мактанчык булма, тырышлык бәхет китерә, белем зур ачышлар ясарга ярдәм итә һ. б.

Идрис ага укучысына бирергә теләгән киңәшен ачыктан-ачык әйтми. Хикәянең моралең укып чыкканнан соң гына төшенергә мөмкин. Автор аны әйтү өчен әдәбият законнарының күп чараларыннан файдаланырга тырыша. Ул хәтта геройларының исемнәрен дә шул максатка буйсындырырга тырыша. Ялкау бала турында сөйләсә, аның исемен «Авыраяк» дип ала, бер нәрсәне дә тиз генә хәл итмичә сүз боткасы куертучыларны «Икән-микән һәм Бугай» дип атый. Сүз дә юк, исеме үк образны ачуга ярдәм итә.

«Батырлыкта матурлык» китабы балалар өчен чыгарылган. Әмма аның кайбер хикәяләре балалар турында зурларга атап язылган. Гомумән, бу китапчык зурларга да, нәниләргә дә кызык булачак. Тик редакторга гына бер сүз әйтәсе килә: бу әйбәт китапка кергән хикәяләрнең барысын да осталык, үткенлек ягыннан бер дәрәҗәгә күтәрәсе булган икән. Юкса «Урман букеты», «Алма», «Уйнар өчен әзләдек», «Чәчәкләр кебек матурайдык» дигән хикәяләргә әле тапкырлык җитеп бетми кебек. Вакытында авторга шул турыда әйтелгән булса, Идрис ага, һичшиксез, аларны тагын бер кат карап чыгар иде.

Теләк итеп тагын шуны әйтәсе килә: бу хикәяләр кырык өч кенә булып калмасын иде, алдагы елларның берсендә без шундый йөз хикәяне укысак иде.

**Л. ИХСАНОВА.**



# СӘХНӘГӘ ГАШЫЙК

Аны күрәсең килә икән — бер дә әллә кайлардан эзләп йөрмә, тот та кичен театрга бар. Татар дәүләт академия театры — аның икенче йорты. Әнә ул алтынчы рәтнең кырыйдагы урындыкларыннан берсенә тыйнак кына кунаклаган да, меңәрләгән тамашачыларның берсе булып, вакыйгалар агышына көенеп һәм сөенеп спектакль карап утыра; я залга кушылып дәррәү көлеп җибәрә, я ярсып кул чаба... Ләкин шулай да ул битараф күзәтче, гади тамашачы гына түгел. Ул — эш өстендә: тамашачысын, аның ихтыяҗларын өйрәнә, аның йөрәк тибешен тыңлый... драматургның күңелендә яңа әсәр өлгерә, яңа образлар җитлегә...

Кайбер язучы турында, ничектер, ул инде дөньяга килгәндә үк атаклы булгандыр, дип уйлыйсың. Хәй Вахит хакында алай әйтеп булмый. Дөрес, аның да әдәби иҗатка омтылышы яшьтән үк көчле була, иртә беленә. Бөек Ватан сугышына кадәр үк инде ул балалар өчен әсәрләр яза, үзенең беренче китапларын чыгару бәхетен татый. Ләкин иҗатта үзен табу һәм раслау өчен Х. Вахитка шактый күп вакыт кирәк булып чыга. Әйе, аның шигырь җыентыклары, әкиятләре, сәхнә әсәрләре нигездә уңай бәя алалар. Әмма алар әдәбиятыбызда сизелерлек күренеш булып калмыйлар. «Талант тырыш хезмәт нәтиҗәсендә генә чын мәгънәсендә чәчәк ата ала», диләр. Бу сүзләрнең дөреслеген раслау өчен мисал кирәк булса, Х. Вахит иҗатына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Яшь язучының егерме елга сузылган өйрәнүләре һәм тәҗрибәләре бушка китмәде. Ул үз сәләтенә лаеклы иҗат мәйданын драматургиядә тапты, аның таланты шушы өлкәдә чәчәк атты.

Х. Вахитның тынгысыз, эзләнүчән кеше булуы аның әдәбиятта үз сукмагын табуында гына түгел, бу сукмакның үзенчәлекле булуы өчен көндәлек кайгыртуында да чагыла. Аның «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Кайда соң син!», «Карлыгач канат кага», «Соңгы хат», «Күк капусы ачылса» кебек пьесалары нәкъ менә шул эзләнүләрнең җимешләре төсендә барлыкка килде. Беренче карашка, боларның кайберләре ниндидер яклары белән бер-берсенә охшый, алар кабатланалар кебек. Аерым моментларда, вакыйкларда бәлкем, чыннан да, кабатланулар, охшашлыклар бардыр. Ләкин бу әсәрләрнең көчен һич тә болар билгеләми. Җентекләбрәк карагында, заманыбызның алдынгы тенденцияләрен художестволы гәүдәләндерүдә Х. Вахитның һаман эзләнүен, кыю тәҗрибәләр уздыруын һәм ничек тә кабатламаска тырышуын ачык күрергә мөмкин. Бу — жанр үзенчәлекләрен үзләштерә баруда да, яңадан-яңа тормыш материалына мөрәҗәгать итүдә дә, композицион төрлелеккә омтылуда да, яңа фикерләр байлыгына ирешергә тырышуда да чагыла.

һәр язучы аерым бер жанрда үзен иркен сизә, аның яраткан темасы, үз сурәтләү алымнары була. Х. Вахитның яраткан өлкәсе — бүгенге тормыш, бүгенге кешеләр, бүгенге конфликтлар. Әйе, аерата кыюлык, күзәтүчәнлек, күп эзләнүләр һәм тормышны тирән белүне таләп итә торган өлкәдә эшли ул. Коммунизм төзү кебек гүзәл эшкә алынган халкыбызга лаек әсәрләр иҗат итү, бүгенге геройларның бай образларын сәхнәгә чыгару — иҗатта моннан да югарырак, мактаулырак вазифаның булуы мөмкинме!! Х. Вахитның яраткан жанры — комедия, аның да «лирик комедия» дип аталган тармагы. Нәкъ менә шушы жанрда драматург җитди уңышларга ирешә.

Монда юбиляр турында тагын да бер мактау сүзен әйтми үтеп булмый: Х. Вахит комедия жанрының бөтен мөмкинлекләреннән тулы файдаланырга омтыла. Ул, мәсәлән, һәр комедиясендә үзәккә уңай геройны куеп сурәтли; ә бу жанрда искене, торгынлыкны тәнкыйтьләү белән янәшә яңаны раслауны, яңаны яклауны сәнгатьчә берләштерү гаять авыр һәм катлаулы бурыч булуы яхшы мәгълүм. Х. Вахит күпчелек әсәрләрендә моны уңышлы эшли. Тәлгать, Рәхилә, Нурсәнә, Әпсәләм («Беренче мәхәббәт»), Марс, Зәйтүнә һәм Нургата («Рәхим итегез»), Ильяс Айтуганов, Диләрә, Сәрьян («Карлыгач канат кага»), Сәрия һәм Шәүкәт («Кайда соң син!»), Газиз һәм Рәмзия («Күк капусы ачылса») кебек сөеп, йөрәк җылысы белән сугарып иҗат ителгән образлар бирде ул. Х. Вахит комедияләрендәге һәм аның «Соңгы хат» әсәрендәге уңай геройларның кешелеклегенә, олы йөрәкле, югары идеаллар белән коралланган булуларына, ниятләренең изгелегенә сокланмыйча мөмкин түгел. Аларда бүгенге хезмәт кешеләренең күп кенә матур сыйфатлары гәүдәләнә. Сәхнә әсәрләрендә Х. Вахит үзенә генә хас лиризм белән, дулкынланып совет яшьләренең рухи ныгуларын, характерлары үсүен сөйли.

Х. Вахит чын-чынлап театрга гашыйк. Илленче елларның урталарыннан алып безнең көннәргә кадәр аның исеме театр афишаларыннан төшми. Аның рухи омтылышлары һәм сәләтләр даирәсе музыкаль драматургия кебек тагын да бер үзенчәлекле һәм катлаулы сәнгать төрен үз эченә ала. Юбиляр музыка белән драматургияне үзара бәйләп торучы аз санлы авторлардан берсе һәм иң күренеклесе дияргә мөмкин. «Самат» һәм «Дим буенда» операларын композитор Хөснул Вәлиуллин аның либреттоларына нигезләп язды. Мансур Мозаффаровның гаҗәп бай интонацияле, үзенчәлекле һәм җыйнак эшләнгән «Бәхет юлы» сюитасы Х. Вахит сүзләренә иҗат ителгән. Күп кенә җырлар авторы буларак та Х. Вахит исеме концерт залларында һәм радио-телевидение тапшыруларында да еш яңгырый.

Шунысы куанычлы, Тукай премиясе лауреаты Х. Вахит үзенең юбилей көннәрен иҗаты чәчәк аткан чорда каршы алды. Әле аның «Илһамия» исемле соңгы комедиясе буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы кайчан гына булган иде, ә инде драматург яңа әсәрен өлгертте. Яшь замандашларыбызның гүзәл образларын рухланып җырлаучы Хәй ага Вахит — җитлеккән художник. Халкыбызның яратып һәм олылап әйтә торган «ага» сүзен без бу очракта һич тә юбилярның яшенә ишарә ясау өчен түгел, ә олы иҗатына, мактаулы хезмәтенә хөрмәт йөзеннән кулланабыз. Бу иҗат, бу хезмәт тамашачыларга куаныч китерә һәм, ышанабыз, ул әле сәхнә сөючеләрне озак вакытлар куандырыр.

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН.



# МАНСУР КРЫЙМОВ

*(1898—1940)*

Октябрь революциясе халык массаларында гасырлар буе җыелып-тупланып килгән иҗат ялкынын кинәт кузгатып, бермә-бер дөрләтеп җибәрде. Кыска гына вакыт эчендә буразналар арасыннан, завод-фабрикалардан һәм сугыш кырларыннан әдәбият мәйданына бик күп талантлы яшьләр килде. Араларында революция җырчысы булырга хыялланган кыю йөрәкле яшь шагыйрь Мансур Крыймов та бар иде.

Мансур Крыймовның тормыш юлы күпләгән яшьтәшләренекеннән берни белән дә аерылмый диярлек. Ул 1898 елда Татарстанның Апас районы Чүри-Бураш авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Туып ата-ана назлавын күрергә дә өлгерми, бөтенләй ятим кала. Аны үз авылларының бер кешесе тәрбиягә ала. Берничә ел авыл мәктәбендә укыганнан соң, 1915 елның язында яшүсмер Мансур, бәхет эзләп, Кавказга китә. Анда баргач, берникадәр вакытлар Грозный нефть промысelларында эшли. Әллә ни рәт чыгара алмый, шуннан туган якларына кайтырга дип, яңадан юлга чыга. Әмма, шулай бер кузгалган килеш, туры гына өйгә кайтып керү дә насыйп булмый. Астрахань шәһәренә кайтып җиткәч, аның акчасы бетә. Берничә айлар Астраханьдагы татар байларында хезмәтче, соңрак кибетче булып тора. Ахырдан Епифановларның балык промыселына кара эшче булып яллана. 1917 елның гыйнварында шуннан армиягә алына...

Яшьли җәбер-золым күреп үскән Мансур Бөек Октябрь революциясен шатланып каршылый. Алай гына да түгел, революциянең беренче көннәреннән ук үзе дә яңа җәмгыять саклаучы көрәшчеләр сафына баса. Кызыл Армия сафларында Колчак, Врангель бандаларына каршы сугыша. Гражданнар сугышыннан кайткач, Мансур Крыймов Мәскәү янындагы заводларның берсенә эшкә керә, соңыннан башкаланың «Кызыл шәрык» типографиясендә наборщик һәм корректор була.

Мансур Крыймов үзенең беренче әсәрләрен унсигезенче елларда ук яза башлый. Ә 1921 елдан инде ныклап әдәби иҗат эшенә тотына. Шагыйрьнең әдәби мирасы

«Кызыл бәдәвам» (1925 ел), «Чүкечем җырлары» (1925 ел), «Авыл җырлары» (1926 ел), «Гармун көенә» (1926 ел), «Кечкенәләр җыры» (1926 ел), «Шигырьләр» (1927 ел), «Аллы-гөлле гөлчәчәк» (1928 ел), «Эш иртәсе» (1929 ел) кебек җыентыкларына һәм 1961 елда басылып чыккан «Шигырьләр һәм поэмалар» исемле китабына тупланган. Югарыда саналган китап исемнәренә караганда иҗатының чәчәк аткан чорында Мансур Крыймов елына бер-ике җыентык биреп барган. Бу инде аз түгел. Жанр төрлелеге ягыннан да аның иҗат мирасы шактый бай күренә. Ул калдырган әдәби әсәрләр арасында без шигырьләр һәм хикәяләр, җырлар һәм маршлар, инсценировкалар һәм зур-зур поэмалар очратабыз.

Билгеле, бүгенге көн таләпләреннән чыгып караганда, әдәбиятның бүгенге үсеш дәрәҗәсе югарылыгыннан торып якын килгәндә, Мансур Крыймов иҗатында аерым уңышсыз урыннар һәм кимчелекләр дә бардыр. Аның күп кенә шигырьләрендә, мәсәлән, Һади Такташка хас интонацияләр яңгырый. Аерым әсәрләрендә Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Бабич кебек әдипләрнең шигъри авазларын тоеп-сиземләп каласың. Әмма Мансур Крыймов иҗатында иң нык, иң көчле яңгыраган аваз — революциянеке, Октябрь авазы. Үзенең характеры, әдәби эшләнеше һәм сыйфат дәрәҗәсе ягыннан аның иҗаты егерменче еллар татар совет поэзиясеннән аерылгысыз. Егерменче еллар поэзиясенә хас көчле яклар да һәм кимчелекләр дә аның әсәрләрендә ярылып ята. Шул сыйфатлар аның әсәрләрен көчле, үзенчәлекле итә.

Егерменче елларда әдәбият мәйданына килгән башка күп кенә татар шагыйрьләре кебек үк, Мансур Крыймов та шигъриятне революцион корал дәрәҗәсенә күтәрде. Аның беренче карашка шактый кимчелекле күренгән, әгәр шулай әйтергә яраса, бик үк сәнгатьчә яңгырамаган шигырьләре революцион пафос һәм тәвәккәллек көчләре белән аерылып торалар. Мансур Крыймовның күп кенә әсәрләре киң катлау укучылар массасы биеклегеннән торып, игенче, эшче, кызылармеец исеменнән язылган. Аның шигырьләрен популяр, үтемле иткән сыйфатларның тагын берсе әнә шунда булган. Бүген, тууына 70 ел тулган көнне, Мансур Крыймовны без революция шагыйре буларак, актив, сугышчан поэзия вәкиле буларак искә алабыз һәм хөрмәт итәбез.

## Искәндәр Рушан

### Үлмәүнең зарары, өйләнмәүнең файдасы турында Хөлли Мәймүнович фикерләре

...Бу дөньяда иң бәхетле кеше —
Мәрхүм булган бәндә, әлбәттә:
Мәрхүм бит ул — тайпылмый да инде,
Шелтәгә дә эләкми гадәттә.

Тере бәндә — бүген әйбәт тә ул,
Ә нишләр бит әле иртәгә?
Иртәгә ул, ә кем белә аны,
Унга-сулга может китәргә...

Турыдан яр юлны, Хөлли! диләр,
Тукайларча яшә син, диләр.
Диләр дә бит... Әмма мәсьәләгә
Объективно килә белмиләр.

Без әгәр дә тушы проблеманы
Диалектик нитеп карасак:
Ни җанашы аның, ни баласы!
Тукай бит ул — круглый холостяк!

Шуңа күрә генә кыю булган,
Теләсә лә генә нишләгән:
Охранкадан бүтән, черт та аны
Милләтче бит син дип нитмәгән.

Тукайны да инде «җәдитче» дип,
Мөмкин дә бит тетеп салырга,
Но аңарга кулны суздың исә
Можно даже башсыз калырга.

Татар яклый аны — Г. Тукайны,
Сәйдәшен дә яклый. Но зря.
Нигә яклый аны? Нигә булсын,
Культурасы түбәнгә күрә.

Да, дөньяда иң бәхетле кеше —
Мәрхүм булган бәндә, әлбәттә:
Мәрхүм бит ул — тайпылмый да инде,
Шелтәгә дә эләкми гадәттә.
Яшәп ята полный рәхәттә...

## Хөлли Мәймүновичның колоритлар һәм калорияләр турындагы «фәлсәфә»ләре

Рөхсәт итегез, граждан иптәшләр,
Бүгенгесе көндә түшында,
Рәхим итеп, сезгә әйтергә
Панисламист кызлар турында.

Мәккәдә дә, Әтнәдә дә түгел,
Ә түшында — центр урамда
«...Ханә» дигән кафе ачканнар! —
Мин гөмбәгә китеп торганда.

Шул кафеда: чәмчә башмаклы
Вә калфаклы Миңлебикәләр,
«Салырга» да рөхсәт бирмичә,
Милли меню тәкъдим итәләр.

Менә бит ул әйтә тормасан,
Кая илтә милли «хикмәтләр»:
Башмак киеп коммунизмга
Барып буламыни, иптәшләр?!

Тәкъдим итеп милли катыкны
Вә тутырган симез тавыкны,
Эчке яктан аздырмакчылар
Минем кебек честный халыкны.

Ә мин сорыйм: Кем ул — Колорит?
Кайда туган, ничек яшәгән?
Ренегатмы чыгыш ягыннан,
Ортодоксмы ул, мәсәлән?!

Ревизионист булмыйм дисәң син
Тикшер барын төбенә кадәрле:
Демократик ашмы, мәсәлән,
Аристократ ашмы бәрәңге?

Ә мин әйтәм: демократик аш —
Бәрәңге дә, суган, кәбестә.
Мөмкинмени турау шуларны
Буржуазный милли бәлешкә?!

Миңа әйтәләр:— нигә бәлештән
Кача икән түшы сөрсегән?
Качам, чөнки анда эчтәлек
Милли форма белән өртелгән!

Ин культурный ризык: бутерброд,
Виски, хэнжо, импорт колбаса!
Ә тутырган тавыклар ашау
Милләтчелек факты ләбаса!

Безнең инде һәр халык белән
Хәреф тә бер хәзер, мәктәп тә.
Бәс ашлар да, күзләр-кашлар да
Бер булырга тиеш, әлбәттә!

Мөмкинмени сәвит онылнан
Камыр басып чәкчәк ясарга! —
Һәм милләтсез сыерның сөтен
Милли катык итеп ашарга?!

Әмма түшы калфаклы кызлар
Күпме генә тозак кормасын,
«Милли меню» дигән нәстәне
Ничек кенә миңа сузмасын,

Нинди генә колорит белән
Маташмасын мине «сыйларга»,
Мин карт чыпчык — һичбер татарка
Аздыралмас мине, иншалла.

## Элекке «Ялт-Йолт» журналындагы «Шүрәле» традициясе җырлары

### И ЛӘ ТАМАША

Бәләбәйгә барыр идем
Радио дулкыннар аша,
И лә тамаша:
Безнең дулкын Бардага да
Барып җитми ләбаса ла,
Барып җитми ләбаса.

Өне дә юк, тыны да, дип,
Үпкәлидер Тәнәкәй.
И лә, Бәләбәй:
Казанский радионың
Радиусы бәләкәй лә,
Радиусы бәләкәй.

Аклы ситса күлмәгеннең
Табалсам да ишләрен,
И лә, Чибәрем:
Радиоларым юк якларда —
Байкалларда ишләрем лә,
Сахалинда ишләрем...

Алтайларга китүчеләр,
Җан азыгы алыгыз,
И лә алыгыз:
Филармонны, театрны
Рюкзакларга салыгыз ла,
Чемоданга салыгыз.

## Түбән Кама түбән түгел

«Без,— диде ул,— яшьлем шәһәре салабыз ич... Ә исеме... иске, шигъри түгел. Бигрәк тә т ү б ә н дигәне...»

Г. ӘПСӘЛӘМОВ.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре юк әле.
Синең хәл дә Түбән Кама,
Нәкъ шулай ук шул әле.

Биллаһидыр, суга салам
Йөзегемнең кашларын,
«Түбән» дигән кушаматтан
Котылмаса башларым!

Түбән дигән сүзегезне
Бүтән әйтмәсәгезче:
Безнең бөек эшебезне
Түбәнәйтмәсәгезче!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре юк әле:
Бездә, жаный, мондый хәлләр,
Исемсезләр күп әле.

## Инде дә...

Инде дә тел «яхшырмаса»,
«Яңармаса» инде дә:
«Көфер» сүзне—«Һиндстан»ны
Сөрде илдән «Индия».

Син, янәсе, и «яңа» тел,
Тиешлесең «баерга».
«Яман» сүзне — «Каһирә»не
Алмаштырып «Каир»га...

## Нәби Дәүли

### Мыштым

Минем белән бергә туган да ул,
Минем белән бергә көн итә.
Батырларны хәтта куркытырлык
Картлык дигән исем йөретә.

Арысланны аучы куган кебек,
Мине дә ул туктамый куа.
Кая гына барсам — шунда килеп,
Юлларыма читлеген куя.

Ә мин качам, төрле хәйлә корам,
Соргсалар яшьне яшерәм.
Физкультура ясыйм, ванна керәм,
Мин бит әле һаман яшәрәм.

Курортларга барам, сулар эчәм,
Комга ятып арка кыздырам.
Өндә генә түгел, төшемдә дә
Кызларга мин һаман кызыгам.

Арысланны аучы бәлки тотар,
Читлегенә ябар бервакыт.
Ә мин әле йөрим бу дөньяда
Шигырь белән күңел юатып.

Кычкырмыйча, бер дә сиздермичә
Картлык йөри һаман эземнән,
Мин сакалны кырып утырганда
Карап тора мина көзгедән.

Һәм без икәү менә шул сәгатьтә
Очрашабыз йөзгә-йөз килеп.
Мин сөйләнәм: — Әле иртә,— диеп,
Ә ул әйтә: — Инде кич,— диеп.

Куркытырга аны мөмкинме соң
Тамак ярып әйткән сүз белән?
Җыерчыклар төшкән биткә карый
Үземдәге ике күз белән.

Я килә дә керә минем өйгә,
Валидолын куя өстәлгә.
— Мин доктор,— ди,— сина киңәш итәм.
Бу «запасны» сакла кесәндә.

Бик ягымлы сүзләр әйткән була,
Янәсе ул мине кадерли.
— Пенсияңне кимер тыныч кына,
Син почетлы кеше хәзер,— ди.

Мин дә аңа — рәхмәт, рәхмәт, диям,
Эчтән генә үзем ярсынам.
Шушы баллы, татлы таблеткада
Минем өчен агу бар сыман.

Картлык оста андый уеннарга,
Кирәк булса хәтта алдарга.
Баштан сыйпап кайчак юатырга...
Мең-мең төрле мәкер аңарда.

Я килә дә үз хатыным булып,
— Бәгырем минем, матур картым,— ди,—
Ревматиздан сине дәваларга
Җылы ката алып кайттым, ди.

Кайвакытта очрый дустым булып,
Кызганычлы итеп күз ата.
Көрешүдән элек башын чайкый,
Кар-тай-ган-сың, диеп сүз ата.

Я оныгым булып килә дә ул,
Тезләремә менеп утыра.
Әкиятләр миннән сөйләттерә,
Я китаплар куша укырга.

Бабай, диме миңа, дәү әти, ди,
Шул сүзенә күңел юана.
Арабызда дуслык саклар өчен
Дипломатия телен куллана.

Һай, күңелле миңа бу сәгатьтә,
Бу шатлыкка тагын ни җитә?
Нәни малай шулай мыштым гына
Алып керә мине читлеккә.

## Таш кыз янында

Бер вакытны шулай, яшь чагымда,
Йөри идем музей залында.
Туктап калдым кинәт исем китеп,
Яп-ялангач бер кыз янында.

Оныттым мин шунда үз-үземне,
Карадым да шушы таш сынга.
Наполеон да башын игән диләр
Шушы гранит гүзәл каршында.

Әйтерсең лә ул кыз кинәт кенә
Телгә килеп миңа эндәшер:
— Торма, егет, монда авыз ачып,
Сөйгән ярың күрсә көнләшер...

Белмим, шулай күпме торганмындыр,
Кинәт кемдер какты җилкәмә.
Карасам — ул сакчы хатын икән
Һәм охшаган иде әнкәмә.

— Җитәр,— диде,— озак карап тордың,
Исен китеп һуштан язарсың.
Бәхетеңне син дә бер табарсың,
Тере кызга шулай карарсың...

Бүген дә мин йөрим шул музейда,
Шул ук таш кыз тора каршымда.
Ул карый да миңа, көлә кебек,
Ак чәчләрне күреп башымда.

Инде мине беркем кумый моннан,
Беләгеннән кызның тотсам да.
Беркемнең дә исе китми хәзер,
Кочагына кереп торсам да.

Карт диләрме, әллә йөрәгендә
Инде утлар сүнгән диләрме?
Таш кызларга түгел, тере кызга
Мәхәббәте үлгән диләрме?

Хуш инде, хуш, таш кыз, кабат килмәм,
Соңгы тапкыр сиңа тукталдым.
Йөрәгемдә яну беткән булса,—
Димәк,—
Кемдер алган аның утларын.

Онытмаска матур истәлеген
Шул йөрәккә язып калдырган.
Димәк,—
Кемдер янган минем мәхәббәттә
Һәм үзе дә мине яндырган.

## Тост

— Иң яхшы ат нинди ат?
— Без атланып йөрмәгән ат.

— Иң төз мылтык нинди мылтык?
— Без атмаган мылтык.

— Иң матур кыз нинди кыз?
— Без сөя алмаган кыз.

— Иң татлы шәраб нинди шәраб?
— Без эчмәгән шәраб.

— Иң акыллы сүз нинди сүз?
— Без әйтмәгән сүз.

Күтәрик тостны —
Без атланып йөргән ат өчен,
Без аткан мылтык өчен,
Без сөйгән кыз өчен,
Без эчкән шәраб өчен,
Без әйткән сүз өчен,
Күтәрик тостны.

# „КАЗАН УТЛАРЫ“ ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ 1968 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


М. Ф. Вәлиев. **Хезмәт иялрен интернациональ тәрбияләү — идеология эшенең мөһим бурычы.** Мәкалә. № 5.

**Тукай исемендәге премияләр Комитетында.** № 6.

**Иң яхшы әдәбият һәм сәнгать әсәрләре өчен Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премияләрен булдыру турында.** № 4.

**Укучыларыбызга ачык хат.** № 10.

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ

Н. И. Альтман. **Ленинның беренче скульптурасы.** Истәлек. № 12.

Альберт Рис Вильямс. **Ленинның шәхси тормышында тимердәй дисциплина.** Истәлек. № 12.

А. В. Луначарский. **Ленин һәм сәнгать.** Истәлек. № 12.

С. Антонов. **Төн кына бару.** Хикәя. № 11.

А. Белевич. **Ленинга хат.** Шигырь. № 11.

Н. Богданов. **Кешенең эзе.** Хикәя. № 11.

В. Сидоров. **Ульяновлар семьясында.** Хикәя. № 11.

Назыйм Хикмәт. **Владимир Ильич белән сөйләшү.** Шигырь. № 11.

С. Щипачов. **Һәйкәл.** Шигырь. № 11.

ЛЕНИННЫҢ КӨРӘШТӘШЛӘРЕ

В. Скворцов. **Кырыс марксист.** № 4.

РОМАН, ПОВЕСТЬЛАР, ХИКӘЯЛӘР, ОЧЕРКЛАР, ПАРЧАЛАР, МӘЗӘКЛӘР

А. Азимов. **Шөкәтсез малай.** Фантастик хикәя. № 4.

**Атаклы кешеләр тормышыннан чын хикәяләр.** № 4.

Г. Ахунов. **Хуҗалар.** Роман. №№ 8, 9, 10.

Р. Батуллин. **Мираж.** Хикәя. № 1.

А. Ганиев. **Янәшә.** Хикәя. № 3.

Г. Галиев. **Минем Мәликәм.** Хикәя. № 7.

М. Глухов. **Тибрәндереп күңел кылларын.** Очерк. № 8.

Ә. Еники. **Вөҗдан.** Повесть. № 12.

Э. Касыймов. **Бир кулыңны, дустым!** Повесть. №№ 1, 2.

Л. Ихсанова. **Ана көндәлеге.** Повесть. № 11.

М. Маликова. **Казан каласы — таш кала.** Повесть. №№ 4, 5.

М. Мәһдиев. **Без — кырык беренче ел балалары.** Хикәя. № 5.

К. Марган. **Парчалар.** № 6.

Г. Мөхәммәтшин. **Габделхәйнең бәхетсез көне.** Хикәя. № 1.

В. Нуруллин. **Шинельсез солдатлар.** Повесть. № 3.

Нгуен Чунг Тхань. **Са-ну урманы.** Хикәя. № 8.

С. Радзиевская. **Су хуҗасы.** Очерк. № 12.

М. Рафиков. **Биш пуля.** Солдат хикәясе. № 9.

С. Сабиров. **Матрослар десанты.** Очерк. № 5.

С. Сабиров. **Гәрәйнең бер җае.** Хикәя. № 10.

И. Салахов. **Иртәнге очрашулар.** Хикәя. **№ 11.**
Р. Төхфәтуллин. **Агымсу.** Повесть. **№ 6.**
**Төрек халык мәзәкләре. № 6.**
Ә. Фазылҗанов. **Алтын.** Хикәя. **№ 11.**
Р. Фәизов. **Авыртмас башка.** Юмореска. **№ 9.**
Ф. Хөсни. **Кичке дога.** Хикәя. **№ 2.**
Ф. Хөсни. **Бәдретдин.** Хикәя. **№ 7.**
Ф. Хөсни. **Поп кызы Әхсәнә.** Хикәя. **№ 10.**
Г. Әпсәләмов. **Миңа унтугыз яшь иде.** Повесть. **№ 10.**

## ӘДӘБИ МИРАС

Ф. Гыйльманова. **Язучы, журналист һәм публицист.** Мәкалә. **№ 7.**
М. Галәү. **Болганчык еллар.** Романнан өзек. **№ 7.**

## ПОЭМАЛАР, ШИГЫРЬЛӘР, БАЛЛАДАЛАР

П. Апушев. **Ишкәкләр минем кулда.** Шигырь. **№ 3.**

Н. Арсланов. **Сагындым. Диңгездә. Кølеп бакса иде. Нигә. Өмет. Айга карап. Уникe батыр турында баллада.** Шигырьләр. **№ 4.**

Н. Арсланов. **Тел тибрәтеп бер сүз әйтмим. Гамьсезлектән җырлый, диләр мине. Дүрт киңәш. Рус балалайкасы. Синең тавышың. Акыллыга «башлы» дисәләр дә. Үз фикереңне үткәрергә тырыш. Эчемлек тә әйбәт. Ике тәрҗемә.** Шигырьләр. **№ 12.**

Х. Аюпов. **Аргымагым.** Шигырь. **№ 3.**

Г. Афзал. **Дөнья сакта. Вагъдә. Дулкыннар. Нинди үлчәү. Иске кабер ташларын караганда. Читкә киткәннәр сүзе. Патша һәм шагыйрь. Яшәмәдең. Болын — хатфә. Ян, өзгәләнь. Ике кеше.** Шигырьләр. **№ 5.**

Ә. Баянов. **Синең вөҗданың. Мин — диңгез. Кеше кайгысы. Ышан елларга. Уйладым да кабат. Уянсалар. Сөйгән җирем.** Шигырьләр. **№ 6.**

К. Булатова. **Еллар миңа. Мин зур үскәч. Табигатьтә. Яр буйларын.** Шигырьләр. **№ 3.**

Ш. Галиев. **Бармак-карандаш. «Керпе гөл». Яңа мылтык. Төрле тавышлар. «Кәбестәсе кайда». Тәмле чәчәк. Алма. Кызык.** Шигырьләр. **№ 4.**

Ш. Галиев. **Чаң турында баллада. Борынгы заман. Хакыйкать. Тормыш — рифма. Бәйрәм итә халык. Көнкүрештә шөгыльләр күп. Үкенүләр. Тормыш кәмите. Тормыш иләгендә. Авыр минутларда. Яшь идем. Оныткандыр диеп. Дога.** Шигырьләр. **№ 7.**

Ш. Галиев. **Балалар дөньясы. Шигырьләр циклы. № 8.**

Р. Гатауллин. **Гомер бакый. О, күңелнең көче. Кайларда йөрмәдем. Нинди яз бу. Бер як читтән торып. Ерак Марс авылы. Әллә бик тугры түгелбез. Ул чакта мин. Зур рәхмәт.** Шигырьләр. **№ 6.**

Р. Гатауллин. **Үпкә. «Бөеклек» турында.** Шигырьләр. **№ 10.**

З. Гомәрова. **Тәрәзә төбендә. Күчердем дә күчердем. Йокы чүлмәге.** Шигырьләр. **№ 8.**

Н. Дәүли. **Кеше турында монолог.** Поэма. **№ 1.**

Н. Дәүли. **Мыштым. Таш кыз янында. Тост.** Шигырьләр. **№ 12.**

Р. Закиров. **Омтылыш. Шул да бәхет. Син килмәдең. Тынгы белмим. Кем уйлаган. Китмәскә иде. Авылым кызына. Сорамагыз. Вакыт үтә. Дуслык хисе.** Шигырьләр. **№ 2.**

Р. Закиров. **Торналар киткәндә. Тормыш җыры.** Шигырьләр. **№ 10.**

Г. Зәйнашева. **Йозак. Яңгырдан соң.** Шигырьләр. **№ 3.**

Зөлфәт. **Тимерче турында баллада. № 3.**

Зөлфәт. **Мәскәү. Айлы соната. Җиргә кирәк. Походтагы солдат кебек. Хемингуэй үлеме. Кеше. Өстәлемдә минем кәрәгә. Ышаныч. Син йоклыйсың. Җырлый белмиләр бөркетләр. Шундый ташлар бар Казанда. Шушы халык чабатадан йөргән. Сине Блок уйлап тапкан бары.** Шигырьләр. **№ 5.**

Г. Камалов. **Тайгада. Кара урман.** Шигырьләр. **№ 2.**

Х. Камалов. **Тормыш дулкыннары.** Поэма. **№ 7.**

Т. Камалиев. **Абыйлар.** Шигырь. **№ 3.**

Г. Латыйп. **Балыкчылар җылым тарта. Үз дигәнен итә ул. Бәзнең урам чатында. Бага белән ата.** Шигырьләр. № 1.

Г. Латыйп. **Җыр үткәндә.** № 2.

Лэнгстон Хьюз. **Ленин турында баллада.** № 1.

Ш. Маннур. **«Патша кызы», Кызлар хаты. Борынгы шагыйрьдән. Картлар гыйшкы. Омтыла кеше яңага. Кайтып булса. Җенем сөйми.** Шигырьләр. № 10.

Ә. Маликов. **Салкын-Алан.** Поэма № 6.

Р. Мингалимов. **Таш дивардай.** Шигырь. № 3.

Р. Мингалимов. **Сүзләр эзлим. Раузага. Без бер дөнья. Шулай кирәк. Хәтерләү. Сорама. Камышлы. Шигырьләрем белән сөйләшү.** Шигырьләр. № 11.

К. Мостафин. **Исәп. Апрель. Теләк. Унҗиденче елның матрослары.** Шигырьләр. № 2.

К. Мостафин. **Төз наратлар утка аумасыннар. Урманнарга тагын ялкын капкан. Кешеләр, китмәгез! Күңелемдә сабый малай яши. Мин — бер кеше.** Шигырьләр. № 10.

Э. Мөэминова. **Онытмадым.** Поэма-монолог. № 5.

З. Нури. **Синең җырың. Адашу.** Шигырьләр. № 3.

З. Нури. **Ирексездән галәмче. Кеше һәм балта. Һаман тәнкыйтьләнүче. «Дан нәсе». Күренеп тора. Былчыракта. Хатыннарының холкы. Кунак киткәндә. Өч көн үткәч. Спектакль карагында. Искиткеч яңалык. Дөрес адрес.** Шигырьләр. № 5.

З. Нури. **Өйләнүдән курыккан ирләргә.** Шигырь. № 10.

Н. Нәҗми. **Куркам. Татар теле. Карлар ява. Төн уртасы.** Шигырьләр. № 4.

Петрос Антеос. **Канәфер чәчәкләре.** Шигырь. № 1.

Б. Рафиков. **Җир тынычлык тели. Яшел шәлен салып иңбашына. Мәңге бетмәс яралар. Берәүләре күккә чөеп.** Шигырьләр. № 2.

Г. Рәхим. **Авылым.** Шигырь. № 3.

Г. Рәхим. **Октябрь. Мин бит җирдә яңа кеше әле. Ник. Бер көн сиңа үлем килсә. Урам буйлап килә идем. Мәхәббәттә синең белән. Без бары җирне яраттык. Сез геп сынап карамагыз. Кайчагында. Ул мәҗлес.** Шигырьләр. № 11.

И. Рушан. **Үлмәүнең зарары, өйләнмәүнең файдасы турында. Хәлил Мәймуновичның колоритлар һәм калорияләр турындагы «фәлсәфә»ләре. Элекке «Ялт-Йолт» журналындагы «Шүрәле» традициясе җырлары. Түбән Кама. Инде дә.** Шигырьләр. № 12.

Б. Сөләйманов. **Мин ялгызым. Кара төндә. Мин Себердә.** Шигырьләр. № 6.

С. Сөләйманова. **Туган җирем. Мәкер. Таш.** Шигырьләр. № 9.

М. Сөндекле. **Икмәк валчыгы. Бер генә. Назим Хикмәттән.** Шигырьләр. № 5.

Х. Туфан. **Шигъри елъязмалар.** № 2.

Уилтон Джон Браун. **Ленинча көрәшергә.** Шигырь. № 1.

Е. Уткин. **Тик йөз адым. Бишек сиртмәсе. Юк, син дәһи түгел. Романтикам. Син җир кебек.. Төнге яшен. Печән өсте.** Шигырьләр. № 2.

К. Фәсәхов. **Үлем аша үлемсезлеккә.** Шигырь. № 1.

Р. Фәйзуллин. **Балачактан туры. Ишетәсеңме. Күпсенмә, күк. Сөерсең, дисең. Мәңгегә яратам димим. Яктыга төшә күз. Күпмегә туйды. Ул көннәрне инде. Шәфәкъләр алсу-алсу. Хакыйкать ул. Сөю көчле иманнан. Теләге бәхеттә иде. Хәерлегә булсын.** Шигырьләр. № 8.

Р. Харисов. **Ат.** Шигырь. № 3.

Р. Харисов. **Мулланур.** Шигырь. № 8.

С. Хәким. **Эмблема. Белгәннәр тик тора.** Шигырьләр. № 1.

С. Хәким. **Таулар, таулар. Татарлар елмаеп үлделәр. Изге бер ут. Дүрт яран. Кайтым төрле чикләр аша уздым. Озын чылбыр. Тышта буран. Янып, син кил. Хисап бирәм.** Шигырьләр. № 4.

В. Хәйруллина. **Төнге урман. Чулпы җыры. Әнисә. Урамда.** Шигырьләр. № 3.

А. Хәлим. **Тубин җыры.** Шигырь. № 3.

Ф. Шиһапова. **Күңелле. Тамчылар.** Шигырьләр. № 3.

Ш. Шәрәпов. **Линейка — рецензент. Мин хатынның кушканнарын. Чәч турында такмаклар.** Шигырьләр. № 2.

Ф. Шәфигуллин. **Мин диңгездә утрау күрдем.** Шигырь. № 3.

И. Юзеев. **Соңгы сынау.** Драматик легенда. № 9.

Р. Ягъфәров. **Диңгезче сүзе.** Шигырь. № 3.

Ясумаса Кисида. **Ленин китаплары.** Шигырь. № 1.

Ф. Яруллин. **Сине шуңа яратам. Кое казучы карт сүзләре. Бусагалар. Кызыгып калам. Әллә күңел, әллә еллар. Үзгәреш.** Шигырьләр. № 5.

Р. Әхмәтҗанов. **Бәйрәм. Ташлар белән. Рәхимҗан күпере. Сөрелгән җир. Сөкем борчый җанымны. Сорыйсың. Бер кычкырдым. Таш өстендә гөлләр.** Шигырьләр. № 10.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

П. Апушев. **Күңелдәге һәйкәл. Владимир Комаровка. Аның кыры. Гашыйклар.** Шигырьләр. № 8.

И. Газизова. **Уйчан тыйнаклык.** Мәкалә. № 9.

Ф. Гыйльметдинов. **Әсәрдә һава да булсын.** Мәкалә. № 9.

Ә. Гыйззәтов. **Хат ташучы. Күпме мин белгәннәр. Чия бакчасында.** Шигырьләр. № 10.

Ә. Дәминов. **Монологлар һәм диалоглар.** Мәкалә. № 9.

З. Маликов. **Кояшлы уграулар.** Мәкалә. № 9.

Э. Мостафин. **Көймә көтеп утырабыз. Юллар чатында. Ак каеннар. Чәйгә салган. Авылда бер көн. Бер җыр килә. Яңгыр тамды. Аккошлармы. Һавада кошлар гына.** Шигырьләр. № 8.

Ә. Рәшитов. **Мунчадан репортаж. Семей. Мәдхия.** Шигырьләр. № 8.

В. Шәрипова. **Сагындырган сукмаклар.** Мәкалә. № 9.

Н. Әхмәдиев. **Хикәяченең яңа китабы.** Мәкалә. № 9.

М. Әгъләмов. **Еракка китеп кара.** Шигырьләр циклы. № 11.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Черкез-Али. **Хезмәттер. Күзең кебек. Тәрәзәмне бүген.** Шигырьләр. № 3.

Р. Бурнаш. **Туганнар кабере. Ышанмыйм. Кояш белән җил.** Шигырьләр. № 3.

Җ. Камалетдин. **Багдадтан сәлам.** Шигырь. № 1.

Я. Колмый. **Каен да мин. Кем бай! Елмай әле.** Шигырьләр. № 4.

А. Мефаев. **Минем теләк. Сөям.** Шигырьләр. № 3.

Р. Мурад. **Яулар кичтем. Йолдыз. Композитор.** Шигырьләр. № 3.

М. Ногман. **Караимнар янында.** Мәкалә. № 1.

С. Сәйфуллин. **Ук җитмәс.** Легенда. № 7.

П. Тычина. **Муса Җәлил Киевта.** Шигырь. № 3.

Р. Халид. **Татарстан шагыйрьләренә. Күк миләүшә кебек. Еллар. Диңгезне сагындай.** Шигырьләр. № 3.

Э. Фазыл. **Ана. Миләүшә. Ике көрешү.** Шигырьләр. № 3.

Ф. Яннакопулу. **Сандугач һәм бөркет. Син дустыбыз безнең.** Шигырьләр. № 4.

**Ялкынлы елларда.** Шигырьләр. № 11.

## ПЬЕСА, СКЕТЧ

Р. Ишморат. **Шаулыйлар дулкыннар.** Лирик драма. № 7.

С. Кальметов. **Зыян янчыгы.** Скетч. № 9.

## ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Ш. Бикчурин. **Каты токым.** Очерк. № 5.

М. Васютин. Җ. Рәхимов. **Депутат.** Очерк. № 2.

Х. Зарипов. **Тәмле ашлар остасы.** Очерк. № 9.

Л. Ихсанова. **Җир хуҗалары.** Очерк. № 3.

Я. Мостафин. **Бронзадагы җөйләр.** Очерк. № 3.

Р. Надиев. **Архитектор.** Очерк. № 3.

Т. Сагыйтов. **Өлкән дуслар ярдәме.** Очерк. № 12.

М. Хәмитов. **Геология докторы.** Очерк. № 6.

А. Хәсәнов. **Контрибуция.** Очерк. № 7.
А. Хәсәнов. **Йолдызлар сүнәр өчен кабынмый.** Очерк. № 11.
Х. Хәйруллин. **Хуҗида үскән батыр.** Очерк. № 10.

ТАТАРСТАННЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

М. Гайнуллин, М. Һадиев. **Шагыйрь һәм революционер.** № 11.
И. Гыйззәтуллин. **Шамил Усманов — комиссар.** № 12.
Р. Хәйретдинов. **«Чулпан» — беренче совет газетасы.** № 11.
А. Яхин. **Революция солдаты.** № 12.

БЕЗНЕ ОКТЯБРЬ ҮСТЕРДЕ

М. Максуд. **Кайбер истәлекләр.** № 2.
И. Салахов. **Давыллар, утлар аша.** Очерк. № 1.
З. Сәйдәшев. **Бәхет биргән җирем.** Очерк. № 2.
Ә. Хәмидуллин, В. Скоробогатов. **Коммуна улы.** Очерк. № 1.

СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. Балакин. **Лидия Сәйфуллина ант итә.** № 2.
М. Рафиков. **Төркемле рәсем.** Очерк. № 2.

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Р. Мостафин. **Кичер, илем.** Очерк. № 1.
Р. Мостафин. **Үнөченче.** Очерк. № 2.
Р. Мостафин. **Батырлар елмаеп үлделәр.** Очерк. № 3.
Р. Мостафин. **Алман илендә.** Очерк. № 4.
Р. Мостафин. **Серле йомгак эзеннән.** № 5.

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

С. Алишев. **Бәхтияр Канкаев.** № 1.
М. Гыймадиев. **Утлар-сулар кичкән кеше.** Очерк. № 11.
З. Әхмәтҗанов. **Мәңге шиңмәс чәчәкләр.** Очерк. № 12.
Ш. Рәкыйпов. **Упкыннар кочагында.** Очерк. № 6.

РЕВОЛЮЦИОН ХӘРӘКӘТ ТАРИХЫННАН

Р. Нафиков. **Татар революционерларының разночинец-демократик хәрәкәткә катнашулары турында.** № 5.

ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Х. Госман. **Антитезалы тасвир кайлардан килә.** № 5.
И. Нуруллин. **Мәгърифәтчелек реализмы турында.** № 4.
А. Фәтхи. **Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр.** № 2.

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

М. Мөхәммәдиев. **Тел байлыгыбыз һәм аңардан файдалану.** № 7.

ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Г. Ахунҗанов. **Мәкаль һәм әйтемнәр.** Мәкалә. № 3.
М. Госманов. **Мәкальләр — тарихи чыганак.** Мәкалә. № 3.
М. Маннурова. **Ибраһим Гази — портрет остасы.** Мәкалә. № 4.
Ф. Урманчеев. **Халык хикмәте әсәрләре.** Мәкалә. № 3.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫННАН МАТЕРИАЛЛАР

Ш. Абилова, З. Максудова. **Лутфи Идел буйларында.** № 6.
Р. Гайнанов. **Галимҗан Ибраһимов «Әльислах»та.** № 9.
Ә. Кәримуллин. **Казан татар матбагачылыгы тарихыннан.** № 7.

З. Максудова. Онытылган шагыйрьләребез. № 1.
М. Мәһдиев. Шәкертләрнең авыз иҗаты. № 3.
И. Салахов. Фәхретдин бине Мифтахетдин. № 8.
Г. Таһирҗанов. Фирдәүси һәм Колгали. № 12.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Б. Әхмәтов. Хәзерге гарәп дөньясында. № 11.

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Х. Мәхмүтов. Яңа табышмаклар. № 1.
М. Мәһдиев. Себер татарлары иҗаты. № 10.

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА — ШАГЫЙРЬ

Н. Дәули. Олы юлга чыкканда. № 11.
Ә. Рәшитов. Газаплы эзләнүләр, сөенечле табышлар. Мәкалә. № 10.

## ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Ә. Баянов. Офыкларыбыз киңәя. Мәкалә. № 9
Ә. Давыдов. Быелгы дүрт санны укыгач. Мәкалә. № 9.
С. Хәким. Тукайларны эзлим. Мәкалә. № 3.
Ф. Хөсни. Заманалар һәм язмышлар. Мәкалә. № 3.
Ф. Хөсни. Хикәя укыйсым килә. Мәкалә. № 8.
М. Әмир. Иҗат дәрте. Мәкалә. № 5.
М. Әмир. Игътибар җитми. Мәкалә. № 8.
Г. Әпсәләмов. Халык онытмас. Мәкалә. № 3.
Г. Әпсәләмов. Көн дә уйлый торган уйлар. Мәкалә. № 7.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. Гәрәй. Җырлар аша сөйли күңелләр. № 11.
М. Госманов. Гаделлек җырчысы Мөхәммәдьяр. № 2.
Л. Ихсанова. Кыскалыкта осталык. № 12.
В. Нуруллин. Җир хуҗасы. № 11.
А. Халиков, Р. Фәхретдинов. Татар халкы турында зур фәнни хезмәт. № 8.
Н. Ханзафаров. Көлү — үткен корал. № 2.
Р. Харисов. «Эзләр» буйлап. № 10.
Р. Харисов. Шинельсез солдатлар. № 12.
Ф. Шиһапова. «Ялгыз җилкән» повестеның тәрҗемәсе. № 5.
С. Әдһәмова. «Кара чәчәкләр». № 5.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. Галиуллин. Поэманың барыр юллары. № 2.
М. Мәһдиев. Халык әдәбиятыбызга бер караш. № 11.
Р. Харисов. Җәйләр, көзләр нинди булыр! № 6.

## БЕЗНЕҢ САФКА

Ш. Галиев. Уйлана, эзләнә. № 4.
С. Хәким. Яхшы җыр сирәк туа. № 4.

## ИСТӘЛЕКЛӘР

З. Кәримова. Онытылмас хатирәләр. № 9.
Н. Исәнбәт. Унсигезенче елдан бер сәхифә. № 4.
В. Хангильдин. Көтелмәгән бер очрашу. № 3.

## УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Г. Шамуков. Архитектура сәнгатебезнең бер истәлеге. № 9.

МАКСИМ ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Г. Бәширов. **Үзебезнең Горький.** Мәкалә. № 3.
М. Горький. **Акулина әби.** Хикәя. № 3.
Ш. Садретдинов. **Тамчыда кояш чагыла.** Мәкалә. № 3.
Х. Туфан. **Тәрәзә.** Шигырь. № 3.

ӘЛИШЕР НӘВОИНЫҢ ТУУЫНА 525 ЕЛ

Ә. Нәвои. **Бик күп аһ орсам. Дусларым яшерен яга торган. Гыйшыкта кемгә дә сердәш була алмас. Ярдан аерылса әгәр гашыйк. Тиле күңелем минем. Горурлыгың ташытма. Юлдан язды. Тәмуг белән. Каннан артык.** Шигырьләр. № 5.

ШӘҺИТ ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

С. Сабиров. **Кайнар йөрәкле көрәшче.** № 12.

ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

З. Бәшири. **Замандашларым белән очрашулар.** Истәлек. № 6.

ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Ф. Бурнаш. **Яшь йөрәкләр.** Либреттодан өзек. **Хатлар.** № 1.

АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

А. Алиш. **Совет әкияте тудыру юлында.** Мәкалә. № 8.
А. Алиш. **Чәчәк. Мин дәү, син кечкенә.** Хикәяләр. № 8.
Г. Кашшаф. **Гаделлек солдаты.** Мәкалә. № 8.
Ф. Ибраһимова. **Алиш — әкиятче.** Мәкалә. № 8.

ХАТИП ГОСМАНГА 60 ЯШЬ

Г. Кашшаф. **Хатип Госман.** Мәкалә. № 5.

ФАТИХ ХӨСНИГӘ 60 ЯШЬ

Ә. Еники. **Безнең Фатих.** Мәкалә. № 2.

ӘНӘС КАМАЛГА 60 ЯШЬ

Ш. Зәйни. **Драматург үткән юл.** Мәкалә. № 3.

ХӘЙ ВАХИТКА 50 ЯШЬ

А. Әхмәдуллин. **Сәхнәгә гашыйк.** Мәкалә. № 12.

БАЯН ГЫЙЗЗӘТКӘ 50 ЯШЬ

М. Гайнуллин. **Әдәбият һәм сәнгать белгече.** Мәкалә. № 7.

СӘЕТ КАЛЬМЕТОВКА 50 ЯШЬ

Г. Ахунов. **Усал телле драматург.** Мәкалә. № 5.

«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНА 50 ЕЛ

Г. Минский. **Якын дустыбыз, акыллы киңәшчебез.** Мәкалә. № 3.

«СОВЕТ МӘКТӘБЕ» ЖУРНАЛЫНА 50 ЕЛ

Ф. Ибраһимов, Ф. Шәрифуллин. **Данлы юл.** Мәкалә. № 11.

ТАТАРСТАН НЕФТЕНӘ 25 ЕЛ

Ш. Бикчурин. **Тамырлар.** № 7.

МЕНДЕЛЕЕВСК ХИМИЯ ЗАВОДЫНА 100 ЕЛ

Т. Сәгыйтов. **Буыннар язмышы.** № 8.

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ф. Вәлиев. **Борынгы Болгар.** № 7.
Ә. Кәримуллин. **Кульязма мирасыбызның кайбер мәсьәләләре.** № 2.

М. Мерзабеков. **Кәрвансарай.** Мәкалә. № 3.
Г. Саттаров. **Җирле географик атамалар сүзлекчәсе.** № 7.
Г. Таһирова. **«Гөлҗамал».** Мәкалә. № 6.
Н. Хәкимуллин. **Һиндстанга сәяхәт.** Очерк. № 1.
Н. Хәкимуллин. **Җир сулышы.** Очерк. № 8.

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ТИРӘСЕНДӘ

Г. Бәширов. **Без кем идек, кем булдык.** № 11.
Э. Касыймов. **Җиде сорауга бер җавап.** № 10.

ТУКАЙ КӨННӘРЕНӘ

Б. Салихов. **Бер рәсемнең тарихы.** № 4.
Э. Сәгыйдова. **К. Сәгыйд архивыннан.** № 4.
А. Шәриф. **Тукай һәм әзербайҗан әдәбияты.** № 4.

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

А. Файнберг. **Чишмәләр ерактан башлана.** № 6.
Я. Гиршман. **Җыр башлаучы, юл башлаучы.** № 10.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

С. Червонная. **Имтихан уңышлы узды.** Мәкалә. № 7.
Н. Юзиев. **Музалар туганлыгы.** Мәкалә. № 1.

ЯЗУЧЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

Г. Бакиров. **Каләм һәм сугыш.** № 8.
Ш. Галиев. **Әз-мәз мәзәк.** № 1.
И. Гази. **Су шигърияте. Тирәкләр. Яңгыр астындагы мәхәббәт.** Мунчада. **Профессорда кунакта.** № 11.
**Съезд көндәлеге.** № 6.

ЮРИСТ ЯЗМАЛАРЫ

М. Насибуллин. **Мәзһәр Богданов маҗаралары.** Очерк. № 9.
Н. Ямалиев. **Тәрәзәгә кем аткан.** № 8.

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

**Әдипкең уңышы.** № 2.

УКУЧЫ СҮЗЕ

В. Булатов. **Кыйммәтле әсәр.** Мәкалә. № 3.
Ш. Шәяхмәтов. **Әлбинә кулын бирерме!** № 7.
Р. Якупов. **Рәхмәтләр юллыйм.** № 8.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Г. Бакир. **Язучы һәм педагог.** № 1.
Н. Гайсин. **Дәрҗия Аппакова.** № 3.
М. Госманов. **Мәрҗани турында берничә сүз.** № 1.
Ә. Синегулов. **Гиз-эль-Габиднең тууына 50 ел.** № 2.
Җ. Фәйзи. **Виртуоз мандолинчы.** № 1.
М. Гали. № 3.
Р. Ильяс. № 3.
Ф. Сәйфи-Казанлы. № 9.
Г. Волков. **Педагогның якты язмышы.** № 8.
М. Крыймов. № 12.
**Яңа китаплар.** №№ 1, 2, 4, 6, 9.
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыгы.** №№ 1—11.

# ИҢ ЯХШЫ ҖЫРЛАРГА КОНКУРС

Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел һәм Совет Татарстанына 50 ел тулу көннәре якынлашу уңае белән, профсоюзларның Татарстан өлкә советы Президиумы, Татарстан культура министрлыгы, Татарстан язучылары һәм композиторлары союзлары, Татарстан хор җәмгыяте иң яхшы җырларга конкурс игълан иттеләр.

Конкурс даһи Ленин һәм аның шәкертләре образын, Ленин васыятьләрен тормышка ашыру буенча партия эшчәнлеген, социализм һәм коммунизм төзү чорында халкыбызның героик эшләрен, совет власте елларында СССР халыкларының туган-даш семьясында Совет Татарстаны ирешкән уңышларны чагылдырган хор репертуары өчен, солистлар һәм ансамбльләр өчен яңа җырлар тудыруга композиторларны һәм шагыйрьләрне күбрәк тарту максаты белән игълан ителде.

Конкурсның жюрие советына түбәндәге иптәшләр кертелде: Ахмеров К. Г.— профсоюзларның өлкә советы секретаре (жюри председателе), Фәйзи Җ. Х., Яхин Р. Х.—композиторлар, Нигъмәтҗанов М. Н.— музыка белгече, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Илдар Юзеев — шагыйрьләр, Гариф Ахунов — Татарстан язучылар союзының җаваплы секретаре, Таҗетдинов Ә. Г. — КПССның Татарстан өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары, Надыйров Ф. Г.— ТАССР министрлар советы каршындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты председателе, Әминов Ю. З.— ТАССР культура министры урынбасары, Фәрхиев Р. Д.— ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты секретаре, Зәбиров М. Х.— «Социалистик Татарстан» газетасының редактор урынбасары, Гудкова В. Я.— «Советская Татария» газетасының фән һәм культура бүлеге мөдире, Хәялиев С. Б.— Татарстан хор җәмгыятенең җаваплы секретаре (жюри секретаре).

## Конкурс шартлары

Конкурс 1968 елның беренче декабреннан 1970 елның беренче февраленә кадәр дәвам итәчәк.

Конкурска җибәрелгән җыр текстлары машинкада басылган, ә ноталары тушь белән язылган булырга һәм девиз белән җибәрелергә тиеш. Девиз куелган аерым конвертта шагыйрьнең һәм композиторның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адреслары күрсәтелергә тиеш. Ул конверт жюри карары чыкканнан соң гына ачылачак.

Конкурска җыр язганда композиторлар шагыйрьләрнең моңарчы газета-журналларда басылган текстларын да файдалана алалар.

Конкурста әсәрләре яхшы дип табылган авторларга түбәндәге бүләкләр биреләчәк:

*Беренче бүләк (берәү) — композиторга 300 сум,*
*шагыйрьгә 200 сум.*
*Икенче бүләк (берәү) — композиторга 200 сум,*
*шагыйрьгә 150 сум.*
*Өченче бүләк (икәү) — композиторга 150 сум,*
*шагыйрьгә 100 сум.*

Бүләк алмасалар да, конкурс жюрие тарафыннан әйбәт дип табылган җырлар радио һәм телевидение аша тапшырылачак, газета-журналларда басылачак һәм ТАССР культура министрлыгы тарафыннан сатып алыначак.

*Искәрмә: 1. Конкурска җибәрелгән әсәрләр авторларга кире кайтарылмый.*
*2. Ноталарсыз җибәрелгән җыр текстлары кабул ителми.*

**Конкурска дигән җырлар түбәндәге адрес буенча җибәрелергә тиеш:**

*г. Казань, ул. Баумана, д. 60. Хоровое общество ТАССР.*
*Жюри.*

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210